ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

8.2012





**Нури Арсланов**
**(1912—1991)**

**Казан утлары**
**Qazan utlari**

2012

# 8
**(1078)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Газинур МОРАТ. Вөҗүдендә дала җәйрәп яткан... *Шигырьләр*....5
Таһир НУРМӨХӘММӘТОВ. Кабан күле, әй, алкын. *Бәян*....10
Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА. Бу бәхеткә исем кушып булмый. *Шигырьләр*....49
Салават ЮЗЕЕВ. Үлгәннәрне бүлдермә. *Роман*....53
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Мин тормышны өзелеп яратам. *Шигырьләр*....110

### ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Кави НӘҖМИ. Миңлебикә кодагыйның кайгысы....113

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Күкрәгендә шигъри сагыш *(Рөстәм Мингалимгә 75 яшь)*....122
Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Таләпчән тәнкыйтьче....129
Рифат СВЕРИГИН. Хакыйкать эзләп....131

### ТАРИХ

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Себер юлы серләре яки тарихи табышлар....134

### КИТАП КҮЗӘТҮ

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Үз заманының каһарманы....141
Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ. Гасырлар илчесе....143

### ХӘТЕР

Фәндәс САФИУЛЛИН. Бәләкәй чак бәләкәйлек түгел ул....148

### СӘНГАТЬ

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Җырлы-моңлы еллар... *(Татар дәүләт филармониясе оешуга 75 ел)*....168

### ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы....171
«Татар энциклопедиясе» битләреннән....174

### АК ҖИЛКӘН

Алсу НУРГАТИНА. Шигырьләр....177
Надия ВӘЛИЕВА. Кичер мине, кичерә алсаң... *Хикәя*....179
Ким ШАКИРОВ. «Сабый ачышлар»ыгыз юкмы?....181

### ЮМОР ҺӘМ САТИРА

БАТУЛЛА. Яңа мулла....184

«Казан утлары» архивыннан....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан....190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман С.ЮЗЕЕВА «Не перебивай мертвых»;
повесть Т.НУРМУХАМЕТОВА «Озеро моей юности»(начало); рассказ К.НАДЖМИ;
стихи Г.МУРАТА, Л.ФАТХУТДИНОВОЙ, А.СИТДИКОВОЙ.
«Литературная критика»: Т.ГАЛИУЛЛИН. «В душе — поэтическая грусть»;
А.ЗАКИРЗЯНОВ. «Требовательный критик»; Р.СВЕРИГИН. «В поисках истины».
«История»: Р.ШАРАФИЕВ. «Тайны сибирских дорог...»
«Книжное обозрение»: статьи Р.ФАЙЗУЛЛИНА «Достойный сын своего времени»,
Р.БАДРУТДИНОВА «Соединяя века».
«Память»: воспоминания Ф.САФИУЛЛИНА о послевоенном детстве.
«Искусство»: статья Г.БАЙРАМОВОЙ, посвященная 75-летию образования Татарской государственной филармонии.
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: стихи А.НУРГАТИНОЙ; рассказ Н.ВАЛИЕВОЙ.
«Юмор и сатира»: рассказ БАТУЛЛЫ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: День Республики; драматург Шамиль ФАРХУТДИНОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by S.YUZEEV «Do not interrupt the dead»;
story by T.NURMUHAMETOV «Lake of my youth» (beginning); story by K.NADJMI;
poems by G.MURAT, L.FATHUTDINOVA, A.SITDIKOVA.
«Literary criticism»: T.GALIULLIN. «In my heart -poetic sadness»; A.ZAKIRZYANOV.
«Demanding critic»; R.SVERIGIN. «In search of truth».
«History»: R.SHARAFIEV. «Secrets of Siberian roads ...»
«Book review»: articles by R.FAYZULLIN «Worthy son of his time»,
R.BADRUTDINOV «Combining centuries».
«Memory»: Memoir by F.SAFIULLIN of postwar childhood.
«Art»: article by G.BAYRAMOVA devoted to 75th anniversary of formation of Tatar State Philharmonic.
«Science»: F. Garipova. «History of our villages».
«Pages from «Tatar encyclopedia».
«White Sail»: poems by A.NURGATINA; story by N.VALIEVA.
«Humor and satire»: story by BATULLA.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Republic Day; playwright Shamil FARKHUTDINOV.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.08.2012, график буенча 01.08.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-758. Тираж 4011.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча
Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Газинур
Морат

# ВӨҖҮДЕНДӘ ДАЛА ҖӘЙРӘП ЯТКАН...

## Аять

**Адәм балчыктан яралгач,
Коела комы гына.
Аллаһның улы булмыйдыр,
Буладыр колы гына.**

## БДИ

**Ничә гасыр бер имтихан бара,
Ничә гасыр бер үк сынаулар.
Соравы да шул ук —
Үз телеңдә
Җавап табалмастай сораулар.**

**Бу җиһанда кай кавемнәр яши
Ил-телләтә ясак түләп тә.
Ничә гасыр бер үк сынау бара
«Бүленмәс һәм бердәм» дәүләттә.**

## Петербурда, Тукай һәйкәле эргәсендә

**Басып тора юллар чатында ул,
Мәңге дымык җилләр иркендә.
Безне хәзер шәһри Питерга да
Тукай үзе дәшеп китерә.**

**Бер җанына җылы табалмыйча,
Илдә йөдәп йөргән чагында,
Ул үзе дә килеп чыккан, әнә,
Урыс пайтәхете ягына.**

Газинур МОРАТ (1959) – *шагыйрь, публицист; «Түбә», «Җәяүле кошлар», «Төнге әверелеш» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының М.Җәлил, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләкләре иясе. Казанда яши.*

Бер җанына дәва эзләп килеп,
Тынсыз иткән тынчу һавасы.
Җир читенә барып юансаң да,
Табылмастыр инде дәвасы.

Иң зур илдә сулар һава җитми,
Иң зур илнең кысан читлеге.
Сыктый-сыктый сыза бара Вакыт,
Читлектәге былбыл шикелле.

Иң зур илдә мыскал ирегең юк,
Иң зур илдә мыскал хаккың юк.
Каган бабаң кебек, Дала буйлап
Бер җилдерер идең, атың юк.

Дала түгел — каласында менә
Качар җай юк тынчу һавадан...
Гасыр узган юкса...
Ә илләрдә
Ютәл өянәге һаман да.

Басып тора юллар чатында ул,
Мәңге дымык җилләр иркендә.
Ел да аңа апрель иртәсендә
Агъэбиләр чәчкә китерә.

## Шамакай

Казнаның ул күз-колагы иде
(Ә ханныкы иде заманы),
Хәрәмләшү белмәс халык сүзен
Ул Хакныкы диеп санады.

Хак сүзне ул әйтте ханга гына,
Ханлыктагы хәлләр хакында.
Ул бердәнбер иде...
Ә үзенең
Юк иде чын исем-аты да.

Ул бердәнбер иде — хак сүз өчен
Башы киселмәгән дивана.
Ә ул әйтә иде: «Син хан чакта
Бу ил, ахры, килмәс иманга».

Ә ул әйтә иде: «Яраннарың
Койрык болгап йөреп тирәңдә,
Казна алтыннарын каза итеп,
Хан сарае корып кинәнә.

Вәзирләрең азгын алаша кук —
Җарияләр генә уенда.
Казыйларың бурдан бәк әвәләп,
Бәкләр табыныннан туена.

Имамнарың кайсы имансыздыр,
Монафикътыр кайсы, томана...

Халкың хәзер мәзәк тыңлап, әнә,
Ат кәмите карап юана.

Оят качты илдән...
Бар өммәтең
Шәрәлекнең җитте чигенә.
Азау ярган вәзир-яраннарың
Шәрә калдырмасмы сине дә?
Шәрә калдырмасмы?!»

Ә хан аны оеп тыңлый иде,
Гелән сүрелгәнче чырагы.
Уйлый иде үзе: «Ни сөйләмәс
Бу тилемсә, исәр сыңары.

Тинтәк белән, әнә, дөнья тулган,
Шамакайга шаның ни аңа?
Шайтан кәлимәсен сөйләп йөри,
Үзе өнди, имеш, иманга».

...Ә шулай да ул бердәнбер иде —
Башы киселмәгән дивана.

## Сәхнә арты

Монда гел башка тамаша,
Монда гел бүтән хәлләр —
Мәйләүдән чәйләүгә күчкән
Әҗәл белән Әлмәндәр.

Хәлил белән Исмәгыйльнең
Эшләре көйле шуңа —
Шәраб уртлый-уртлый алар
Бер почмакта кәрт суга.

Күзге каршында ясканып
Утыра, әнә, Булат.
Ул да беркая качмаган
Мәйсәрәсен урлап.

Сәрвәр белән Мәхдүм инде
Олыгайган чак кына.
Алар, әнә, гәп куерта
Оныклары хакында.

Гел үз сүзе белән сөйли
Монда сәхнә халкы да.
Чын тамаша дигәне дә
Бәлки, сәхнә артындадыр,
Бәлки, сәхнә артында...

## Сүз әйттеңме...

Җавап тотар көн килер ул,
Сүз әйттеңме кыеп...
Шигырь язу — бер шөгыльдер,
Шагыйрь булу кыен.

## Арыслан

*Лев Гумилев рухына*

**Хакның фатихасы кирәктер ул**
**Хакны әйтер өчен халыкка...**
**Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан,**
**Көн итсә дә үзе тарлыкта.**

**Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан,**
**Чорлар буйлап җилгән туратта.**
**Бөек, диеп, кушаматын хәтта**
**Каторжаннар кушкан ГУЛАГта.**

**Бөек шагыйрьләрнең бөек улы,**
**Гаҗиз калып ялган, мәкердән,**
**Тимер читлектә дә, яшеренеп,**
**Хак тарихны язган хәтердән.**

**Язган —**
**кыйтгалардан**
**кыйтгаларга**
**Кубарылып илләр күчкәнен.**
**Һуннар хакын хаклап, берьялгызы**
**Әйләндергән тарих көпчәген.**

**Дала хакын, Алла хакын хаклап,**
**Аралаган безне яладан.**
**Әлмисакта төрк һәм тереклек**
**Бер тамырдан гүя яралган.**

**Бер тамырдан гүя яралганбыз,**
**Таралганбыз җиһан буйлата.**
**Мәрткә киткән Дала балбалларын**
**Хәтер үзе килеп уята.**

**Мәңге тынмас Сак-Сок иңрәүләре**
**Сеңеп калгандыр күк ташларга.**
**Мәшригендә һәр бирмеш көн, әнә,**
**Татар бугазыннан башлана.**

**Мәгърибендә һәр бирмеш көн, әнә,**
**Алып тауга кайтып сыгына.**
**Сак-сок иңрәүләре әверелгән**
**Кыйтгаларның уртак җырына.**

**Бөек шагыйрьләрнең бөек улы,**
**Арыслан да үзе, алып та...**
**Вөҗүдендә Дала җәйрәп яткан,**
**Көн итсә дә кимлек-тарлыкта.**

## 1910 ел, 7 ноябрь

**Ил агасы ерак юлга чыккан,**
**Яшьлегендә узган таныш юлга.**
**Каф тау тарафына китеп барган,**
**Догалы күк белән кавышырга.**

Фәрештәсе качкан үз илендә
Ишеткән ул чаңнар каргышын да...
Үз-үзенә кайтып барган чакта
Бер Раббысы белән кавышырга
Күкләр өненең ул аһәңен дә
Ишеткәндер азан тавышында...

Лев Толстой хәзрәтләре кебек
Сәфәрләрдә язсын кавышырга.

## Хөрмәтле Чыңгыз әкә ядкәре

Ике мең дә сигезенче сәнә
Язын озаткан бер заманда:
«Чыңгыз әкә Кукмарага кайта», —
Дигән хәбәр килде Казанга.

Чыңгыз Кукмарага кайта икән,
Кукмарага — Күк Тау иленә.
Бабалары гомер иткән нигез
Көтә икән аны биредә.

Чыңгыз әкә Кукмарага кайта —
Гомер күрмәстәй бер тамаша.
Ул — Нәгыймә абыстайның улы —
Минем якташ икән ләбаса.

Ул да, әйдә, үзе ачып керсен
Идел-йортның ырыс капкасын.
Язу язарга да ярыйдыр, дим,
Чыңгыз әкә булса якташың.

Ул да, әйдә, кочып еласын бер
Безнең шәҗәрәи талларны...
Идел-йортка чаклы кайтты Чыңгыз,
Кайтып кына җитә алмады.

Кайтып җитәсе лә иде юкса,
Сәфәренә чыкса иртәрәк.
Төп нигезгә юллар, һай, урау шул,
Ул гел ерак, һәрчак читтәрәк.

Йөз чакрымнар гына иде юкса,
Казан белән Күк Тау арасы.
Төп нигезгә кайтып баш орырга
Гел кичегә адәм баласы.

Бер атлам юл калган иде юкса,
Шуны узу язсын кемгә дә.
Кукмарага кайтып бара Чыңгыз
Гасырдан да озын көннәрдә.

Таһир
Нурмөхәммәтов

# КАБАН КҮЛЕ, ӘЙ, АЛКЫН*

БӘЯН

Сабый чакта бәләкәй кулың нәрсәгә генә сузылмый. Бигрәк тә ялтыравыклы нәрсәләр кызыктыра. Әгәр инде алар төрле төстә булып күз явыңны да алып торсалар, бөтен дөньяңны онытасың инде: синең кулларың канатка әйләнә, син очар коштай алга талпынасың һәм әлеге җемелдәвек нәрсәне эләктереп алмый торып, эләктергәннән соң да үзен күреп туймый торып, күңелеңне һич тынычландыра алмыйсың. Ярый әле тыелып кына калсаң. Син ул тәтиләрне тел очың белән татып та карыйсың, тәмләп ялыйсың һәм кайчакларын, авыз эчендә әрле-бирле китереп йөрткәннән соң, йотып та җибәрәсең.

Мин алсу чырайлы, күксел сакаллы бер бабайның: «Каяле, үзенә бик матур чалбар кисеп бирим. Мин кисәрмен, әтиең тегеп тә куяр. Синең әтиең тегүче бит, тегүче...» — дип үтә тәмле телләнеп үземне бик һәйбәтләп сөннәткә утыртып куйганын хәтерлим. Күп булса миңа ике яшь булгандыр. Артык селкенергә ярамаган өчен, күзләреңне ян-якка тасрайтып, кадаклап куелгандай, бер урында тик утырасың. Ләкин син бала гына бит әле. Көйсезләнеп бармагыңны теге-бу нәрсәгә төртеп күрсәтә-күрсәтә: «Бир!» — дип елыйсың. Андый чакта, әлбәттә, күзәтүсез калдырмыйлар сине. Ә инде ул күзәтүче «чалбар кисү»нең ни икәнлеген кичергән «стажлы» бер малай кәмәше дә булса, ул синең тирәдә бөтерелеп кенә йөри, сораган әйберләрегезне китереп биреп кенә тора. Миңа да бер малайчык шулай ташып торды. Хәтта бер юлы подшипник шарлары китереп тоттырды. Ул шарлар борчактан чак кына эре булсалар да, әмма бик күңелле ялтырыйлар. Син әлеге «чалбар»ыңны да онытып, ул елтыр шарчыклар белән рәхәтләнеп

* Журнал варианты.

Таһир НУРМӨХӘММӘТОВ (1936-1999) – *тәрҗемәче, язучы; күпсанлы тәрҗемә китаплары авторы. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

уйныйсың, үзләрен телең белән әйләндергәләп, әчкелтем тәмнәрен татыйсың. Синең авызың тулы селәгәй. Ул селәгәйне йоткан чагында нинидер саллы нәрсә авыр гына булып эченә төшеп китә. Төшсә соң. Төшә бирсен. Әле бетмәгән бит әле, уч төбеңдә тагын ялтыр-йолтыр килешәләр. Алары да кабат авызына килеп керәләр һәм кабат эченне салкынайтып, тәгәри-тәгәри, түбәнгә төшеп китәләр. Ниһаять, өйдәге бер өлкәнрәк кеше исенә килә, учларынны ачтырып карый: «Кая куйдың!» — дип кычкыра, сине күзәтергә куйган малай кәмәшен орышып ала. Ләкин ул малай да аптыраган: шома тимер шарчыклар юк. Шунда, татлы конфет суырган шикелле авыз кыймылдатып утырганыңны күреп, тиз генә тел астына бармак тыгалар да, йотып бетермәгән подшипник шарчыгын селәгәе-ние белән көрәп чыгаралар.

«Аһ, харап буласың бит!» Бу тавышта өзгәләнү дә, менә хәзер үлә бит инде бу бала дигән кебек, бер төрле өшеткеч шом да бар. Ләкин бу озакка бармый. «Һәй, инә түгел әле, үз юлы белән чыгар!». Чыкмаса соң. Түгәрәк тимер йотып кемнең үлгәне бар?! Докторлар әнә балага, нинидер матдәләр җитеп бетмәгәч, тимер порошогын да каптыралар әле. Дару урынына каптыралар. Подшипник шарлары порошок түгел түгелен. Ләкин кеше дигәнең үз башыннан нәрсәләр генә кичермәгән. Бала чакта безгә дә аз-маз кичерергә туры килде. Хәтерлисезме кара-каршы агач бүкәнгә чуен ватыкларын кагыштырып арыштыр, тоздыр ярдырган вакытларны. Сугыш афәтләрен кичерергә язган балаларның да ашказаннары әнә шул чуен тешле яргычлардан бер дә ким булмагандыр, подшипникның корыч шарларын да алар тегермән кебек тартып чыгаргандыр.

Ләкин сугышка иртә бит әле. Мин сабый күзләренең ялтыравыклы нәрсәләргә биниһая кызыгуы турында гына әйткән идем. Һәр ялтыраган нәрсә сине алга омтылдыра һәм кайвакыт, очынган күбәләкне көйдергән ут шикелле, сине тешләп тә куйгалый.

Мин теге күксел сакаллы бабай кискән, әтием исә чынлап та тегеп биргән кыска балаклы, арык иңбашларыма көчкә генә эләгеп торган аркылы-торкылы баулы кара чалбарымны киеп, җинел аякларым белән җил кебек йөгереп йөри башлаган идем инде. Без байдан калган аслы-өсле йортның караңгы кухнясында яшәдек. Өебездә күзгә ташланырлык әйберләр булуын хәтерләмим. Анын каравы гөмбәзле эченә кереп утырсаң, үзе бер «квартира» булырлык урыс мичебез бар иде. Миче мич тә бит, ләкин үзе генә дә ярты бүлмәбезне биләп тора. Ягъни җил аяклы малайга кинәнеп уйнарга ирек бирми. Шуннан ничек инде өй эчендә калмак кирәк. Тиздән минем йорт буенча сәяхәтләрем башланды.

Ул чакларны кием котлаттыра торган гадәт бар иде. Сиңа берәр кием тексәләр, ягъни кибеттән ботинка-мазарны алып кайтып бирсәләр, син инде тиз генә өй борынча чыгып китәсең. Әлеге кара чалбарымны киеп куйганнан соң мин дә чыгып сыздым. Кайсы күршегә генә кермим: «Котлы булсын!», «Өстеңдә тузсын!», «Яңасы өстәлсен!» дип башымнан сыйпыйлар, кулга берәр нәрсә тоттыралар. Инде бусагадан узып та синең яңа киемеңне күрми торсалар, син барыбер моны сиздерәсең, күрше апайгамы, әбекәйгәме күз атып карыйсың да, чалбарыңа төбәләсең. Әле аңа, әле чалбарга. Инде дә сизмәсәләр, бармакларың белән кыска балагың очыннан тотып башыңны чайкап торасың. Шундук күреп алалар, аннары мактый-мактый, изге теләкләр тели-тели, кулыңа бер тиенне китереп тә тоттыралар. Сиңа шул гына кирәк. Бәхет кошын тоткандай, чыгасың да йөгерәсең.

Күршеләргә бер кергәндә юлым унмады. Ишекләрен шактый кагып торгач кына ачтылар. Өй хуҗалары эштә икән. Эреле-ваклы балалар булса да, бәләкәй сеңелләре генә миннән чак кына кече, ә апалары белән

абыйлары буйга да калку, яшькә дә өлкәннәр. Әлфиянең дә, Хәкимнең дә, кече сеңелләре Зәйтүнәнең дә иң әүвәл күземә ташланган нәрсәләре шул булды: өчесенең дә чәче әфлисун кебек җирән, ап-ак чырайлы һәм өчесенең дә битенә, бигрәк тә борын сыртларына дым сарган калай күгәрекләре кебек сипкелләр сибелгән. Әле бергә уйнап, рәхәт балачакның сәхифәләрен башлап җибәргәч тә, мин сонга табарак шуны белдем: бу кечкенә күршеләрем гел дип әйтерлек өйдә ялгыз калалар, әти-әниләре хәтта, эшкә киткән чакларында, аларны өсләреннән бикләп тә китәлиләр иде. Ләкин бу юлы, бәхеткә, ишекләре тыштан бикле түгел, алар мин килеп кергәннән соң башта, бу нинди җәнлек дигәндәй, мәченеке шикелле түм-түгәрәк яшькелт-соры күзләре белән миңа тасраешып карап тордылар, аннары көне буе берүзләре генә сугышып та, елашып та туеп беткән булсалар кирәк, яңа бер малайның килеп керүенә гаять тә куанышып, чинашып-чыркылдашып ике ягымнан эләктереп тә алдылар, өйгә мине, каз мамыгыдай җиңел тәнле малайны, җилтерәтеп алып кереп тә киттеләр. Үзебезнең ярым-караңгы бүлмәдән соң аларның биек түшәмле, зур-зур тәрәзәле өйләре миңа әкияттәге патша сарае сыман булып тоелды. Ләкин барыннан бигрәк мине гаҗәпләндергәне әлеге зур тәрәзәләрдән туктаусыз нур бөркелеп торгандай өй эченең гаять тә якты булуы иде. Мин хәтта бу яктылыкка күзем чагылып, аны йомып та тордым бугай әле. Шулай да өй җиһазларының күплеге, өстәл асларында да, почмакларда да әйберләрнең тәртипсез аунап ятуы иркенлекне кыса төшә. Аннары ниндидер тынчу ис килә, бигрәк тә ишек катындагы чиләк янында бу ис басып торгысыз иде.

Әлбәттә, монда чалбар да онытылды, без өйдә әүмәкләшеп котыра-котыра уйнаганбыздыр да — болары әлләни истә калмаган. Истә калганы тимер үтүк иде. Мин башта аның үтүк икәнен дә белмәдем. Үтүк ул кытыршы чуенлы, авыр капкачлы һәм күмер белән кыздыра торган була. Әти үзе теккән киемнәр өстеннән авызы белән «пуф!» дип су бөрки-бөрки аны арлы-бирле йөрткән чагында өскә чапе-чопы килеп парлар бөркелә торган иде. Бу исә очлырак башлы ялтыравык йомарлам кебек кенә бер нәрсә. Ләкин ул ак самавыр кебек, көзгедәй ялтырый иде шул. Ә мин әле бик кечкенә, һәр ялтыраган нәрсәне тотып карыйсым килә. Өстәвенә әлеге сипкел йөзле җирән башлар ниндидер бер кызык та уйлап чыгарганнар булса кирәк, чыш-пыш серләшәләр, ишелгән каты җеп очын стенадагы тишеккә тыгып куйдылар. Аннары алар кояш нурларын уйнатып торган әлеге бәләкәй түмгәкне өстәлдәге бер тимер күтәрмәгә утырттылар: «Бар, ал, сиңа булсын! — диделәр. Мин ике кулым белән дә ак тимергә барып тотындым. Иң әүвәл мин берни дә абайламый тордым, кулым ак тимергә ябышып калгандай булды, аннары шул тиклем авыртуга тәкатем корышып, ике кулымны да тиз генә тартып алдым. Карасам, учларым да, бармак битләрем дә ак кәгазь кебек пешеп чыкканнар. Шунда җирән башларның сикерешеп кычкыруларын, эчләрен тота-тота көлүләрен күрсәгез! Ә мин тиреләре бөтерелеп-бөтерелеп килгән кулларыма карап торам, кычкырып еламасам да, учларыма күз яшьләрем тәгәрәп төшә һәм алар түзеп булмаслык итеп үтереп-үтереп ачыттыралар. Ә яңа күршеләрем җирән йонлы җен балалары кебек котырышып биешәләр, күзләреннән яшел очкыннар чәчеп, разбой сала-сала, узышып кычкырышалар. Мин үземнең газабым белән аларга әйтеп бетергесез хозурлык китердем.

Миңа соңыннан да әтием-әнием дә, өлкән кешеләр дә: «Һәр ялтыраган алтын түгел», — дип колагыма тукый килделәр. Ләкин гамьсез балачак һәр әйткән сүзне истә тотамыни. Үземнең дә ялтыравык тәтиләргә кызыгып кешеләргә зыян китергән чакларым булды.

Минем туганнан-туган ике апам бар иде. Әле фин сугышына хәтле үк бәхетле яшьлекнең гөрләп торган чаклары. Апамның кечесе — Мәчтүрә апам — озынчарак карасу йөзле булып, үзенең чем-кара чәчен ул вакыттагы модага ияреп, муен тирәли кистергән, кәҗә мөгезе кебек алга табарак бөтереп тә йөри иде. Ул инде буй җиткереп килгән, гәүдәгә дә, эшкә дә гаять житез кыз бала иде. Әнием тегүче сыйфатында мех комбинатка урнашкач, күрәсең, мин Мәчтүрә апа карамагында кала торган булганмындыр, гел аның итәгенә ияреп йөргәндәй йөри идем. Ә бервакыт апам, миңа әйтмичә генә базаргамы, кибеткәме китеп баргач, мин дә аның артыннан чыгып йөгердем. Урам буенча бардым-бардым да, кешеләр арасында чагылып киткәләгән кызыл башлыкны югалттым. Адаштым. Ә инде берничә көн узып мин милиция ярдәмендә табылганнан соң, өйдә бик каты сөйләшү булды булса кирәк, Мәчтүрә апам йөзе белән почмакка борылып озак-озак яшь сыкты. Үземнең дә Мәчтүрә апамның муенына асылынып, аның кара кашларына тия язып торган коңгырт төстәге монсу күзләренә карап мышык-мышык килгәнемне хәтерлим.

Күрәсең, апамның боегып калуы, минем югала язып әти-әниемне хәсрәткә салуда гына түгел. Хәер, ул вакытларда балалар бер дә югалмый тормый, һәм моны Казан аша таборлары белән йөреп торган чегәннәрдән дә күргәлиләр, һәрхәлдә аларга сылтыйлар иде. Низаг чыгуның сәбәбе тирәндәрәк, апам өйдә артык кашык булып саналып килде ахрысы. Ник дигәндә, әле ятим дөньяга килгәнче үк, әтиемнәр 1921 елгы ачлык елында, ятим калган апамнарымны да үз канатлары астына сыйдырып, ерак казакъ җирләрендәге Семи каласына киткәннәр, анда баш-күз алып матур гына яшәгәннәр һәм соңыннан да андагы тормышлары турында тылсымлы бер мәмләкәт итеп сагынып сөйли торганнар иде. Әтиемнәр мәгълүм сәбәпләр аркасында туган туфракка кайтырга мәҗбүр булганнар (ул сәбәпләрне мин соңрак әйтеп китәрмен). Апамнар да бәрәкәтле казакъ җирендә әйбәт кенә урнашкач, безнең әллә ни ишле булмаган гаиләбез Казанга кайтып, шуннан инде бер дә кузгалмаслык булып, төпләнеп калганнар. Кайтуын кайтканнар да бит, ләкин бу, үз кайгыңны гына кайгыртып, тыныч кына яшәү озакка бармаган. Көннәрдән бер көнне энәле-җепле тагылып, ике апам да безнең өскә кайтып төшкән һәм әтием әйтмешли, чөй өстенә тукыма булып яши башлаган.

Мин менә хәзер апамның яшь сарган зур күзләрендәге тирән кайгыны үземнең нарасыйлыгым белән аңлап бетермәгәнмен шул. Шулай да, алга китеп булса да, әйтергә кирәк, апамның язмышы соңрак зур фаҗига белән очланса да, ул каравыл кычкырып сыгылып төшә торган җаннардан булмады, тормыш рәнҗетүләрен эченә йотып, тыныч кына Казагыстанга китеп барды, анда үзенең сынган күңелен эчтән төзәтергә тырышып карады. Ул шунда ук авыр сугыш елларын үткәрде. Үзе кебек кара-туткыл бер малай үстереп җай гына яшәп яткан җиреннән аның көтмәгәндә үле хәбәре килде. Юк, малаеның игелеген күрергә язмаган аңа. Самавыр куеп торган чагында, күлмәгенә ут эленгән, тәненең пешмәгән җире калмыйча, җиргә бәрелә-сугыла үлгән. Әле бездән киткән чагында өебездә аның инде фасоны югалган кызыл калфагы калды. Бәйрәмнәр булган саен, урамда җилфердәгән әләмнәрне күрәм дә агач ефәге җебеннән эре шакмаклы итеп бәйләгән шул башлыкны исемә төшерәм. Кайчандыр ул урамдагы узгынчылар арасына кереп югалган иде...

Икенче апам гаиләбез өчен нык кына таянычка әйләнеп бара, ул «Спартак» комбинатының азык-төлек комбинатында эшли, миңа да конфет-прәннек акмаса да, тама торган иде. Бу Шәмсенур апа белән безнең язмыш җепләребез бик озакка бәйләнде, бу хакта алдарак сүз күп булачак әле.

Хәзергә шуны гына әйтәм, ул яшь чагында чынлап торган ягымлы авазлы, бик тә җор күңелле таза гына кыз иде. Ул театрга йөрергә ярата, Мәчтүрә апам да, күп кенә иптәш кызларын да үзенә ияртеп академияга алып бара торган иде. Әйтәм бит, ул вакытлар, әле сугышның кара сөремле көннәрен күз алдына да китермәгән көләч яшьлекнең шау-гөр килеп торган чаклары иде. Театр хәтта халыкның үз эченә килеп кергән, спектакльгә билетларны хезмәт ударникларына зур бүләк төсендә бирәләр һәм безнең апаларыбыз кебек яшьләргә театр, зур бәйрәмнәр кебек, әйтеп бетергесез куанычлар китерә торган иде. Бервакыт «Мактаулы заман» спектакленең бөтен Казанны шаулатканын хәтерлим. Апамнар бу спектакльне карап кайтканнан ничәмә атналар буена аны искә алып сөйләп йөрделәр. Шундый дәртләнеп, илһамланып сөйлиләр, әле театрның нәрсә икәнен белмәгән хәлемдә, ягъни сөйләүчеләрнең шатлыгына ияреп кенә мин дә учымны учка чәпелдәтеп куя торган идем. Ләкин минем хикәям болар турында, хәтта апамнар турында да түгел, ә бала күңелен кызыктырган тәтиләр, матур төсләр турында иде бит. Инде үземә алты-җиде яшь тулып, чын малай булып йөри башлагач та мин әнә шул сихри матурлыкка таба омтылудан һич тыела алмадым һәм үземнең тыңгысызлыгым аркасында бервакыт үзем дә унайсыз хәлгә калдым һәм кешене дә бәлагә тарыта яздым.

Бер көнне безгә, апамнар белән театрга барырга дип, чибәр генә бер кыз килгән иде. Мин дә игътибар итәрлек булгач, ул гади чибәр генә булмагандыр. Мин инде аны хәзер, бала чагымдагыча хыялымдагы сихри төсмерләрне дә кушып тасвир итә дә алмамдыр, күрәсең. Ул тулы ай кебек якты чырайлы. Маңгаенда нәкъ ак җептәй сузылып төшкән чәч юлы астындарак, бәләкәй генә туш тамчысыдай кара миңе бар, ә чәч толымнары исә күгелҗем күлмәге өстеннән кучкыл чия төсендәге аркан кебек сузылып төшкәннәр. Барыннан бигрәк хәйран калдырганы шул: аның ак муеныннан икеме-өчме рәтле аллы-гөлле мәрҗәннәре асылынып тора иде. Ул киенгән — эше беткән, шуңа бер дә кабаланмый, күлдәге аккош кебек тыныч кына йөренгәли, күлмәкләрен үтүкләгән, сөрмә тарткан апамнарга булышкалый, хәтта керосинка өстенә кыздырырга куйган тимер шипшина алып өлкән апамның чәчләренә бөтеркәләр ясап куя һәм горур башын арткарак ташлап, ул бөтеркәләрне матур микән дигәндәй, карап-карап ала. Менә ул апамнар ясанып беткәндә, минем яныма килеп, күлмәк итәген бармак очлары белән генә тотып иелә төште һәм исемемне белсә дә кабат ни өчендер сорап куйды.

Минем күзем аның яшел, сары һәм кызыл нурлар белән уйнаклап торган мәрҗәннәрендә иде, шулай да мин ярым пышылдап кына, исемемне әйттем. Ул минем мәрҗәннәр белән мавыгуымны күреп:

— Тотып карыйсың киләме соң, матурым? — дип сорап куйды.

Мин:

— Әһе, — дип әйтергә дә өлгермәдем, кулымны аның матур ак муенына суздым.

Ник суздым икән? Ник мин муенса җебен саксызланып тарттым икән?

Җеп өзелде дә, яшел, сары һәм кызыл мәрҗәннәр шыбыр-шыбыр идәнгә коелды. Алар өстәл, карават һәм сандык асларына тәгәрәп керделәр, минем аяк сыярлык идән ярыкларына төшеп югалдылар. Тавыш купты, ыгы-зыгы башланды. Өлкән апам кулга катырак иде. Кулын төйнәп, баш очымда йодрыгын уйнатып алды, хәтта бер сугуында, кунак апа башыма кулын куеп, мине аның йодрыгыннан саклап калды:

— Тимә! — дип кычкырды, ләкин барыбер апам болай да сөяк белән тиредән генә торган арык аркамнан бордырып чеметеп алырга өлгерде.

Мәрҗәннәрне иелеп һәм тез башлары белән үрмәләп җыя-җыя күлмәкләр дә таушалгандыр, бөдрәләнгән чәчләрнең дә рәте киткәндер, анысын инде карап торырга вакыт булмады, әлеге маңгаенда миңе булган, калын толымлы чибәр апа:

— Барабыз, мин сезне ложага кертеп утыртырмын, күлмәкләрегезне беркем күрмәс! — дип, апамнарны барыбер алып чыгып китте.

Шунысы бик нык хәтергә уелып калган: үземнең мышык-мышык мәрҗәннәр җыеп йөргәнне әйткән дә юк. Яшькә чыланган, калтыраган учым белән мәрҗәннәрне алып биргән чагымда, кунак апаның да озын керфекләрендә яшь тамчылары калтырап торуын күреп калдым. Ул мине кызганган сымак булып күренде. Дүрткә бөкләнгән чиста кулъяулыгының очын гына тигерә-тигерә күзен берничә мәртәбә сөртеп алса да аның эре күз яшьләре берничә мәртәбә идәнгә дә тәгәрәп төшкән иде һәм минем аларны да мәрҗәннәр кебек җыеп үзенә кайтарасым килеп киткән иде.

Мин икенче көнне иртә белән дә саташып, сулыга-сулыга ятканмын булса кирәк. Апам эшкә киткән чагында мине уятып аркамның чеметкән турысыннан йомшак кына сыйпап куйды. Аның йөзе болай да таза, түгәрәк иде. Өстәвенә ул миңа әнә шул йөзен кояшландырып елмаеп та куйгач, мин башымны беленер-беленмәс селкеп:

— Әһе! — дидем.

Ул көнне миңа кичен конфетның тагы да тәмлерәге — шоколад дигәне эләкте. Мәрҗән вакыйгасы шуның белән бетте. Аннары, ярама тоз салмасын өченме икән, теге чибәр апа да безгә килеп йөрмәс булды. Бәлкем әле ул үзе дә онытылган булыр иде. Ләкин аның ак муеннары, нурлы чырае һәм куерак ягымлы салмак авазы бала күңеленә мәңгегә сеңеп калырлык берничә сәбәп бар иде. Без бит Кабан күле буенда үскән малайлар. Әлеге зур моңлы күзле Мәчтүрә апамның миңа сөйләгән әкиятләре арасында Кабан күленә бәйле бер легендасы да бар иде. Ул легенда халыкта чынлап та булганмы, әллә апам аны, туган яклардан аерылып чит җирләргә китәр алдыннан хәсрәткә батып үзе генә уйлап чыгарганмы, мин бу мәсьәләдә тәгаенен генә әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, апам легенданы өзелеп яраткан Кабанына, бу күлнең әкияттәгечә айлы, сихри кичләренә бәйләгәндер кебек тоела.

Зөһрә исемле кыз булган. Ул бик ярлы, ләкин үзе кебек үк матур, баскан җиреннән ут чыгарырлык бер яшь кенә егетне яраткан. Әйткәнемчә, егетнең чибәрлеге дә, уңганлыгы да бар, тик байлыгы юк. Зөһрә кызга байлык нигә кирәк? Ул аңа кияүгә чыгарга дүрт куллап риза.

Тик кызның әти-әнисе усаллар. Байлыксыз ничек яшәрсез, казык башын кимерерсезме? «Кимерсәк кимерербез, тик шул егеткә генә чыгам». «Алайса без сине каргыйбыз!»

Әти-әниләре бердәнбер кызларын каргыйлар: «Җир йөзеннән юк булсаң иде!..» — диләр. Менә инде кыз хәзер җир йөзеннән юк булырга, айга менеп яшәргә тиеш. Ул айга китәр алдыннан таң атканчы елап чыга. Аның күзеннән кайнар яшьләре елгалап-елгалап ага һәм төне буе түгелгән күз яшьләреннән мөлдерәмә күл хасил була. Бу легендада казык тешләрен ыржайта-ыржайта кабан дуңгызлары чабып йөрмәсә дә, ни өчендер күлне Кабан дип атаганнар. Бәлкем аның исеме борын-борын заманнарда Зөһрә кыз күле булгандыр. Халыкта тагы да кыскарак итеп Зөһрә-күл дип йөртүләре дә бик мөмкин бит?

Аннары мин, нишләптер, балалык кирелеге белән микән инде, Зөһрәнең айга менеп китүенә дә ышанып бетмәдем. Маңгай уртасында ясмыктан чак кына кечерәк миңе булган ак чырайлы, авыр толымлы һәм күлмәге кебек үк зәңгәр күзле теге апа безгә килеп чыккач, мин бервакыт аңа чак кына йомыла төшкән керфекләрем аша карап:

— Зөһрә-кыз бит бу!.. — дип уйлап та өлгермәдем, шундук үз уемнан үзем сискәнеп тә киттем. Бу охшатуым шулкадәр дөрес булып тоела иде, ул балалык фантазиясе белән өртелеп еллар буена күңелемнән китми йөрде. Әгәр хатирәләр яңартылып тормаса, бу сурәт тора-бара тоныкланыр һәм бөтенләйгә онытылыр да иде. Тик, мин, үсә төшеп, каршыдагы биек мәктәпкә укырга йөри башлаганда, әле яр буе тирәкләренең бер генә яфрагына да сары инмичә, көзнең рәхәт җылы җилендә лепердәшеп утырган бер кичендә күлгә бер матур кыз баткан дигән хәбәр таралды. Үзен бик тиз тартып чыгарганнар да, ләкин бик күп су йотып өлгергән. Кызны одеялга салып чайкап карасалар да, косып чыгара алмаган, һушына килмәгән. Җирдәге одеял өстендә озын зифа буе белән, зәңгәр күлмәк аша күкрәк очларын чак кына белендереп нәкъ тере кебек ята икән.

Күршебез Нәфисә апа, апа гына түгел, карчык кеше иде инде ул:

— Үзем күрдем, бу тиклем дә матур итеп яратыр икән Ходай! — дип, кулы белән ботына сугып куйды: — Ул маңгаендагы фәрештә мөһерен күрсәң, ул ефәк толымнарын күрсәң! Ник кенә ата-ананы санга сукмый икән бу кыз балалар, — дип уфтанды Нәфисә карчык, аннан йортыбызның аскы катында яшәүче кипкән балыктай ябык, чәтертен хатынга пышылдап кына әйтте:

— Карале, Хәят, алданган ди бит.

— Тфү, тфү, әстәгъфирулла, — дип төкеренеп алды Хәят апа, аннан Нәфисә карчыкка усал гына карап куйды: — Алданмасын, шул кирәк! — диде.

Бу сөйләшү вакытында минем чәч төпләрем чемер-чемер килде.

Фәрештә мөһерен Нәфисә карчык авызыннан берничә мәртәбә ишеткәнем бар — миң була инде ул. Аннары зәңгәр күлмәге, калын ефәк толымнары... Минем болай да башым авырткалый, бигрәк тә күлдә күгәргәнче коенганнан соң, тимер кыршау белән кыскандай, башым авырта иде. Инде менә хәзер бердән башым әйләнеп, аңкы-миңке хәлдә өйгә кердем дә сандык өстенә бөгәрләнеп яттым. Мәчтүрә апаның Себергә[1] киткәненә бер-ике ел. Шәмсенур апа да кияүгә чыгып Газиз җизнинең агасы яшәп яткан балыклы Әстерхан каласына киткән һәм алар шунда бөтенләйгә төпләнеп калырга уйлыйлар иде. Мин үз-үземә хуҗа булып япа-ялгыз калдым. Япа-ялгыз диюем шуңа: эти белән әни көне-төне эштә иделәр.

Ләкин бала — бала инде. Ул сандык өстенә менеп ятса да, өстенә юка гына бер җәймәне генә булса да ябынырга кирәк икәнен белми. Мин чыдап ята торгач өшеп үк киттем. Тешем-тешкә тимәде, калтыравым хәтта гүя сандыкка күчте, ул зың-зың килеп селкенеп торды. Бу әүвәле дә мине әледән-әле җәфалый торган чып-чын бизгәк тоту иде.

Медицина фәнендә шундый аңлатма бар бугай: тәндә каршылык көче бетсә, ягъни иммунитетлар зәгыйфьләнсә, сырхау кешене бары тик карап торган вакытында да кәефсезләнеп китүең мөмкин. Ә мин ныгып җитмәгән сөяк булмавым гына түгел, суга батуның нәрсә икәнен үзем дә кичергән, инде шул ук суда җанын калдырган кыз турында иләмсез сүзләр ишеткән, өстәвенә үземнең яшь канымда Себер бизгәген алып кайткан булганмын. Чөнки мин Семипалатинскида туып кайттым, ә анда мине тайганың озынборыны тешләгән булган күрәсең[2].

Бизгәгемнең яңартуына суга батып каравым да ярдәм иткәндер дип әйтеп киткән идем инде. Ә ул хәл болай булды.

Элекке елларда, сугышка хәтле үк әле, Кабан күлендә берничә мойка

[1] Ни өчендер безнең әтиләр Семина, ягъни Семипалатинск шәһәре якларын Себер дип йөртәләр иде. География төшенчә итеп караганда бу бик үк дөрес булмагандыр.

[2] Әле Бөек Ватан сугышы башлангач та мин бизгәк белән авырып алдым. Врачлар канымны микроскоп аша тикшерткәч: «Каян килгән бу Себер маляриясы сиңа?», — дип шаккаттылар.

бар иде, моны төп казанлылар хәтерли дә торгандыр. Аларның икесе капма-каршы якта, өченчесе, озын агач барактай каплаулысы Мәржани мәчете астында ярты чакрымга сузылып киткән әмерикан өрәнгеле бакча турысында иде. Мойканың уелдыкларында хатын-кыз көне буе ким-кырыч килә: бәләкләр белән суга-суга кер уа, мунчала белән ышкый-ышкый юрган юа, бигрәк тә анда аркага көянтәләп кер чайкарга төшүчеләр күп була торган иде.

Ә малай-шалайны әйткән дә юк, аларның кинәнеп уйный торган урыннары ул. Әлбәттә билет сатучылар малайларны куып торалар, шуның саен алар анда кереп торалар. Мойка тирәсендә дә, сулы уелдыкларда да көтүе-көтүе белән маймычлар йөзә, хәтта бу маймыч көтүләрен иярткән олы-олы көмеш балыклар да күренгәли. Аннары анда шыпырдый-шыпырдый, бакалар шикелле коенуы үзе бер рәхәт, арсан басма такталарына тотынып ял итәргә дә була. Мәнә мин дә анда кайвакыт көнемне уздыра торган идем. Ләкин минем әлеге бәхетсезлегем бик кечкенә чагыма туры килде, мин әле ул вакытта йөзә дә белмим, хәтта тездән суга керергә дә курка идем. Ә мәнә мойкада ялан тәпи белән лач-лоч йөгереп йөрүе кызык. Һич югы үскәнрәк малайларның су эчендә котырышуларын күзәтүе кызык. Бервакыт малайларын да, уктай атылышып йөргән маймычларын да карап туйгач, мойкадан ерак түгел, вак дулкыннар өстендә сикергәләгән бер алсу алмага күзем төште. Алма дулкыннар белән мойкага таба килә, ләкин бик акрын килә. Инде килеп җиттем дигәндә дә шул ук дулкыннар белән уйный-уйный кире китеп барды. Әнә шулай бер ерагаеп, бер якынаеп, сикерә-сикерә йөзгән вакытында мин аны эләктереп алмакчы булдым, кулым белән аңа таба үрелдем һәм мойканың лайлалы тактасында аягым таеп чулт итеп суга чумдым.



Әнисе

Инде буй җиткереп үсеп беткәч тә әти миңа: «Поездга бик якын килмә, суырып ала ул», — дип әйтә торган иде. Мин суга чумып та киттем, мойка астына суырылып та кердем. Шулай да мин баш очымда хатын-кызларның шырый итеп кычкырып җибәрүләрен, тып-тып йөгерешкәннәрен тоныкына ишетеп калдым, аннары, башым артка киткән хәлемдә, экрандагыча, кояшлы якты яссылыкта мойканың уелдыкларга бүлгәләнгән кара шәүләсен күрдем. Шуннан инде күз алларым сүнеп китте...

Мин Кабан күлендә суга батучыларны бик күп күрдем. Аларга җан өрдерү өчен ниләр генә эшләп бетермиләр иде. Мөгаен мине дә шулай иткән булганнардыр. Мин караңгылык эченнән якты дөньяга чыкканда, тирә-якны үз күзем белән күрерлек хәлгә килгәндә, әнием мине сөлге белән ышкып тора иде. Ул мине яткырып та, утыртып та, хәтта бастырып та туктаусыз бөтен тәнемне ышкыды. Мин аның күз яшьләрен дә күрмәдем, акырып елавын да ишетмәдем, тик әле сулары чыгып бетмәгән колагыма аның сызланып ыңгырашкан авазлары гына чалынып-чалынып киткәли иде. Ләкин бер нәрсә аерым ачык исемдә калган. Әнә шулай шыншып тәнемне уып торган чагымда ул кинәт гасабиланып миңа сөлге белән китереп сукты, тагын кизәнеп сукмакчы булды. Ләкин мин монысында суктырмыйча башымны иеп калдым. Иелеп калдым калуын, тик сандык өстеннән идәнгә егылып төштем. Мүкәләп, гәүдәмне акрын гына турайтып аяк өсте басканда, борыным шабыр кан иде. Әнием мине шундук кочагына алды:

— Балам, ике күзем, бәгырь кисәгем... — дип башымнан да, аркамнан

да сыйпый-сыйпый, иркәләү сүзләрен тезеп китте һәм бу юлы инде тыелгысызланып елады. Әниемнең җылы кочагында сөелү, иркәләнүләремне борынымны канатып булса да яңадан кайтарыр идем дә бит, юк шул, булмый, ул еллар үткән, чәчләр агарган. Әниләр безгә чак кына кул тигерсә дә үпкәли идек, авызларыбызны турсайтып дәшми йөри идек. Ә бит мин кемдер тешләп ташлаган юк кына алма өчен дә әниемне кайгы упкыннарына салганмын.

Ул әтисе, ягъни минем бабам, вафат булганнан соң метрикасын төзәтеп, үзен олы итеп күрсәтеп, уникe яшьтән үк чуен юлга җир казу эшенә кергән, чөнки сеңелләренең, Шәмсенур апа белән Мәчтүрә апамның, тамагын туйдырырга кирәк булган. Унөч яшендә, ачлык елында, кияүгә чыккан һәм сеңелләрен дә ияртеп барысы бергә эшелонга төялеп ерак Семигә киткәннәр. Анда бер-бер артлы минем кыз туганнарым — үз апаларым туганнар һәм бер-бер артлы өчесе тиң үлеп киткәннәр. Инде дүртенчесенә мин туганмын. Малай да булгач, ничек тә яшәргә кирәк бит инде миңа. Еллар үтеп, үзем дә балалар атасы булгач, дөньяның әчесен-төчесен күп татыгач, хәзер мин болай фараз итәм: бәлкем әнинең, яшьлеге белән, балалар багуда алай ук тәҗрибәсе дә булмагандыр. Аннары балалар гына мыни — ишле гаиләне нанлы һәм кантлы[3] итү өчен әти белән бер үк арбага җигелеп эшләгән бит ул. Моңа өстәп тагын казакъ һавасының бик үк рәхимле түгеллеген, кышын кырык-илле градуслы зәмһәрир суыклар, җәен исә янә миләрең кайнап чыгарлык чилләләр булуын әйтергә кирәк. Әле эссе, әле салкын. Тамырлары белән йомшак табигатьле Идел-Чулман якларына барып тоташкан безнең сыек буыннарыбыз ерак Себердә тернәкләнеп китә алмаган — казах җире безнең нәселне кабул итмәгән. Инде минем дә, тумас борын ук, үпкәм ялкынсынып алгач, безнең гаилә яңадан туган туфракка кайтып төшкән.

Инде мин әниемне күптән гафу иткәнем һәм үз гаебемне дә таныганым хәлендә ак калай белән нәкышләнгән шул ук яшел сандык өстендә саташып ятам. Мине әле әнием, әле зәңгәр күлмәк кигән ак чырайлы бер кыз сөлге белән суктыралар. Юк, юк, бу болай булырга тиеш түгел, алар мине яраталар, назлап-назлап сөяләр иде бит. Һәм саташулы төшемдә чынлап та алмашу барлыкка килә. Инде мине хәзер алмаш-тилмәш җирән башлы, ут кебек сипкелле бер малай белән бер кыз кыйныйлар. Ләкин ни өчен әле алар сукканда сөлге минем башыма шап итеп төшми, дыңк итә. «Ә, белмисезмени әле ни өчен? Менә кара», — ди җирән чәчле малай, сөлгене ачып матур гына алманы күрсәтә. «Мә, ал», — ди ул аны миңа сузып. Мин алманы алып куш учымда тотып торам. Тик нигә әле ул зурая бара һәм ни өчен ул минем кулларымны пешерә? Ә Хәким белән Әлфия: «Петерсен! Петерсен!» — дип үрле-кырлы сикерәләр, күз алдымда аларның җирән башлары аслы-өсле биеп тора. Ниһаять, мин, учларымны көйдерүенә түзә алмыйча, зур алсу алманы атып бәрәм һәм җирән башлы күршеләрем шундук юкка чыгалар. Ләкин алманың кызуы тәнемә күчкән, башым да ут кебек яна.

Мин ике-өч көн эсселе-суыклы булып калтыранып яттым, әнием аптекадан алып кайткан әрем кебек әче төймәләрне йота-йота саргаеп беттем.

Әнием дә, җирән битнен теге «җен балалары» — күршеләрем дә ярый инде, тик менә зәңгәр күлмәкле кыз ни өчен төшемә керде икән?

Сугыш башлангач та безне, укучыларны, күл буеның «кәҗә мәктәбе»нә күчерделәр. Ни өчен аны «кәҗә мәктәбе» дип атаганнарын мин һич белмим. Алабутасы, мәче борчаклары, тәмле кыяклары да котырып үскән

[3] Казакъ җирендә татарлар да икмәкне нан, шикәрне кант дип йөртәләр.

яр буйларында көтүе-көтүе белән кәжәләр йөргән өчен микән әллә? Тимер баскычлы, ике генә катлы бу мәктәпне моннан күп еллар элек, әле унтугызынчы йөзләрдә үк «күл буе мәдрәсәсе» дип тә йөрткән булганнар. Мәдрәсә булса да, барыбер кәжәгә барып тоташса кирәк ул. Анда бит гомер буе укып, сакалларын селкетеп йөрүче шәкертләр дә булган. «Кәжә мәктәбе» сүзе безнең өчен мәзәк тә, шул ук вакытта: — Кайда укыйсың син? — дигән сорауга:

— Кәжә мәктәбендә, — дип җавап биргән чакларында гарьлек тә булып тоела иде.

Ярый, дөньяга зур якты тәрәзәләре белән караган дүрт катлы ак мәктәбебезгә каерылып карый-карый, кәжә мәктәбенә күчеп тә киттек ди. Әмма зурдан зур бинаны буш тотып булмый бит инде. Ул ашыгыч рәвештә госпитальгә әйләндерелде.

Авыр сугыш елында госпиталь безне дә егылудан саклап килгән таяныч булды дисәм, бу бер дә дөреслеккә хилафлык китерү булмас. Мәсәлән, әни миңа киоскалардан сыра алып кайтырга кушкалый иде. Бу бик авыр бурыч, чөнки, беренчедән, бөтен күл буе төбәкләрен актарып чыксам да, мин аны кыенлык белән генә табам, икенчедән, табу бәхетенә ирешсәм дә, аңа бик озак чират торам. Кайсы малайның чират торасы килсен инде? Ләкин башына төшкәч торасың икән.

Ямьле җәй көннәрендә яралылар һавага чыгып йөриләр, күл буена да төшкәлиләр. Шунда инде сумкага салган зур чирегендәге сыраны чайкаттырып авырулар яныннан үтәсең. Шунда инде кемнең дә булса күзенә чалынмыйча калмыйсың.

— Эй, малайка, постой! Пиво што-ли? Ну?! — дип, шундук аксый-аксый килә берәрсе.

Ул да түгел, сине сырып та алалар. Күзләрен йома-йома, стаканыннан сугыш елының сыек сырасын чөмерәләр һәм әлбәттә инде сумкана йә шикәр кисәге, йә берәр телем ипине салырга онытмыйлар. Безгә госпитальнең бүтән игелекләре дә тиде, анысы турында — соңрак. Ә хәзергесен сөйләп китүем шуңа: ул минем әлеге зәңгәр күлмәкле кыз турындагы истәлегемне яңадан кузгатып җибәрде.

Бервакыт, сугыш елының беренче кышында, дөресендә, кыш башында күз бәйләнгәндәрәк, безгә госпитальнең бер яралы егете килеп керде. Башы да ялангач, халат изүләре дә ачык. Кулын кулга сугып аларга тынын өреп торды да, бармакларын як-якка тырпайтып, кызарган плитәбезгә таба сузды.

Шунысы да мәгълүм булсын, сугыш алдыннан гына безгә, ике бала күтәреп, Шәмсенур апа белән Газиз җизни кайтып төште, алар халыкта шомлы хәбәрләр тарала башлагач, Әстерханда калырга итмәгәннәр. Газиз җизни шофер иде, үзенең машинасына ук утырып сугышка китеп барды һәм менә үзе югында, аның малае да туып өлгергән иде. Яшь бала да булгач, юк утынны бар итеп, өйне җылы тотарга тырыша идек без.

Яралы егет апам белән дөнья хәлләрен сөйләшеп утырды. Кыз чаклары да искә төшепме, бер мәлне ул мин очлы күздән бик яшереп тота торган төргәкне чыгарып, егеткә карар өчен резинка белән будырып куйган бер бәйләм фотокарточкалар бирде. Яшерсен, мин барыбер аларны беләм. Анда маржа кызы тетя Феня белән өчәүләп төшкән карточка да бар. Икесе дә түгәрәк шома битле. Тетя Феняның кыска чәче туры гына төшкән. Ачык муены да бик юан. Ә Шәмсенур апаның тубалдай чәче сарык бәрәненеке кебек бөтеркәле-бөтеркәле — тимер бигудины кыздырып бу хәлгә китерү өчен үзенә генә дә ике литр керосин киткәндер. Карточкадан зур күзле, нечкә муенлы, шулай ук кыска кармак кебек алга очлайган чәчле Мәчтүрә

апа да өлкән күгәрченнәр янына ялгыш килеп эләккән яшь күгәрчен кебек оялып кына карап тора. Аннары әлеге төргәктә Шәмсенур апамның Газиз жизни белән төшкән сурәте дә бар. Икесе дә башларын бер-берсенә кыңгырайтканнар. Жизни киң ачык маңгайлы. Бик матур төз борынлы. Модалы костюм кигән, ап-ак якасын кыйгач буйлы ефәк галстук белән төйнәп куйган. Четерт-четерт итеп янган мич яктысында карточка карап утырган яралы егет бер заман ничектер сискәнеп китте:

— Зөһрә! Каян килеп эләкте бу кыз сезгә, Шәмси апа? — диде.

Мин дә сискәнеп киткәндәй булдым. Нинди Зөһрә? Нишләп бутый әле бу абый?

— Зөһрә, безнең артисткабыз! — диде Ранен абый сокланып һәм шул ук вакытта сораулы күзләре белән Шәмсенур апага төбәлеп.

— Батты, суга батты бит ул! — дидем мин ике арадагы тынлыктан файдаланып. Зәйнәп карчыктан ишеткәннәремне түкми-чәчми сөйләп бирим дигәндә генә Шәмсенур апа минем авызымны каплады.

— Ни сөйлисең син, җүләр малай! Тфү, тфү, әйттем исә кайттым диген!

— Тфү, тфү, әйттем исә кайттым, — дидем мин апамның сүзләрен кабатлап.

Шунда бишектәге энем елап җибәрде, мин шыгыр-шыгыр бишек тирбәтергә керештем.

— Сезнең артистка булса, безнең подшефный иде ул. Безне театр бусагасыннан беренче мәртәбә ул алып керде, — дип, апам сугышка хәтле ничек-ничек итеп театрга барып йөрүләре турында сөйләп китте.

— Ә мине танныйсызмы, Шәмси апа?

— Каян танып бетерәсең инде бөтен госпитальне, энем, — диде апам. Шул вакытны ут бирделәр, чебен нокталары белән бизәлгән тузанлы лампочкабыз яныйм микән, юк микән дип кызарып торды да тирә-юньгә саран гына яктысын чәчә башлады. Өстәл астында үзалларына уйнап утырган сеңелләрем мүкәли-мүкәли чыктылар да соргылт халат кигән сәер абый каршына басып, бармакларын авызга капкан хәлләрендә, башларын чайкый-чайкый, аңа карап тора башладылар.

Ранен абый халат кесәсеннән бармак башыдай гына ике кисәк шикәр чыгарды да балаларга тоттырды. Ул миңа да карап куйды, мин ымсынып, төкрегемне йоттым. Ләкин абый, нишлим соң, юк бит дигәндәй, иңнәрен генә сикертеп алды. Шәмсенур апа башы белән тәрәзәләргә ишарәләгәч, мин шытыр-шытыр китереп маскировка кәгазьләрен төшерә башладым.

— Алайса танымыйм дисең инде, ә, Шәмси апа?

— Ничек таныйм соң, энем, — диде Шәмсенур апа, гаепле кеше сыман сүлпән тавыш белән.

— Хәтерлисеңме «Мактаулы заман» комедиясен... — һәм ул күңеленнән сөйли башлады...

Без үскән вакытта телевизор кебек нәрсәнең исе дә юк. Концерт, театр дигәннәрен дә белмибез, ишетсәм дә, тамашаны күреп кайткан апамнарның бик әсәренеп сөйләүләре аша гына ишетәм. Безнең бөтен сәхнәбез кино иде. Тукай урамындагы «Чаткы»[4] кино-театрындагы картиналарның берсен дә калдырмаска тырыштык. Хәтта кызыграк фильмнарны эзләп шәһәр читендәге кино-театрларга да барып чыга идек.

Шулай да театрның әлифбасын ук булмаса да «ә» хәрефен уздык дип әйтә алам мин. Күршедә, коридорыбызның каршы ягында, бер аягына чак кына чатанлап йөри торган иптәшем бар иде. Аның әтисе Сергей абый, үзе

[4] Хәзер ул Тукай исемендәге кинотеатр дип атала.

кебек үк очлырак иякле Каюм исемле абый белән, айлар буена районнардан кайтып кертмиләр, командировкаларга йөриләр иде. Ләкин болары әле минем үсә төшкәч белгәннәрем. Ә без бөтенләй дә бәләкәй чакта аның белән беренче мәртәбә танышуым менә ничегрәк булды. Ул безнең ише борыннан акканнарын лаш-лош кире суыручы балаларны тезеп куя иде дә безгә тамаша күрсәтә торган иде.

Ул вакыт безнең йортта электр уты юк иде әле. Керосин лампочкасының яктысы тымызык кына. Сирай абый анысын да әле, филтәне борып, киметә төшә. Менә ул безнең каршыга «сәхнә»гә чыга. Әүвәле ул ниндидер таягын безнең баш очыбызда йөртә, без дә, башыбызны бутап, карашыбыз белән таяк очы артыннан йөрибез.

Аннары Сирай абый очкыннар чәчеп торган күзен лампа яктысы төшкәч аяк астына күчерә. Без дә аның утлы карашы белән сихерләнеп күзләребезне аның аяк турысына төбибез. Менә Сирай абыйның ярым карлыккан тавышы ишетелә:

— Ванька, встанька!

Идәндә, сыек яктылык эчендә, бер нәмәкәй торып утыра да кире сузылып ята, бары аякларын гына кыймылдатып куя.

— Алай ялкауланырга ярамый инде, тор әйдә, Ваня, — ди Сирай абый.

Ваня киерелгәләп акрын гына торып баса. Без аның бер хәрәкәтен дә ычкындырмыйча, авызыбызны ачып, карап торабыз.

— Ә теперь, Ваня, попляши.

Сирай абый, биергә өндәгәндәй, өстә кулларын йөртә һәм ул йөрткән саен, аның ишарәләренә буйсынып, Ваня да аякларын тыпырдаткалый, нечкә беләкләрен тегеләй-болай аткалый.

— Веселее попляши, Ванька, быстрее!

Ванька чынлап та сикеренергә тотына, бу безне тәмам әсәрендерә, без дә дерт кенә аяк өсте басабыз, якын ук килеп карамакчы булабыз, ләкин Сирай абый буш кулын шундук безгә таба ташлый, кире урыннарыбызга утырырга куша. Без буйсынып утырабыз.

— Быстрей, быстрей, Ваня!..

Ваня бик кызу биергә, бөтерелергә керешә, кул-аяклары очып кына йөри. Без дә аның тактына кушылып, идәндәге аякларыбызны тыпырдатабыз, инбашларыбызны сикертәбез.

Ваня шулкадәр кызу биеде, бер заман капланып китте дә: «Уф!» дип кулы белән аякларын як-якка ташлап идәнгә сузылып ук ятты.

Без бу тамашаны кат-кат күрдек һәм, үсә төшкән саен, кайбер серләренә төшенә башладык. Безнең күзләребезгә Ваньканың кул-аякларын сикерткәләгән нечкә генә жепләр күренгәли башлады. Аннары без аның катыргыдан ясалган гәүдәсен шәйләдек һәм инде, тора-бара, тамашадан сүрелә төштек. Дөрес, без үзебез дә катыргыдан кисеп Ваньканы ясап карадык, сикертеп тә карадык, ләкин Сирай абыйның кәмитен бервакытта да кабатлый алмадык. Сәнгать кызык кына нәрсә икән: әгәр аңа ышансаң, ул синең күңеленне яулап ала. Әгәр инде аңа ышанмый башласаң, безнең кебек техникасын тикшерергә керешсәң, сәнгать юкка чыга икән.

Ләкин Ранен абый миңа тамашаны кабат искә төшерде, алай гына да түгел, «Мактаулы заман» комедиясеннән бер-ике өзекне уйнап, театр сәнгатенең инандыргыч илаһи көчен күрсәтеп бирде ул.

Шуннан ярałы егет:

— Аһ син, Зөһрә!.. — дип, артистка кызның озын толымнарын салындырып төшкән зифа буена, аннары кояш нурлары кебек сирпелеп торган керфекләренә бик озаклап карап торды.

— Энем, сез аның белән бергә уйнадыгызмы соң? — дип сорап куйды Шәмсенур апа.

— Сугыш алдыннан без әле бик яшь артистлар идек, — диде Ранен абый, үзенең тыңламый торган вак бөдрәле чәчен артка таба сыпырып куеп. — Шулай да Зөһрә бик тиз алдырды. Күрәсез бит нинди чибәр, горур караш, солтанатлы буй-сын. Ә бәрхет тавышы!.. Сәхнәгә чыгу белән, толымнарын аркасына чайкап атып, беренче аваз салуга, пышын-пышын утырган тамашачылар да шып тынып калалар, аның тас-тас атлап йөрүләрен, аның бөртек сүзенә хәтле мөкиббән булып күзәтәләр иде... Ә мин... мин алай ук булдыра алмадым шул.

— Нишләп инде алай, — дип, егетне кызганган сымаграк әйтеп куйды Шәмсенур апа.

— Нишләпме? Булдыра алмадым, шул гына. Аннары кайбер низаглар килеп чыкты. Һәммәсе дә шул сәләтемә ышанычымны югалтудан килеп чыкты. Сугыш башланыр алдыннан гына күчмә театрга киттем.

Мин кара маскировка кәгазьләре белән тәрәзәләрне томалап бетергән идем инде. Апам, Ранен кунакны өй ашы белән сыйлап алырга уйлап, сулы табакка өшегән бәрәңге салып куйган иде. Менә хәзер, коймакка дип, туңы кайтып бетмәгән ул бәрәңгеләрне мин, бармакларымны кызарта-кызарта, калай угычның үткен тырнаклары өстеннән арлы-бирле йөртергә керештем. Туктагыз әле, бәрәңгеләр, алай бик үк кыштырдамагыз — минем Ранен абыйны тыңлыйсым бар бит. Үзем акрын гына бәрәңге уам, үзем башымны егет ягына кыңгырайта төшеп тыңлыйм:

— Мин авылдан-авылга йөргән театрда уйный башладым. Көн дә юк, төн дә юк миңа. Өнемдә дә роль, төшемдә дә. Юк, мин әйтәм, барыбер мин артист икәнемне исбатларга тиеш. Исбатлаган да булыр идем, менә бит, фашист пулясы беләгемне тиште, — дип, Ранен абый гипслы кулын күтәреп куйды. — Их, яу кырыннан исән-сау кайтсаммы?! — дип, абый, өзгәләнеп, тынламас чәчле башын селкеп куйды. — Шәмси апа, зинһар, театрга барып кайтыйм. Анда минем иптәшләрем, аннары... Ичмаса балконга гына булса да менер идем дә... Бик сагындым бит, Шәмси апа?

— Ничек инде, ничек бу суыкта? — дип аптырап китте Шәмсенур апа. — Бу халатың белән күрсәләр, өрәкме икән әллә, дип качарлар үзеңнән.

— Шул-шул менә, бер иске генә чикмән шикелле нәрсәң юкмы икән, дип кергән идем мин.

Минем колакларым үрә торды. Уып бетермәгән бәрәңгемне суга чупылдаттым да апам янына йөгереп килдем:

— Ә жизнинең костюмы? Каракүл якалы пәлтәсе?

— Кысылма! — дип, апам усал гына итеп идәнгә аяк тибеп куйды.

Мин бөрешеп үк килдем, суга дип торам, олылар сөйләшкәндә кысылуым өчен апам бер дә башымнан сыйпап тормый иде.

— Белмим инде, белмим, — дип гажизанә басып торды ул.

— Миңа костюм да кирәкми, шушы халатны капларлык бер җиңелрәк пәлтәң булса...

— Булмый инде, булмый алай гына, — диде Шәмсенур апа, кулларын алъяпкыч астына тыгып, почмактагы фанер чыралары купкалаган иске шкафка озак кына карап торды.

Мин беләм, Шәмсенур апа бераз шикләнә дә булса кирәк. Сугыш елы бит, ничек ышанмак кирәк кешегә? Бервакыт, сугыш беткәннән соң, жизни кайтып керер. «Кая китте минем киемнәр?» — дип сорар. Ничек дип җавап бирер апам?

Әнә ул кулын изәп куйгандай булды.

— Энем, әйдә өстеңне сал, — диде, Ранен абыйны кызарган плитәле

мичебез янына алып килде. Шуннан соң бер дә сөйләп бетерә алмаслык тамашалар булды. Апам жылы суга сөлгене манып сыга-сыга Ранен абыйның аркасын, күкрәген ышкыды, муенын сөртте. Юу эшен бетергәч:

— Әйдә, башмагыңны да сал, — дип тагаракка жылы су койды. — Бер кулың исән әле, тәпиеңне үзең ю, — диде.

Күп тә үтмәде, Ранен абый эчәдән-җептән киенеп куйды. Гипслы кулын жин эченә кертүе кыенрак булды булуын.

Инде киенеп беткәч, Шамсенур апа аңа читтәнрәк карап торды да, кинәт сыгылып төшеп, башын Ранен абыйның иңенә китереп салды:

— Газизем, бәгырем, кайларда син? — дип үксеп елап җибәрде.

Сеңелләрем дә, ана кушылырга дип, авызларын җәя башлаганнар иде, Шәмсенур апа идәнгә бер генә типте, тегеләр шундук тындылар.

Ранен абый, рәхмәтләр яудырып, ишектән чыгып китте. Минем колагыма хәтта ишегалдында кар шыгырдаган сыман булды. Жизнинең ак салган табан кырыйлары сары күн белән капланган, шулай ук үкчәсенә дә йөрәксыман күннән тегелгән ак фетры гына ап-ак карны шулай матур итеп шыгырдата ала иде.

Китте Ранен абый театрга. Бәлкем театрга гына да түгелдер әле...

Шулай итеп, бу Ранен абый аша, озын толымлы, зифа буйлы һәм нурлы йөзендә йолдыз сымак миңе булган әлеге чибәр апа янәдән да минем күңелемдә калкып чыкты. Әлбәттә сугышның хәсрәтле көннәре аны оныттырып та тордылар, дөресендә ул, хыял күгемдә матур итеп калыккан жиреннән болытлы көннәрдәге кебек, бөтенләйгә сүнгән дә булыр иде. Ләкин кайвакыт бала күңеленә бәләкәй генә нәрсә дә житә бит һәм андый чакта, очкын килеп төшкәндәй, хыялларың янә дә кабынып дөрләп китә торган була.

Әтием дә, жизнәм дә чалбарларын кигән яки салган чагында идәнгә көмеш акчалар коела торган иде. Әлбәттә, алар җыеп алына. Ләкин ярыклардан азмы төшкән дисең алары идән астына. Кайвакыт ул көмешләрне пычак белән азапланып та алып булмый.

Инде әти дә, жизни дә фронтта. Акчаны һич житкереп булмый. Аптыраганнан идән астын актарырга тотынасың. Анда, ник борчыйсың дигәндәй, озын мыекларын кыймылдатып, як-якка кара тараканнар чабышып китәләр. Күгәреп беткән тузаннан, киезләнгән йон ише нәрсәдән әллә нинди ачы исләр борынны ярып керә. Ниһаять, актара торгач бер тимер нәрсә ялтырап китә һәм синең йөрәгең дерт итеп сикереп куя. Озак мәшәләнә торгач, ике пычак очы белән кыстырып бер егерме тиенлекне тартып чыгарасың. Егерме тиен зур байлык түгел түгелен, ләкин аңа өстәп тагын берәрсен сосып чыгарсаң, каләм ише нәрсәләргә бик ярап куя.

Ә бервакыт мин анда төсле борчакларны күреп бөтенләй тынсыз калдым. Караңгылыкта акча, зөбәрҗәт һәм якут ташлары кебек үзалларына нурланып яталар. Ничек чыгарыйм икән дип уйланудан гына да тәмам тирләп чыктым. Пычак белән кысып алып булмас. Саксыз кылансаң, атылырлар да китәрләр тараканнар янына. Аларның кадерен беләмени ул мыекбайлар.

Уйлый торгач, мин моның әмәлен таптым. Бакыр чыбыкның бер башын бөгеп уенчык чүмеч кебек алкаландырдым да, шуңа теге борчакларны көрәп кертеп, берәм-берәм суырып чыгардым.

Менә аларның өчесе дә хәзер минем кулымда. Уч төбемә һәрберсенең яшькелт-зәңгәрсу, ялкын кебек сары һәм кызыл шәүләләре төшкән, ул шәүләләр учымны гына түгел, минем бөтен тәнемне, хәтта күңелемне дә рәхәт кенә жылыталар, изрәтәләр сыман. Ул да түгел, кардай ап-ак муендагы барлык мәрҗәннәр тезмәсе күз алдыма килә. Туктале, бу Мәчтүрә апа сөйләгән Зөһрә кыз муенындагы мәрҗәннәр тезмәсе дә түгелме соң? Ни өчен

әле ул Кабан күленең якты шәме булган айга менеп киткән, безнең кебек, һич югы адашы — артистка апа кебек җирдә генә яшәргә ярамады микәнни соң аңа? Юк, ул айга менмәгән булырга тиеш. Алайса кая киткәнме? Соң үзе елгалап түккән күз яшенә кереп эрегән булырга тиеш ул. Шуңа күрә дә миңа Кабан күле җанлы булып тоела да. Күлнең бер күпердән икенче күпергәчә өлеше аның кайгыдан агарган көмеш чәчләренә уралган матур ак муены булырга тиеш, ә гәүдәсе Ерак Кабаннарга хәтле сузылып киткәндер, хәтта чак кына күпертмә тезле бик килешле аякларын ул ерактагы Иделгә үк чыгарып, билле-билле аякларын агымсуда кытыклаттырып чайкалдырып ятадыр. Соң алайса әлеге яшелле-кызыллы-сарылы мәрҗәннәре кайда? Мин ул мәрҗәннәр турында чак кына уйланып торам. Безнең тәрәзәбез күл ягына карамый, ишегалды ягында. Иртәнге сәгатьләрдә ишегалды күләгәсе, ачык тәрәзәләрдән, челтәр пәрдәләрне җилфердәтеп, саф һава агымы керә. Мин җылы түшәктә киерелгәләп ятам да, башымны күтәрә төшеп түбәндәге утын сарайлары, күрше йортның җимеш бакчасы аша, чираты буенча бездән өченче булган биек йортның стенасына күз салам. Ул минем өчен һава торышының күрсәткече булып хезмәт итә. Әгәр көн сүрән икән, стенаның да әллә ни чырае булмый. Әгәр көн аяз икән, биек ак йортның стенасы яктырып тора. Менә шул якты мине ниндидер эчке сере белән тышка куып чыгара. Мин күл буена атылам.

Ходаем, менә кайда ул яктылык дөньясы. Су өстендәге алтын тәңкәләрне күрсәгез икән! Аз гына карап торсагыз да, күзләрне камаштыра. Әлегә күгелҗем күккә күтәрелеп өлгермәгән кояш үзе әллә ни белми дә шикелле, калай савытта эреп барган сары май кисәге кебек ул. Аның каравы аргы яктагы кызыл чиркәүнең эреле-ваклы гөмбәзләренә карарлык түгел, алардан яп-якты көмеш нурлар чагыла. Мин ирексездән күзләремне кысам. Ләкин барыбер күз алдымда нурлар биешә. Шуннан мин, бабайлар кебек, кулымны каш өстенә куям һәм берәм-берәм күл тирәләрен күзләргә керешәм.

Әнә, чылтыр-чылтыр килеп, Болак күпере аша трамвай узып бара. Аннан ерактa, яшькелт тау өстендә, миләш тәлгәше кебек, төзелә башлаган зур бинаның кызгылт кирпечләре күренә — аны опера театры булачак диләр. Аның уң як күршесендә, якындарак, борынгы крепостьларны хәтерләтеп, шулай ук бик зур бер кызыл йорт күтәрелеп килә — монысын акча санарга өйрәтә торган финанс институты булыр диләр. Тагы да уңдарак, үзе үк биек кыя сымак булып, Шамский больницасы калкып тора. Ләкин бу — аръякның күккә ашкан иң зур биеклеге. Шуннан ул түбәнәя бара. Тау битендә каракучкыл яшеллеккә күмелеп агач йортлар тезелеп утыра. Ул йортлар су буенда да бик күп, ләкин алар хәзергә зәңгәр томан эчендә әле. Менә шул зәңгәр томан эченнән кинәт кенә күк көймәсенә бер сары ук атыла — монысы күлнең өстенә ишелә язып утырган мәчет. Шуннан соң күл буе йортларының теземе кинәт өзелгән кебек була — анда Сорочий базары артында сазлык җәелеп ята. Әнә, өзеклек күршесендә, гүяки урман эчендә, Ботан бакчасы. Кабанның ерак күпере артында, дамба өстеннән яшел вагоннарын тезеп поезд үтеп бара. Ул соңрак минем үземне дә, хыялларымны да кабат-кабат Арча якларына алып китәчәк әле, хәзергә әле бераз сабыр итеп торыйк. Күлнең бу ягында, уң кулдарак, Вахитов заводының моржасыннан соргылт төтен чыгып тора, шунда ук, суның нәкъ читендә, салпы таллар башларын иеп утыралар. Ә таллардан соң... Таллардан соң бетте инде. Хәер, үзебезнең усак-тирәкләре бар икән әле. Алар безнең каршыда гына, зур-зур тәпиләрен күл суында юдыртып, шаулый-шаулый утыралар. Мин аларны гигант гөсләләрнең кылларына охшатам. Җил тиеп киткән саен, алар үзләренең серле музыкаларын уйныйлар сымак. Без алдарак бу көйләрнең кайберләрен ишетербез дә әле.

Менә шулай, битемне-кулымны юып та тормыйча, мин үзебезнең Кабаныбыз белән күрешә торган идем. Аның тирә-як читләре нәкъ менә Зөһрә мәрҗәннәре кебек, аллы-гөлле төсләр белән, минем бала күнелемне балкыта иде. Алар миндә бала чагымның хыяллары булып мәңгегә сакланып калдылар. Безнең бала чакта, бетмәс-төкәнмәс уеннар арасында хәзерге төсле телевизорны алыштыра торган бер уеныбыз бар иде. Кәгазьне бөкләштереп учыбыз хәтле генә дүрт почмаклы тартма ясыйбыз. Аның бер чаты тишек була. Без төрле төстәге кәгазьләрне турап шул тишектән салабыз да, ана шулай ук кәгазьдән төрелгән көпшә тыгабыз. Көпшә аша тартма эченә күз салсаң, нәрсәләр генә күреп бетермисең — ул дию пәриләре, ул пәһлеван батырлар, ул җир өсте һәм җир асты патшалыклары! Тартманны әйләндерә торасың, янадан-яна әкият дөньяларын күрә торасың.

Без, юеш борынлы малай-салайлар, сугышка хәтле әнә шундый аллы-гөлле дөньяда яшәп килдек. Шуңа күрә дә әлеге мәрҗәннәр белән мавыгып китүем өчен укучылар мине гафу итсен. Аларның һәр бөртеге — безнең рәхәт балачагыбызның дөньясы. Дингез тозын беләсезме сез? Табигать аны ачы да, тозлы да дингез суыннан ясый. Алар кайчак су читендәге тәти ташлар арасында, кояш нурын беленер-беленмәс кенә шәүләләндереп, тоныкк кына ялтырап яталар. Алар мина күз яшьләре, хәсрәт тамчылары булып күренә.

Безнең балачагыбызның аллы-гөлле мәрҗәннәре арасына әле сугышка хәтле үк ачы, тозлы йомры ташчыклары тезелә башлаган иде инде. Дөрес, алар берән-сәрән генә күренделәр, ә сугыш башлангач...

Юк, әле минем һаман сугышны якынайтасым килми. Аннары мин сезне үзебез белән, әнә шул балалар патшалыгы белән рәтләп таныштырмадым да бит әле. Мәрҗәннәр тезмәсен тоташтырып бәйләп куйган төен безнең йортыбыз ул, безнең ишегалдыбыз. Кабан күленең биегәеп торган көнбатыш ярында ак таштан корылган уникенче мәктәп бар. Дөрес булса, аны Петр патша заманыннан ук калган мамык фабрикасы ихатасына салганнар. Фабриканың янганын мин дә хәтерлим әле, мина ул вакыт дүрт-биш яшьләр булгандыр. Төнлә белән урамның икенче ягында торган безнең йортка да кызыл буран кебек чаткылар сибелде, ялкын бөркелде. Әлбәттә, безнең йортта яшәүчеләр һәммәсе качып беткән, бары җиз каскалы пожарниклар гына түбәгә һәм урам як стенасына өзлексез су сиптерәләр иде.

Асты кирпеч, өсте шыңгырдап торган сагызлы нарат бүрәнәле йортыбызга ут ничек эленми калгандыр. Зәйнәп карчык аны: «Ходай саклаган, Ходай», — дип искә төшерә торган иде. Ә мин аны бала вакытындагы фантазиямне кушып болай аңлатыр идем: безнең йорт гап-гади материал — агач белән кызыл кирпечтән салынган булса да, бик зур зәвык белән салынган. Мин әле аның матур кашагалы, йөзлекләренә әллә нинди әкәми сырлар төшеп беткән биек-биек тәрәзәләрен әйтеп тә тормыйм, андый тәрәзәләр күл буеның бүтән йортларында да бар. Ә менә йорт чатының өске катыннан кинәт кенә тышка чыгып торган, манарадай һавага омтылган балкон беркайда юк. Ераккарак китеп, бу очлы түбәле, өстәвенә шпильле манарага, әле уң күземне, әле сул күземне йомып карыйм да, йортыбызны дингез буеннан чайкалып барган тылсымлы бер карабка охшатам. Ә кайвакыт ул муенын һавага сузган, бик күп акыллы күзләре булган бер хайванга охшап китә сымак.

Юк шул, Зәйнәп апай бәгърем, аны саклаучы Ходай булмагандыр шул. Күл буеның кашка бизәге булган йортыбызны беләсеңме кем саклап калган? Зөһрә-кыз саклап калган аны, беләсең килсә! Ул пожарникларга булышкан, күл суын аларга мул итеп биргән. Ул күл буеның яме бозылуын бер дә теләмәгән...

Көннәр җылынып, җир өстенә хәтфәдәй чирәм җәелгәч, без котырынып уйный торган идек. Түбәбездә, күк йөзендә, чыр-чу килеп карлыгачлар куышса, ишегалдында разбой салып без бөтерелешәбез. Шулкадәр тавышка ничек безнең колак пәрдәләребез ярылмаган, ничек безнең тамакларыбыз исән калган! Мөгаен, олы кешеләргә, бу шау-шуны ишетмәс өчен, колакларына мамык тыгарга, аның да өстенә башка шәл бәйләп йөрергә кирәк булгандыр.

Иң элек урамга чыкмыйча гына өй эчендә уйный торган уеннардан башлыйк. Әти-әниләр эштә булып эчең пошып китсә, шундук күңел ачырлык бер-ике иптәшеңне чакырып кертәсең. Бишташ уены күзеңне дә елтыр-елтыр йөртерлек, бармагыңны да житез хәрәкәтләндерерлек нәкъ менә шундый тыныч, вакытны сиздерми генә үткәрерлек уен иде. Әлбәттә бишташны безнең ярыклы идәндә уйнап булмый, шуңа күрә без аны күп очракта әле мин әйтеп үткән балконлы квартирга кереп уйный торган идек. Бу әүвәле бай абзыйның җәйге кунак бүлмәсе булган булса кирәк, алар балконда да Кабан күле манзарасына күз салгалап, өф-өф өреп чәй эчеп утырганнардыр.

Бүлмәнең идәне шоп-шома паркет. Чуар ташны саксызрак чиртеп җибәрсәң, аның карават астына әллә кайларга кереп югалуы мөмкин. Аннары аны караңгыда мүкәли-мүкәли эзләп йөрергә туры килә.

Күп вакыт мин Нурия исемле кыз, Гадыйль исемле малай белән уйныйм. Алар шушы квартирада яшәүче Мәрьям апаның абыйлы-сеңелле балалары. Аларның этиләре юк, гомерләрен монсу гына үткәрәләр, ләкин гади генә яшәсәләр дә, заманына күрә мәдәниятле генә гаилә иде бу. Мәсәлән, Мәрьям апа балаларны җыеп китаплар укый. Бервакыт хәтта, безне көлдерә-көлдерә, «Фәтхулла хәзрәт»не дә укыган иде.

Аннары карават турысында, сап-сары итеп юылган бүрәнә стенадан якты бүлмәгә (чөнки балкон да булу өстенә янә берничә биек тәрәзә бар иде) алтын путалы ике картина да карап тора. Аның мин берсен хәтерләмим инде. Әмма икенчесендә кызгылтланып җирләр ачыла башлаган, күл-күл кар сулары җыелган яз көнендә, әлегә шәрә агач очларында каргалар әйләнгәли. Нишләптер алар миңа үзебезнең яр астындагы тирәкләргә оялаган карга илен хәтерләтәләр һәм үзләренең авазлары белән квартираның монсу тынлыгын бозалар кебек. Соргылтка якын кара чәчле, кара чутыр Нурия миннән бер генә яшькә олы булса, аның абыйсы өч-дүрт яшькә олы һәм мин аңа гаҗәп каты чәчле, алсу чырайлы һәм тулы тәнле малайга, Гадыйль дип кенә дәшәм, бәлкем «Гадел»не бозып шулай әйтә торган булганмындыр.

Мәрьям апаның ирсезлеге өстенә, тагын бер кайгысы бар, аның кызын көзән җыера иде. Дөресендә, аякларын көзән тота иде. Өянәге килә башлау белән, Мәрьям апа аның балтырларын, тубыкларын ышкырга керешә. Үзе өйдә югында кирәк була калса дип, ул мине дә ялтырап торган кара туткыллы бу аякларны кулым белән тиз генә ышкый башларга өйрәткән иде. Һәм мин, беркем дә өйдә юк чагында Нурия андый-мондый авырып китсә, йомшак учларым белән шул мизгелдә үк аның аякларын уарга керешә идем.

Менә без, табаннарыбызны табанга терәп диярлек, идәнгә утырганбыз да, бишташлы уйныйбыз. Учыбыздагы чуерларны чиратлашып идәнгә чәчеп җибәрәбез. Ташларны чамалап чәчергә кирәк, бер-берсеннән ерак килеп төшәрлек булмасын. Максат — бер ташны чиртеп җибәреп икенчесенә тигезү. Менә мин, кунак кеше, ташларны беренче булып чәчеп җибәрәм. Тырнагым белән чиртеп, бер ташны тигезеп алам, икенчесен. Ләкин өченчесенә тигезә алмыйм, чирткән ташым, бөтерчек кебек әйләнгәләп,

тигезергә тиешле таш янынннан узып китә. Ах, булмады. Чират хәзер Нурияныеке. Менә ташлары күнелле генә тәгәрәшеп сузылган аякларыбыз арасына таралалар. Чылт иткән тавыш ишетелә — эләкте. Тагын чылт итә — тагын тиде. Бары бишенчесе генә, аны тыңламыйча, кытыклый-кытыклый, минем тез астыма килеп керә. Нурия моңа бер дә борчылмый: «Сиңа кунакка китте ул!» — ди. Чират минеке. Мин сабырсызланып, кулымны артыграк селтәп, ташларымны бик еракка таратам. Юк, беренчесе дә тимәде. Минем ачуым килә. Ә Нурия: «Кара никадәр таш миңа кунакка килде!» — ди һәм пырх итеп көлә. Ул минем кебек кабаланмый, ташларны өстән аска бик оста төшерә. Тегеләре дә, аның нәфис магнитлы бармакларыннан бик ерак китәсе килмәгән кебек, бер күчкәрәк җыелалар. Ул аларның һәммәсен дә отып ала. Отып алгач, нәүбәт янә дә аныкы. Миңа күземне тасрайтып утырырга гына кала. Ул тагын тарата һәм бишенче ташны «ялгыш кына» тигезли. Мин дә, таратканнан соң бишенче ташка житәм. Хәзер инде табанны табанга тигезеп кенә чиртеп булмый. Мин мышный-мышный дүрт аякланам. Авыздан телем дә чыккан булырга тиеш әлбәттә. Юк, тагы да иелә төшәргә, ятып төзәргә кирәк. Чиртәм һәм ташны почмакка очырам. Нуриянең күзеннән шаян очкыннар чәчелгән кебек була, ә минекеннән яшьләр атылып чыгарга житешә. Мин, уйнамаска теләгәндәй, үпкәлим. Нурия мине төрлечә юата. «Әйдә сиңа булышам», — ди. Һәм бер уенда бишенче ташны минем өчен чиртә. Тигезли каламы соң! Минем үз ташым кебек үк тоелмаса да, барыбер миңа күнелле. Ә иң соңыннан ул миңа бөтенләй оттыра. Без икебез дә шатланышабыз, кычкырып көләбез. Аннары уеннан туеп балконга чыгабыз. Түбәнәеп барган кояш инде аргы якның тәрәзәләренә кызыл утларын кабындырган. Ерактагы таллар көне буе кояш кызуында сәлперәешеп утырганнан соң сыннарын турайта төшкән кебек күренәләр, алар инде хәзер яфраклары белән салкынча дымны эчәләр. Әнә урмандай утырган ботан бакчасы артыннан Арча тарафыннан кайтып килүче поезд күренде, ул да юлда шаянланып арган булса кирәк, бик ашыкмый, вагоннары чайкала, ә араларындагы чуен тәлинкәләре ара-тирә ыңгырашып куя.

Бу нинди тонык тавыш әле, әллә каян җир астыннан килгән кебек: «Тук!», «Тук!» Менә дөбердәгән кебек тә булып китте. Әллә күк читендәге әнә теге болытлар буш мичкә тәгәрәтәме? Шул вакыт Нурия: «Тиз, балконнан чык, әни кайтты!» — дип мине кулымнан тотып бүлмәгә алып керә. Әнисе безне балконга чыгудан тыя, егылып төшәрбез дип курка. Нурия, авырткалый торган аякларын да онытып, ишеккә йөгереп китә, шалт итеп келәне ача. Бусагада башына яулык бәйләгән, аз гына күләгәләнеп торган ач яңаклы, юка гәүдәле хатын күренә. Бу — Мәрьям апа.

Кыш аеның озын кичләрен кыскарта торган күз бәйләш уены да ошый иде безгә. Монысын инде дүрт-биш кешесез дә уйнап булмый. Аннары бүлмәнең иркенрәк булуы хәерле. Шунлыктан без коридор каршысындагы Ринат дуска җыенабыз. Нурия, мин, Ринат һәм, керсәләр, аларның уң як күршесе абыйлы-энеле Илдус белән Илгизәр. Хәер, мин Гадыйльне онытканмын бит әле. Гадыйль белән Илгизәр икесе дә бездән өч-дүрт яшькә олырак, ә калганнарыбызның аермасы бер яшькә генә иде. Бер аягына чак кына чатанлап йөргән чем-кара чәчле Ринат дустымны сез беләсез инде. Илдус саргылт чәчле, аксыл маңгаенда сары кашы чак-чак беленгән юаш малай. Юаштан бигрәк астыртын кебегрәк иде ул. Бу мәсьәләдә абыйсы да ким түгел, өстәвенә уен вакытында кәҗә шикелле теләсәң каян сикереп чыгарлык чая һәм төлке кебек хәйләкәр иде. Төлке дигәннән, аның бите дә, бу шук җанварныкы төсле, кыскарак ияге белән кинәт кенә очлаеп бетә. Аның гәүдәсенең дә һәр әгъзасы чатлы-ботлырак

иде кебек. Ә Гадыйльнең — тупыйграк тулы гәүдәле, карасу-каты чәчле икәнлеген әйткән идем инде.

Ләкин Гадыйль дә, Илгизәр дә безнең белән сирәгрәк уйныйлар, ни дисәң дә, яшь аермасы үзенекен итә. Абыйсыннан башка мыштым Илдуснын да безнең белән әллә ни уйныйсы килми. Менә шундый вакытта инде, без теләр-теләмәс кенә, коридорның аргы башында ук утрау кебек аерылып калган Хәкимнәрне кертәбез. Бу җирәнбашлар көне буе өй саклыйлар, әтиләре аларга беркая аяк атларга кушмый, хәтта хәҗәтләрен дә өйдә генә үтиләр иде. Ә кичләрен алар читлектән ычкынган җәнлекләргә охшап калалар, бөтен йортны, ишегалдын бетереп чабалар, әйтерсең лә дөньяны ялкын өереп йөри.

Күз бәйләшне уйнарга керсәләр, Ринатың әнисе Ниса апа, карават башына бәйләгән көнҗәләдән җеп җегерләп утырса да, бер дә алардан күзен ычкындырмый: «Әй, җен балалары!» — дип тыеп кына тора. Ләкин күз бәйләш уены вакытында кайсыбызны тыя аласың да, кайсыбызны җинә аласың.

Менә тастымал беләнме, киң шарф беләнме Нуриянең коңгырт түгәрәк күзләрен бәйләп куябыз. Бер-ике мәртәбә үзен баскан урынында әйләндерәбез дә читкә чарпалабыз. Нурия башы әйләнгәндәй аз гына чайкалып тора да сукыр кеше кебек ике кулын алга сузып безне эзли китә. Ул безне тотам дигәндә генә, без елт кына аңардан тайпылабыз һәм, качып котыла алуыбыз өчен, пырх-пырх көлешәбез. Ә Нурия, безне тотам дип, йә идән уртасындагы өстәлгә килеп бәрелә, йә куллары белән караваттагы мендәрләрне сөзеп аударып төшерә. Нуриягә берсенең дә тоттырасы килми, ул озак бөтерелгәләп йөри, ниһаять, кызгана төшеп, мин ана үземне тоттырам.

Менә минем дә күземне кысып бәйлиләр, хәтта кашларым шытырдап киткәндәй була. Мин уңга-сулга атылып эзләргә керешәм. Кинәт туктап тыңланып торам. Әнә тешләрен ыржайтып Хәким көлә, ул хәтта, аяк очларына гына басып, янына ук килә дә аркадан төртеп куя, мин сыек гәүдәм белән чайкалып чак кына егылып китмим һәм моның белән иптәшләремне шатландырам. Берсендә, шул ук Хәкимне тотып алам дип, комод янына куелган түгәрәк аркалы җиңел эскәмияне аударып җибәрдем. Бу венский эскәмияне комотны сакларга куялар, бу тирәгә килергә ярамый дигәнне аңлата ул, чөнки комод өстендә өч бүлемле көзге бар.

Ниһаять, мин күз караңгысына да, тирә-юнь әйберләргә дә ияләшеп җитәм, көтмәгәндә өстәл астына сузылып теге җирән башларның иң кечесен — Зәйтүнәне аягыннан тырылдатып тартып чыгарам. Ләкин ул уеныбыз өчен бик файдалы түгел, чөнки арабызда ул иң кечкенә кыз. Күзен бәйләсәң дә, баскан җиреннән кузгалырга куркып, тик тора. Ләкин апасы Әлфия, үзен тоттырып, аны бик тиз алыштыра. Менә без өстәл тирәли тыз-быз йөгерешәбез, шуып кына өстәл астыннан да чыгып китәбез, почмакларга, хәтта карават астына да посынып, эчебездән тынабыз, чөнки Әлфия бик сизгер, авызынны ачып торсаң, кармак кебек бармаклары белән хәзер үк каптырып алыр. Бер мәртәбә, өстәл тирәли яшь колыннар кебек чабышып йөргәндә, Хәким, ялгыш кына кыланган кебек, Ринатны инә белән апасына таба этеп җибәрде, тегесе аны капшагыч куллары белән кочаклап та алды.

Чатанлый-чатанлый өстәл тирәли Ринат йөгерә. Ул үз өен бик яхшы белә, аягына аксаса да безне пыр туздырып йөри. Ринатның безне тотасы килми, тотса да исемебезне юри дөрес әйтми. Ә дөрес әйтмәгәч янадан көтә башлыйсың. Ниһаять ул, үзенең каршына безне берәм-берәм этеп җибәреп, караватка ук сикереп менгән Хәкимне тотып ала.

Хәким — зур балык. Аның җәтмәгә килеп керүенә без һәммәбез дә шатланышып тыпырдашабыз. Ләкин Хәким бик хәрәмләнеп уйный. Ул күзен бәйләткән чагында ук, ничектер маңгаен киереп, кашларын аска-өскә йөрткәләп, шарфның кысуын киметә. Ниса апа моны бик тиз күреп ала: «Каяле, үзем бәйлим әле», — дип, шарфны арттан шактый тыгыз итеп төенли.

Ләкин Хәкимне алдап буламы соң. Ул безне өермә кебек куып йөрткәндә башын артка ташлап-ташлап ала. Алай иткәндә тымызык кына яктыны, селкенгән шәүләләрне чамалап була. Ул куа, без йөгерәбез. Эскәмияләр дә авып китә, өстәл дә урыныннан куба. Караватның измәсен изәбез. Ләкин Хәким торган саен нахаллана. Башын артка ташлап утның кайда, шәүләләрнең кайда икәнен чамалавы гына җитмәгән, безне кычкыртып куып йөргән вакытында ул, шарфны җәлт кенә кулы белән сыдырып, маңгай ягынарак күтәреп тә куя. Әлбәттә, кызарган йомры бите белән шарф арасындагы ярыктан ул безне бик тиз күрә һәм кабарынкы симез кулы белән берәребезне эләктереп тә ала.

Бу кызык уенның азагы күңелсез беткән очраклары да булгалады. Бервакыт шулай, Ринат көткән чагында, Ниса апа уяулыгын югалтып җибәрде булса кирәк. Ринат ялан аягын идәнгә баса сымаграк шап-шоп салып өстәл тирәли безне куып йөргәндә, Ниса апаның болай да кысылгалап торган күзләре туктаусыз йомыла башлады. Керфекләрен гел менә челт-мелт кагып тора. Аннары ул караватт башындагы йон бәйләменә янагын куеп уйланып торды. Керфекләре бу юлы тибрәнми иде инде. Без нәкъ менә шул чакта артык узынып киттек ахрысы. Бер заман дыңгырдап идәнгә көзге килеп төште. Хәзер инде тәгаенен генә хәтерләмим: минеме, Нуриянеме теге ташбаш комодка таба этеп җибәргән иде. Комод әлбәттә яңа түгел, ул Сорочийдан арзан бәягә генә алынган, бер төшкән аягы урынына шакмак кына кыстырып куелган иде. Инде, өерелешеп тузан очыртып йөргән бер мизгелдә, бу шакмак аяк бер читкә атылган, комод кыегайган, өч бүлемле көзге идәнгә капланган иде.

— Таһир төшерде! — дип Хәким шундук буынтык-буынтык симез бармагын миңа төртте.

— Ул! — дип апасы да чәчрәп чыкты.

— Абый түгел, апа түгел! — дип, бәләкәй Зәйтүнәләренә хәтле тәтелдәп алды.

Мине бары Нурия генә яклап чыгып:

— Хәрәмче! Янгаллама! Син төртеп җибәрдең бит, син! — дип, Хәкимнең өстенә килә башлаган иде, тегесе:

— Нәрсә яклыйсың чебешенне! (Минем кушаматым шундый иде) Аягыңны уган өченме?!. — дип эре тешләрен агартып көлде дә өйдән чыгып сызды. Апасы белән сеңлесе дә шундук юк булдылар.

Ниса апа:

— Ах, җен балалары, ах, көзгемне харап иттеләр бит! — дип аны идәннән күтәреп алганда, чынлап та аңа кыйгачланып сызык сызылган, көзге чатнаган иде.

Ул вакытта зур көзгеләр һәрбер өйдә юк, күрәсең аз да, аннары кыйммәт тә сатылгандыр. Мин, мәсәлән, үзенә алмаш таба алмыйча, ялтыравыгы шадра-шадра кубып беткән арты кара фанер терәүле, бәләкәй китап хәтле генә иске көзгебезне хәтерлим.

Шунлыктан булса кирәк, әлеге көзге хәбәре бөтен йортка ишетелде, начарга юраучылары да табылды. Көзге ватылгач, имеш, кемнеңдер күзе сүнә, ягъни ул гүр иясе була.

Без һәммәбез дә бер атналап шомланып йөрдек. Ләкин атналар үтте,

айлар үтте, йортта үлем-төшем күренмәде. Бары сәрхуш Минһаҗ абыйның подвал базына егылып төшүен генә уен-көлке итеп сөйләп алдылар. Безнең ишегалдына карап торган ике тәрәзә турысында, аскы каттан да астарак озынча шакмак итеп казылган чокыр бар. Подвалда Хәят апалар яшиләр, әллә ни зур булмаган тәрәзәләре әлеге чокырның кирпеч белән эчләнгән стенасына карый, әлбәттә өстәп саран гына яктылык та төшә. Тагын шул: бу чокыр, саклык өчен, җир тигезлегендә агач борыслар белән киртәләнеп алынган.

Ләкин Минһаҗ абзый бик үк сакланып тормаган шул, арткы капка астыннан үрмәләп кенә кереп, шушы чокыр яныннан узганда, подвалдагы утны үзләренең караңгы бүлмәсендәге ут дип белепме, авыр аягын чак-чак кына күтәреп, «үз бусагасыннан» атлап чокыр төбенә килеп төшкән. Ярый әле сынган киртәгә тотынып калган, үзенә әллә ни зыян китермәгән, шулай ук тәрәзәләрне дә ватмаган. Әнә шул ватылмаган тәрәзәне ачып, Минһаҗ абзыйны өйгә генә алып керәсе һәм баскычтан менгезеп кенә чыгарасы иде дә бит. Ләкин Хәят апа әле яз башланып кына килгән салкын көннәрдә тәрәзәне ачамы соң. «Ничек төшкән булса, шулай чыксын, үләт себеркесе!» — дип жикеренде ул өстән иренә. Минһаҗ абзыйны биш-алты ир-ат каеш дилбегә белән тартып чыгардылар. Чатнаган көзге онытылды. Күз бәйләш уены тагын дәвам итте. Ләкин без теге җирәнбашларны өебезгә бүтән кертми идек инде. Хәрәмчеләрне яратмый идек без.

Ике сафка тезелеп кара-каршы җыр әйтешкән күмәк уен да безнең яраткан уеннарыбыздан берсе иде. Кечкенәрәк чагыма туры килгәнгәме, бу уен җырының беренче куплетларын хәтерләмим, ләкин ахыры болай бетә иде:

Ак кирәк, күк кирәк,
Фәлән матур кыз кирәк.

Димәк, балалар житәкләшеп, ун-унбиш адым ара калдырып, кара-каршы басалар. Рәткә тезелгән балалар, каршы якка карап, көй уңаена житәкләшкән кулларын да алга-артка чайкаштырып, әле мин оныткан җырны җырлыйлар һәм каршы яктагы малаймы, кызгамы атап аны үз якларына дәшәләр:

Ак кирәк, күк кирәк,
Әлфия — матур кыз кирәк!..

Әлфия, җирән чәчләрен ялкын кебек туздырып уктай әлеге сафка каршы йөгереп китә. Әгәр ул әлеге сафны өзеп чыга алса, җиңелгән иптәшләренең күнелгә ошаган берәрсен әсир итеп үз сафына алып китә. Әгәр житәкләшкән кулларны йөгереп килгән шәпкә аера алмаса, ул үзе бу сафта кала. Җиңдермәгән саф хәзер инде үзе җырлау хокукын ала һәм ишегалдын тутырып малайлар-кызларның яңгыравык авазы ишетелә:

Ак кирәк, күк кирәк...
Таһир — матур егет кирәк!

Мин җилдә очкан кош мамыгыдай йөгереп килсәм дә, сафны өзү түгел, урыннан да кузгата алмыйм, туп кебек артка атылам, ләкин мине кем дә булса егылудан тотып кала, күп очракта Нурия кулымнан чытырдатып кысып алып кала иде.

Бу бик тату уен, биредә беркем дә рәнҗетелми, йә «матур кыз», йә «матур егет» булып кала. Аннары безнең бу уеныбызны өлкәннәр дә, үзләренең

балачакларын искә төшергәндәй, бик яратып, бер-берсен уен-көлкеле сүзләр әйтешеп, тамаша кылалар иде.

«Куыш-куыш» уены безне тагын да ныграк житезләндерә торган бик елгыр уен иде. Без, кайбер урамнардагы кебек, иптәшләребезне жир өстендә куып житеп аның аркасына сугып кына уйнамыйбыз. Гомумән, бездә иптәшеңне тоту кыен. Без баскычтан каралтыларның икенче катына да тыр-р-рт-рт итеп менеп китәбез, икенче кат террассасыннан башкага чабып узып аның чатына кушылып киткән утын сарайлары түбәсенә үрмәләп төшәбез, ә түбәдән, күзебезгә ак-кара күренмичә, жиргә сикерәбез. Бу тикле маймыл кебек чабуга аякларыбыз ничек түзгәндер. Һәрхәлдә, күгәрмәгән, сыдырылмаган жиребез калмый. Шуңа күрә дә бу уенга кызлар катнашмый диярлек, бик әрсез Әлфия генә безнең белән куыш-куыш уйный, ләкин аңа әти-әнисеннән бик каты эләгә, чөнки уеннан соң, кул-аякларыбыз канавы өстенә, киемнәребез дә каян да булса умырылган була иде. «Бу кадәр ирдәүкә булырсың икән!» — дип, юка иреннәрен кыса-кыса орыша иде Әлфияне әнисе. Ә инде Хәким бөтенләй узынып киткән чакларында әтисе аның колагын шытырдатып бора торган иде. Шунысы да мәгълүм булсын: Хәким тәнгә йомры һәм көпшәгрәк булса да, аны житезлектә беребез дә уздыра алмый иде.

Үзегезгә дә күренгәнчә, безнең уеннар «малай» һәм «кызларныкы»на аерыла бара. Дөрес, без малайлар да, онытылып, курчаклы һәм әти-әни булып уйнап киткәлибез, ләкин бу уеннардан без торган саен ерагая бара идек. Мәсәлән, зур ташларны тигереш уйнаганда, кызларга атланып йөреп булмый бит инде. Бу уенның хикмәте шунда: иптәшеңнең ташына да тигезергә кирәк һәм аны ераграк та атарга кирәк. Ташың сикерә-сикерә нихәтле ераграк китеп туктаса, иптәшеңнең сыртында шул хәтле ераграк атланып барасың. Хәким кебекләр белән уйнап оттырырга язмасын, ул ит капчыгын күтәрә алмый жаның чыга. Бер адым күтәреп барасың да туктыйсың, күтәреп барасың да туктыйсың. Ни тиклем генә мышкылдасаң да, барыбер алып барып житкерә алмыйча, йөген-ниен белән юл тузанына шап итеп авасың. Нинди генә әр-гарь ишетмисең, хәтта атна буена оялып өендә ятасың. Шуңа күрә без таш тигерү уенын авырлыгы минем чамада булган Ринат белән уйныйбыз, без ташларны артык еракка атмыйбыз. Мин дә аны аркамда юыртып алып барам, ул да мине, аягы авырткан ат кебек, акрынлап ташыма хәтле алып барып житкерә.

Ләкин уеннарның да патшасы, минемчә, уникe таяк уены иде. Сез үзегезнең түземегезне ничек тә булса сынаганыгыз бармы? Әллә гомумән түземсез — сабырсызмы сез? Әгәр андый булсагыз, бу уенга якын да килмәгез! Безнең бу уеныбызда йортыбызның өске кат, аскы кат, хәтта подвалдагы өченче кат малайлары да катнаша. Уен никадәр жәфа чиктерсә, шулкадәр комарлы булыр шикелле тоела, аннары уенның асылы да остарак яшеренүгә, боландай житезлеккә корылган иде бит инде ул.

Бу уен өчен бер метр чамасы такта кисәге кирәк. Жир белән такта арасына яртымы, бөтенме кирпеч кыстырыла. Тактаның бер ягы баса төшкән үлчәүне хәтерләткән озынрак башына әрдәнәләп уникe таяк өеп куясың. Ул таякларның буе безнең, ягъни балалар сөяме белән бер, бер ярым сөямнән артмый. Ярый, тактаның жиргә орынып торган башына таяклар өелде. Күтәрелеп калган икенче башын нишләтергә соң? Ул башына аягың белән китереп бассаң, тактаның икенче очындагы әлеге таяклар һавага сикерә. Жиргә таралып төшкән менә шул таякларны «көтүче» жыйган арада малайлар кайсы кая качып бетәргә тиеш. Ә качарлык урын бездә житәрлек.

Безнең йортның Сафьян урамына караган төп капкасы һәм ишегалдыннан

урап узганнан соң күл ягына килеп чыга торган арткы капкасы бар. Әгәр Сафьян ягына чыгып чатлыкка барып карасаң, анда тиз-тиз килгән бер-ике генә малайны булса да күрәсең әлбәттә. Ләкин алар синең чатлыкка чыгып иркенләп эзләвенне көтмиләр шул, күл ягы капкасы астыннан елт кына шуып керәләр дә такта янына йөгереп килеп таякларны һавага очыралар. Шуңа күрә йорт әйләнәсендәге малайларны табу өчен хәйлә дә кирәк. Сафьян ягына чыккан булып башыңны гына күрсәтәсең дә, тиз генә кире әйләнеп килеп күл ягы капкасы ягына борыласың. Анда «җәтмә»гә бер-ике «балык» эләгә инде. Капка астыннан пуфылдый-пуфылдый беленер-беленмәс саргылт кашлы Илдус кереп килә. Аның артыннан Ринатның җемелдәвек кара башы күренеп кала. Кичекмәстән такта янына кайтып: «Капка астында башта Илдусны, аннары Ринатны күрдем!» — дип тактага төртә-төртә кычкырып әйтәсең. Инде Илдус белән Ринат уеннан чыгалар, такта тирәсенә килеп бер читтәрәк йә җиргә чүмәшеп утыралар, йә утын сарайларына сөялеп басып торалар. Илдусның бите кызарган, маңгаенда бөрчек-бөрчек тирләр. Бу арткы капка астыннан корсагын җиргә кыса-кыса үрмәләп кергән өчен генә түгел. Аның эчендә ут хәзер. Чөнки, әгәр мин малайларны берәм-берәм эзләп табып аларның исемнәрен такта янына килеп әйтсәм, киләсе уенда ул көтәчәк бит, җиргә таралып төшкән таякларны җыячак, безне эзләргә керешәчәк. Ләкин миңа әле тантана итәргә иртә. Мин әле малайларның яртысын да эзләп тапмаган. Әлбәттә, йортның тышкы ягында алар калмагандыр. Ләкин ишегалдының каралтылары тирәсендә дә яшеренер урыны күп бит.

Мин сезгә ишегалды түребездә ике катлы каралты барын әйткән идем инде. Бу каралтының уң як канаты эчке якка таба бик тирән булып, аскы катында капкасы ике якка ачылмалы зур лапас, янә дә иң кырый читендә, зур ишектән кергәч, тезелеп киткән ат араннары бар. Каралтының өске катында шулай ук зур-зур ишекле ике иркен бүлмә бар. Аларда, ягъни өске коры һавада, бай абзый үзенең юртаклары өчен печәнен, сүс яки тире-яры кебек нәрсәләрне саклагандыр. Ләкин аларның сайгаклары хәзер калҗайган, өрлекләреннән купкан, туктаусыз шыгырдыйлар, кыскасы, качу өчен куркыныч та, чөнки убылып аска төшеп китүең мөмкин, аннары җайсыз да иде. Бу уен көтүчесенә файдага, чөнки качу өчен аз булса да урын кими төшә.

...Тәрәз пәрдәләрен акрын гына селкеткәләп, өйгә иртәнге саф һава керә. Мин әле йокымнан аерыла алмыйча, талгынлык эчендә рәхәт кенә изрәп ятам. Челтәрле ак пәрдә кабат лепердәп куя, тәрәзә төбеннән лып итеп төнге кунактан кайткан мәчебез сикереп төшә дә, мырр-мырр килеп муен турыма ук ята, мыеклары белән мине кытыклый башлый. Мин күземне ачып әүвәл мәчегә, аннары һава торышын күрсәткән күрше йорт стенасына карыйм: ул нур бөркегән кино экранынннан да яктырак. Димәк, көн кояшлы, димәк, берәр җиргә барырга була. Ләкин шул вакыт нык итеп сызгырып җибәрәләр. Минем кылт итеп исемә төшә, миләш капкандай авыз кырыйларым җыерыла. Теләр-теләмәс кенә торам да кулъюгыч янына киләм. Борынымны учымдагы суга тигезеп, юеш кулым белән битемне югандай итәм дә, сөлгегә төртенеп алам. Ләкин бер дә ишегалдына чыгасым килми. Апам кайнарлап биргән чәйне эчеп алгач та әле ишек тоткасына барып тотынырга кыймыйм. Ләкин ачы итеп кабат сызгырып җибәрәләр. Бу юлы инде сызгыруга янаулы тавышлар да өстәлә:

— Чык тизрәк, чыкмасаң кара аны!..

— Әйдә, чебеш, тары чүпләргә! — Монысы инде Хәким хикылдый.

Мин майлы ипиемне кабып бетерәм дә, аны тиз генә чәй белән юдыртып, ашыга-кабалана урамга чыгам. Анда һәммәсенең авызы ерылган.

— Башлыйбызмы? — диләр. Мин:

— Әһе, — дип башымны кагып куям. Подвал Рәшите үзенең аю тәпие белән каты итеп такта башына китереп баса. Һавага таяклар очып менәләр дә, эре тамчылы яңгырдай, шыбыр-шыбыр җиргә коелалар...

«Уникe таяк»ның гайрәтне чигерерлек алҗыткыч чаклары да, күңел сөендергеч рәхәт мизгелләре дә була. Ни генә димә, Хәким кебек калай әтәчләрне дә без җирдән җим чүпләттерә идек. Дөрес, ул әллә ни көтеп азапланмый, бервакыт моның серен дә әйтеп ташлаган иде.

Бездә маймы, повидломы яккан ипине тышка күтәреп чыгу гадәте бар иде. Авызыбызны тач-тач китереп бүтән малайларны да кызыктырып ашау безгә нindидер куаныч китерә иде. Бүтән малай кулында ризык-фәлән күрсәм, үземнең дә авызымнан сулар килә. Шундук ул малай янына барып: «Бераз чеилә әле?» — дисең. Ул ипиен читеннән генә сиңа каптырып ала яки бер чеметем сындырып бирә. Әлбәттә, минем үземнән күбрәк «чеиләтәләр» иде. Бер заман шулай Хәкимне яхшы гына сыйлаганнан соң, ул бер кулы белән мине җилкәләп үк алды:

— «Уникe таяк» уйнаганда син бик эзләнеп йөрмә, — диде. — Тактаң яныннан ерак китмә, эзләнгән булып кына йөр. Нишләп озак торды соң әле бу? Нишләп эзләми? — дип малайларның эчләре поша башлый. Яшеренгән җирләреннән үзләре үк сузылып карый башлыйлар. Сиңа шул гына кирәк тә. Берәм-берәм тактага исемнәрен төртәсең.

Мин, бу сүзләргә ышанмыйчарак, Хәкимнең күзләренә төбәлебрәк карадым. Юк, аның соргылт-яшел күзләре мәченекедәй майланмаган иде. Шуннан Хәким тагын бер серне ачты:

— Ни пычагыма бөтен таякны да эзлисең, җитмәсә түбәдән алып төшәсең? Кесәңдә өч-дүрт запас таяк тот. Җитми икән, кесәңнән чыгар да өстә. Вакыт янга кала.

Минем күзем шар булды. Тора-бара мин тугандаш күршеләремнең бер сүздә булуын, көтүченең кайсы якка киткәнен әйтеп, тиз генә малайларны яшеренгән урыннан дәшеп чыгаруларын белдем. Бу намуслы уен түгел иде әлбәттә. Икенче яктан, йә мин Ринатка, йә ул миңа күз ишарәсен ясаган булсак кына да, мин теге көнне төн уртасына хәтле чебеш булып тары чүпләр идеммени?

«Уникe таяк» уены миңа нихәтле генә кыен ашатмасын — мин хәзер дә аны яратып исемә төшерәм: ул мине ачуымны эчемә йотып булса да түзәргә өйрәтте, сабыр булырга өйрәтте. Шуңа күрә рәхмәт яусын сиңа, «уникe таягым!»

Кушаматларның малай чакта беркемне дә кимсетми калганы юк. Мин болай да хисчел, юкка-барга да кызарынам. Әгәр үземнең гарьләнүемне кеше алдымда тойсам, минем баш бетте инде, һич кенә дә тынычлана алмыйм. Әгәр инде, бәхетсезлегемә каршы, үземдәге кимсенү хисен бүтәннәрнең сизенүләрен дә тоеп калсам һәм алар миңа карап торсалар, минем битемә генә түгел, җаныма да ут кабына, күземнән яшьләр атылып чыга һәм мин, ул яшьләрне күрсәтмәс өчен, беләгем белән күземне каплыйм. Миңа кайсыдыр җиңел кулдан «Чебеш» дигән кушаматны таккач та, мин кая барып сугылырга белмичә йөрдем. Өстәвенә бу исемне сукыр стенабызга язып миңа мәңгегә тамгалап куйдылар.

Безнең бер стенаны иңләп алырдай мичебез арты белән коридорга чыга. Аның әүвәл вакытта шикәрдәй ап-ак чынаяклы плитәләре, бормалап-бормалап алтынланган читләре белән ярым-караңгы коридорыбызны бизәп торганын хәтерлим әле мин. Көннәрдән бер көнне управдом килеп: «Бу ни эш! Хәзер байлар заманы түгел бит инде, бу күзгә стенадан каранып йөрергә! Удар бишьеллык хәзер!» — дип шаулады, шаулады да, безгә менә дигән

советский голландка салдырырга вәгъдә итеп, әлеге чынаяк плитәләрне сүттереп алды. Управдом бу йортта яшәгән әүвәлге байны сүгә-сүгә бик каты шаулаган булса да, плитәләрне атлы арбага төяттергәндә:

— Чатный күрмәсен! Кырыйлары кителмәсен! Тырналмасын! — дип, олаучы янында биеп кенә йөрде, хәтта газета төпләменнән битләрен ерта-ерта плитәләр арасына кыстыргалады. Ап-ак керәч плитәләр дә төялеп китте, советский голландка да салынмады, коридорга балчык артын күрсәтеп, өебездә кибән хәтле урыс миче утырып торды. Менә шул балчыклы сукыр стенабыз язу тактасына әйләнде. Нәрсә генә язып бетерми иде анда малай-шалай. Ә бер көнне анда: «Таһир-чебеш» дип уеп-уеп язылган минем кушаматым да пәйда булды, өстәвенә өч бармаклы, кечкенә томшыклы, төртке күзле рәсемем дә пәйда булды. Мин аларга тырнакларым белән ташландым, калай кисәге белән кырып карадым, ләкин тирән уелган келәймәмне бетерә алмадым һәм тыела алмый еладым. Ахырда, Шәмсенур апам:

— Кайсы нәҗесе баланы хурлаган. Ну тотсаммы, кулын тапап-тапап бетерәм! — дип, әлеге сурәтләрне юеш ком белән ышкыды. Сурәтләр бетте бетүен, әмма кушаматым ябышып калды. Бары Нурия, Ринат кебек дусларым гына миңа үз исемем белән дәшәләр иде. Хәер, подвал малайлары чирәмгә чакырган чагында мине бер дә хурламыйлар, йомшак кына итеп үз исемем белән дәшәләр иде. Аларның гаилә башы Нурулла абзый үз аты белән электр станциясендә эшли, электр үткәргеч өчен урамнарга дегетле баганалар ташый, ә төптән чергән искеләрен станциягә тапшыра, утынга мохтаҗ кешеләргә дә алып кайткалый. Ләкин ул иске баганалар кыйммәт йөри, чөнки алар бик коры утын, хәтта кибеп яргаланып беткән булалар иде.

Алар атларын сугыш хезмәтенә алынганчы әлеге ике якка ачылмалы лапас түрендә тоттылар. Моңа да кушып, тагын Хәят апа ишле гаилә өчен кәҗә дә асрады. Атка фураж да кайткалый, җәйлектә печән дә хәзерләнә, кәҗәләре дә көтүгә йөри. Кәҗәне без кичке шәфәкъ вакытында, мәзәк өчен генә булса да, каршы чыгып алабыз. Тамагы туеп кайтса да, кәҗә алдыннан яшел чирәмнең кайчан артып калганы бар. Шунлыктан без, куллары кычытып торган малайлар, ана дип чирәм йолыккалыйбыз, хәтта болын чирәмен эзләп бик еракка китәбез, Ботан бакчасы каршына хәтле барып житәбез. Әле ул вакытта, хәтеремдә калганча, Казгрэссның зәһәрле сары сулары Кабан күленә агызылмый, яр буйларын пычратмый, шуңа күрә яр буеннан башланып киткән тигез яланлык зөбәрҗәт кебек балкып тора, су төбе кызыл балчык булып, халык коенган чагында бераз болганып китсә дә, сәламәтлек өчен зыянсыз ару-чиста иде.

Хәят апа: «Морожныйга, кинога ярап куяр әле», — дип көмеш ун тиенлекләр белән күзләребезне кыздыргаласа да, без ул ерак болынга аның өчен генә бармыйбыз. Без анда, бер-ике капчык үлән йолкыганнан соң, чәчкәле чирәм арасында рәхәтләнеп уйныйбыз, котырынып-котырынып бата-чума су да керәбез. Күнелләребез биниһая рәхәтлек эчендә хушлана. Ә теге көмеш ун тиенлекләр Хәят апаның үз малайларыннан да артмый. Гаиләләре бик ишле кәҗәләрен, атларын кушып санаганда ун башка житә яза иде бугай.

Минем судан курыкмаска өйрәнүем кызык кына булды. Башта мин камыш бәйләмнәре өстенә ятып кул-аягымны хәрәкәтләндерергә өйрәндем. Камышны без Иске бистә арасындагы күлләрдән алып кайта идек. Алып кайтасың да баш-башын тигез итеп кисәсең, ике кисәккә бүлеп бау белән бәйлисең. Ике бәйләм арасындагы аркылы жепләргә аркан белән дә, түшең белән дә ятарга була. Сузылып ят та аягыңны типкәлә, суны алдан этәргә тырыш, кулларың белән суны алдан ерып бар.

Шушындый күнекмәләргә өйрәнгәннән соң без бер-ике адымга булса да читкә дә киткәләдек, ләкин, кул-аякны йөртергә кирәк икәнен һәрвакыт онытып, куркуыбыздан онытып булса кирәк, бик тиз су төбенә төшә башлыйбыз һәм батмас өчен шундук чытырдап камышка ябышабыз. Камыш безнең пристань, безнең коткаручыбыз. Шулай да бу пристаньнан, үзебез дә абайламыйча, һаман саен ерагая барабыз, бер-ике адымга, аннары икеөч адымга, этләрчә хәрәкәтләнеп китәбез дә, ашыга-ашыга камыш янына кайтып ял итәбез.

Берсендә шулай ераграк китеп әйләнеп карасам, пристанем юк, мин куркудан жай гына хәрәкәтләнергә кирәк икәнен дә онытып, кулларым белән суны шап-шоп кыйнарга тотындым, ә аягым, баскан кешенеке шикелле, төпкә төшеп бара. Чәчрәгән су борыныма керә, күземне каплый, бер мәртәбә голт итеп йотып та жибәрдем. Шунда кемнеңдер ярдан кычкырганын ишеттем:

— Каушама! Тыныч кына йөз!

Мин камыш тирәсендә йөзүләремне исемә төшереп су коенудан туктадым, аягым белән арлы-бирле тибенергә тотындым, алар шундук өскә күтәрелделәр. Инде кулым да суны артка көри башлагач, күл мине күтәреп алгандай булды, йомшак кына тирбәтеп куйды. Мин авызымдагы суны төкерә-төкерә ярга таба йөзеп киттем. Алда берәүнең симез ак иннәрендә калай күгәреге кебек сипкелләре, аннары янып торган жирән башы чагылып китте. Көч-хәлгә яр буена чыгып життем дә, аяк астында яткан трусигымны алып, исерек кеше шикелле бераз чайкалып тордым, аннары трусигымны кулыма тоткан килеш кенә өйгә элдерттем. Утынлык түбәсенә мендем дә, теге трусикны киеп алганнан соң, ут кебек кызган такталар өстенә сузылып яттым...

Исәнме, Зөһрә-күл! Синең белән менә шулай чын малайларча күренүем, синең белән татулыгым мәңгелеккә булсын инде. Син мине бу юлы батырмадың бит. Рәхмәт сиңа яшькелт-зәңгәр күзле, матур муенына аллыгөлле мәржәннәр тезмәсен киеп куйган күлем! Мин хәзер сабый бала чак уеннарыннан акрынлап аерыла барам. Алардан аерылам, ә сиңа, менә бит, үзең дә күреп торасың — якыная барам. Мин хәзер моннан соң синеке! Тик син мине, артык иркәләмәсәң дә, бик үк рәнжетмә инде, балаларча шукланган чакларымда миңа ачуланма, яме?!

Мин янә кулымны каш өстемә куеп ерак су буйларын күземнән үткәрәм. Әллә кайлардагы кызыл кирпечле миләш тәлгәшләре, кыя кебек басып торган Шамский больницасы, агачларга күмелеп утырган эреле-ваклы агач йортлар, янә бөдрә урманлы Ботан бакчасы, янә дугасыннан туннеле күренеп торган чуен юл дамбасы — һәммәсе, һәммәсе зәңгәр томан эчендә селкенгәлиләр. Мин үзем дә аръяк малайларына, мөгаен, селкенеп күренәмдер, юк, күлнең зәңгәр ефәкле рәшәсеннән генә түгел. Мин чынлап та, аякларымны авыштыргалап, башымны як-якка кыңгырайткалап, еракеракларга карап торам, терекөмеш йөгерткәндәй ялтыраган су өстеннән кара төртке эзлим. Ул төрткенең миңа таба якыннан зураюын телим мин. Ләкин ул төртке зураймый, хәтта югалып кала, байтак вакыттан соң гына ялтыравык су өстенә калкып чыккандай була.

Йортыбызның аскы кирпеч катында бездән шактый олы бер малайлары булган рус гаиләсе яши. Вованың, әле мин әйткән малайның, әтисе эре-эре шадралар белән чокырланган бик зур түгәрәк битле, такыр башлы, ләкин кысыграк күзле бер кеше булып, нәкъ менә шул нурлы кыска күзләре аркасында микән, гел елмаеп тора сыман иде ул. Бу урыс безгә буржуйның нинди булуын өйрәтте. Ишелеп торган корсагын алга бүселдереп, «Менә шундый булалар алар буржуйлар», — диде. Һәм очрашкан саен ул бездән:

«Буржуйлар нинди була, ягез әле күрсәтегез?» — дип сорый. Һәм без булмаган эчләребезне көчәнеп киерә-киерә алга чыгарып күрсәткәч: «Юк, сез әлегә вак буржуйлар», — дип, кысык күзләренә хәтле генә түгел, хәтта шадраларына хәтле елмаеп шаркылдап көлеп җибәрә торган иде.

Менә шундый карсак буйлы юан абыйның малае бик нечкә билле, төз гәүдәле булуына без гаҗәпләнә идек. Вова подвал Кәрименнән чистарак һәм бик пөхтә киенеп йөри. Шикәр кебек ак күлмәк, пычактай кырлы итеп үтүкләнгән чалбар киеп чыкканын күрсәк, без аны олы кеше сымак күз алдына китереп, аңа хөрмәт белән карап куя идек.

Вованың безне көймәгә утыртып су буеннан әйләндереп йөрткәне бар. Бу безнең өчен шатлык кына булмыйча, зур бәйрәм булды. Шуңа күрә Вованы күрдек исә, аның тирәсендә тулганабыз, аңа малайларча нинди дә булса яхшылык эшләргә тырышабыз.

Бүген Вова иртә белән үк көймәне яр буена чыгарып, безгә сакларга кушып, йөгерә-йөгерә яр башына менеп китте. Ул югалып торган арада мин, ишкәкне ике кулым белән тотып, ишеп карадым. Ишкәк калагын күтәргәндә тамчылар тама, күнелле генә итеп ишкәк тимере шыгырдап ала. Ләкин бу рәхәтлек озакка сузылмый. Вова иптәшләре белән көймә янына йөгереп төшә. Яннарында чыпчык кебек чыркылдашкан ике кыз да бар. Мин һаман, көймә борынындагы чылбырны тотып, мине дә утыртасыларына өметләнеп торам әле. Ләкин Вова, иптәшләрен көймәгә урнаштырганнан соң: «Сине соңынтынрак», — дип, кулы белән җилкәмә йомшак кына орышып, көймәне борыныннан этә дә үзе дә аңа сикереп менә. Шулай көймә борынына баскан килеш, миңа тагын әйләнеп карый:

— Без озак тормабыз, яме? — ди. Мин, бердән ташланып:

— Әһе, — дип башымны кочып куям. «Озак тормабыз» дигәннәренә дә менә ике-өч сәгать үтте инде. Кояш аргы яктан чыгып күл өстенә күчте, ул күлне бик озын текә нурлары белән коендыра, талларны, шул исәптән мине дә пешерә. Минем арык иңбашларым, бигрәк борын сыртым ут кебек кызды. Мин вак дулкыннар чайкалып торган ташка бастым да учым белән битемә, ачыткан җилкәләремә су бөркедем. Аннары, якты су өстендә күчеп йөргән ноктаны тагын бер кат күземнән үткәреп, Вовага моннан соң әйләнеп тә карамаска булып, алабута һәм кычыткан арасындагы сукмактан йөгерә-атлый өскә менеп киттем.

Малайлар үпкәсе иртәнге чык кебек кенә ул, бик тиз онытыла. Без Ринат белән кичкә кырынлап су станциясенә киттек. Су станциясе Кабанның иң биек көнбатыш ярына салынган. Яр башында ул бик зур пристань кебек түбәсенең кыл уртасында озын колгага эленгән флагын җилфердәтеп тора. Пристань дигәнебез үзе дә исәпсез күп кырлы баганалар, тоташ тәрәзәләр белән бик хикмәтле итеп корылган, анардан түбәнгә таба ике-өч җирдән сыгылмалы баскыч төшә, баскычның сынган бер җирендә тирә-юнь манзараны күзәтеп ял итеп алу өчен озын эскәмияле киң мәйданчыклары бар. Баскыч түбәнгә төшеп җиткәннән соң су өстенә ындыр табагыдай җәелгән галәмәт зур басмага килеп тоташа. Басманың бөтен ягын көймәләр сырып алган. Арада ниндиләре генә юк. Койрыклы-койрыксызлар, эчләре бик тирән һәм сайрак булганнары, очлы һәм тупыйграк борынлылары, күп ишкәкледән алып сыңар ишкәкле булганнары, аннары бер урынлы һәм ике урынлы байдаркалар — кыскасы, бу көймәләрне санап бетерерлек түгел, аларның күбесе чылбырланып су өстендә чайкалып тора, ә берише басмага менгезеп капландырып куелган иде.

Станциядә бәйрәмнәр үткәрелә. Андый вакытта җепләр белән төрле төстәге әләмнәр элеп куела, алар гүяки оркестр уйнаган көйгә һавада биешеп торалар. Боларның да өстенә кичен станция ут дөньясына күмелә,

җил тегермәннәре кебек, чытыр-чытыр килеп утлы канатлар әйләнә, һавага яп-якты койрыклы ракеталар очырыла, аларның аллы-гөлле чаткылы көлтәләре чыж да чыж килеп караңгы күлнең уртасына ук төшеп сүнәләр иде.

Без Ринат белән әнә шул станциягә су буйлатып кына килеп життек. Әлбәттә, без кем дип, күкрәкләрне киереп кенә баскычтан төшә алмыйбыз, безнең кесәдә тишек бер тиен дә юк. Станция ихатасына керсәк тә әле без ыштан балакларыбызны сызганып су эченнән керергә тиеш, чөнки станциянең тау башыннан ике яклатып төшкән коймасы әрсезләнеп су читенә үк килеп терәлә.



*Сеңлесе белән*

Без, челәннәр кебек атлап, өзелеп калган койма башын әйләнеп уздык та яр читендәге яртылаш су белән тулган көймәгә кереп калай банкылар белән аның көне буе кояшта ятып җылынган суын бушатырга керештек. Яныбызга шундук башына фуражка кигән сыек тузма сакаллы урыс абзый килеп житте:

— Пацаны, эта лодка дырявая, вон ту надо, ягъни: малайлар, бу көймә тишек бит, әнә тегесен бушатырга кирәк, — диде һәм, озын чабулы күлмәгенең чуклы бил бавы очларын селкетә-селкетә, безне басма түрендәге бер көймәгә алып китте.

Без көймәнең аяк асты такталарын алып куйдык та саркып кергән суны ашыга-ашыга түгә башладык.

— Шипко не надо, устанете, — диде урыс абзый һәм янтыгын кашып куйды. Шулай да без бу көймәнең суын бик тиз түгеп бетердек.

Урыс абзый, — ана «дядя Андрей» дип дәшәләр иде бүтән малайлар, — тагын яныбызга килеп житте:

— А теперь вон ту, — диде, ике ишкәкле көймәгә күрсәтте.

«Ту» икән «ту». Без анысының да суын бушатырга керештек. Ләкин «ту»лар бетмәде, өстәлә торды. Дядя Андрей хәзер инде бездән ишкәкләре өч парлы булган көймәләрнең суларын бушаттыра башлады. Без инде хәзер бик ашкынып түкмибез, берәр банканы чупылдатып көймә кырыена түгәбез дә хәл алып ял итеп торабыз, тагын чумырып алып түгәбез дә тагын ял итәбез. Беләкләребезнең тәмам көче бетте инде. Бер мәртәбәсендә мин суы-ние белән банкамны төшереп җибәрдем, ярый әле суы яртылаш кына иде, чулт итте дә калкып чыкты, мин тиз генә аны тартып алдым.

Ринат та килгән юлыбызга таба башын еш кына борып карап куя. Аннары кояш баер вакыт җиткәч, яр буе күләгәләре күлнең уртасына ук сузылып кергән, аргы як йортларының тәрәзәләре бакырдай кызарып яналар иде.

— Устали, но теперь домой, — диде Андрей дәдә. — Утром приедете што-ли? — дип көлемсерәп сорап куйды.

Ринат дәшмәде. Мин янә:

— Эһе, придем, — дип башымны кагып куйдым.

Икенче көнне дә без төш җитә язганчы көймәләрдән су бушаттык. Шуннан Андрей дәдә безгә эче юешләнеп торган бер көймә бирде, бер пар ишкәк тоттырды.

— Только далеко не отходить! — дип кисәтте.

Без теләсәк тә ерак китә алмыйбыз, чөнки ишүебезнең рәте-чираты юк,

аннары басма тирәли йөри генә башлыйбыз — көймәбезгә су тула, туктап аны күгәргән калай банка белән бушатырга керешә идек.

Тиздән Андрей дәдә, янтыгын кашып торган кулын безгә изәп, басмага кайтырга кушты. Инде без чыгып җиткәч:

— Хватит на сегодня, — дип көймәне чылбыры белән басма читендәге калын тимер алкаларга бәйләп куйды. Аннары килеп шулай әйбәт кенә эшләп йөрсәгез, әнә теге көймәне бирермен диде. Без әйләнеп карадык. Көймәнең эче коп-коры, җитмәсә үзе бик сылу, матур иде. Без сөенә-сөенә башыбызны кактык, киләбез дидек.

Һәм чынлап та килә торган идек, тырышып су түгә торган идек. Без Андрей дәдә белән тәмам дуслашып киттек, ул безгә хәзер тәмам ышанып карый, көймәләрнең төрлесен бирә, алай түгел, менә болай кирәк дип, ишеп күрсәтә иде. Чынлап та без ишә белмибез, йә ишкәк калагын суга кирәгеннән артык батырабыз — ул чагында ишкәкне каерып көчәнеп ишәргә туры килә: йә ишкәк калагын су өстеннән тайдырып җибәрәбез дә Ринат белән икебез берьюлы алагаемга чайкалып китәбез, дөбердәшеп егылабыз. Ә Андрей дәдә ишкәкләрне суга артык чумырмаска, сай гына батырып-батырып алырга куша. Аннары ул ишкәкләрне кире табан кайтарганда су өстеннән сөйрәтмәскә кирәк, чөнки алай итсәң, көченне бушка сарыф итәсең, хутың кими, ди.

Менә без көймә борыны белән су өстен сызгалап ишкәк ишеп йөрибез. Әле ишәргә өйрәнеп җитү өчен күп эш кирәк. Шулай да ян-якта су уймакланып кала, ул уймаклар шаян гына әйләнгәлиләр дә су төбенә төшеп качалар кебек. Көймә борыныннан, һавада почмакланып очкан торналар кебек, унга да, сулга да дулкыннар тәгәри. Алар яр буена барып җитеп чайкалалар, су читендәге яшел кыякларны башларыннан сыйпагандай итәләр, безгә таба бил яздырып карап торган кер чайкаучы апаларның матур балтырларын иркәләп кытыклап алалар. Безгә кызыгып кәкре аяклы малайлар, тычкан койрыгыдай гына толымлы кызчыклар карап кала. Чү! Алар арасында кулын кашына куйган, башын кыңгырайтып, нечкә сыйракларын авыштырып карап торган мин үзем дә бар түгелме соң? Юк инде ул чыдый малай, юк! Ул малай хәзер ишкәк итә, көймәне майлап куйгандай су өстеннән шудыртып бара һәм аның йөрәге шатлыктан дөп-дөп итеп кага, аңа чиксез рәхәт, чөнки аңа тик үзе генә ашкынып алга бара, ә ярдагы җанлы-җансыз нәрсәләрнең һәммәсе дә баш иеп калгандай тоела иде.

Безнең әти-әниләребез артык карун түгел, морожныйга да, кинога да тиеннәрне биреп торалар. Ләкин кайсы малайның киноны атнасына бер генә түгел, ә ике мәртәбә карыйсы килми, кайсы тәмле тамакның атнасына бер генә морожный түгел, ә җиләк изгән ике тәгәрмәч алсу морожный ашыйсы килми икән?! Шуна күрә безгә акчаны тегесенә-монысына да үзебезгә табыштырырга туры килә. Без иске-москы чүпрәкләр дә, чүп-чар түгелә торган җирләрдән сөяк-санаклар да җыеп тапшырабыз. Шешәләрен дә калдырмыйбыз. Хәтта шундый хәйләкәрлеккә барып җиттек, шешә башлары китек булса, кызгылт сургучны шырпы белән эретеп тамыза-тамыза аларны нинди тәҗрибәле сатучылар да сизә алмаслык итеп ямап куя идек. Инде сатучы апайлар: «Балалардан алмыйбыз» — дип шешәбез-ниебез белән кибеттән бордырып чыгарсалар да без аптырамыйбыз, ишек төбендә берәр өлкән кешене шешә тапшырырга күндерәбез, әгәр ул кеше күнмәсә: «Әбиемә даруга кирәк иде бит, теге-бу», — дип асфальт тротуарга яшь тамчыларын да тамызабыз һәм безнең хәлебезгә керәләр, шешәләрне тапшырып бирәләр иде. Көймәдә йөзү хокукын да без, әниләребезнең тиеннәренә түгел, ә үзебезнең ябык беләк көчләребез белән яулап алдык.

Шуңа күрә күл өстен гизеп йөрү безгә икеләтә рәхәт һәм ләззәтлерәк иде.

Беренче елларны без су станциясенә әле кунак кына булып килеп йөрсәк, соңга таба инде без аның хуҗасына әйләндек. Башта без Ринат белән бер пар ишкәкле көймәнең утыргычында инне ингә куеп ишсәк, аннары без ике пар ишкәкле көймәдә һәрберебез аерым итеп йөри башладык. Ләкин монда ишкәкләрне икең бергә йөртеп ишү кирәк, берең суны каерганда, икенчең әле җилпенергә генә торсаң, көймә йөрешенең ритмы бозыла, кызулыгы кими. Без ишкәкләрне бер үк вакытта йөртеп, парлап ишәргә өйрәндек һәм безнең көймәбез су өстеннән талпынып-талпынып алга оча иде.

Күп тә үтмәде, без аерым көймәләрдә бер-беребез белән узыша башладык. Андый вакытта ишкәк тимерләре тагы да тырышып җырлый, тавышлары аргы якларда ук ишетелгәндәй була. Көймә үзенең борыны белән алга таба сикереп куйгандай итә, үзебез утыргычтан төшеп калып, көймәләребез исә әллә кайларга — Ерак Кабан ярларына ук барып кадалыр сыман тоела иде.

Ләкин көймә хикәя генә булса, аның матур тылсымлы шигыре байдарка икән. Байдарканың хасиятен кайберәүләр белеп бетермидер әле. Аның бу хасияте ике башы да очлы борынлы итеп, уртасында утырыр өчен оялы итеп ясалуында гына түгел. Аның хикмәте, беренчедән, ике малай да күтәреп китә алырлык җиңеллегендә булса, икенчедән, бу хикмәт аның пар калаклы ишкәгендә. Терсәк көчләреңне кызганмасаң, әнә шул ике як очлары да калаклы булган ишкәгең белән шундый җилдерәсең ки, баш очында очкан акчарлак та сине куып җитмәве мөмкин. Әле алай гына да түгел. Ишкәгең белән тормоз биреп, каегыңны мизгел эчендә туктата аласың, бер урында бөтерчек кебек бөтерелдерә аласың. Аннары байдарка белән тагын бер трюк ясарга мөмкин. Ишкәнче аның түгәрәк оясына кереп утырганнан соң, тезеңне дә, бил тирәләрен дә су чәчрәмәслек итеп махсус клеенкасы белән каплап куясың. Без юешләнеп утырсак утырырбыз, клеенканы япмыйбыз, чөнки ул билебезне тынгысызлап тора, ишәргә комачаулый кебек иде. Әнә теге трюк дигән нәрсәне эшлисе килгәндә каплавыч белән як-ягыбызны яба идек әлбәттә. Ябабыз да каекны әле бер, әле икенче якка чайкалдырабыз. Бу хәрәкәт кызуланганнан кызулана бара һәм бервакыт каен нык кына авышкан чагында без аны кинәттән капландырып башыбыз белән суга чумабыз да икенче яктан көпчәк кебек әйләнеп тә чыгабыз. Бу шундый тиз эшләнә, кайвакыт башыбыз чыланырга да өлгерми, утырган оябызга да су керми кала.

Без байдарка белән су коенырга да яратабыз. Күлнең тоташ чуклы яшькелт үләннәре үсми торган кап-кара җирләрен сайлыйбыз. Андый җирләрнең тирән чоңгыллы икәнен, төпләреннән бозлы чишмәләр тибеп торганын, димәк ки анда су керү тиеш түгеллеген без соңыннан гына белдек. Ләкин безне андый урыннарның саф суы кызыктыра иде. Үткән эшкә салават дигәндәй, бала чакта аны-моны уйлап тормауларын без хәзер онытыйк инде. Әйе, без байдарканың очына менеп бастык бит әле. Менә без кулларыбызны күтәреп учны учка кушабыз да кинәт аякларыбыз белән этенеп пелт итеп суга чумабыз. Табаннарыбыз белән этенгәләп су астыннан күпмедер барганнан соң дельфиннардай калкынып чыгабыз һәм шундук әйләнеп карыйбыз: байдарка да аяк белән бер кат этелгәннән соң су өстеннән шуып баруын дәвам итә. Без аны куа китәбез. Корсакларыбыз белән шуышып өстенә менгәннән соң тагын һәм тагын чумабыз.

Бервакыт байдаркабыз, кырынаеп китепме, су чумырып ала. Ана кереп утыру файдасыз хәзер, менсәң акрын-акрын төпкә иңә бара. Шулай да ояга басып торасың. Су башта биленә җитә, аннары иңнәреңне, ахырда

башыңны да күмә. Шунда гына пошкыра-пошкыра судан атылып чыгасың, башыңны чайкап, чәчеңдәге, битеңдәге суны селкеп төшерәсең һәм су тулы байдарканы этә-төртә ярга таба йөзеп китәсең. Яр буенда байдарканы капландырып суын агызуы берни тормый. Су шаулап агып беткәннән соң байдаркаң күл гизәргә янадан әзер. Кереп утырасың да ишкәк очың белән су төбеннән җиңелчә генә этеп, бер кат җылынып алыр өчен, акчарлаклар белән узышырга китәсен.

Көймә безне тулы бер дөньяга алып чыкты. Элек мин Кабан тирәсен тирбәлеп торган зәңгәр рәшә аша гына карасам, хәзер инде яр буйларын җентекләп күзәттем.

Аргы яклар гына түгел, үзебезнең як та матур икән ләбаса. Кабан почмагына сыенган электр станциясеннән өрәңгеләр үсеп утырган озын гына бакча сузылып китә. Аның артында Комсомол урамының иң беренче йорты — әле утызынчы елларда гына салынган бик зур таш пулат. Аның сул ягында, бер-берсенә охшатмаска тырышып салынган икешәр, хәтта өчәр катлы агач өйләр. Алар артында, Каюм Насыйри урамында яшел түбәле ап-ак мәчет. Әнә, аңа таба, өйлә намазына, кайсы аксак, кайсы бөкрерәк гәүдәле калтыравык картлар агыла.

Су станциясен мин сезгә әйттем инде. Ул текә ярыбызның да иң биек ноктасына уенчыктай утыртып куелган. Колгасындагы флагы иң эссе көнне дә күлнең дымлы һавалы агымыннан селкенеп куя, яшьләрне спорт белән шөгыльләнергә чакыра. Анда чынлап та яшь-җилкенчәк тавышы. Бигрәк тә минем колакка Андрей дәдә җитәкчелегендә эшләгән малайлар чыр-чуы, калай банкалар белән көймә төбен кыра-кыра су бушатулары аерым ачык булып ишетелә. Күп тә үтми, алар да күл өстенә үз сукмакларын салырлар.

Су станциясеннән соң тау аз гына сөзәкләнеп киткән кебек була. Анда, шул сөзәклек буйлата бик күп озынча тәрәзәле ике катлы ак бина җәелеп утыра. Бу кайчандыр Каюм Насыйри балалар укытып йөргән Духовная семинария. Безнең заманда анда технология техникумы урнашкан иде бугай, безнең квартирыбызга каршы тар гына озын бүлмәдә квартирант булып яшәүче Якуп абый да шул техникумда укып йөри иде. Галстук та бәйләп йөргәч, ул безгә, ул чорда, хәзерге академиклардан бер дә ким булмаган бик мәхәббәтле кешедәй күренә. Без аның берәр китап-мазарны, беләзеген аз гына бөгә төшеп, йомшак кына тотуына, шул ук вакытта аксылрак чәчле башын бик туры тотып йөрүенә кызыгабыз, үзебез шулай йөреп карарга тырышсак та, һич тә аны килештерә алмый идек. Без аны яратабыз, ул үзе дә бик бала җанлы булып, Сафиян урамының юл белән ике арадагы чирәмлегенә кырын ятып, безгә ничәнче кат инде «Ак бүре»не сөйли, ләкин һәрвакыт үзгәртеп сөйли, һәм без, чык төшеп, юешләнеп беткәнчегә кадәр аны йотлыгып тыңлыйбыз.

Аның өлкәннәрне җыеп та ниндидер китап укулары сизелгәли. Ләкин бу безнең өчен яшерен сер булып кала. Колагыбызга ниндидер Галимҗан, ниндидер Ибраһимов дигән исемнәр генә чалынгалый иде.

Ярый, мин үзебезнең ярга күз салгалап күл өстен айкап йөрим бит әле. Менә тау түбәнәя бара, анда Күл буе мәдрәсәсе, аннан ике катлы агач йортлар тезелеп китә дә кинәт кенә үр башланып, якты тәрәзәле дүрт катлы мәктәбебез калкынып күренә. Ә аның да күршесендә — безнең йортыбыз, безнең балачак бишегебез. Ләкин без бу сабый чак бишегеннән үз аякларыбыз белән төшеп җир өстенә тып итеп бастык инде. Ул гына да түгел, зур күлләрне гизеп йөрибез инде. Баш очымда рәхимле кояш, тирә-ягымда минем яраткан яр буйларым. Ләкин нәрсәдер җитми. Ни өчендер, кем беләндер шатлыгымны уртаклашасым килә. Әнә ул балкон

тәрәзәсеннән карап тора түгелме соң? Ул мине күрми шул. Мин көймәмне тирәкләр арасына юнәлдереп тиз генә яр буена чыгам да чылбырны борын асты юешләнгән кәтүк хәтле генә бер малайга тоттырам.

— Хәзер төшәм, аннары сине дә йөртермен, яме? — дим.

Малай, ризалыгын аңлатып, башын кагып куя.

Мин артымнан тузан туздырып тау башына йөгерәм.

Бер-ике минуттан инде Нурия сакланып кына көймәгә уза. Мин чылбырны ычкындырасы килмәгән малайның учларын йомшак кына ачам да көймәне этеп җибәреп үзем дә җәһәт кенә эчкә карап утырам, ишкәккә тотынам. Көймәне борып, гайрәтле генә итеп Ерак Кабан ягына китеп барганда әлеге кәтүк малайның еламсыраган йөзен күрәм.

— Без хәзер әйләнеп кайтабыз! Аннары сине йөртәм, ярыймы?! — дип кычкырам мин аңа.

Малай тагын башын ия, беләге белән юеш борынын сыпырып ала. Аягын авыштыргалап, бездән күзен алмый карап кала. Менә ул кулын кашы өстенә куя да шул хәлендә башта бер карамчыкка, аннары ноктага әйләнә. Калды минем сабый чагым яр буеннан карап...

Су өсте балкыймы, әллә Нуриянең күзләреме? Ул кечкенә толымлы, күперебрәк торган, ләкин әле тарак эзләре дә язылып бетмәгән кучкыл чәчле башын әле бер якка, әле икенче якка борып йөртә, зур коңгырт күзләре белән яр буйларын йотардай булып карый, туктаусыз елмая. Елмайган чагында аның тип-тигез энҗе тешләре кояшта чагылып-чагылып китәләр. Ул сөенеченнән нишләргә белми, әле көймә кырыенда шупырдаган суны кушучлап алып, түгәрәк көзгесеннән карагандай, аңа текәлеп карап тора, һәм суда уйнаган кояш шәүләләре аның кара тутлы шома битләрен яктыртып җибәрәләр. Ул да түгел, Нурия тагын көймә кырыеннан кулын көрәтеп су чәчрәтә. Су тамчылары һавада салават күпере төсләрен чагылдырып шыбыр-шыбыр коелалар, ә кайбер тамчылары аның үз өстенә төшкәч ул:

— Ай-й-й! — дип кычкырып җибәрә һәм әнисенекедәй ябык җилкәсен җыерып бөрешкәндәй итә. Ул да булмый, Нурия кулларын аз гына күпертмәле тез башларына куеп, үзалдына карап уйга кала. Шундук минем күзем аның инде җиткән кызларныкы кебек матурая башлаган карасу аякларына, билләнеп торган табаннарына төшә. Бу аякларның тырнакларына хәтле миңа алсу нәфис булып күренә. Ә бит кайчан гына әле...

Әйе, узган көзне, болытлап торган сүрәнрәк бер көнне, Мәрьям апа аны җылы гына киендереп, аякларын балалар одеялы белән дә төреп, Нариман урамындагы больницага алып китте — анда балалар поликлиникасы бар иде. Күрше ишегалдындагы Каюм карттан алып торган арбаның тәгәрмәчләре юлның йомры ташларында сикереп куйган саен, Нурия сай әрҗә кырыена чытырдап ябыша, ә кайвакыт кычкырып та җибәргәли. Менә юл ташлары юешләнеп ялтырый башладылар — вак кына яңгыр сибәләргә кереште.

Мәрьям апа кызын докторлар янына күтәреп кереп киткәч, мин арбаны саклый калдым. Яңгыр инде шактый гөжелди башлады. Мин капканың дуга сымаграк түбәсе астында сыенып торсам да, анда да калай ертыкларыннан яңгыр үтә, салкын тамчылар яка эчемә тамып муенымны кадап-кадап алалар иде. Бервакыт калтыранып торган чагымда бер узгынчы хатын — нишләп монда торасың, бар эчкә кер, — дип, үземне орышып та алды.

Ләкин миңа арба янында торырга кушылган, шуңа күрә, тешем-тешкә тимичә дерелдәсәм дә, мин аны саклап торам. Ул арба безнең утын сарайлары артында бакча тоткан Каюм картныкы, югалса велосипед көпчәгедәй биек тәгәрмәчле арбаны Мәрьям апа каян алып түләсен?

Ул көнне Мәрьям апа, «баланы туңдырганга» үзен тирги-тирги, икебезне

дә арбага утыртып кайтты. Бер-беребезгә елышып кайтсак та мин юл буе җылына алмадым. Өйдә кайнар чәй эчкәч кенә миңа җан керде. Инде Мәрьям апа «Ташкент көчтәнәче» дип кипкән кавын да чыгарып куйгач, күнелем бердәм күтәрелеп китте. Кибеп тә җитмәгән токмачтай телемнәрне мин күземне йомгалый-йомгалый ашадым.

Йомры таш өсләрендә арба сикерә. Тынып тора да тагын сикерергә тотына. Бер күтәрелә, бер төшә. Юк, көймәм чайкалып киткән икән. Ерактанрак моторлы көймә узды, безгә килеп җиткәнче дулкыннарының хәле бетсә дә, алар көймәнең койрык-борынын сикертеп алдылар. Нурия чырыйлап кычкырып җибәрде, көймә читенә чытырдап ябышты. Аннары, юкка да курыкканлыгы өчен, бөтен күзләре һәм ак тешләре белән көлеп куйды. Мин салмак кына каерып ишәм. Мае кипкән ишкәк тимерләре моңсу гына шыгырдыйлар.

Без инде күлнең тараебрак киткән җирләреннән йөзеп барабыз. Әнә биек моржалы Вахитов заводы. Бирерәк атаклы Пләтән мунчасының ихатасы. Ике уртада озын коймалы «Кызыл Шәрыкъ» заводы. Болар минем алдымда ни өчендер бер җепкә тезеләләр. Ни өчен түгел, ә тәгаене дә шулай бит. Берсендә кайнатылган йомырка сарысыдай сап-сары сабын белән, икенчесендә юынып сафланып чыгасың. Ә инде өченчесенең «Ситро» дип аталган әчкелтем җимеш суын эчеп тәмам хушланып китәсең. Ә бу таллар шул хәтле иелеп нишлиләр соң? Бетмәс-төкәнмәс яфраклары белән дә күлгә сузылгалап су эчәләр микәнни? Шулкадәр дә туймас булырлар икән.

Безнең икебезнең дә күзебез иңкүләнеп киткән уң якта. Болар мәңге юеш җирләр. Өйләре дымланып каралып торсалар да, бакчаларына килешә бу дымлы һава. Әнә читән-рәшәткәләрдән кояш күзләре — кабак чәчәкләре чекрәеп карап тора. Әнә чия куаклары күпереп утыралар. Ул да түгел, борынга тәмле әнис, бераз төчерәк укроп исләре килеп бәрелә, яңа өлгергән яшь кыяр исләре борынны кытыклап ала һәм без Нурия белән төкрекләребезне йотып куябыз.

Менә без күпер астыннан чыгып барабыз. Өстә, күпер сайгакларын дөбердәтеп, атлы арбалар, сигналларын биреп җиңел һәм йөк машиналары үтә. Ә аста бака үләннәре чолганган, әкәм-төкәмнәр һәм сөлекләр сырып алган күпер субайлары.

Менә бөдрә урманлы Ботан бакчасы да. Анда дөньяның төрле кошлары сайрый, җәнлекләре кычкыра, арада арслан патшаның үкереп куюы да ишетелеп киткәли кебек. Без караңгырак туннель эченнән чыгып барабыз. Монда һәр аваз, хәтта су чупырдаган тавыш та үзенчә калтырап яңгырый. Әгәр: «Нурия!» дип кычкырсаң, туннель аны ике як күл өстенә пушка шикелле атып җибәргәндәй итәр иде. Юк, кызлар исемен гомумән кычкырып әйтергә ярамый. Аларга пышылдап кына дәшәргә кирәк. Әмма миннән пышылдап дәшү дә килми. Аның каравы мин хәзер ишкәк тота беләм. Ишкәк белән салмак кына селтәнеп, көймәне Ерак Кабанның якты һәм үтә саф суы өстенә алып чыгам. Монда инде әнә шул саф, тонык судан, гел яшеллектән торган манзара ачыла. Еракта аксыл иген кырлары, тау түбәләрендә утырган авыллар күренә. Ә якында гына камышлар, җикәнбашлар шыбырдаша.

Без бер-ике сабак җикәнбашны суырып алдык та кире юлга чыктык. Көймә яхшырак йөрсен өчен гадәттә койрык ягына нәрсә белән булса да бастыра төшеп, яки кеше-мазар утыртып өч ягын, ягъни көймә борынын күтәртә төшәләр. Нурия бик авыр гәүдәле булмаса да, барыбер көймә борыны күтәрелә төшкән һәм без терекөмештәй су өстеннән шуып кына барабыз. Шунда кылт итеп башыма бер уй килә. Киләчәктә дә безнең тормыш көймәләребез шулай җай гына, матур гына йөзеп барсын иде. Ул

чакта минем көймәмнең хутын җинеләйтүче кем булыр икән? Шулай ук Нуриянең ишкәкчесе кем булыр икән?

Кабан күленең төбе күренми, караңгы. Бу да минем өчен караңгы иде. Еллар тәгәрәп ага тордылар. Европадан да, безнең Көнчыгыш чикләребездән дә, күнелләребезне алҗытып, янадан-яна хәбәрләр килде. Испаниядә республикачыларның Франко фашистларына каршы көрәше безне батырлыкка өндәде. Без Испаниянең бер патриот малае турында кино карадык. Малай фашистлар кораблена килеп эләгә, кок ярдәмчесе булып эшләп йөри. Республикачыларны юк итәргә баручы, тешләрен ыржайткан акуладай була бу корабль, үзенең карынында снарядлар илтә. Әлеге малай түзеп торамы соң бу хәлгә, ул барлык совет малайлары күнелennән эшләргә теләгән нәрсәне үти: снарядлар төялгән трюмга чиләк белән утлы күмер ташлый, үзе исә сикереп диңгезгә чума, чын моряклар кебек ярга таба колачлап йөзеп китә.

Ә инде сугыш башланганнан соң төшә башлаган салкын төннәрнең берендә өебезгә кулын марля белән муенына аскан бер кеше килеп кергәч, аксылрак чырайлы, шулай ук шадралы бер кеше килеп кергәч, ни өчендер мин аны Мөфәхәр абыйга охшаттым. Аның кул бәйләүләре генә түгел, бөтен өсте-башы: яралылар госпитальдә кия торган соры халаты да, чәчләре, колаклары да керле һәм сөремле иде. Ләкин бу кеше Мөфәхәр абый түгел иде әлбәттә. Ул Шәмсенур апаның таныш авылдашы булып, күмер арасында кайткан. Менә авылга китешли, җиде төн уртасында безгә килеп кергән. Бу хәлгә мин бик аптырадым. Яралы булгач, ни өчен ул госпитальдә ятмый, качкын кебек, күмер һәм сөрем эчендә авылына кайтып бара? Аннары бер кат чистарынып кына чыгарга кергән кеше ни өчен икенче кичне дә бездә калмакчы? Ләкин Шәмсенур апа аны коры тотты:

— Энем, без солдат семьясы, безнең ирләребез фронтта. Бар, син килгән юлың белән кит инде, безне дә, авылыбызны да рисвай итмә, — диде. Шуннан яралы бу кеше югалды. Мөфәхәр абый исә бераз төшереп алып күкрәк төяргә, сабын куыкларын очырырга яратса да, намуслы кеше иде, ул сугыштан сыйрак сөяген чәрдәкләндереп кайтты, таякка таянып йөрде. Һәм хәзер дә ул таягы белән титаклап йөри, дөнья куя. Һәм һәрвакыттагыча аз-маз кәккән була, кулы белән түшен дә суккалый.

Шулай итеп, без сугыш алды елларын үткәрәбез. Ерак Көнчыгышта безне япон самурайлары тынгысызлаган булса, Ленинград ягында илебезнең көчен ак финнар сынап карады. Әле без кыләчәктә Гитлерның үзебезне нинди бәхетсезлекләргә дучар итәсен белмибез һәм ак финнарның мәкер кылуларына шаккатабыз. Агач башындагы «күке»ләре белән азмы кырганнар алар безнең солдат абыйларыбызны. Алтын гәүһәр белән кызыктыруларын күр әле син аларның. Кагындың исә, мина шартлый, сине көл итә. Без нәкъ шул ак фин сугышы чорында бер көтү малай һәм әти белән Чаткыга «Маннергейм сызыгы» дигән фильмны карарга бардык. Бу финнарның бик камил сугыш техникасы, посып яшеренеп ята торган тимер-бетон корылмалары турындагы кино иде. Ну астан гына ут җибәреп яталар да соң ике койрыклы албастылар! Ә дотларына бик калын резин эшләпәләр кигезеп куйганнар. Безнекеләр снарядлар очырды исә, әлеге эшләпәләр аларны кире үзебезгә таба сибә. Ник дисәң, резин кысылып килә дә ата да бәрә, ата да бәрә снарядны безнең якка. Безнекеләр дә төшеп калганнардан түгел шул, эшләпәнең хикмәте турында уйланганнан соң, әнәле снарядлар аттыра башлыйлар. Снаряд теге резина эшләпәгә килеп кадала да тимер-бетон корылманы пыран-заран китерә.

Әнәле снарядлар чынлап та булганмы, аллә ул безнең, ягъни малайларның фантазиясе идеме, һәрхәлдә безнең гаскәр әнә шул куәтле Маннергейм

сызыгын да йомычка урынына туздырып ташлады. Фильмның да асылы менә шул хакта иде. Ленинград ул елны куркыныч астында иде. Аңардан эвакуацияләнүчеләр дә булгандыр күрәсең. Безнең йортка да, Хәким Ибатуллиннарга бер гаилә ленинградлылар кайтып төшкән иде. Алар җирәнбаш Хәкимнәрнең кардәше булып, безнең күл буе йортыбызда әлләни озак яшәмәделәр, фин сугышы бетү белән кире үз шәһәрләренә кайтып киттеләр. Ләкин аларның бер малайлары безгә кызыклы истәлекләр калдырып китте.

Безнең «академигыбыз» Якуп абый капыл гына юкка чыкты. Колактан-колакка ишетелгән сүзләргә караганда ул, сабагын «үзе укымыйча», ниндидер «Галимҗан», ниндидер «Ибраһимов»ларны укып йөргәне өчен юкка чыккан. Аны безнең йортыбыздан кемдер чаккан булган. Аның квартир хуҗасы Миңнегөл апа әллә ни вакыт телсез калып йөрде. Аннан соң да хатыннарга өзек-өтек сүзләрен пышылдап кына әйтә торган булды. «Төн уртасында алып киттеләр... Аның хакында бер сүз дә сөйләмәскә куштылар... Ник сөйлим, кирәкми, сөйләмим... Әмма үз сабагын укымый дигәннәре хак түгел. Кичләрен сызыклар да сыза, укый да ич. Нихәтле керосин гына яндырып бетерде. Сөйләмим, юк, кирәкми...»

Капка янәшәсендәге чирәмлеккә кырын ятып әкият сөйләүчебез югалды. Ләкин без хәзер капка төбендәге озын эскәмиягә тезелеп утырып үз белгәннәребезне үзебез сөйлибез. Әкият түгел икән, барыбер чынын-ялганын кушып әкияткә охшатыбрак сөйлибез.

Менә бер кичне әлеге Ленинград малае да әңгәмәбезгә кушылып китте. Ул рус мәктәбендә укыса да, татарчага оста, чөнки әтисе-әнисе белән ул: «әтием», «әнием» дип иркә сүзләр әйтә-әйтә гел туган телебездә сөйләшә иде.

— Безнең Ленинградта өрәкләр күбәйде, — дип борчак аттырырга кереште ул. — Өсләренә кәфен уранганнар, аяклары тирбәнеп тора, сиртмәле. Берәр йорт каршындагы агач башыннан җиргә сикереп төшәләр дә һавага сикереп менеп тә китәләр. Өске каттагы тәрәзәләрдән карыйлар: кем бай яши, кемнең өендә әйбер күп. Бигрәк борынгы рәсемнәрне урлыйлар. Ленинградта музейларның исәбе-хисабы юк. Ә картиналар бик кыйммәт тора. Тегеләр картинаны кәфен астына кыстырып тәрәзәдән сикерә икән дә шундук күздән югала икән. Милиция бик күпләрен тотты инде.

— Янгалама, — ди Нурия, — синең ул өрәгеңә картина ниемә кирәк?

— Алар өрәк кебек киенгәннәр генә бит. Кешеләрне куркытыр өчен. Революция вакытында качкан байлар алар. Йә инде аларның малайлары. «Алар безнең картина, — диләр икән, совет заманында ясалмаган, диләр һәм заграницага алып чыгып саталар икән. Милиция бик күбесен тотып судить иттерде. Судта болай дигәннәр: «Картиналар да, барлык музейлар да, Ленинградның борынгы гүзәллеге дә — халык байлыгы. Бу байлыкны урлаучыларны рәхимсез хөкем көтә».

Мин уйга калам: ярый инде, картиналарны, музейлардагы җәүһәрләрне урлап та булсын ди. Ә гүзәллекне ничек урлыйсың. Нәрсә ул гүзәллек? Мин, үз уема үзем чуалып, бу хакта буталып кына Ленинград малаена сорау бирдем.

Ул да ык-мык итте, юньләп җавап бирә алмады. Ләкин моннан соңгы көннәрдә ул әтисе белән ишегалдында да, урамда да бик еш сөйләште. Минем колагыма: «Казан малае сорады» дигән сүзләр дә чалынып калды. Димәк, кунак малай әтисе белән киңәшләшә, аңардан сораша. Һәм чынлап та, кичләрнең берсендә, ул миңа болай дип аңлатты:

— Беләсеңме, гүзәллек ул — матурлык. Менә Ленинград бик матур: Нева проспекты, диңгез буйлары, урамнардагы йортлар. Ул тагын бакчаларны,

парктагы күлләрне, буаларны күрсән. Агачлар да мен төрле. Кызыл, шәмәхә, алтын төсендәгеләре дә бар, бигрәк тә көз көне матур алар. Ул шарсыман куаклар! Менә болар һәммәсе дә, иртә-кичләрен күл буйларында, шәүләләре белән бергә, ак томанга төренеп, йоклап утыралар. Ә күл уртасында менә синең кебек бронзадан коелган бер малай, һавага кувшин күтәргән дә, аз гына чупырдатып ишетелер-ишетелмәс кенә, су агызып тора. Менә гүзәллек шулар була инде.

Мин тагын аптырашка калдым. Ленинград дигәч тә, парклар бездә дә юк түгел инде анысы. Әнә — Арча кырында. Урыс зираты читеннән барасың да, коймa аша гына билетсыз керәсең. Яки ял йорты аша чокырлар арасыннан гына. Анда тайларга утырып чаба торган карусель бар, тимер бишекле шыгырдаучы таганнар, баш түбәмдә зырылдатып әйләндерә торган самолет бар. Ну, агачлар агач кебек инде. Яфраклары төрле төстә булмаса да, урман кебек ямь-яшелләр. Әйе, бер түгәрәк буа да, бассейн ягъни. Тирәләренә зур гына бакалар тезелгән дә, авызларыннан су аттырып торалар. Минем ул бакаларга атланып та караганым бар әле. Әнә шул «гүзәллек»не алып үземнең Кабаныма җибәриммени инде мин? Кабанда болай да бака күп, иртә-кичен бакылдап колакны тондырып бетерәләр.

— Гүзәллекне урлап буламыни? — дип сорадым мин һәм ленинградлының үзенең дә авызын каплап куйдым, ләм-мим бер сүз әйтә алмады.

Ләкин аның, авызына су капкандай, дәшми йөрүе озакка бармады. «Вәзир» әтисе белән киңәште дә, янә бер кичне чыгып әйтте:

— Була икән, — диде.

Ул болай аңлатты: әгәр син агачны кайгыртмасаң, аны тәрбияләмәсәң, ул корый. Син аның гомерен урлаган кебек буласың, син, димәк, җинаятьче.

Аннары Ленинград малае болай диде:

— Гүзәллекне бүтән төрле дә урлап була. Капкалары, парадный түбәләре чуеннан челтәрләп эшләнгән, баскыч култыксаларына хәтле бик әкәмәт сырланган, үзе исә әллә каян күренеп торган аккоштай бер таш йорт ди. Андыйлар Ленинградта бик күп. Алар йөз илле, ике йөз ел элек ясалганнар. Бу борынгы заман һәйкәлләрен байлар салмаган бит, эшчеләр, крестьяннар килеп салган. Әти әйтә, Петр патша татар осталарын да бик күп чакырткан, ди. Нихәтлесе сазлыкларда күмелеп калган. Аларның сөякләре өстенә үк мәрмәр сарайлар корылган. Менә мин әйткән әлеге аккоштай йорт тәрбиясез кала ди.

Түбәләре, матур-матур кәрнизләре, челтәрле коймa-капкалары яңгыр суларыннан акрынлап күгәрә, чери, стеналары куба. Домуправ аңа: «Советский түгел, иске заман калдыклары!» — дип төкереп тә бирми, ремонт ясаттырмый. Йорт ишелә, харап була. Гүзәллек урлана...

— Әти әйтә, элек Казанда «Бакыр бабай» һәйкәле булган, ди. Кайда ул хәзер? Беркем белми. Аннары менә Кабанны кара, Болакны кара. — Бу китте инде хәзер тезеп. Әллә каян килеп тә безнең шәһәребезне күп белгән булып кылана. Кабанны мин үзем дә беләм һәм яратам. Болагы аша Проломныйдагы «Электро» һәм «Уппон» киноларына йөрибез. Бер көнне, бу кунак малаен да ияртеп, «Рот-фронт» киносына да барган идек әле. Малаен, Болак күпере аша чыкканда, каналга озак кына карап торды.

— Матур, — диде. — Бездә мондый киң каналлар күп түгел, ләкин аннан тарраклар меңнән артык. Аннан Нева елгасы Иделдән аз гына калыша. Ике яры да гранит белән тышланган. Сезнең Болакны да шулай итсәләр. Тик менә әшәке сулар агызып үзен сасытмасалар икән...

Кинога барган ул көнне мин Болакның да «гүзәллек»кә кергәнен белми идем әле.

— Сезнең Болакта ни өчен су агып тормый? — диде кунак малае.

— Язын ага. Идел суын Кабанга агызып, кертәләр.

— Хәзер мунча сулары гына агып төшәме?

Мин үзалдыма кызарынып киттем. Моның сәбәбе дә бар иде. Проломныйга чыксак, бәдрәф таба алмый аптырап бетә идек. Безне бердәнбер коткаручы шул Болак күперләре иде. Хаҗәтең төшкәндә кайда инде аны-моны уйлап торулар — йөгерәсең күпер астына.

Үзем өчен дә, иптәшләрем өчен дә менә хәзер колакларым пешеп чыкты. Ярый әле кунак малае сүзне Кабанга таба борды.

— Әтием сөйли: шәһәр уртасында шушындый зур күле булган шәһәрләр бөтен Советлар Союзында юк. Кадерен белмиләр, ташландык хәлендә тоталар, ди. Нәрсәгә ул алабута әрәмәләре. Кәҗәләр өченме? Ә менә талларыгыз, йөз яшьлек тирәкләрегез гүзәл. Ичмаса әнә шуларны урлатмасагыз иде...

Сөйләнгән була шунда. Ярый ул сезнең анда, Ленинград-Мәскәүләрдә, пешкән-төшкән. Ә безнең монда менә икмәгенә дә чират була башлады.

Мин ипине Сафьян башындагы кибеттән йөгереп кенә үзем алып кайта идем. Алып кайканда буханканың бер чаты кимерелеп бетә, урам буенча чемченеп кайтуы нишләптер бик тәмле була иде. Хәзер инде болай тиз генә ипи алып кайтып бирәм димә. Беренчедән, бик озак чират торасы булгангамы, мине, ягъни баланы, əти-әнием чират торгызмаска тырышалар. Икенчедән, мин, мәсәлән, язгы юеш көнне көне буе торып та ипи алып кайта алмавымны хәтерлим. Аның каравы, әллә нигә бер булса да, тышы ялтырап кетердәп торган зур иләк шае түгәрәк ипине күтәреп кайтуы минем өчен үзе бер зур бәйрәм иде.

Андый чакта әнием:

— Зур үстең бит инде, балам, — дип аркамнан да сөеп куя торган иде. Керосин кытлыгы да башланды. Примусны мин коридордагы иске өстәл өстендә пешкәкли-пешкәкли үзем яндырам. Чыгымлый башласа, тар гына калай тасмасы очына беркетелгән кылдай нечкә корыч чыбык белән керосин парларын сиптерүче чебен күзе хәтле генә тишекне чистартам. Ләкин кайвакыт нихәтле генә пешкәкләмим, әлеге чебен күзенә төртә-төртә нихәтле генә чистартмыйм, примусыбыз янмый. Шуннан мин аны күтәреп селкетеп карыйм, юк, керосины чайкалмый, ул беткән. Чөнки әти белән икебезгә, ә кайвакыт бер үземә, Татарстан урамына барып чиратка басарга туры килә. Ә кибетченең зур тимер чанында кара май кебек болганып торган, кай арада яшькелт-шәмәхә төсләр белән ялтырап киткән керосинына барып житкәнче ярты көн үткән була. Менә сиңа Болак, менә сиңа гүзәллек!

Шулай да бу Ленинград малае мине уйга салып китте бит әле. Кабанның үзен әйтмим дә инде, безне яр буе тирәкләребез, электр станциясе һәм «Кызыл Шәрыкъ» заводы артындагы талларыбыз да үзләренең кыргый-сәер булулары белән аның күңеленә бик хуш килгән иде кебек.

Ләкин мин карыйм да хәзер су буйларына, Зәйнәп карчыкның: «Ходай рәхмәте белән үскән ул тирәкләр» дигән сүзләрен дә исемә төшереп, бердән шикләнеп куям. Безгә мәктәптә табигать белеме керә башлады инде. Укытучыбыз: «Алла юк, бөек, көчле, кодрәтле табигать кенә бар», — дип сөйли иде. Бу тирәкләребезне дә шул бөек табигать яратканмы? Ничек ул аларны, алып батырлар кебек, су читенә бертигез итеп тезеп куя алган? Кеше кулы үстермәде микән аларны? Мөгаен шулай булырга тиеш. Димәк, Кабан ямьле булсын өчен, яр башлары ишелеп төшмәсен өчен, аны безнең

ерак бабаларыбыз да кайгырткан булгандыр. Алар гүзәллекне безгә хәтле үк бик яхшы белгәннәр иде микәнни соң?

Менә инде ул йөз яшьлек тирәкләр сирәгәеп бара. Бигрәк тә Меховой клубы арты шәрәләнеп калган. Ул тәңгәлдә тирәкләрнең черек төпләре генә анда-санда каралып тора. Минем әни мехкомбинатта эшли иде. Мехкомбинатта эшләүченең малае булгач, аларның клубы артындагы шәрәлек ничектер мине дә гарьләндергән кебек була иде.

Аннары без үзебез дә бәләкәй җинаятьчеләр түгел идек микән? Кемнең генә су өстенә бәләкәй каеклар җибәрәсе килми. Аларны без башта, кәгазьдән эшләп, йортыбыз каршында яңгырдан соң җыелып калган күлдәвекләргә җибәрә идек. Су өстен җыерчыкландырып җил дә исеп куйса, безнең көймәләребез оча гына иде. Аннары без көймәне, ак җилкәндә бастырып куеп, агач кайрысыннан ясый башладык. Ә кайрыны без пычак белән тирәкләрдән каерып алабыз. Зуррак җилкәннәр ясыйсыбыз килсә, кәүсәнең тирән җыерчыклары арасыннан кайрының зуррак кисәкләрен дә табабыз, пычак белән булмаса, кечкенә балта белән каерып төшерәбез. Көймә астын шомартып, ә эч ягын куышландырып ясаганнан соң, безнең җилкәннәребез, дулкыннар өстендә сикерә-сикерә, Кабан күленә сәяхәткә китә. Ләкин тирәкләребез лайлалы үзагачына кадәр тишкәләнеп тә кала иде бит әле. Анысына нишләп игътибар бирергә, безнең күзләр күл уртасына ук җитә язган көймәләребездә.

Керосин кытлыгы башлануы турында әйткән идем инде. Без ара-тирә ашларны үзе үк чиркәү эче хәтле булырлык урыс миче алдында өч аяклы таганга чуен утыртып пешерә башладык. Ләкин монысына да утын кирәк бит. Утынны моңа бик саклап тота идек, чөнки салкын кыш та киләсе бар бит әле.

Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, йортыбызның өске катында яшәгән берданбер урыс малае Гена бер әкәмәт нәрсә уйлап чыгармасынмы. Ул бездән олырак яшьтә булып, «Конструктор»дан әллә нәрсәләр эшләп бетерә. Аларның өйләренә эләккәләгән чагында мин дә тырыштырып карыйм, ләкин даими күнекмәләрем булмаганга, әллә ни майтара алмыйм.

Гена кургаштан йомры балык сыман бер нәрсә коеп, аның койрыгына таза гына җеп бәйләп куйды. Гена «балык»ны болгый-болгый чөеп җибәрсә, ул һавага сызгырып менеп китә. Тирәкләрнең коры ботагына чалынып чолгангач, Гена әлеге җептән тартып, ботакны сындырып төшерә. Шул ысул белән, бер чыкканда, кимендә ике-өч пешерерлек утын алып кайта иде.

Чүлмәкчедән күрмәкче, мин дә бу тәҗрибәне кабатлап карадым. Тик мин кургаш урынына таш кына бәйлим. Бәлкем аны начаррак та бәйләгәнмендер. Коры ботак урынына кайчак, шырт-шырт уалгалап, яшел тармаклар да очып төшкәли иде. Әлбәттә, бу төрле утын хәзерләвебез озакка сузылмады. Подвалда яшәүче бер көтү малайның алар өстендә, ягъни йортыбызның аскы кирпеч катында яшәүче Фәһимнең әнисе Гадения апа да әлеге җирән башлы Хәкимнең әнисе Гизыль апа да бертуганнар булып, аларның балалары Хәким әтисенә «җизни» дип дәшәләр. Ишегалдының ярты малае «җизни» дип йөрткәч, аның исеме шундыйдыр дип белеп, без дә, ягъни бүтән малайлар да, ана «Җизни абый» дип дәшә торган булдык. Әнә шул Җизни абый бер мәртәбә ботак сындырып йөрүебезне күреп калып:

— У-у-у, корткычлар! Халык дошманнары! Колагыгызны борырга кирәк сезнең! — дигәч, бигрәк тә минем котым ботыма төште, «халык дошманы» ул заманда бик куркыныч сүз иде. Без шуннан соң ике атна буена күл

тирәсендә күренмәс булдык. Менә шул җизни абыйның үз малае белән кызык килеп чыкты. Хәким «корткычлык»та барыбызны да уздырды. Ул карт бер тирәкнең су эченә кыйгачлап кереп торган озын ботагына калын бау бәйләп төште. Шул бауны кысып тотып, тау битенәрәк менә дә, сәгать теле кебек түбән атыла, суның түренә кереп, бавын ычкындыра һәм шап итеп суга чума. Бу таган атынган сыман килеп чыга. Хәким бу атынып чумуда бик остарып китте, котыртып бүтән малайларны да атындырды.

Бер тапкыр Хәким:

— Нәрсә циркны бушлай карыйсыз, акчагызны хәзерләгез. Менә хәзер программаның иң зур номеры була! — дип кушучлап тирә-якка кычкырып белдерү ясады. Тау башына ук менеп, хәтта ярдәмгә аягы белән этеп җибәреп выжт итеп түбән китте. Ләкин кинәт кенә ботакның шартлап сынуыннан куркыпмы, кулын вакытсыз ычкындырды да баш түбән суга чумды. Хәким үзе юк, су өстендә табаннары гына селкенгәли. Аякларын, кайчы кебек, арлы-бирле селкетә. Җитмәсә өстенә сынган ботак килеп төште. Хәким көчле иде, алай озак изаланмады. Ләкин судан чыкканда аның ялкын кебек җирән башы кап-кара иде.

Күлнең тирәкләр тирәсендәге төбе, ни гомерләр буена коелган яфраклар коелып чери-чери, калын ләмгә әйләнгән. Хәким шул ләмгә кадалган җиреннән көчкә генә ычкына алган. Судан чыкканда аның башы-бите, колаклары, авызы да гел черек ләпек кенә иде. Ул тиз генә юынды да, бауларын да ташлап, тиз генә өенә ычкынды. Без исә, аның хәле көләрлек булмаса да:

— Менә сиңа кирәксә цирк! — дип авыз ерып калдык.

Күл буе тирәкләре рәнҗемәдеме икән безгә үзләрен әнә шулай борчыганыбыз өчен? Мөгаен, рәнҗегәннәрдер. Терсәкне бик тешләр идем дә, җитми шул. Ник шунда бер тылсымлы кул табылмаган безгә. Көймәләрне модельчылар түгәрәгендә дә ясарга мөмкин булгандыр бит югыйсә. Җитәкләп кенә илтәсе иде үзебезне шунда. Ә Хәкимне су станциясенә генә алып барасы иде. Анда күккә ике-өч катлы манара ашып тора. Күнегүләр дә ясаштырса, аның очыннан ук сикерер иде ул суга һәм, мөгаен, чемпион да була алыр иде. Хәзер исә әти-әниләре аны читлеккә ябып куялар, өй саклаталар. Хәким читлектән ычкынгалый ычкынуын — моңа гына башы җитә аның — ләкин ирекккә чыккач, ул койрык чәнчеп чапкан бозаудай чаба, уен уйнаса вәхшилеккә хәтле барып җитә. Без дөрес тәрбияләнмибез ахры. Әти-әниләребез бу сүзне еш кына кабатлый. Үзләренең исә безгә күз салырга да вакытлары юк. Шунлыктан, без урам һәм күл йогынтысында үсәбез.

*Ахыры киләсе санда.*



Ләйсән
Фәтхетдинова

# БУ БӘХЕТКӘ ИСЕМ КУШЫП БУЛМЫЙ

***

**Бәрелеп китмәгез үткәндә!**
**Сөртмәгез яшемне — кипкәндә.**
**...Күтәрмә һичкайчан, мин сине**
**Өзелеп-өзелеп көткәндә.**

**Җанымның тәнемә сыймавы —**
**Күңелнең килбәтсез биюе.**
**Йөрәкне учыма кыстым да**
**Туйганчы йөгердем мин бүген...**

**Колакта уйнаган җырларның**
**Сүзләрен ишетмә. Ишетмә!**
**Буй җитеп, яшь белән үссәм дә,**
**Акылым һаман да бишектә...**

**Бәхетле чакларның вакыты**
**Сизелми үтә дә китә ул.**
**Тик күктә очынып йөрүләр**
**Бер якты һәм кыска күренеш —**
**Үтә ул...**

**Очасы килгәндә, тилмереп,**
**Оныту кирәктә күңелгә —**
**Юату сүзенә түгел лә,**
**Вак-төяк эшләргә күмеләм...**

**Бәрелеп китмәгез үткәндә!**
**Башкалар еласа, көлмәгез.**
**Кайгылы вакытта килмәгәч,**
**Бәхетле чакта да килмәгез.**

Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА — *Казан Идел буе (Федераль) университеты талибәсе. Шигырьләре һәм әдәби-публицистик язмалары көндәлек матбугатта даими басылып килә.*

***

Адымнар — вак кына,
Сүзләр дә сак кына.
Шулай да гомернең
Буталчык юлында
Еш кына
Абынам.

Күзләрдә моң гына,
Тавышлар тын гына...
Ә күңел шау-шулы,
Гөрләвек, ташулы
Язларны сагына.

Һәрбер көн — әкият,
Һәр гамәл — могҗиза.
Шулай да
Хыялга, өметкә
Язылган юлларны
Еш сызам.

Йөрәктә тибеш бар,
Кан дигән инеш бар.
Табигать-тәнемнең
Яшәеш чорында
Бары өч килеш бар:

Туасың, яшисең, үләсең...
Елыйсың, көләсең.
Һәм тагын еш кына
Яшәеш заяга узганын
Беләсең...

Кайвакыт, дусларың
Хушлашып киткәндә,
Тамак та кырмыйсың.
Ә кайчак, үкенеп,
Тик күккә багасың,
Җирләрне тырныйсың...

...Селкенми керфек тә,
Битараф, битараф!
Сиңа бит барыбер
Һәр тараф.

Һәр гамәл, һәр мизгел,
Һәр хәбәр — барыбер.
Тик күңел леперди:
Өмет бар — бары бер.

Бер сынык икмәктә
Яшәеш өмете.
Ә тормыш, хәйләкәр,
Җитәрлек чеметте.
Икмәккә үрелеп җиткәнче —
Кибектем.

Мәгънәсез сүзләрең.
Тырышма,
Сатылмас акылың.
Мин бүген
Йоттым да фикерне,
Юләрлек йортының
Ишеген шакыдым.

...Тәнкыйтең гаҗәеп,
Белемең югары,
Искиткеч!
Мактавың, ясалма елмаю өстәсәк —
Исерткеч!

Тик синең бу гаҗәп
Сәләтең бер тиен —
Асылын белмисең
Гамәлнең.
Бар, киен!
Сагынгандыр күптән
Буш өең.

Йөрәгең, акылың сугышы
Үткәнен көткәндә,
Соңарма.
Ә синең ясалма йөзеңдә
Катырып куелган сурәтең
Язмышның иң авыр сынавын
Үткәндә — чыдармы?

***

Бу бәхеткә исем кушып булмый,
Бу бәхеткә хәтта... сүз җитми!
Аллаһыма рәхмәт — бар күңелдә,
Касәсенә тулып җан түгелә,
Ярыймы, мин
бу халәттән китмим?

Мин һәрвакыт шундый булыр идем,
Шулай яшәр идем һәр көнне!

Әгәр күңел шулай якты торса,
Бу бәхеттән һәрчак аң яктырса —
Ярдәм, изге гамәл эшләр өчен
Куяр идем бөтен көчемне...

Аптырыйм да, кайчак, башкаларга...
Мондый бәхет бар бит күпләрдә!
Әмма бар да сукыр хисле бугай...
Ихлас тойсаң шушы бәхетеңне,
Яши алмас идең, карамыйча
Ходай сүзе, җиде күкләргә...

Белсәм дә мин бүген бәхет аша
Авыр көннәр чират аласын,
Бүген менә каршы дәшә күңел!
Килә минем шушы яктылыкта —
Бу бәхеттә мәңге каласым!

Ә авырлык килсен, ансыз булмас,
Тик бәхет тә барсын янәшә.
Яме, Ходам?
Күкрәгемнән чыгып көләч күңел
Күккә карап бүген мең дәшә...

Бу бәхеткә исем кушып булмый.
Бу бәхеткә хәтта...сүз җитми!
Авырлыклар килсә килер инде,
Ходай безне сынар, ә мин хәзер
Бу бәхеттән китмим!

## Кирәкми

Кирәкми, елмайма, кирәкми!
Күзләрең пыяла — күрәм бит.
Сорама хәлемне, сорама —
Һич мөһим түгелен беләм бит.
Әйдә, кит!

Кирәкми ярдәмең, кирәкми!
Өметең — миннән дә җавап бит.
Кәгазьгә, сүзләргә түгел лә —
Күңелгә карап кит!
Эшеңнең мәгънәсе буш булса —
Харап ит!

Кирәкми мактаулы сүзләрең,
Кирәкми, кирәкми, кирәкми!
Миңа бер ихлас иҗегең,
Бер ихлас фикерең кирәк бит!
Сирәк бит...

Егылсам, мең рәхмәт сораучы —
Торгызыр кулың да кирәкми.
Мин түгел ул шундый бер кире —
Йөрәк бит!...

***

Күңелдә ут уйный.
Ә акыл һаман шул —
Йөрәкне тыймый.
Чарасыз ачуның дәрманы
Күңелгә сыймый.

Күзләрне яндыра,
сулышны өтә...
Тыныч бул, барсы да
Иртәме, соңмы —
бер үтә.

Йодрыкны йомарлап,
Сүзләрне тотып,
Күмер кисәген —
Ачуны йоттык.

Күңелдә ут уйный...
Тик сабыр булырга
Тиеш мин.
Кызларга һич тә бит
Усаллык килешми...

***

Ялгыз калдырып,
Дуслар киткәндә,
Тормыш газабы
Җанны өткәндә
Яшермә йөзең,
Качмасын күңел!
Син бит чын кеше,
Ә курчак түгел!

Хәйләкәр дошман
Чыркылдап көлсә,
Иң зур сереңне
Бар галәм белсә,
Борчулы көннәр
Өеңә керсә...
Ихласлыгыңны
Югалта күрмә.
Дошманнар йөрсен —
Син аны күрмә.

Читләр янына
Эләксәң килеп,
Ясалма сүзләр
Башыңа килер.
Тешләрсең телең,
«Тәртипле» булып,
Җаныңа керер
Корымлы болыт.

Бәлки оялу,
Ә бәлки башка...
Бик еш ясалма
Фикерләр башта.
Йөрәгең нәрсә
Сорап типкәнен
Оныта күрмә
Инде, үскәнем...

***

көлке хыялларны вакыт таптый.
күңел генә көлми — көрсенә!
кайчак, язмыш, хыялланып көткән
бер көнне дә безгә күпсенә.

Салават
Юзеев

# ҮЛГӘННӘРНЕ БҮЛДЕРМӘ

РОМАН

## Зариф картның мыгырдавы

Зариф карт ялгызы гына яшәгән. Хәтерем ялгышмаса, анын кайчандыр хатыны белән алты кызы булган. Хатыны яшьләй күзен йомган, ә кызлары бер-бер артлы кияүгә чыгып, кайсы-кая таралышкан. Шуннан бирле Зариф картның аларны күргәне булмаган.

Беләсездер, бездә, өлкән яшьтәгеләргә, гадәттә, хөрмәт белән карыйлар, тик Зариф карт кына андый хөрмәттән мәхрүм. Авыл жирендә һәркемнең тормышы-көнкүреше уч төбендәге кебек. Кемдер ихтирамга лаек, кемдер юк, Зариф карт соңгысына карый иде, ахры.

Карт үзен сәер тотканга, аны «ычкынган»га санадылар. Берәүгә дә бәйләнми, комачау итми, үзенчә яшәп ятса да, үз-үзенә сөйләнеп йөри торган гадәте булганга «шөребе бушаган» дигәннәрдер инде. Урам буйлап кычкыра-кычкыра сөйләнеп килгән картны, чыннан да, саташкан дип уйларлык. Вакыт-вакыт ул, таягына таянып, туктап тора, аннары тагын кузгалып китә.

Ә без, бала-чага, картның чыкканын гына көтеп торабыз, өлкәннәрдән берәү күреп куып җибәргәнчегә кадәр аның артыннан калмыйча, үртәп җанын алабыз. Картның исә бездә эше юк шикелле, баруын белә, безгә күз дә салмыйча, сөйләнә-сөйләнә, өенә кереп китә.

Ышанасыңмы-юкмы, мин гомерем буе сиптереп аккан суның, сызгырып искән җилнең телен аңлап була, дип уйладым.

Комдагы кошлар эзен теләгән очракта укып була дип санадым.

Күктә ялтыраган яшенне әфсен көче дип ышандым.

Әле дә мин агачтагы сызыклар, таштагы ярыклар, су өстендәге түгәрәкләр, биттәге җыерчыклар, — гомумән, бу дөнья тарафыннан тудырылган шундый могҗизалар турында гел уйланып йөрим.

Шулай да бер сорау гел башымда бөтерелә. Кеше шартлы кыскартылма — кодлар, мәсәлән, Морзе әлифбасын алыйк яисә яшерен язу өчен шартлы билгеләр — шифрлар, формулалар, сигнал, символлар булдырган. Ә нигә Аллаһы Тәгалә шуның ишеләрне элегрәк булдырмаган икән?

Кешенең саташуы да — бу дөньяның серлелеге барлыкка китергән нәрсә. Ә «түбәләре кыйшайганнар»ның мыгырдаулары икеләтә кызыклы.

Әмма Зариф карт заманында мин әле кечкенә, мондый кызыксынулар

*Ахыры. Башы узган санда.*

уяныр яшьтә түгел идем. Башка малайларга ияреп, мин дә картны үчекләүдән тәм таптым. Бервакыт малайлар белән, бу өендә нишли икән дип, тәрәзәсенә күз салырга булдык. Карт урамда нинди — өендә дә шундый икән: башта, сөйләнә-сөйләнә, озаклап чәй эчте, аннары намазга кереште.

Кайсыдыр малайның абыйсыннан:

— Ул нигә үз-үзе белән сөйләшә икән? — дип сорадым.

— Үзе белән гәпләшерлек акыллы кеше юк дип саныйдыр, — дип җавап бирде ул әллә чын, әллә юри.

Еллар узды, мин дә үсмерлек чорына аяк бастым. Абый әйтмешли, теләсә кая борын тыгар яшькә җиттем. Әмма сер капчыгы — Зариф картка карата битараф калалмадым. Бервакыт шулай карт, гадәтенчә, борын астыннан мыгырданып, капка төбендәге эскәмиядә язгы кояшта җылынып утыра. Янынннан үтеп барганда, картның сүзләре колакка чалына:

— Сәламәт бул, кадерлем, авырма.

Әллә нишләп киттем. Бабай бу сүзләрне миңа әйтте ахры дип, борылып карадым. Юк: күзләрен әллә кая төбәп, үз-үзенә сөйләнүе икән. Шунда кылт итеп искә төште: кичә моннан узып барганда, карт бик каты итеп төчкергән иде түгелме? Әйе-әйе, хәтта янында чемченеп йөргән тавык та, бу нихәл дигәндәй, пырылдап читкә очты бит. Баш шәрифләремне эшләтә башладым: бу ике вакыйга арасында берәр бәйләнеш юкмы, янәсе. Кинәт әллә нинди чит-ят җил исеп, тәнем эсселе-суыклы булып киткәндәй тоелды. Соң бер тапкыр мәчеткә юнәлгән карт авызыннан:

— Мәккәгә бара торган юл 212 авыл һәм 12 шәһәр аша уза, — дигән җөмләсен ишетеп, аптырап торган идем.

Ә икенче көнне:

— Каһирәдәнме, әллә Истанбул ашамы баруыңа карап, — дигәне шул җөмләнең дәвамы түгелме соң?

Шикләрем куера баргач, түзмәдем, кулыма кәгазь-каләм алып, ике көн рәттән карт артыннан калмый ияреп йөрдем.

Беренче көнне язып алганнарны кичен укып чыктым. «...быел нәрсә яхшырак булыр дип исәплисең, хөрмәтлем? ...әлбәттә...төнгә дисәң, эш башка, ә иртән? ...Бохарада булсаң, аның суын һәм исен оныта алмыйсың ... кайчак хәтта су белән җил дә килешә алмый... һәм шуңа охшаш өзек-төтек җөмләләр.

Икенче көн дә уңыш китермәде. Кәгазь битендә язылганнарны аркылыга-буйга укысам да берни аңламадым.

Булмаган эш артыннан йөрмим әле дип, өченче көнне картны тынычлыкта калдырдым. Әмма дәфтәр битләрендәге теге язмалар магнит кебек үзенә тартып тордылар. Түзмәдем, кояш офык артына качарга әзерләнгәндә, битләрне уен карталары кебек өстәлгә җәеп салдым. Ничектер кулымда икесе ике көндә язылган ике бит эләгеп калды. Кызык өчен, икесен янәшә куеп укый башладым һәм үзем дә сизмәстән, кулыма каләм алып сүз һәм сүзтезмәләрдән җөмләләр төзергә тотындым. Шулкадәр бирелеп, саташкан картны, авыл, гомумән бар дөньямны онытып, сүзләргә качкан мәгънәне аңларга тырыштым. Ниһаять, сер чишелде. Беренче көндәге мыгырдаулар белән икенче көнгеләре диалог булып чыкты бит. Менә тыңлагыз:

— Быел нәрсә яхшырак булыр дип исәплисең, хөрмәтлем?

— Чәйне күз алдында тотасыңдыр, дип уйлыйм.

— Әлбәттә.

— «Мең дә бер кичә», кадерлем, кичке намаздан соң мин шуны эчәм.

— Төнгә дисәң, эш башка. Ә иртән?

— Бохараның яшел чәен. Аннан яхшыракны эчкәнең юкмы?

— Әгәр Бохарада булсаң, аның суы һәм исен оныта алмыйсың.

— Гаҗәп, гадәттә син минем белән бик сирәк килешәсен.

— Кайчак хәтта су белән җил дә килешә алмый.

Ниһаять, кайчаннан бирле баш ватып эзләгәнемне таптым. Ләкин бу — математика фәне дәрәҗәсендә, җаваплары үзгәрүчән, ягъни билгеләр рәвешендә. Миңа исә бу билгеләр артына яшеренгән вакыйгаларны табарга кирәк.

Тик моны аңлаганчы, берничә еллар үтте. Карт исә мыгырдавында булды. Ул, кәефенә карап, әле үзенең бүгенге «мин»е, әле кичәге «мин»е белән сөйләшә бирде.

Зариф картның үлеме дә үзенчәлекле булды.

Карт, гадәтенчә, капка төбендәге эскәмиядә сөйләнеп утыра.

— Зариф, син «Аждаһа коесы» сортына ничек карыйсың? Беләм, син бу чәйдән Көнчыгыш Төркестанда авыз иттең. Зариф, нигә эндәшмисең? Нигә җавап бирмисең?, йоклыйсың мәллә? Шуның кадәр озак йоклап була дип уйламаган идем. Зариф, мине ишетәсеңме?

Карт берара тынып калды. Аннары, торып, өенә кереп китте, җеназа өчен кирәкле бар нәрсәне хәстәрләде, бер малайны, иртәгә ясин чыгарга килсен дип, муллага йөгертте.

Кичен исә Зариф карт өстенә үзенең өй түбәсеннән зур боз кантары төште. Соңыннан, шуны сизмәскә соң дип, үз-үземне озак битәрләдем. Үлем шулай үкенечле була инде, нишлисең.

Исламбәк Топчибаш сөйләгәннәрнең бик аз өлеше генә болар. Күп нәрсәне аңлап җиткермәсәм дә, үземнең карашымны белдерергә хакым бар дип санавым аркасында, безнең арада бәхәсләр дә кабынып ала. Аңлау дигәннән, бу турыда Мәхмүт Топчибашның үз фикере булган. Улы Исламбәк авызыннан ничек ишеттем, шулай китерәм:

«Чын-чынлап аңлау аңлашу нәтиҗәсендә килми. Ул үзеннән-үзе туа. Мәсәлән, шушы диалогны күз алдына китерегез:

— Ник кайчаннан бирле кулыңны кушырып утырасың?

— Чәч үстерәм.

Дөрес, мәгънәсез тоела. Ә мин диалогны менә болайрак аңлатам. Үсә сүзен, әлбәттә, чәчкә карата кулланып була. Чәч әкрен генә үсә-үсә дә, ниһаять, син теләгән озынлыкка җитә. Аңлый алмаганда да ашыкмаска кирәк. Көннәрдән бер көнне, чәчнең үскәнен күргән шикелле, аңламаган нәрсәңнең серенә төшенерсең».

Исламбәк Топчибаш өендә башланган әңгәмәләр, бәхәсләр кайчакларда конторда, йә булмаса юл уңаендагы кәһвәханәләрдә дә дәвам итте.

— Зариф карт ул — персонаж, аның кебекләрне тиз генә аңлап булмый, — ди ул, тәрәзәдән Галат күпере аша агылган халык ташкынына карап. — Әти дә, мин дә аны кызыклы шәхес дип санадык. Ни өчен икәнен беләсеңме?

Ул безнең тирәдә бөтерелгән официантка кәһвә китерергә кушты да сүзен дәвам итте.

— Чөнки Зариф карт, әйтерсең кулыннан эләктерә дә шундый урынга илтә, син анда үзеңнең киләчәгең һәм үткәнең белән сөйләшә аласың. Әтинең моңа исе китә иде. Хәтерлисеңме, аның хикәясендә чит-ят җил бар иде? Вакытлар узу белән, әти Зариф картның табигыйлыгына ышана барды. Инде картлык бусагасын атлагач, болай дигән иде: «Мисал өчен, бүлмәгә кереп булмый, ди. Киләчәк тә сиңа шулай тоелыр. Тик аңлап кына бетермисең: тырышсаң, барыбер үтә аласың. Әйтик, сәгатьне уятыр өчен иртәнге җидегә куясың. Бу — син иртәнге көнең белән бәйләнешкә кердең, дигән сүз. Яки чәй пешерәсең. Башта чәйнекне кайнар су белән әйбәтләп чайкыйсың, аннары озаклап чәй сайлыйсың, кашык белән үлчәп саласың.

Бөтен торышың белән шуңа йотыласың һәм үз-үзеңне тотуыңнан ярарга тырышуың күренеп тора. Кемгә? Үзеңнең киләчәгеңә — берничә минуттан бу чәйне эчәргә тиешле кешегә — сиңа.

Моннан тыш, таныш булмаган киләчәк белән дә үзара бәйләнеш булырга мөмкин. Берничә көннән генә (яки атнадан, айдан — кая язасың) укыячагын белгән хәлдә, дустыңа хат язасың. Әмма шуның кадәрле вакыт күчеше көтелсә дә, хат аласы кеше сине тыңлап торган шикелле, аңа хисләреңне бушатасың. Тагын шуны әйтим, язучы да кәгазьгә уй-фикерләрен төшергәндә киләчәк белән сөйләшә, чөнки ул үзенең әсәрен ун, хәтта йөз елдан соң да укыячакларына ышана.

Мыегыңа чорна: киләчәк белән бәхәстә — отасың, чөнки әле ул булмаган; ә үткән белән бәхәстә — оттырасың, ул безне үз иркенә буйсындыра. Соңгы сүз минеке дип уйлыйсың, әмма ул тиешле кешесенә барып җитә алмый һавада эленеп калырга да мөмкин. Леонардога кычкырып маташасың — ул дәшми. Ибн Рөшдигә яисә Габденнасыйр Курсавига мөрәҗәгать итәсең — тик алар синең белән сөйләшергә дә теләми. Киләчәк белән диалогларын алар:

— Мин инде әйтәсен әйттем, кабатларга теләмим, — дип кырт кисәләр.

Мавыгып киттем, ахры, — Исламбәк Топчибаш туктап, тын алды. — Әтинең бар фикерләрен әйтеп бетерү мөмкин түгел. Кызганыч, язып куя торган гадәте булмады.Үзенчә, һәр әйткән сүз ташка чокып язылган кебек, һавада да язылып калыр, дип уйлый иде.Әтием, төшенгәнсеңдер, башкалардан аерылып торган шәхес, аны Истанбулда, Иске Шәһәрдә һәм, гомумән, үзе булган җирләрдә әле дә хәтерлиләр.

Без кәһвәханәдә кечкенә чәшкәләрдән кәһвә йоткалап утырабыз. Кемнәрдер кальян тарта, залда зәңгәрсу төтен эленеп тора. Әкренләп тәрәзә артында караңгылык канат җәя. Килүчеләр дә артканнан-арта бара. Исламбәк Топчибаш аларның сәламнәренә, елмаеп, җавап кайтара.

— Беләсеңме, әти дә, картайгач, Зариф карт кебек үзалдына сөйләнә башлады. Күпләр «түбәсе китте Мәхмүтнең» дип санады. Әмма мин аның үзенең кичәгесе һәм үзенең иртәгесе белән сөйләшкәнең анлый идем. Менә, диалогын кесә дәфтәремә теркәп бардым, — дип, куен кесәсенә тыгылды. Тыңла:

— Мәхмүт, ишетәсеңме, мин сиңа шуны әйтергә телим?

— Әйе, кадерлем.

— Миңа синең тавышың ошамый.

— Киләчәкнең үз тавышы, Мәхмүт, әле аерырга өйрәнмәдеңмени?

— Мин сиңа шуны әйтергә телим.

— Әйт.

— Бервакыт безнең милләт үзенең киләчәгенә мөрәҗәгать итәчәк, әмма җавап ишетмәячәк.

— Син нәрсә сөйлисең, Мәхмүт?

— Күзләреңне ач, Мәхмүт.

Исламбәк дәфтәрен япты да кесәсенә шудырды.

— Сүзен сүзгә язып бардым.

Бертын сүзсез утырдык. Тирә-яктагылар нард, шахмат уйныйлар. Безнең янга официант килде:

— Исламбәк бәй, шахмат китеримме?

— Кирәкми, бүген бездә башка уй-ният, — диде ул, миңа күз салып. Бу уеннарның берсе дә миңа таныш түгеллеген чамалагандыр дип беләм. — Менә кәһвәдан баш тартмабыз.

Кәһвә китерделәр.

— Мин сине монда тикмәгә генә алып килмәдем. Игътибар иткәнсеңдер, Истанбулда кәһвәханәләр бик күп, чөнки мондагылар кәһвәсез тора алмый.

— Дөресен әйткәндә, бу эчемлекне аңлап бетерә алмадым, — дидем мин.

— Мөхәммәд пәйгамбәр бик каты авырып киткәч, аның янына Җәбраил фәрештә килеп, Кәгъбә ташы шикелле кара бер эчемлек эчергән, ди. Шуннан пәйгамбәр савыккан һәм көче артуын сизгән.

Исламбәк Топчибаш, сүзләрне шуннан тартып чыгаргандай, чынаяк төбендәге кәһвә куесына карап сөйләде..

— Бу эчемлекнең асылын аңламадым, дисең инде. Тирә-ягына кара әле.

Кәһвәханәдә бер буш урын да калмаган. Һәркем үзен өендәге кебек хис итә: сөйләшәләр, көлешәләр, кыскасы — шау-гөр киләләр.

— Йә әйт, тагын кайсы эчемлек шуның кадәр кеше җыя ала?

Тирә-юньдәгеләргә күз салгач, башка бер фикер килде: урманда агачлар бергә чайкалган кебек, мондагыларның чырайларында да ниндидер уртаклык сизелә.

— Беренче кәһвәханә 1554 елда Константинопольдә төзелгән. Аннары инде киткән... Ләкин...

Исламбәк Топчибаш сүзен бүләргә мәҗбүр булды. Якында гына шахмат уйнап утырган икәү нәрсәдәндер әләгешеп китеп, шактый зур гауга куптардылар. Тегеләр тынычлана төшкәч, ул җөмләсен дәвам итте.

— Кәһвәханәләрнең төтенле бүлмәләрендә җыелган халыкта гомуми фикерләр туарга мөмкин. Тәртипсезлек, чуалышлардан котлары очкан хөкүмәт башлыкларына мондый хәлләр ошамый, әлбәттә. Мәсәлән, солтан Мәхмүт Дүртенченең кәһвәханә тотучыларны һәм анда йөрергә яратучы ике йөзләп кешене җәзага тартырга кушуы билгеле. Икенче көнне үк шәһәрдәге бар кәһвәханәләрнең ишегенә йозак эленгән. Бу хәл исә кәһвәгә мөкиббәннәрнең чынлап та баш күтәрүләренә китерергә мөмкин. Моны аңлаган киңәшчеләре һәм вәзирләре хакимнең фикерен үзгәртә алганнар. Ярый әле теге үз кул астындагыларның сүзен җиргә салып таптамаган.

— Шулай, безнең монда килүебез тикмәгә генә түгел, — диде ул. — Чөнки сүз тагын әтием Мәхмүт Топчибаш турында барачак. Миңа калса, аның тормышыннан алынган вакыйгалар сиңа да кызыклы тоелыр.

Истанбулга килеп чыкканда Мәхмүт Топчибашка 26 яшь була. Аның бу Бөек шәһәргә килүенең сәбәбен хәзер тәгаен генә әйтеп биралмыйм. Бәлки игенчеләр белән бергә базарга килгәндер, эш эзләп килүе дә ихтимал, чөнки татар качакларына Анталия җирендә тормыш итү җиңел булмаган. Өстәвенә, гаиләсендә өч баласы бар. Мин иң олысы, ул вакытта сигез яшьтә булганмын.

Аның кесәсендәге акчасы кунакханәдә төн кунып чыгарга гына җитәрлек булган. Кичен кунакханәдә урнашкан кәһвәханәгә төшкән. Кеше шулкадәр күп, утырырга урын да калмаган. Нәкъ мондагы кебек, анда да шахмат уйнаганнар. Мәхмүт Топчибашның анарчы шахмат фигураларын, алар белән ничек йөреш ясаганнарын күргәне булмаган. Үзең дә аңлагансыңдыр, әти бик дулкынланган. Агачтагы сызыклар, акылы авышканнарның мыгырдаулары белән иләсләнгән кеше шахмат уены белән кызыксынмый каламы? «Өстәвенә, — диде әти соңыннан, — яхшы уенчы һәрвакыт мөмкин булган йөрешләрне алдан уйлап, киләчәк белән аралаша. Шахмат ул — символлар белән эш иткән математика фәненә тартым. Әмма кешеләр бу символларның табигый нигезе турында бөтенләй оныткаңнар. Ә бу табигый нигезнең үзендә киләчәккә күз салу мөмкинлеге бар».

Мәхмүт Топчибаш берничә көн рәттән кәһвәханәдән чыкмый

уенчыларны күзәткән. Көтмәгәндә, кайсыдыр аңа уйнарга тәкъдим иткән. Ул риза булган һәм, уенда җинеп чыккач, үзе дә шаккаткан. Аннары уен артыннан уен киткән, һәм аларның барысы да җиңү китергән. Кесәсенә акча керә башлагач, ул авылга кайту уеннан ваз кичкән.

Бервакыт уен барышында Мәхмүт Топчибаш үзендә кемнендер карашын тоя һәм як-ягына карана. Тәрәзә янындагы өстәл артында утырган әфәнде икән ул. Икенче көнне дә бу әфәнде шул ук урында кәһвә йоткалап утыра. Шулай берничә көн үткәннән соң, официант Мәхмүт Топчибаш янына килеп:

— Гаяз бәй сезнең белән сөйләшергә тели, рәхим итеп, аның өстәле янына барсагыз иде, — ди.

Бу шул — аны күзәтеп утырган әфәнде була. Әти үзенә тәкъдим ителгән урынга утыра.

— Гадәттә мин Бишекташта — өем янындагы кәһвәханәгә йөрим. Соңгы арада аягым никтер монда тарта, — дип сүз башлый Гаяз бәй. — Шәп уйныйсың. Күрәм: синдә тоемлау көче бар. Иртәгә иртән минем конторга сугыл әле, — ди.

Ул вакытта бу кеше турында бер ымы белән аккан елганы кире якка бора, кичке ашка тау йота, диңгезне эчә ала, дип сөйләгәннәр. Тагын көнгә берничә тапкыр киемен алыштырып, шуңа яраштыра иттереп исемен дә үзгәртә, — дигән сүзләр дә йөргән. Кәһвәханәгә һәрвакыт йөрүче берәү, Гаяз бәй ишек артындагы кешенең үзе кергәнче үк кем икәнлеген әйтеп бирә ала, дип әйткән, имеш.

Гаяз бәй — акчалы кеше. Әтием фикеренчә, мондыйлар өч төркемгә бүленә. Беренчесе — иң киң таралганы. Аңа акчаның ни икәнен аңлаган кешеләр керә. Икенчеләр теләкне акчадан алда куялар, иң сирәк очрый торган өченче төркем — теләктән алда нәрсә торганын аңлаучылар. Гаяз бәй соңгы төркемгә карый. Шулай итеп, ул Мәхмүт Топчибашның үзенә кирәкле кеше икәнен бер күрүдә сизә. Шуңа ярым надан авыл егете булуына карамастан, ул аны канаты астына сыендыра һәм фирмасында шактый җитди урын тәкъдим итә. Гаяз бәй ялгышмый: Мәхмүт Топчибаш бу эшне тиз арада үзләп, фирманың табышын икеләтә арттыра. Гаяз бәй кысмыр булмаган, яхшы хезмәткәрләре өчен акчасын җәлләмәгән. Берникадәр вакыттан Мәхмүт Топчибаш та баеп киткән, йорт сатып алган һәм Анталиядә калган гаиләсен алып килгән. Шулай итеп, без Истанбулда төпләнгәнбез. Тормышыбыз кискен үзгәрде — матур киенү, тәмле ашау мөмкинлеге туды. Фәкыйрьлеккә ияләшкән кебек, яхшыга да бик тиз ияләштек.

Гаяз бәй белән әтием шактый якынаеп, кичләрен Бишекташ кәһвәханәләренең берсендә шахмат уйнап үткәрделәр. Мин аларның уеннарын күзәтергә ярата идем. Башка уенчыларның күзләреннән бөркелеп торган хәйлә, мәкер дигән нәрсә аларда бөтенләй дә булмады. Читтәгеләргә алар уеннан битәр тыныч кына әңгәмә корып утыралар кебек күренгәндер.

— Әти Гаяз бәйне зур хөрмәт белән искә ала иде, — диде Исламбәк Топчибаш һәм чираттагы кыйссаны тәкъдим итте. Мин аңа үземчә «Гаяз бәй сандыгы» дип исем бирдем.

## Гаяз бәй сандыгы

Мин беркайчан да Гаяз бәйне ахыргача белеп бетерә алмадым.

Бервакыт ул мине өенә чакырды. Эш буенча аларда берничә тапкыр булганым бар иде, монысында да сөйләшү өчен чакыргандыр дип уйладым, чөнки сәбәпсез генә килер дәрәҗәдә якынаймаган идек әле.

Ул мине чәй эчү сылтавы белән кунак бүлмәсенә дәште. Ишектән кергәч, күзем стена буенда бастырып куелган Солтан Әхмәт мәчетенә охшатып ясалган кеше ярым биеклегендәге зур сәгатькә төште. Икешәр касә чәй

эчәргә өлгердек микән, сәгать дүртне сукты. Хәер, сукты дип әйтү дөрес булмас, бик матур көй яңгырады. Хуҗа сәгать эченнән ишетелгән бу көйне борынгы марш дип аңлатты.

— Алтын Урда язмышы хәл ителәчәк Туктамыш белән Аксак Тимер арасындагы каты сугышта шушы марш яңгыраган, — дип өстәде ул. — Музыкантлар барысы да кырылып беткән, әмма Туктамышның исән калган бер сугышчысы бу көйне отып алган. Ул, атына атланып, бу көйгә сызгыра-сызгыра, кыпчак далалары буйлап чапкан һәм балаларына тапшырган. Берничә гасыр буе далалар буйлап күчеп йөри торгач, көй Кемердагы сәгать остасына килеп ирешкән.

— Игътибар белән тыңлале, — диде ул. — Вакыт сынаулары да баса алмаган җиңү тавышларын ишетәсеңме?

— Әйе, аңа дала җиле белән сызгырган гавыш та өстәлгән димме.

— Синең булган егет икәнеңне белә идем. — Гаяз бәй канәгать елмайды. — Әйдә, мин сиңа бер сандык күрсәтәм, — дип, ул мине үзе белән барырга әйдәде. Өйдә исә адаша торган: бер бүлмә аша икенчесенә, аннары өченчесенә һәм башкасына үтәсе, ул арада бер-берсеннән тигез ераклыкта тәвә кошы йомыркалары яткан ике яклап ишекләр тезелеп киткән коридорга килеп чыгасың. Йомыркаларга аптырап каравымны сизеп, хуҗа, алары төрле хәшәрәтләрне, үрмәкүчләрне куркытыр өчен, дип аңлатты.

Ниһаять, иң ахыргы бүлмәгә кердек. Ул мине почмакта торган тимерләнгән бик зур сандык янына алып килде.

— Аксарай базарында сатып алган идем. Күрәсеңме, ничек матур эшләнгән?

Чынлап та, сандык искиткеч матур бизәкләр белән каплап алынган. Бераз сокланып торгач, хуҗа капкачын ачты. Аның буш икәнен күреп, Гаяз бәйгә аптыраулы караш ташладым.

— Менә кара, монда икенче төп бар. Аннары өченчесе, дүртенчесе китә.

— Барысы ничәү инде?

— Күпме булуы синең өчен мөһим түгел.

Өйгә китәр алдыннан:

— Шушы сандыкны күрсәтү өчен генә чакырган идегезмени? — дип сорадым.

Ул шаккатты:

— Нәрсә, бу азмыни?

Әгәр бер төшем белән бәйле булмаса, бу сандык вакыйгасы әллә кайчан башымнан очкан булыр иде инде. Гомерең буе төш күрәсең, әмма шулар арасыннан берничәсе (бәлки берседер?) генә хәтердә уелып кала. Бу төш тә бик озак вакытлар күңелемнән китми азаплады.

Гаяз бәй өендә йөрим икән. Кунак бүлмәсендәге Солтан Әхмәт мәчетенә охшатып ясалган теге сәгать янына килеп басканмын.Үзем дә сизмичә, андагы манараларны санарга керешкәнмен, имеш. Саныйм-саныйм — һич исәбенә чыга алмыйм икән. Ул да түгел, сәгатьтәге манаралар саны чынлыктагыга туры килми, имеш. Уянгач, хикмәтенә төшенергә маташтым. Соңрак аңладым: мәчет рәвешендәге сәгать чынбарлыктагының күчермәсе, төш — шулай ук, димәк, күчермәдән күчермә булганда, ялгышлык китәргә мөмкин икән.

Шулай итеп, Гаяз бәйнең өендә күпме йөргәнмендер, төштә вакытны чамалап булмый, иң соңгы бүлмәгә килеп тердем. Тик урынымнан кузгала алмыйм, башыма кереп оялаган нәрсәнедер күрми калдым дигән уй артка борылырга куша. Нишлим, әмергә буйсынып, әкрен генә кирегә киттем.

Бүлмәләрнең берсендә стена кырыенда, ниһаять, башта искәрми үткән караңгы чокырны күреп алдым. Якынрак килдем һәм аска таба төшеп киткән баскычны шәйләдем. Басмалар буйлап төшә башладым, моңарчы Гаяз бәй телгә алмаган аскы катка җиттем. Ишекләр тезелеп киткән озын коридор буйлап атлый торгач, икенче башына барып чыктым һәм шундый ук караңгы чокырга тап булдым. Баскыч буйлап тагын да аскарак төштем. Шулай берничә тапкыр дәвам итте: коридор буйлап барам да аска төшәм икән. Ниһаять, соңгы басманы атлауга, гаҗәпләнүдән катып калдым — кабат баштагы урынга килеп чыкканмын.

Кунакханә бүлмәсендә Гаяз бәйне очраттым.

— Аста ничә кат бар соң сезнең? — дип сорадым.

— Анысы синең өчен мөһим түгел, — дип җавап кайтарды ул.

Төшем шул урында өзелде. Нишлисең, әдәби әсәрдә тәмамлау булса, театрда пәрдә төшсә, кино беткәч, титрлар чыкса — төштә бу мәҗбүри түгел.

Ярар, төшләр турында күпкәрәк китте, ахры. Монысын да Гаяз бәйгә бәйләнешле булганга гына сөйләдем.

Истанбулда төпләнеп, Гаяз бәй фирмасында эшли башлагач, төштә генә күреп була дип уйлаган дөнья рәхәтенә чумдым. Миннән көнләшкәннәр: «Аңар женнәре дә булыша», — дип сөйләгәннәр. Әйдә, сөйләсеннәр. Минем исә көннәрем эш белән үтте: сөйләшүләр, килешүләр, очрашуларда сүз акча турында барды, табышлар саналды, һәр килер бүленде. Мин баш күтәрми эшләдем. Акча ару-талуны оныттырды. Миңа Анталиядән алып килгән гаиләмне — хатыным, өч баламны һәм туачак өч нарасыемны киендерергә, ашатырга-эчертергә кирәк. Соң, өчәү җитмәгәнмени, диярсез. Килешәм. Әмма каныбызда борынгыдан килгән, ыруың бетәргә тиеш түгел, дигән канун һаман үз көчендә иде әле.

Бар нәрсәм җитеш: өем, мине туендырган менә дигән эшем, балаларыма белем бирер мөмкинчелегем бар. Иртәгеге көнем өметле. Тик көннән-көн мине тынгысызлык били бара. Әйтерсең, бүлмәдән бүлмәгә нишләргә белмичә тинтерәп йөрим. Төшләремнең дә рәте китте, нигәдер үземне гел бәхетсез итеп күрәм. Көннәрең гел бертөрле үтә, шуңадыр, диярсең. Билгеле бер вакыттан соң мал-мөлкәт, байлык канәгатьләнү китерми башлый, аны даими яшәү мохите итеп кабул итәсең икән. Аннары үз-үзеңә ачынып сорау бирәсең: шушы идемени инде бар теләгем?

Ул елларда, ничектер, Сәетбәк ишан белән аралаша башладым. Ул миңа бер гыйбрәтле кыйсса сөйләде. Дөньяда бер адәм яшәгән. Бай булганга, җаны ни теләгән — шуны эшләгән. Төрле җирләргә сәяхәт кылган, кыйммәтле әйберләр, матур-матур хатыннарның мәхәббәтен, фәкыйрьләрнең төшенә дә кермәгән нәрсәләрне сатып алган. Әмма бервакыт тормышында кара полоса башланган, хәтта дөньядан туеп, үз-үзенә кул салыр дәрәҗәгә җиткән. Тора-бара бар мөлкәтеннән колак каккан: янгын чыгып, йорт-җире көлгә әйләнгән, байлыгы һәм җирләре сатлык адвокатының хәйләсе белән башка берәү кулына күчкән. Бер сүз белән әйткәндә, бар байлыгы җилгә очкан, һәм ул көч-хәл белән очын очка ялгап яшәргә мәҗбүр булган. Уйлана торгач, Аллаһы Тәгалә әүвәл борчу-хәсрәт биреп, шул юл белән үзен үлемнән коткаруына, тормыш өчен көрәшкәндә генә аның кадере булуына төшенгән.

Кыйссадагы каһарман урынына үземне куеп карадым. Бар малымны югалту — миңа файдага булыр идеме? Җанымны сыкратып торган тынгысызлыктан коткарыр идеме? Бу чагыштыру урынсыз икәнен беләм, чөнки мин булганыннан канәгать. Мин әле — беренче буын баймын. Тырнак астыннан элеккеге тормышымның пычрагы да чыгып бетмәгән.

Юк, күктәгеләр ихтыяры белән бүләк ителгән тук, житеш тормышымда түгел канәгать булмавымның сәбәбе.

Шулай аптырап йөргән көннәремнең берсендә, Жамалетдин исемле күренекле бер әфәнде төшке ашка чакырды. Аның белән мине сәүдә эшләре бәйли иде. Өстәл янында безнең даирәдән тагын берничә кеше утыра. Үзенең өстенлеген күрсәтү өчен, хужа күркәдән ким кабарынмады. Сүз дә юк, арабызда иң бай, иң атаклы Жамалетдин бәйнен моңа хакы бар, тик болай кылануы аны көлке кыяфәттә күрсәтә. Мин дә уенга кушылып, акчам һәм урын-дәрәжәмне күздә тотып, мөмкинлекләрем турында шапырынырга тотындым. Аннары саф һавага чыгып, Босфор дулкыннары, акчарлакларны күзәтеп торганда гына, үземнең нинди мыскыл хәлдә калуымны абайладым.

Кичерешләремне Сәетбәк бәй белән уртаклашкач, ул мине житәкләп диярлек өенә алып китте. Кулыма иске-москы тоттырды да:

— Ки! — дип боерды.

Хәерче киемнәренә төренеп, ишан кушуы буенча Эдирне-Капи зиратының капкасы төбендә утырган башка фәкыйрьләр янына чүмәштем.

— Тәкәбберләнмә, — диде Сәетбәк, — һәр үткән-барганнан хәер сораш.

Миләрне кайнатырлык эссе көн. Кулымдагы бакыр савытка чылтырап төшкән акча тавышына башымны күтәреп карыйм. Алдымда — бөтенләй икенче дөнья, астан өскә караганда кешеләр башка икән.

Хәер өстәп утырганда, үз алдымнан нинди генә йөзләр үтмәде: араларында хәлгә кереп жәлләүчесе, ярдәм итәргә теләүчесе белән рәттән жирәнеп карауучысы, бурычын гына үтәүчесе дә, бернәрсә аңлатмаучы жансыз чырайлысы да бар иде.

Көн азагында яныма бер кеше килде дә сыртыма камчы белән сыдырды. Авыртуга тешемне кысып түздем, чөнки бу адәмне Сәетбәк жибәрүенә шикләнми идем.

Бу хәлләрне башта ук уен кебегрәк кабул иттем, әмма никадәр генә кызык тоелмасын, ул да тормышымны үзгәртә алмады.

Берничә көн үземне тынычлангандай хис иттем, ишанның бу сабагы урынлы кебек тоелды. Тик танышларым белән очрашу, кеше арасына чыгу — мине янә элекке халәтемә кайтарды.

Нәрсә телим соң мин? дигән сорауга жавабым ап-ачык: миңа — тагын да күбрәк акча, дан һәм хөрмәт кирәк. Миңа карап башкаларның күзләре януын телим. Башкалардан өстен булу кирәк миңа. Шуннан ни? дип сорыйм үз-үземнән. Менләгән кеше нәкъ шуны тели.Тик эш башкада: андый теләкләрнең чикга ашмасын беләм, әмма, запойга киткән эчкече кебек, барыбер шул турыда гына уйлыйм.

Берзаман шуңа барып життем: зуррак уңышка ирешкән саен, шуның кадәрле үк бушлык тоя башладым. Түзмәдем — Гаяз бәй янына килдем:

— Мин Анталияга кайтырга булдым.

Ул кунак бүлмәсендә, кәнәфидә утыра. Солтан мәчетенә охшатып ясалган сәгать ике туларга унбиш минутны күрсәтә.

— Нәрсә, башлаган эшеңне ташларгамыни исәбең? — дип сорады Гаяз бәй.

— Әйе.

— Юкка. Аллаһы Тәгалә күрсәткән юлдан тайпылырга ярамый.

— Кайчак дөрес юлдан баруыбызга ышанып бетмибез бит, — дидем мин, карулашып.

Гаяз бәй урыныннан торып, бүлмә буйлап әйләнеп килде. Сүзне Истанбул кәһвәханәләренә, кальян тартуга борды. Миңа таныш булмаган кальян тартучыларның исемнәрен атады.

Ике тулганын искәртеп, сәгать эченнән көй агылды.

— Сәгать җидегә Рәхим кәһвәханәсенә кил әле, — диде Гаяз бәй.

Инде аның яклавына мохтаҗ булмасам да, чакыруын аяк астына саласым килмәде.

Кояш офык артына тәгәри. Шәһәрдә ут алганнар. Шул утлар яктысында күккә ашкан манараларга сокланып, Рәхим кәһвәханәсенә атлыйм. Ишектән керүгә, хезмәтче малай каршы алып, мине Гаяз бәй утырган өстәл янына озатып куйды. Кеше азлыкка гаҗәпләнеп, карана-карана, күрсәтелгән урынга утырдым.

Гаяз бәй, төтенгә уралып, ашыкмый гына кальян тарта. Үземнең ниятләрем турында әйтә башлауга, кулы белән ишарәләп туктатты да, миңа мундштук сузды.

Моңарчы татып карамаган төтенне эчкә суырдым. Ул арада янибызга кәһвәханә хуҗасы Рәхим килеп җитте. Бу кешегә карап, гомерен кояш яктысы күрми шушы дүрт стена арасында үткәрә, ахры, дип әйтерлек. Тән тиресе, төтен эченнән саркылган шәм ялкынына охшап, саргылтым төстә, ә кыркылган башы кипкән кабакны хәтерләтә, күзләре без кебек, сине үтәли тишеп карыйлар.

— Кальян ничек, шәпме? — дип сорады ул.

Җавапны Гаяз бәй бирде:

— Бүген төтене искиткеч.

— Кадерле кунакларым өчен генә тотам, күмердән тыш кипкән дөя тизәге өстим, — диде Рәхим. — Әтидән өйрәнеп калдым, ул аның остасы иде, чөнки аңарга солтанның үзе өчен әзерләргә туры килгән.

Без дәшми-нитми тартуыбызда булдык, Рәхим безне игътибар күрсәтелергә тиешле кешеләр санап, сөйләвен дәвам итте.

— Беренче карашка дөя тизәгенең искитәрлек берние юк сыман, әмма барысы да аның кайдан җыелган булуына бәйле. Әти әйтүенчә, иң шәп урын — Дәмәникъ белән Алеппо кәрван юлы уртасында. Елга бер тапкыр мин дә үз хезмәткәрләремне шунда җибәрәм. Шул алып кайткан җитә, чөнки кальянны чын-чынлап тарта белүчеләр әллә ни күп түгел. Менә, Гаяз әфәнде, сезнекенә, үтенечегез буенча, төелгән энҗе белән хуш исле үлән өстәдем.

Гаяз бәй, рәхмәтен белдереп, башын селкеде.

— Нәрсәсе белән шәп соң ул дөя тизәге? — дип сорадым мин.

Рәхим болай дип җавап бирде:

— Әкрен һәм озаклап черүе белән. Тыңлагыз әле, хөрмәтлем. Кеше гомерен мин йөгереш белән тиңләр идем. Йөгерәсең-йөгерәсең дә берзаман хәлең бетеп, атлар-атламас хәлгә киләсең, йә бөтенләй туктап каласың. Дөя тизәгенең черүе дә шуңа охшаш. Менә шуңа андый кальянны тартканда, дөянең салмак адымнарын тоясың, ди торган иде әти.

Рәхим, сүзен тәмамлап, хезмәтегезгә һәрвакыт әзермен, дип, китеп барды.

Берникадәр вакыт сүзсез генә кальян тарттык. Каршымда утырган Гаяз бәйнең төтен эченнән күренгән йөзе, Рәхим әйткәндәй, салмак кына селкенгән кебек тоелды.

Кәһвәханәгә әкренләп кеше җыелды, шау-шу да арта төште. Бар да дулкынланган, ни турындадыр сөйләшәләр.

— Хөрмәтлем, нәрсә булган? — дип сорадым күрше өстәлдәге иптәштән.

Аның әйтүенчә, озакламый монда империянең иң оста шахматчысы Гассан Мәмәт юл уңаенда кереп чыгачак икән. Бу хәбәрне ишетүгә, йөрәгем каты-каты тибәргә тотынды. «Әллә уйнап карарргамы?» — дигән

уй килде башыма. Тирә-ягымдагылар исә оста каршына кемне утыртырга дип бәхәсләшәләр. Берсе: «Мәхмүт Топчибашны!» — дип кычкыруга, бар да миңа борылды. Әгәр Гассан Мәмәт каршы килмәсә дип, ризалыгымны сиздердем.

Бөек шахматчы ике кеше озатуында килеп керде һәм тәкъдим ителгән урынга утырды. Бер чынаяк кәһвәсын да эчәргә өлгермәде, аны ир-атлар уратып алдылар һәм, кызып-кызып, ни турындадыр сөйләргә тотындылар. Уйнарга кыстадылар, ахры. «Мәхмүт Топчибаш...иртәгә көн белән...» дигән сүзләре генә ишетелеп калды. Гассан Мәмәт минем якка борылып карады. Бер генә секундка карашларыбыз кисеште. Аның кешеләре килеп, мэтрның минем белән уйнарга риза булуын белдерделәр.

Кара-каршы утырып, уенны башлап җибәрдек. Безне сырып алган ир-атлар тын да алмый уенны күзәтәләр. Колагымда Гаяз бәй өендәге сәгать чыгарган марш яңгырагандай булды. Кайчандыр ул Туктамыш белән Аксак Тимер арасындагы хәлиткеч сугыш алдыннан яңгыраган булса, бу юлы сугыш кыры шахмат тактасы белән алышынды.

Читтәрәк, ике кулын күкрәгенә кушырып, Рәхим басып тора. Ирен читенә эләгеп калган елмаюыннан, аның нәрсәдер белүе сизелеп тора.

Уен билгеләнгән вакытта тәмамланды. Мин оттым. Бу хәл һич көтмәгәндә булды: Гассан Мәмәт белән тамашачылар гына түгел, үзем дә шаккаттым. Тирә-якны шатлыклы тавышлар күмде. Оста, җиңелүен танып, кулымны кысты. Миңа мактау арты мактау яуды. Мин — җиңүче, сөенечемнән бер баш югары күтәрелдем, күктәгеләр исә минем хөрмәткә җиңү маршын уйнадылар. Дулкынланган тамашачылар кулларына күтәрделәр, йөзләгән, меңләгән куллар мине күккә чөйделәр. Дулкынланудан җир белән күкне аермас хәлгә җиттем. Аннары барысы бергә төтенгә әйләнде. Төтен эченнән Гаяз бәйнең йөзе күренде. Ул элеккечә минем каршымда утыра һәм ашыкмый гына кальян тарта.

Мин, аптырап:

— Гассан Мәмәт кайда? — дип сорадым.

— Кем соң ул? Беренче тапкыр ишетәм, — диде ул, гаҗәпләнеп.

Тирә-ягыма каранам. Бар да, тыныч кына гәпләшеп, кәһвә эчәләр. Миңа игътибар итүче дә юк.

— Бүгенгә җитәр, — дип, урынымнан тордым да Гаяз бәй белән саубуллаштым.

— Кая ашыгасың, — диде ул, гаҗәпләнеп. — Иртә бит әле.

Урамга чыккач, күкрәгемне тутырып, диңгез һавасы суладым. Кояш инде баткан, куе караңгылык эченнән манаралар чак-чак кына шәйләнә. Йөрәгем тынычланып җитмәгәнгә, извозчик яллап тормадым, җәяү генә атларга булдым.

— Кирәк бит, ә, үзеңә-үзең зыян салу аркасында нинди генә хәлләргә юлыкмыйсың!

Янымнан үтеп баручының сүзләрен ишетеп:

— Сез нәрсәне күз алдында тотасыз? — дип сорарга мәҗбүр булдым.

— Нигә чит кеше сөйләшкәндә тыгыласыз? — диде ачулы тавыш. Борылып карасам, аның янында иптәше бар икән. Гафу үтенергә туры килде.

Салкынайтып җибәрде. Йөзләрчә тапкыр үтелгән юл, тизрәк өйгә кайтыр өчен адымнарымны кызулатам.

Артымда кемнеңдер мышнаганы ишетелде.

— Туктагыз! — дигән тавышка артыма борылдым. Тыны кысылган берәү мине куа килә иде.

— Мәхмүт әфәнде! — диде ул, көчкә сулышын алып. — Без сезне инде

көне буе эзлибез. Әле генә Рәхим кәһвәханәсеннән өйгә кайтып китүегез турында әйттеләр. Сез хәзер үк солтан сараена барырга тиешсез.

Ул арада яныма югары даирә кешеләре генә утырып йөри торган экипаж килеп туктады.

Тәкъдим ителгән урынга утырдым. Яныма әлеге адәм урнашты.

— Кузгал! — дип боерды ул кучерга.

Экипаж алга ыргылды.

— Вакытыгыз бик аз, — дип аңлатты озатучым. — Белмим, ничек шулай килеп чыккандыр, сезгә вакытында хәбәр итә алмаганнар. Гафу сорыйм.

Яңа гына тынычлана төшкән йөрәгем кабат урыныннан купты. Тирә-якка карангалап, кая таба баруыбызны чамаларга тырышам. Элек якынына да килү тыелган җирләрдән бара торгач, каравыл каланчасы янына җиттек. Сакчылар, берсүзсез, солтан сарае урнашкан территориягә үткәреп җибәрделәр. Аны-моны абайлап өлгергәнче, экипаж матур итеп уелган биек ишекнең зиннәтле баскычы янына килеп тә туктады.

Каршы алырга чыккан хезмәтчеләр шунда ук безгә ташландылар. Берсен-берсе бүлдереп:

— Тизрәк! Хәзер сезне чакырачаклар, бер генә секундка да соңларга ярамый! — диештеләр.

Мине, ашыктырып, зур залга алып керделәр. Зал уртасында рәтләргә тезелеп, таныш түгел кешеләр басып тора.

— Урыныгыз менә монда, — дип, бер хезмәтче мине сафның иң башына китереп бастырды.

Нәкъ шул вакытта минем исем яңгырады:

— Мәхмүт Топчибаш!

Каршыма империянең югары хәрби дәрәҗәсе — генерал формасы кигән берәү килеп басты.

— Солтан хәзрәтләре әмере буенча, — диде ул, — сез «Ватан алдындагы хезмәт өчен» ордены белән бүләкләнәсез.

Көчле алкышлар астында, аяк астындагы җир авышкандай тоелды. «Ниһаять, теләгем кабул булды, барысы да хаклы рәвештә», — дип сөендем мин, күкрәгемә таккан орденны сыйпап.

Оркестр тантаналы марш уйнап җибәрде. Шулвакыт залның ерак почмагында ике кулын күкрәгенә кушырып торган Рәхимгә күзем төште. Гадәттәгечә, аның ирен кырыйларында саран гына елмаю ябышып калган. Маршны игътибар белән тыңлыйм, анысы Гаяз бәй өендәге теге зур сәгать эченнән чыккан көй икән. Ул да түгел, бар да төтенгә әверелде, һәм каршымда кабат Гаяз бәйнең йөзе калкып чыкты. Мин әле һаман да аның белән Рәхим кәһвәханәсендә кальян тартып утырам икән.

Исемә килеп, күкрәгемә таккан орденга кулымны сузам — ә анда берни юк. Гаяз бәй барысын да аңлагандай елмайды.

— Житәр! — дидем дә, саубуллашып, кәһвәханәдән чыгып киттем.

Шәһәрне караңгылык чорнап алган. «Кемгә саный ул мине, — дидем мин урам буйлап барганда, Гаяз бәйгә үпкәләп. — Минем белән шаярырга сабый бала дип белдеме әллә?»

Солтан сараена алып киткән юл буенча барырга теләмичә, чаттан борылып икенче урамга төштем. Озакламый тынычлана төштем. «Нәкъ самавыр кайнап чыкканда өйдә булам», — дип уйладым. Сәгать тугыз тулып килә иде.

Юлымда Җамалетдин конторы калкып чыкты. «Дөрес, ул шушы урамда урнашкан». Ишек төбендә исә, кемнедер көткәндәй, хужа үзе басып тора. Ул:

— Рәхим итегез, үтегез, — дип керергә кыстады.

Үзем дә сизмәстән риза булдым. Конторда ике хезмәткәр, хуҗаларының әмеренә әзер кыяфәттә эш өстәле артында утыралар.

Җамалетдин миңа:

— Менә хәзер саныйбыз. Кайсыбызның акчасы күбрәк икән, — диде.

— Синең бу тәкъдимең миңа ошамый, — дип, аңар каршы төштем.

— Нәрсәгә бер-беребезне алдарга? Икебез дә читкесәдәге табышны санап, төннәрен йоклый алмый ятабыз бит. Әйдә, акчаларны саныйк та, шунда нокта куйыйк.

Санарга тотындык. Безгә ике хезмәткәр ярдәмгә килде. Берсе сөяктән ясалган хисап төймәләрен чалт-чолт китерсә, икенчесе кәгазьдә нәтиҗәне билгеләп бара.

Җамалетдин белән шулкадәр кызып киткәнбез, әйтерсең лә сүз кеше гомере турында бара. Банктагы счетлар, акцияләр, күчемсез милек, кыйммәтле әйберләр, кулда булган акча һәм башкалар — берсен дә күз уңыннан төшереп калдырмаска тырышабыз. Әмма боларны тикшереп карау мөмкин түгел, чөнки янәбыбызда банк күчермәләре дә, күчемсез милек исемлеге, кулдагы акчаны раслаучы берниндидокумент булмау сәбәпле, без аларны хәтердән генә әйтәбез.

Барып чыкмас эшкә тотынуыбызны абайлап:

— Җамалетдин, болар бар да — юкны бушка аудару, — дидем. — Мин бит саннарны кубайтып, сине алдый да алам.

— Юк, син алай эшли алмыйсың. Беләсеңме нигә? Синең миннән баерак икәнеңне исбатлыйсың килә. Әмма миңа түгел — үзеңә. Шуңа алдавыңның мәгънәсен күрмим.

Аның белән килешми чарам юк, һәм без эшебезне дәвам иттек. Күпмегә сузылгандыр, тәгаен генә әйтә алмыйм, тик барыбер очына чыктык. Хезмәткәрләр нәтиҗәләрне чагыштырып, җиңүчене игълан иттеләр.

Тагын мин оттым. Бу шулкадәр көтмәгәндә булды ки, йөрәгем күкрәгемнән сикереп чыгар хәлгә житте. Күңеле төшкән Җамалетдинны юатырга кирәклеген аңлыйм, әмма шатлыклы хисләр күзләремне томалады, куанычымның иге-чиге юк, сөенеч дингезендә йөзәм һәм шунда контор ишеге төбендә кулларын күкрәгенә кушырып басып торган Рәхимне күреп алам. Караңгы булса да ирен читенә кунган елмаюын да сизәм.

— Рәхим, син монда нишлисең? — дип соравыма, бар дөнья төтенгә күмелде, һәм үземнең кабат Рәхим кәһвәханәсендә утыруымны абайладым. Каршымда исә — Гаяз бәй.

Бу юлы инде кәһвәханәдән саубуллашмый-нитми генә чыгып киттем. Гаяз бәй, синме соң бу дигәндәй, гаҗәпләнеп карап калды. Урам буйлап барганда башыма килгән беренче уй: «Әгәр ул бернәрсә дә белмәсә?» булды.

Юл сайлап-нитеп тормый өй ягына карап атладым. Бераз баргач, адашканымны аңладым. Бар урамнар күптән инде аркылыга-буйга гизеп чыгылган, шуңа бу хәлгә аптырадым. Карана торгач, сәбәбенә төшендем: моңарчы аяк басмаган ишегалдына кергәнмен икән. «Борчылырга урын юк, — дип уйладым. — Менә стенадагы арка аша чыгам да өйгә кайта торган таныш юлга басам».

Арка аша үтәргә теләп алга атладым, әмма күпме генә барсам да аның очы-кырые күренмәде, таш тишеп салынган туннельдән барган кебек атлыйм да атлыйм. Адым саен караңгылык та куерганнан-куера бара.

Бераздан алда тонык кына ут яктысы күренде, тавышлар да ишетелгәндәй тоелды. «Әһә, урамга чыгам икән», — дидем мин, куанып. Яктылыкка таба йөгерә-атлый киттем. Гаҗәпләнүемә, арка мине урамга түгел, ә кеше җыелган ниндидер бер зур бинага чыгарды. Халык җыелыштагы кебек рәт-рәт утырган

да карашын сөйләүчегә төбәгән. Беренче рәттә буш урындык күреп, кыяр-кыймас кына барып утырдым. Як-ягыма каранам: залда руханилардан тыш, европалыларга хас киенгәннәр белән рәттән мөселман киемендәгеләр дә бар, димәк, минем уйлавымча, монда укымышлы халык җыелган.

Тынычланып, сүзләренә колак салам: залда нindидер аз санлы халык һәм аның хокуклары турында бәхәс бара икән. Тегеннән дә, моннан да кычкыралар, кайберләре урыннарыннан сикереп торып, үз фикерләрен белдерәләр. Берзаман шау-шу күтәрелеп, берни ишетелмәс булды. Шулвакыт кемдер:

— Ә сез ни әйтерсез, Мәхмүт Топчибаш? Без мондыйларны төп халык дип саный алабызмы? — диде.

Зал кинәт тынып калды. Бар да, кызыксынып, минем җавабымны көтте. Мин әкрен генә торып бастым да болай дидем:

— Авызда тешләр төп хуҗа булган кебек, бу дөньяда теләсә кайсы халык төп халык була ала.

Кинәт тынлыкны көчле алкышлар өзде, хуплау сүзләре яңгырады.

Зал өстеннән күз йөртеп чыктым да үземнең билгеле бер шәһәр оешмасының утырышына эләккәнемне аңладым һәм сүземне дәвам иттем. Залда утырган сәнгать әһелләре, язучылар, философлар һәм башкалар һәр сүземне игътибар белән тыңладылар.

Шулвакыт залның ерак почмагында сизелер-сизелмәс елмаеп һәм кулларын кушырып Рәхим басып торганын күрдем.

Мине алкышлаган тавышлар әкренләп төтен эчендә эреп югалды, инде аңлагансыздыр, мин элеккечә, Гаяз бәй белән Рәхим кәһвәханәсендә утыруымны дәвам итәм икән.

Янәдән кәһвәханәдән чыгып киттем һәм чираттагы маҗарага юлыктым. Бу юлы мине ишек артында көтеп торганнар диярсең. Гаяз бәйнең өенә килеп эләккәнмен. Әле өске катка менәм, әле аскысына төшәм. Ул арада кайсы каттадыр колагыма сәгать чыгарган көй чалынып кала. Белмим, катлар арасында күпме йөргәнмендер, сизелер-сизелмәс елмаеп, шул ук кыяфәттә басып торган Рәхимне ничә тапкыр очратканмындыр — әмма бу тозактан котылыр әмәл таба алмадым. Ул арада мине теге сандыкка салдылар, аның исә төбе артыннан төбе алышып тора икән. Тинтерәп беткәч кенә башымда: «Теге чактагы кебек иң аска төшәргә кирәк, аннары ишектән чыгуга, өске катка эләгәм бит», — дигән уй килде. Килде һәм шунда ук онытылды да.

Газап чигүләрем дәвам итте. Юлым әле бер, әле икенче җиргә килеп чыкты: берсендә алкышлар эләксә, икенчесендә көнләшеп үзәгемә үттеләр. Ахыр чиктә чынбарлыкка бөтенләй ышанычым калмады. Артымда алкышлар ишеткәч, Рәхим янына килгәнем генә истә калган.

— Болар — бар да ялган, шулаймы? — дип сорадым кебек.

Җавапка ул башын селкеде.

Тагын каршымда Гаяз бәйнең йөзе пәйда булуы истә. Аннары кайда чынлык, кайда юк икәнен тикшерерлек хәлем калмаганга, саубуллашырга уйладым.

— Сау бул, кадерлем, — диде ул. — Онытма, иртәгә иртән көтәм.

— Әгәр «иртәгә» һәм «иртән» булса, тугыз да утызда килермен, — дип, кәһвәханәдән чыктым да өйгә юнәлдем.

Дөм караңгы, өстәвенә вак яңгыр сибәли. Кулчатырым кәһвәханәдә онытылып калган, әмма кире борыласым килмәде.

Ниһаять, өемә кайтым җиттем. Гаиләм һәм туган-тумача ишегалдына чыгып каршы алды. Мине күргә, алар, нindидер сер яшергәндәй, чыш-пыш килделәр.

— Син югында шәһәр ратушасы курьеры хат китерде, — диделәр.

— Нинди хат тагын? — Бертуганымның улыннан хатны кычкырып укуын сорадым.

Үсмер конвертны ачты да шәһәр советы җибәргән язуны укыды. Анда мин, ягъни Мәхмүт Топчибаш, җәмгыять файдасына игелекле хезмәтем өчен — хезмәтләрем санап кителгән — исемле медаль белән бүләкләнәм, шулай ук мина шәһәрнең мактаулы кешесе дигән исем бирелә, диелгән. Моннан тыш, солтан сараенда булачак тантаналы мәҗлескә чакырылам. Тирә-ягымда ишетелгән кул чабуларга һәм мактау сүзләренә битараф калдым. Лач итеп бер төкердем дә артыма борылдым: кайдандыр Гаяз бәй сәгате чыгарган марш янгырады. Игътибар белән тынлап торганнан сон, көйнең билгеле бер урыннан ишетелүенә төшендем, димәк, анын башлангыч ноктасы бар. «Дөньяда бар нәрсәнең башлангыч ноктасы була», — дип, сөйләнә-сөйләнә, көй ишетелгән якка атладым һәм өемә килеп кердем. Кунак бүлмәсенең почмагында Солтан Әхмәт мәчетенә охшатып ясалган Гаяз бәйнекеннән бераз кечерәк сәгать басып тора — көй шуннан чыга икән.

Өйдәгеләрнең кайсыдыр сәгатьне көндез Гаяз бәй бүләк итеп китергәнен әйтте. Бүлмәләр буйлап әйләндем дә, якыннарымны хафага төшереп, ишегалдына чыктым. Нәрсәдер җитми сыман. Бераздан аңладым: Рәхимне эзләп йөрүем икән.

Күкрәгемне тотырып, диңгез һавасы суладым һәм чынлыкта, өске катка тиң түбәндәге катта икәнемне аңладым.

Исламбәк Топчибаш кыйссасын тәмамлады да, әле генә сөйләгәннәрен хәтер иләге аша уздыргандай, алдына карап, бермәлгә сүзсез калды.

— Бу хәлләрдән сон, әтием сүзләренә караганда, анын тормышы үзгәргән һәм ул тынычланып калган. «Иң мөһиме — Аллаһы Тәгалә бастырган тормыш юлындагы хакыйкатьне табу», — диде ул мина. Бераздан ул үз бизнесын булдыра. Гаяз бәй аңа каршы килми, киресенчә, бик нык булыша.

Әти мина үзенә үтәргә туры килгән катлар турында менә нәрсә диде: «Катлар күпме кирәк — шунын кадәрле булды: без бер дә кирәкмәгән нәрсәләргә зур әһәмият бирәбез. Әмма бар нәрсәгә күз йому — шулай ук дөрес түгел. Килеш тә, башынны селке. Һәм бервакытта да шуны онытма: өске катка тиң түбән кат бар. Нәкъ менә шунысында күзләрен барысын да күрә, колакларын ишетә».

**IV бүлек**

Хикәямне өзеп торырга мәҗбүр булдым, чөнки, кадерле укучым, буталып, югалып калуыннан куркам — сөйләүчеләр күбәеп китте дә, кайчакта кем кемгә ни сөйләгәнен аңлап булмый башлады.

Барысын да үз урыннарына куярга телим. Менә сезнең алдыгызда — төп сөйләүче. Кулымда — магнитофон, анын тасмасына юлдашым профессор Сарман Биги сөйләгәннәр язып барыла. Ул мина үз тормышында булган хәлләрне башка вакыйгалар белән аралаштырып бирә. Атап әйткәндә, монда Исламбәк Топчибаш килеп керә. Ул әтисе Мәхмүт Топчибаш турында, әтисе үз чиратында серле, ахыргача аңлашылмас Гаяз бәй турында сөйли.

Кадерле укучым, сине кабат башлангыч ноктага кайтарам. Тәрәзә аша Россиянең урта полосасы басу-кырлары, агачлыклары күренеп кала. Ә мин бар дикъкатемне Истанбул һавасын суларга өлгергән юлдашыма күчерәм.

— Вакытлар узу белән кайбер нәрсәләрне аңладым, — дип дәвам итте ул. — Әйткәнемчә, безнең тормыштагы төп геройлар нинди дер геометрик фигура, төгәлрәге — күппочмаклык тәшкил итә. Бер күзәтүем белән уртаклашасым килә. Әгәр алдыбызда максаты булган кеше икән, димәк,

аның күппочмагы — дөрес һәм тәртиптә. Тагын шунысын да әйтим: бу күппочмакның кайбер биеклекләре тормышындагы персонажлар булмаска мөмкин, шулай да алар аңа ачыклык һәм төгәллек бирәләр. Минем өчен ул биеклек Мәхмүт Топчибаш булды. Аның турындагы вакыйгаларның халык күңелендә калып, телдән телгә күчә баруы нык тәэсир итте.

Мәхмүт Топчибаш бу вакыйгаларны улы Исламбәккә сөйләгән, ә ул, үз чиратында — миңа. Исламбәк Топчибаш — минем укытучым, остазым, ә тәрбиянең иң яхшы ысулы — сабак алырлык кыска гыйбрәтле хикәяләр.

Әле әйтергә өлгермәдем, хуҗамның өч кызы бар иде. Көннәрдән бер көнне шуларның берсен миңа хатынлыкка тәкъдим итте. Бу вакытта инде безнең дуслыгыбыз нык, мөнәсәбәтләребез ата белән улны хәтерләтә иде. Риза булдым һәм Фатыймага охшаган кызын сайладым.

Фатыйманы әле дә булса төшләремдә күрәм. Ул һәрвакыттагыча өермә арасыннан килеп чыга да куеныма елыша. Кочаклашкан килеш озак басып торабыз, ә усал җил безгә комачауламый әйләнеп уза.

Бу адымым аңа хыянәт итү булгандырмы-юкмы — анысын күктәгеләр генә әйтә ала — һәрхәлдә, Фатыйма мине кичергәндер дип уйлыйм.

Сез тормышымда яңа сәхифә ачыласын кызыксынып көтәсездер. Гомер иткән хатыным турында тизрәк ишетәсегез киләдер. Әмма күңелегез төшәсен белсәм дә, ул хакта сөйләмәскә булдым, чөнки алдагы бүлекләрдә Фатыйма күп телгә алынды. Ир-атның гомерендә бер генә хатын-кыз була дип исбатларга теләүдән түгел — юк. Мин ялгыз түгел — шунысын гына әйтә алам.

Шулай итеп Исламбәк Топчибаш белән туганлаштым.

— Мин һәрвакыт малаем булуын теләдем, — диде ул гәпләшеп утырганда. — Аллаһы Тәгалә миңа өч кыз бирде. Менә инде уллы да булдым. Әгәр чынлап теләсәң, теләгең күктәге исемлеккә теркәлә дә иртәме-соңмы үтәлә икән.

Аның бу сүзләре уйга салды. Ә мин нәрсә телим соң? Минлебай Атнагуловны үле килеш күрергә телим. Тагын? Туган илемә кайтырга!

Уемны укыгандай, хуҗам:

— Никадәр генә еракта булса да, дошманыңны очратмый калмыйсың. Юлларыгыз барыбер кисешә. Туган илеңә дә кайтачаксың. Күзләрең тулы сагыш күктәгеләрне битараф калдырмас.

Хәзер, ярты гасырдан соң, сүзләренең дөреслегенә ышандым. Чыннан да, Минлебай Атнагулов белән күзгә-күз очраштык, әмма бу турыда аз гына соңрак. Ә Туган илгә килгәндә... Хәзерге минутларда мин өемә кайтып киләм. Поезд туган ягым белән кавыштырыр өчен, ашыга-ашыга, чакрымнар саный. Тиздән төшләремә кереп йөдәткән авылымны күрәчәкмен, инде аның хуш исле саф һавасын сизәм, өрәкләр аланындагы тавышларны ишетәм.

Кайда калдым әле? Әйе, шулай итеп, күчмә тормышыма нокта куелды, Истанбулда төпләндем. Өйләнүем турында беләсез, балаларым туды. Мин бу шәһәр кешесенә әйләндем, үпкәләрем көндез Кара диңгездән, кичен Ак диңгездән җил алып килгән һаваны сулады.

Чит йортка урнаштым, ә ул мине туганы кебек кабул итте. Тормышым җайга салынды, янымда һәрвакыт бер үк кешеләр, бер үк әйберләр. Әмма мондый рәхәтлекнең дә кыен чаклары була икән. Мәхмүт Топчибаш белән дә шундый хәл булган, хәтерлисездер? Яшермим, минем дә җанымны кая куяр урын табалмаган көннәрем булды.

Кунак бүлмәсеннән Гаяз бәй бүләк иткән сәгатьнең сукканы ишетелә. Һаман бер көй, дөресрәге, марш яңгырый. Күпме еллар узган, әмма вакыт тузаны марштагы кеше һәм җил сызгырган тавышны күмә алмаган.

Мин тәрбиягә тиз бирелә торган кеше, чит тәҗрибә, сүз һәм ишеткән

гыйбрәтле кыйссалар, һичшиксез, күнелемә кереп урнаша. Шунадыр, яна тормышыма тиз күндем, аны ничек бар — шулай кабул иттем. Табышны тагын да арттыру турында баш ватканда, хужам:

— Әтием Мәхмүт Топчибаш башлы булган, әмма белем алырга туры килмәгән. Мине укытырга тырышты, тик уку мине канәгатьләндермәде, чөнки фәннәр өйрәнүгә вакыт аз калды, күбрәк Корьән ятладык. Хәзер укыту башка. Синдәге омтылышны күрәм, укы, белем ал! — дип, мине университетка керергә күндерде. Анын мина, киләчәгемә битараф булмавын сизәм. Югыйсә, ул — акча кешесе, ә андыйлар, гадәттә, эшен дәвам итәсе кешесенен белемлеме-юкмы икәненә төкереп тә бирмиләр. Хәзер анын белемле итәргә теләвен искә алам да ниндидер закончалык күрәм. Хужам белән очрашу, кызына өйләнү, аннары Университет — бу чылбыр ахырда мине дошманыма алып киләчәк, аннары — Туган илемә.

Исламбәк Топчибаш белән очрашу — язмыш бүләге. Ул башкаларга караганда алдан күрә белүче кеше буларак, мина кирәкле юлны күрсәтә белде.

Шулай итеп студент эскәмиясенә утырдым, төгәлрәк әйткәндә, Истанбул университетынын тарих һәм хокук факультеты студенты булдым. Баштарак уку авыр бирелде, чөнки күпме вакытым юлларда үтте, баш исән калу турында уйлаганда, башка мәшәкатьләргә урын калмый икән. Әмма кеше бер тотынса — чытырдатып ябыша; ничек итсә итә — максатына ирешә. Әйткәнемчә, мин тәрбиягә җинел бирелүчеләрдән. Бер язучынын мондый сүзләре бар. «Бар парадокс шунда: тәрбиягә мохтаҗ булмаганнар тәрбиягә җинел бирелә». Мин, чыннан да, язучы әйткәнчә, тәрбиягә мохтаҗ түгелмен: сөйләгәнгә, чит тәҗрибәгә сизгер, үземне житлеккән шәхес дип әйтә алам. Өстәвенә, әле минем дистәләгән төгәл фәннәр өйрәнәсем, йөзләгән фикерләр ишетәсем, меңләгән китаплар укып чыгасым бар.

Ул вакытта Истанбул университетында ватандашым профессор Садри Максуди дәресләр бирә иде. Россия думасынын элеккеге депутаты, барып чыга алмаган татар республикасына нигез салучы, большевиклар тарафыннан эзәрлекләнгән милләтче Максудига Россиядән чыгып качмый чара калмаган. Берничә ел каңгырап йөргәннән сон, ул Франциягә килеп чыга. Озакламый аңа Сорбоннада кафедра тәкъдим итәләр. Бәлки профессор Максуди үзенең гомерен тыныч, ипле кабинеты тәрәзәсеннән Монмартр өстендә уйнаклаган күгәрченнәрне карап үткәргән булыр иде дә — тиздән аны Ататөрек үзе Төркиягә чакыра. Яшь республикага Максуди кебек шәхесләр сулар һава кебек кирәк вакытлар, тиз арада ул, фәнни тикшеренүен җәмгыятькә хезмәт итү белән берләштереп, төрек парламентынын ин актив депутатларыннан берсе булып таныла.

Фәнни хезмәтләренә килгәндә, анын төрек тарихы буенча китаплары, шулай ук лингвистика һәм хокук дәресләре буенча Төркиядә билгеле дәреслекләрен әйтә алам.

Шулай итеп, чираттагы укытучым — ватандашым Садри Максуди булды. Без бер-беребезгә тартылдык, безне үткәнебез, дингез артында калган Ватаныбыз бәйләде. Ә дингезнең бу ягы — кайчандыр яхшы тормыш эзләп килгән һәм мәңгегә бирелә ятып калган качакларныкы.

«Мәңгегә» дигән сүз безгә бик авыр тәэсир итә. Кайчан да булса туган якка кайтырбыз дигән уй белән янсак та, бу турыда кычкырып әйткәнебез юк. Профессор Садри Максудига исә туган илне күрү насыйп булмады. 50нче елларда анын Босфор ярынын ин биек җиренә басып, өе ягына кузгалган корабларны озатып калуы әле дә хәтеремдә. Соңгы көннәре якынлашуын сизенгән ватандашымның күзләре тулы моң, яшьләре түгеләм-түгеләм дип тора — һәм ул моны яшерүне кирәксенми дә иде.

Ярның ни өчен иң биеген сайлавын аңлыйм. Исегездәме, хикәямнең I бүлегендә өрәкләр аланы турында сөйләгән идем. Каракучкыл су алып киткән авылдаш ир-атларның рухлары шунда кайтып урнаша, дидем.

Безнең һәркайсыбызның үз «өрәкләр аланы» бар, дип уйлыйм һәм ул, әлбәттә, бары тик Туган илдә генә була ала. Садри Максудиның рухы да андый алан барлыгын белә, иртәме-соңмы шунда кайтып урнашасын исәпкә алып, кайтыр юлны кыскарту өчен иң биек ноктаны сайлаганын аңладыгызмы инде? Ул көн килде: профессорның рухы диңгез өслэтеп туган якка очып китте, ә төрек байрагына төрелгән гәүдәсен (бу илдә аеруча хөрмәт итүне аңлата) саубуллашыр өчен Сөләйман мәчетенә алып килделәр.

Бу күңелсез вакыйгалардан профессорның көче ташып торган чагына әйләнеп кайтасым килә. Ул мине Сорбоннада хокук курслары узарга күндерде. Әйтергә кирәк, Садри Максуди бик чуар йөрәкле кеше, күп җирләрне күргән, педагоглык талантына ия буларак, укучыларына белем бирүдән тыш, үз карашларын да сеңдерергә тырышты.

Алга таба әлеге дә баягы Максуди таләбе буенча фәнни карьерамны инде Берлин университетында дәвам иттем. Башка бик күпләр шикелле, озак вакытлар Берлин белән Истанбул арасында килеп сарып йөрдем.

Берлинда яшәгәндә, ничектер, картиналар галереясына кердем. Галерея бинасы мин еш була торган Гете институты бинасына тоташкан булгангамы, әллә институтның бер залында картиналар күргәзмәсе оештырылган идеме — төгәл генә хәтеремдә калмаган. Хәер, анысы мөһим түгел. Шулай карап йөргәндә, бер картина янында тораташтай катып калдым. Мин анда туган авылым Айны күрдем. Хатын-кыз күкрәгеме хәтерләткән ике калкулык, калкулыкта урнашкан авыл. Ялгышу һич мөмкин түгел, мин һәрбер өйне, аның хуҗасын биш бармагым шикелле беләм. Менә монысы — Солтанәхмәт Сакаев йорты, тегесе — Гайнан Яушевныкы, астарак елга, әнә, офыкка барып тоташкан Кара урман. Сулышым кысылып:

— Картинаның авторы кем? — дип сорадым хезмәт күрсәтүчедән.

— Уң якта түбән почмакны карагыз әле, — диде ул. — Анда исем-фамилиясенең баш хәрефләре куелган бугай.

Ашыга-ашыга шул почмакка текәләм, анда бары ике хәреф — I. Y. Тукта, бу бит безнең авыл алманы Иоахим Вернер түгелме соң?— дим. Аны эзләп табу кыен булмады. Икенче көнне без Фридрих-штрассе урамындагы кафеда чәй эчеп утыра идек инде.

Аннан соң еш кына очраша башладык. Авыл кешеләрен, Солтанәхмәт Сакаевны, Гыйльметдин мулланы искә алдык, гомумән, иркенләп аралаштык. Авылда чакта, бердән, яшь аермасы зур булганга, икенчедән, укытучым булгангамы, алай артык якынлашканыбыз булмады. Монда без тиң, иш идек, әйткәнемчә, кешеләрне еллар гына түгел, ә үтелгән чакрымнар да тигезли.

Сүз куешкандай, икебез дә Минлебай Атнагуловка кагылмаска тырыштык. Телдән әйтмәсәк тә, күңелебез белән, әгәр сүз аңа күчә-нитә калса, үзенең мыскыллы елмаюы белән берәр почмактан килеп чыгар төсле тойдык.

Вернер:

— Язмышымда Ай авылы кебек башка тукталыш очрамас инде, — дип куйды.

Кайчакларда ул мине үзенең остаханәсенә дәшә һәм яңа эшләрен күрсәтә. Ул күбрәк табигать күренешләрен төшерергә ярата. Картиналарының берсендә Вафа бабай үз куллары белән ясаган көймәне күреп аптырап киттем. Ул ярдагы казыкка бәйләп куелган. Кем өчендер ул гап-гади

бер каек булып күренер. Ә тарихын белүчеләргә — үтә кадерле истәлек! Вернер ул картинасын, мөгаен, минем котылу тарихын тыңлаганнан соң ясагандыр. Икенче бер картинасында Су анасы суга иелгән тал ботагында утыра. Кулына көзгесен тоткан, күзләре исә каядыр читкә төбәлгән. Чит кеше монысын да аңламас, бер гап-гади хатын-кыз дип уйлар иде. Тагын бер кергәч, Вернер миңа чираттагы табигать күренешен күрсәтте. Ул урын да миңа таныш, якын һәм бик кадерле — анда Кара урманга илтә торган юл сурәтләнгән. Тик ул гади күренеш кенә түгел, анда мин өрәкләр аланын күрдем, аларның җырларын ишеткәндәй булдым. Ә башка берәү бу рәсемдә иртәнге томан йә кичке эңгер-меңгерне генә күрер иде.

Вернер белән очрашкан вакытларны искә төшергәндә, шуны уйлыйм: иҗатының кирәклеген тою аның җанын җылыткандыр, илһамына дәрт өстәгәндер. Мин аның бердәнбер рәхмәтле тамашачысы булдым, картиналарының язылу тарихын белгәнгә, андагы вакыйгалар безне үзара бәйләде. Хәер, Вернерның эшләре сәнгать әсәрләре буларак, әллә кем булмагандыр дип уйлыйм, чөнки аларны күбесенчә хуҗабикәләр белән кибетчеләр генә сатып ала иде.

Очрашуларның берсендә алман миңа яңа гына тәмамлаган «Җәзалаудан соң» картинасын күрсәтте. Аның эчтәлеге турында алдарак сөйләгән идем, кабатлап тормыйм. Картинаны карагач, теләсәк-теләмәсәк тә сүз Миңлебай Атнагуловка күчте.

— Әгәр шуннан үч алмасам, минем бәям — сукыр бер тиен! — дидем.

Вернер бераз сүзсез торды да, болай дип куйды:

— Зыялы кеше һәм үч — бергә сыеша алмый торган төшенчәләр.

Ул вакытта профессор буларак, мине чыннан да зыялы кеше дип санарга булгандыр. Мин ярсып киттем:

— Сез зыялы кеше дисез? Мине күз алдында тотасыз? Беләсезме, бер танышым зыялы кешегә менә нинди билгеләмә бирде: ул шундый кеше, һәрвакыт икенче берәүгә уңайсызлык тудырам дип борчыла; аның җаны беркайчан да үз урынында булмый. Ә башкаларга кыенлык китергән, атап әйткәндә, аларны үлемгә дучар иткән бәндәгә ничек яшәргә? Ул нинди хисләр кичерә икән? Димәк, мин өчләтә зыялы кеше булып чыгам. Юк, бу очракта өч дип әйтү дөрес булмас, мин йөзенче, өч йөзенче дәрәҗәдәге зыялы. Бу дәрәҗәләр вакыт-вакыт өметсезлекнең соңгы чиге булалар, җаныңны кая куярга белми бәргәләнәсең, хәтта төшләр дә җиңеллек китерми.

Ярсулы монологымны Вернер бүлдерми генә тыңлап бетерде. Аннары:

— Әгәр күктәгеләр теләсә, юлларыгыз кисешер, — дип куйды.

Бервакыт төшемдә лунатик бүрене күрдем. Ул Фридрих-штрассены нәкъ Вильгельм Яулап алучы манарасы янынннан кисеп чыкты.

Икенче вакыт Су анасы керде. Куркуымны җиңеп, кулындагы көзгесенә күз салдым: анда очы-кырые күренмәгән болганчык суда аермачык булып ир-атларның рухларын күрдем. Аннары ерактан бер тавыш ишетелде. Кемдер дәшә — мин җавап бирәм. Әмма су тавышы безгә сөйләшергә комачаулый. Минем, күрергә теләгән кешемне очратаммы, дигән соравыма ул, әйе, юлларыгыз бер-берегезгә таба килә, дип җавап бирде.

Сугыш башлангач, Вернерны Гитлерның төп идеологы Альфред Розенберг җитәкчелегендәге оккупацияләнгән көнчыгыш территория ведомствосына эшкә алдылар. Аңа сайлау мөмкинчелеге калдырмадылар. Вернер аларга урыс теле буенча белгеч буларак кирәк булды.

Без элеккечә Фридрих-штрасседагы яраткан кафебызда очрашабыз. Вернерның тышкы кыяфәте үзгәрде, йөзендә ниндидер бурычка катнашы барлык, шуның аркасында һәлакәткә дучарлык сизелде. Гаҗәп түгел,

рәссамнарга алдан күрүчәнлек хәрбиләргә караганда күбрәк бирелгән бит.

— Көт, синең дә нәүбәтең җитәр, — диде ул. Минем аптыраулы карашымны күреп, аңлатуны кирәк тапты: аның ведомствосында күптәннән инде төрки халыклар белән үзара бәйләнеш булдыру программасы төзелгән, һәм алар, вакыты җиткәч, өченче рейх составына керергә тиешләр икән. Германиядә яшәүче элеккеге эмигрантларның кайберләре белән үз эшләренә тарту максатында сөйләшүләр бара икән инде.

— Андый сөйләшүләрдә беркайчан да катнашмаячакмын! — дидем мин, кырт өзеп.

— Ант итәргә ашыкма, — диде Вернер.

— Бәлки Сезне мине күндерергә җибәргәннәрдер, ә? — Мин мыскыллы елмайдым.

— Әлегә юк.

Сугыш дәвам итте. Тарихтан кайбер фактларны искә төшерәсем килә. Сугыш хәрәкәтләре СССР территориясенә күчкәч, бик күп сандагы совет әсирләрен нишләтергә, дигән сорау герман хәрби җитәкчелеген көтелмәгән хәлгә куйды. Көнчыгыш ведомствосында көнчыгыш легионнар төзү планы туа. Сугыш башында Гитлер корал йөртү алманнарга гына рөхсәт итела дисә дә, тора-бара Кавказ, Кырым, Әрмән, Идел-Урал (Идел буе халыкларыннан, шул исәптән татарлар да керә) легионнар төзелә.

Лагерьлардагы әсирләрне милләтләргә аера башлыйлар. Моның өчен даими эшли торган комиссияләр төзелә. Вернерга нәкъ шундый комиссияләрнең берсендә эшләргә туры килә.

— Сәер процедура, — дип сөйләде ул, беренче сәфәреннән кайткач. — Берәүләрне бер якка, икенчеләрен икенче якка...

Комиссияләр эшли башлаганчы, әсирләрнең кайсын үтергәннәр, кайсын калдырганнар, аеруча яһүдләрне эзәрлекләгәннәр.

— Әгәр сами эзләре күрәләр икән — исән калу өмете бөтенләй юк. Кайчакта йөзенә карап милләтен аерып булмый. Документлары югалган. Тәннәре кала инде. Тәннән нәрсә белеп була, дисеңме? Була икән. Дөресрәге, җенси әгъзалары «сата». Яһүдләрне кечкенәдән үк сөннәткә утырталар бит. Менә шулай. Әсирләрне рәткә тезделәр дә ыштаннарын төшерергә куштылар. Сөннәтлеләрне читкә алып китеп аттылар. Әмма сөннәткә утырту йоласы мөселманнарга да хас икән бит. Алманнар, билгеле, моны белмиләр. Гомумән, алар өчен әсирләр дә, хайваннар да бер дәрәҗәдә. Менә шунда без — комиссия килеп төштек. Арабызда галимнәр, этнологлар, тарихчылар, тел белгечләре бар. Без ялгышмыйбыз: үзбәкне татардан, грузинны азәрбайҗаннан аера беләбез.

Ашыкмый гына кичке Фридрих-штрассе урамы буйлап атлыйбыз. Карангылык эченнән тузан сирпелә.

— Нинди тузан булды соң бу? — Битемне сыпырам.

— Бу — крематорийдан чыккан көл, — дип аңлатты Вернер. Гади алманнар белеп бетермәгән нәрсәләрдән шактый хәбәрдар иде ул.

Кафедагы сөйләшү бик озак уемнан китмәде. Җенси әгъзаңа карап, яшәргә тиешме кеше, юкмы дип, арала, имеш. Вернер сөйләгәннәр төшемә кереп интектерде. 1943 елның көзендә Берлинда Плетцензее төрмәсендә әсирләрне күпләп юк иткәннәр. (1944 нче елда шушында ук Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең башлары гильотинада киселә). Монысы турында да мин Вернердан ишеттем. Төнлә Берлин күгендә бомбага тоту башлангач, ашыгыч рәвештә төрмәдәге әсирләрне җәзаларга керешәләр. Гильотина ул төнне туктамыйча эшли. Шул матавыкта иртән ирекккә чыгарыласы пианиночы бельгияле Карл Роберт Крейтенның да гомере өзелә.

Күпчелек лагерьлар Польша территориясендә урнашканга, Вернерның сәфәрләре шактый озакка сузыла. Әйләнеп кайткач, без очрашмый калмыйбыз һәм ул һәр сәфәреннән нинди дә булса яңалык алып кайта. «Берсендә әсир татарларны Еллино тимер юлы станциясендәге лагерьга туплаулары турында ишеттем. Комиссия алманлар ягына чыгарга риза булучыларны ачыкларга тиеш. Әсирләрнең хәле ничек, диярсең. Коточкыч, яшәү шартлары түзә алмаслык, күбесе ачлыктан, чирдән үлемгә дучар ителгән.» Вернер сүзләренә караганда, боларның күбесе — бер авыз урысча белмәүче авыл ир-атлары. Ул миңа төрмәдә карандаш белән сызгалаган рәсемнәрен суза, үзе, борылып, тәрәзә аша Фридрих-штрассе урамы буйлап тегендә-монда чабулаган җәяүлеләрне күзәтә. Теге вакытта йөрәгемә уелып калган кадерле урыннар төшерелгән картиналарын караганда да, ул мине истәлекләрем белән бергә-бер калдырып, остаханәсеннән чыгып киткән иде.

Рәсемнәрдә ватандашларымны күрдем. Аларны җир тырнап яшәгәнгә агач тамырларына охшап калган куллары, гомерләрен ат өстендә үткәргән ата-бабаларыбыздан мирас булып күчкән камыт аяклары, әрекмәнне хәтерләтеп, үлгәннәрнең дә тавышын ишетергә сәләтле тырпайган колакларыннан таныдым. Монарчы үзләрен күргәнем булмаса да, һәрберсенең йөзе таныш, үзәк өзгеч дәрәҗәдә якын тоелды. Аларның күзләрендә үзләрен йотарга әзер коточкыч ялкын шәүләсе катып калган. Рәсемнәрдән күзем алалмый, шактый басып тордым. Вернерның тавышы кабат бу дөньяга кайтарды: ул миңа комиссияләрнең берсендә эшләргә тәкъдим итте. Соңрак аның бу тәкъдиме исемә төшкән саен, күңелемне төрле шик-шөбһәләр кимерде. Вернер баштан ук мине Көнчыгыш ведомствосына эшкә тартуны максат итеп куйган һәм әкрен-әкрен генә шуңа әзерләгән кебек тоелды. Тик хәзер өлкән дустымның исәбе риясыз, эчкерсез икәнен аңладым. Үткәнемнең бер өлеше булган авыл ирләренә ярдәм итәсе килгән аның һәм, дөресен әйткәндә, минем дә шунда катнашуымны теләгән. Ә мине көндерер өчен, яшермичә — ничек бар, шулай сөйләргә булган.

Чираттагы юлыннан әйләнеп кайткач, ул миңа лагерьларның берсендә булган хәлне сөйләде. Әсирләрне тезеп, гадәттәгечә, ыштаннарын төшерергә кушканнар. Исегездәдер, шул юл белән яһүдләрне ачыклаганнар. Сөннәткә утыртылганнарын аерым рәткә тезә барганнар, аларны алда ни көткәне билгеле инде.

Нәүбәттәге әсиргә рәттән чыгарга боерганнар, ул исә:

— Мин бит татар, — дип каршы килеп маташкан.

Алманнар аңар ышанмаган. Нигәме? «Моның берничә сәбәбе бар дип уйлыйм, — диде Вернер. — Беренчедән, әсир татарга охшамаган булырга мөмкин, татарның йөз −кыяфәте төрлечә бит — монгол чырайлыдан башлап зәңгәр күзле норвег дигәненә кадәр татар булып чыга. Икенчедән, бердәнбер котылу юлы санаганга, яһүдләр еш кына үзләрен мөселман итеп күрсәтергә тырышкан. (Мәсәлән, нәкъ шулай итеп әсирлектән исән-сау котылып кайткан яһүдләр белән шәхсән үземнең очрашканым бар).

«Өметсезлеккә төшкән күзләре белән тирә-якны айкаганнан соң, әсир җырлап җибәрде, — диде ул. — Әйе-әйе, нәкъ шулай. Ни өчен җырладымы? Чыннан да татар икәнен расларга теләгәндер, бәлки кыл өстендә калган гомере белән саубуллашуы булгандыр — кем белсен.

Борынгы татар халык җыры «Иске карурман»ны сузды ул. Лагерьдагылар, дөньяларын онытып, катып калдылар. Үлгәннәрнең һәркайсының үз аланына очарга әзерләнгән рухлары, туктап, җырга кушылдылар. Башкалар да күтәреп алдылар. Үз көенне җырлап китү — өенә кайтып үлү белән бер бит. Лагерь өстендә татар җыры хакимлек итте. Әсирләрнең кибеп

саргайган битләреннән яшь тамчылары тәгәрәде. Әмма берсе дә күз яше күрсәтүдән оялмады».

— Хәлил, — дип кычкырдым мин Вернер сүзен тәмамлауга, — бу — ул!

— Мин исемлекне тикшердем, — диде Вернер сабыр гына. Лагерьда андый исемне очратмадым.

Билгеле, Хәлилнең күптән бу дөнья кешесе түгеллеген беләм, әмма вакыйга мөмкин булмаганча ышандырырлык тәэсир итте.

Без озак сөйләшеп утырдык. Кабат-кабат әлеге вакыйгага әйләнеп кайттык. Һәр авылның үз Хәлиле бар, һәм ул җырдан башка таяныр терәк калмаган урында килеп чыга, диештек.

Шушы көннән шик-шөбһәләрем таралды, һәм мин әсир татарлар белән эшләү комиссиясенә алуларын сорадым. Көнчыгыш ведомствода сүзе үткән Вернер теләгемне тормышка ашырырга ярдәм итте.

Җәһәннәмгә тиң командировкалар башланды. Миңа йөзләгән кешеләр белән аралашырга туры килде. Татарларның кайларда яшәгәннәре белән генә очрашмадым. Минем бурычым — аларны легионнарга тарту. Бу алар өчен бердәнбер котылу юлы икәнен инде аңладым.

Алгарак китеп, тарихтан берничә фактны искә төшерик әле. Татар һәм Идел буе халыкларыннан төзелгән «Идел-Урал» легионы Кызыл Армия ягына чыга. Билгеле, фашист киеме татар кешесенә ятышмавы күзгә бәрелеп тора. Каска астыннан тырпайган колаклар, азиатлыларга хас яңаклар, битараф карашлар — вермахт өчен хурлык, әлбәттә. Тик алар, Гитлерның әйтүе буенча, «алман канын саклап калу өчен» кирәк булган.

Шул чакларда комиссиядә эшләвем исемә төшкәндә, үземне уңайсыз хис итәм, әмма ничек кенә боргалансаң да, барыбер шул режим белән хезмәттәшлек ителгән һәм кемнендер күзлеге аша караганда моңа бернинди аклану була алмый.Тик, кабатлап әйтәм, башкача эшләү мөмкин түгел иде. Намусымны, кайчандыр мине саклап гомерләрен биргән авылдашларымның рухы борчып торганда, моны эшләргә тиеш идем. Лагерьда исә андый ирләрнең исәбе-саны юк. Әгәр шул чакта аларга ярдәм кулы сузмаган булсам — үземне бервакытта да гафу итә алмас идем.

Шунысын да әйтергә кирәк, Көнчыгыш ведомствода шундый ният белән берничә ватандашым — татар качаклары минем белән кулга-кул тотынып эшләде. Без еш кына милләт язмышы турында бәхәсләштек, алардан хәйран төпле фикерләр ишеттем. Сүз дә юк, төрлебездә төрле караш, әмма фикерләребез кисешкән нәрсә — әсирлеккә эләккән ватандашларыбызны йолу теләге.

— Ходаем, без монда нишлибез? — дип кычкырып җибәрде берсендә профессор Корбан Шәфи. — Нинди шайтан безне монда китереп тыкты?

Аның кебек нечкә хисле кешеләр белән андый хәлләр еш була. Корбан Шәфинең дә нервлары биреште.

— Менә син, — дип бәйләнде ул миңа, — син ник монда?

Янымда берничә кеше булса да, ул нәкъ менә миңа канықты..

— Нигә икәне мәгълүм, — дип җавап бирдем. — Үзең дә беләсең.

— Үзебезнекеләргә булышу өчен дисең. Шулаймы?

Ул канатланып китте һәм тарихка экскурс ясап, зәһәрле ачу белән сөйләргә тотынды:

— Менә ничек икән. Бәладә калганнарга ярдәм итмәкче булабыз. Мактауга лаеклы теләк. Без нинди олы җанлы, мәрхәмәтле, намуслы икәнбез. Тик мин сиңа шуны әйтмәкче булам — татарлар алар бик үзенчәлекле халык. Без бервакытта да бер-беребезне якламыйбыз. Ярдәм

итү мәсьәләсендә әйтеп торасы да юк. Без көнчел, вак җанлы; арабыздан берәү өскә күтәрелә башласа, аны тизрәк батырырга тырышабыз. Ни өчен Алтын Урда таркалды, ә? Чөнки ханнар хакимиятне бүлешә алмады. Казан ханлыгы ник юкка чыкты? Тагын шул ук сәбәп, өстәвенә үзара берләшү булмады. Сталин репрессияләрен алыгыз, күпме зыялының, аның да иң күренеклеләренең җаны кыелды. Генофондны бетердек, дибез. Кем? Үзләре бетерде. Әгәр НКВД тикшерүчеләренең исемлегенә күз салсагыз — күпчелек татар фамилияле. Бу эшне башлап җибәрүчеләр безнең халыкның үз-үзен юк итәргә сәләтле икәнен бик яхшы белгән. Йә Ходай! Яһүдләрне яисә әзәрбайҗаннарны карагыз. Алар бит берсе өчен берсе тау булып калка, берсе өскә күтәрелсә, артыннан икенчесен өстери. Ә безнең үзара шикләнүдән башыбыз чыкмый. Безгә бервакытта да бөек милләт булырга язмаган!..

— Туктагыз хәзер үк. Бу нинди сафсата! — диде Галимҗан Идриси. — Без монда нәрсә өчен? Булышыр өчен түгелмени?

— Әйе, ярдәм итәбез, — Корбан Шәфинең тынычланыр исәбе күренми, — әгәр үзебезгә куркыныч янамаса. Без бит аларның бары хәлләренә генә кирәбез.

Кемдер:

— Сез алманнар белән бергә бөекләр була алабыз дип саныйсызмы? — дип сорады.

Корбан Шәфи дәшмәде. Ул бик шәп галим, сүзнең кай якка борылганын яхшы аңлады. Татарлар, алманнарга елышсак, өченче рейх составында милли республика төзү мөмкинлеге бирерләр, дип ышаналар. Тик герман җитәкчелеге милли хәрәкәтне алдап йөртүен дәвам итә, андый республика төзү турындагы уй аларның башларына да кереп чыкмый.

Корбан Шәфи бу сорауга җавап бирергә кыенсынды, чөнки арабыздан беребезнең үзен сатуыннан курыкты.

Ул арада әңгәмәгә башкалар да кушылды. Галимҗан Идрисинең, мәсәлән, күңеле төшенке түгел, әле ул безне төшебезгә дә кермәгән рухи күтәрелешләр көтүенә ышана.

Бу кеше турында да бер-ике авыз сүз әйтеп китәргә кирәктер. Сугыш тәмамланып, берничә еллар узгач, шундый ук күтәренке өметләр белән ул Мисырда татар республикасы төзергә маташа, хәтта корольдән рөхсәт алуга ирешә. Әмма аның тырышып йөрүе бушка чыга. Тагын 45нче елда, Гитлер җиңелгәч, татар әсирләренә булышуы мәгълүм. Америка зонасында калган совет хәрби әсирләрен Ялта конференциясендә Сталин, Черчилл һәм Рузвельт арасындагы килешү буенча совет ягына бирергә тиешләр. Илләренә кайтсалар да бу әсирләрне төрмәләр, бу юлы — сталин төрмәләре көтүе берәүгә дә сер түгел. Идриси татар әсирләре өчен, алардан Төркия гражданины ясап, ялган паспортлар рәсмиләштерә. Теләгән кеше бу мөмкинлектән файдалана, тик андыйларга туган иленә кайтыр юл мәңгегә ябыла. Мин аларның кайберләре белән таныш.

Берсен Босфор ярында очраттым. Ул Садри Максуди шикелле, еракка юл тоткан корабларны озатып кала иде. Икенчесен Аризон штатында биек тау башында күрдем. Чал чәчләрен җил иркенә куеп, анысы карашын каядыр еракка төбәгән дә, таташтай катып калган. Тагын берсе күптән түгел Франция Альпында, тауда очрады. Ул инвалид арбасында утыра, тирәсендә балалары, оныклары, туганнары. «Ул бездән соңгы көнендә шушында алып килүебезне үтенә», — диделәр алар. Мин аны аңлыйм. Аның рухы үз аланына юл эзли.

Кабат комиссиядә эшләгән чагыма кайтыйм әле. Шулай итеп, әсирләрне легионга язылырга өндим. Җаным өчен шулкадәр авыр, газаплы эшнең нәтиҗәсен беләсегез киләдер. Кемнедер ышандыра алдым, кемнедер — юк.

Әсирләр арасыннан берсе, сүзсез генә тыңлап торды да, лач итеп битемә төкерде. Теләсә нинди хәлдә дә алманнарга хезмәт итмәячәген ул шулай белдерде. Мин битемне сөрттем дә, борылып, китеп бардым.

Лагерьлар, алманнар белән хезмәттәшлек — болар, мөгаен, истәлекләрем арасында иң күңелсезләредер. Моңа охшаш хәлләр аша узганнар бу турыда онытырга тырыша, сүзне икенчегә бора, яисә дәшми калуны өстен күрә.

Хикәямдә кабат Хәлил шәүләсе чагылып үтте. Беренче бүлектә, язмышымда Хәлил ни өчендер һәрвакыт икенче берәү белән янәшә килеп чыга, дигән идем. Шул икенче берәүнең шәүләсе инде офыкта шәйләнә, һәм юллар аны менә-менә миңа китерер шикелле тоела.

Беркөнне Вернер миңа бер хәбәр ирештерде. Аның кулына Кызыл Хач әзерләгән исемлек килеп эләккән. Исегезгә төшерим, бу оешма баштарак совет хәрби әсирләренең хәлен җиңеләйтергә тырышып күп мәртәбәләр совет ягына мөрәҗәгать итеп карады. Алар да әсирләрнең язмышына битараф түгелләрдер, дип уйлады. Тик Сталинның фикере һәркемгә мәгълүм: «бездә әсирләр юк». Шуның белән шул, алар турында кабат сугыш беткәч кенә, анда да хөкем итеп яңадан җәһәннәмгә илтеп тыгу өчен искә төшерделәр.

Кызыл Хач исемлегендә Вернер Миңлебай Атнагулов исемен күргән, аны Польшадагы Хорол лагеренда ябып тоталар икән. Ниһаять, көткәнем чынга ашачак, ничек итеп — анысын күз алдыма китерә алмадым. Йөземдәге үзгәрешне күрептер, Вернер:

— Ашыгыч нәтиҗәләр ясарга ярамый, — дип үгетләргә тотынды. — Бәлки бөтенләй икенче кешедер. Беткәнмени андый исем-фамилияләр.

— Кичекмәстәк шул лагерьга барырга тиешмен, — дидем мин, каударланып.

— Нәрсә кылмакчы буласың? Үтермәкче?

— Кабатлап әйтәм, мин анда барырга тиешмен, һәм сез ярдәм итәрсез дип ышанам.

Хорол лагере, нишләптер, Көнчыгыш ведомство белгечләре күзеннән төшеп калган, шуңа Кызыл Хач исемлегеннән башка кулда бернинди мәгълүмат юк.

Вернер кулыннан килгәнне эшләде: лагерьга комиссия җибәртүгә иреште. Мин дә, комиссия әгъзасы буларак, барырга тиеш булдым. Ниһаять, юлга кузгалдык. Дөрес, анда барып җиткәнче, берничә күрше лагерьда эшләргә туры киләчәк — ләкин анысы моның белән чагыштырганда вак мәсьәлә.

Язмыш күпме еллардан соң дошманымнан үч алу мөмкинлеге бирәчәк. Әгәр ул кеше чыннан да Миңлебай Атнагулов булып чыкса, ничек итеп үч алырга кирәклеген белермен. Әсир буларак, аның бернинди хокукы да юк, димәк, бер аягы белән болай да теге дөньяның читендә басып тора дигән сүз, миңа аны этеп җибәрәсе генә кала.

Көзнең соңгы көннәре. Ачы җил сызгыра. Мин чираттагы командировкага кузгалдым. Вагон тәрәзәсенә инә кебек очлы вак кар бөртекләре килеп кадала. Алда рельслар әле килеп кушылалар, әле аерылып китәләр. Мондый сәфәрләргә ияләшеп килсәм дә, йөрәгем үз урынында түгел. Җилнең ачы улап, тәрәзәгә бәрелүе, болай да тынычлыгын югалткан җаныма шом сала. Варшава шәһәре әкрен генә артка таба шуышты. Кая барам? Нишләп йөрим? Бу караңгылыкта нием калган? Үз-үземне шундый сораулар белән битәрлим.

Лагерьда тикшерүләр тәмамлангач та, Миңлебайны эзләү эшен башлап җибәрдем. Дистәләгән әсирдән сораштырсам да, аны белүче-күрүче табылмады. Гаҗәп түгел, чөнки монда әсирләрнең саны меңнәр белән исәпләнә. Әмма карарым нык, әсирләрнең һәрберсен сораштырып чыксам

чыгам — тапмыйча калмыйм. Әле минем төп вазыйфамны да үтисем бар: әсирләрне легионга язылырга өндәүне дәвам итәм. Эзләү эшләрен артык сузарга да ярамый, ни өчен дисән, көн саен диярлек әсирләрне башка лагерьларга озатып торалар, шулай итеп Миңлебай Атнагулов кулдан ычкынырга да бик мөмкин.

Өч тәүлек узуга карамастан, дошманымның эзенә төшә алмавыма борчыла башладым. Аптырагач, лагерь сакчыларына сүз кушарга булдым.

— Миңлебай Атнагулов? — дип кабатлап сорады сакчыларның берсе.
— Ул бүген иртән үлде.

— Гәүдәсен булса да күрергә мөмкинме?

— Ихтыярыгыз.

Иң ахыргы барак артына килеп чыктым. Мәетләрне теләсә ничек ташлап барганнар. Мина йөзләгән гәүдәне әйләндерергә туры килде. Чираттагы мәет белән матавыкланганда, арттан тавыш ишетелде:

— Иртән үлгәннәрне алып киттеләр. — Мин, сискәнеп, артыма борылдым.

Каршымда гимнастерка белән галифе кигән карт басып тора. Бәлки карт дип әйтү дөрес үк булмас, тик җыерчык баскан йөзе, җансыз күз карашы бу адәмнең күпне күргәнен дәлилләп тора.

— Синең күзеңә караганчы, үлемнекенә каравың яхшырак, карт, — дидем мин.

Ул көлемсерәде:

— Миңа әле 44 кенә, сиңа да шуннан ким түгелдер.

— Сиңа кем дип дәшим?

— Җамалый Рәсүлев булырмын мин. Син эзләгән кеше монда юк. Аларны көндез җир куенына салдылар.

— Алар арасында Миңлебай Атнагулов бар идеме?

— Нәрсәгә ул сиңа?

— Без бер авылдан.

Җамалый Рәсүлев бераз уйланып торды да:

— Киттек, аның янына барабыз, — диде.

Ул борылды да, кулын кесәсенә тыккан килеш, җайлап кына бараклар ягына атлады, миңа да аның артыннан иярми чара калмады. Бараклар янында утырган әсирләр, җирдә яткан яралылар өметләре сүнгән күзләре белән безне озатып калдылар.

Баракларны үтеп, читтәге бушлыкта такталардан корыштырган корылмаларга таба юнәлдек. Күңелне кинәт шом басты. Әллә үтерергә тели инде, дигән шик туды. Нигә, сәбәбе дә бар: беренчедән, алманнар белән хезмәттәшлек иткән өчен үч алырга менә дигән җай. Икенчедән, бәлки бу адәм Миңлебай Атнагулов кешеседер, тегесе үзе белән кызыксынуларын белгәндер дә капкынга төшерергә уйлагандыр. Түзмәдем:

— Мине кая алып барасың? — дип сорадым.

— Эзләгән кешең янына, — диде ул, алдына караган килеш.

Хәер, мин барысына да әзер идем. Әгәр алманнар ялчысы дип саныйлар икән — дөресе шул, ул юлга үз теләгем белән бастым. Дошманым анда көтеп тора икән — коралсыз, ялгызым туп-туры кулына килеп эләгәм түгелме? Миңлебай җен белән бер — хәйләкәр, ул мине, һәрхәлдә, үз кулы белән үтермәс, болай да безнең кебекләрне өзгәләргә әзер әсирләрне генә өстерер. Язганы ни, шул булыр дип, юлымны дәвам иттем. Шулай да кирәге-ние чыгар дип, кулыма юлда аунап яткан тимер кисәге алдым да артыма яшердем.

— Нәрсәгә ул? — диде Җамалый, артына борылып тормастан. — Син бит авылдашыңны күрергә теләдең?

Коралымны ташладым. Мин күрәсен кеше күрмәс. Ачуым шулкадәр көчле, дошманымны кулларым белән буармын шикелле. Барак сыман бер корылманы узып, складка охшаган бинага кердек. Стена буенда безгә арты белән бер адәм басып тора. Җаным упкын өстендә эленеп калган кебек тоелды. Хәзер инде ничә еллар буе эзәрлекләгән кешемнең чыраен күрәм, дигән уйдан башым әйләнеп китте.

— Миңлебай! — дип дәштем тегенә.

Ул борылды. Каршымда тырпайган чал чәчле, газап тулы чырайлы, әсәрләнгән карашлы таныш түгел адәм пәйда булды. Ул нәрсәнедер исенә төшерергә тырышкандай мангаен җыерып торды да көтмәгәндә хахылдап көләргә тотынды.

— Көлүегез сәер, — дидем мин.

— Ул җиде төрле итеп көлә белә иде, — дип аңлатма бирде Җамалый. — Тик хәзер берсе генә — өметсезлек белдергәне генә калды.

Теге адәм, шүрәле кытыклаган сыман, туктый алмый шаркылдый. Аның хахылдавында нindидер билге яшеренгән кебек. Мин аны аңладым — бу язмышымның миннән шулай көлүе иде.

— Акылдан язганнан соң, без аны шушында яшереп асрыйбыз. Югыйсә, алманнар андыйларны бер минут та тотмый.

— Юк, бу мин эзләгән кеше түгел. Ә исем-фамилиясе, чынлап та, Миңлебай Атнагуловмы?

— Әйе. Без аның белән бер взводта сугыштык. Авыр сынаулар аша үтеп, туганнар кебек якынайдык. Аңлагансыздыр: аны ничек ташлыйсың инде. Монда күргәнне беркемгә дә сөйләмәссез дип ышанам.

Мин анар сүз бирдем. Язмыш Атнагулов белән очраштырмаса да, аның кайдадыр якында гына икәненә, кайчан да булса кулыма төшәсенә иманым камил иде.

Комиссиядәге эшемне тәмамлар өчен, Хорол лагеренда тагын берничә көн тоткарланырга туры килде. Тагын бер тапкыр Җамалый Рәсүлев белән күрештек, дөресрәге, ул үзе яныма килде.

— Аңлавымча, син эзләгән кеше, чыннан да, бик явыз адәм, ахрысы?

— Аны тәмуг уты көтә! — дидем мин.

Шуннан соң Җамалый миңа менә нәрсәләр сөйләде.

Башта ул Ромны лагеренда булган икән. Шунда бер адәмне очраткан. Алманчаны шәп белүе аркасында, ул фашистларга якыная алган.

— Шулай тезелеп торабыз, — дип сөйләп китте Җамалый Рәсүлев, — янымда кече лейтенант — Борис Штильман. Ыштаннарыбызны төшерергә боерута, сөннәтлеләрне эзләүләрен төшенеп алдым. Бориска әйттем: безне хәзер читкә чыгарачаклар, исеңдә калдыр: син — татар, исемең Әхмәт, фамилияң Заһидуллин. Онытма, шулай диген. Безгә «Юде!» — дип, аерым рәткә бастырдылар. «Мин — татар» дидем, Борис та минем арттан кабатлады.

Алманнар безгә ышанды дип торганда, алар арасыннан теге әсир чыгып, безне әйбәтләп тикшерергә тотынды. Миңа артыгын бәйләнәсе итмәде, чөнки татарлыгым болай да күренеп тора. Борис янына килеп, аңа татарча эндәште. Билгеле инде, бер авыз татарча белмәве аны сатты. Түзә алмадым, теге кабахәтнең күзләренә батырып карадым да: «Киләчәктә тыныч йокlармын дип уйлыйсыңмы?» — дидем. Ул миңа: «Киләчәгем пуля сызгыруына тиң. Ә аны куып җиткән кеше юк әле», — дип җавап кайтарды.

— Бу — ул! — дип кычкырып җибәрдем. — Мин эзләгән кеше!

Җамалый Рәсүлев миңа карап алды да:

— Борисны башка яһүдләр белән аттылар. Ату — лагерьда һәр көн

кабатлана торган хәл. Әмма монысында алманнар янында басып торган теге адәм үзгәреш керткән, диделәр. Бу вакыйганы күргәннәр атыш дәвамында көй уйнап торды, дип сөйләделәр. Теге адәм патефон җибәреп, музыканы репродуктор аша тапшырырга тәкъдим иткән икән. Алманнарга бу идея шулкадәр ошаган ки, аннан соңгы атулар көй астында башкарыла башлады. Алар моннан үзләренә тәм тапсалар, без исә патефонны борып җибәрүгә, ни буласын күз алдына китерә идек.

— Бернинди шигем юк, хәтта исемен дә сорап тормыйм, — дидем мин.

— Исемен әйткән иден, шуңа сөйләргә булдым.

Димәк, ничек кенә булса да Ромны лагерена барырга кирәк. Мин шунда ук Вернер белән элемтәгә кердем. Әмма, Вернер сүзләренә караганда, ул лагерьда күптән түгел генә комиссия булып кайткан икән. Шулай да ул ничек булса да ярдәм итәренә ышандырды.

Берничә көннән мин Ромны лагеренда идем инде. Ни кызганыч: хәрби әсир Минлебай Атнагулов өч ай элек Германия ягыннан торып сугышырга әзер татарлар җыела торган пунктка — Сельдце А лагерена күчерелгән булып чыкты. Анда исә андыйларны озак тотмыйлар, хәрби берләшмәләр төзелә торган Едлиногка озаталар.

Соңга калуымны аңладым. Берлинга кайткач, Вернердан сораштым. «Ромны лагеренда Минлебай Атнагуловны кулыбыздан ычкындырганбыз, — диде ул. — Комиссия эшләгән вакытта, ул Көнчыгыш ведомство исемлегенә берничек тә керми калалмый. Миңлебайның ничек итеп эз югалтуын бер шайтан гына белә. Хәер, без бит аны Хорол лагеренда дип уйладык. Икебез дә, — дип өстәде Вернер, — исемен ишетүгә кармакка капканбыз».

— Вернер, — дидем мин чын күңелдән, — картиналарыгызны гына ясап ятсагыз иде!

Барысы өчен дә аны гаепле санадым. Сүзләремә хәтере калса да, ул сиздермәскә тырышты. Билгеле, Вернерның монда бер гаебе дә юк, язмышка шулай язылган булгандыр, күктәгеләр язганны безнең үзгәртергә хакыбыз юк.

Болары мин Берлинга кайткач сөйләшүебез. Ә аңарчы теге каһәр төшкән командировкадан көч-хәл белән кайтып егылдым. Юлым Варшава аша иде. Анда, үч иткәндәй, эшелоннар артык күп җыелганга, берничә тәүлек вокзал саклап ятарга туры килде. Вокзал шыплап тулган, баш төртер урын юк, өстәвенә вермахт формасы кигәннәр үтеп-сүтеп тора. Җүнле йокы күрмәгәнгә, болар бар да төштә күргән кебек тоела башлады. Дүртенче тәүлеккә киткәндә, вокзал алды мәйданына чыктым. Кайсы якка карама — анда кеше. Төн канатын җәйгәнгә, тирә-як дөм караңгы. Көтмәгәндә шул караңгылык эченнән тавыш ишетелгәндәй булды. Бу — минем киләчәктән дәшкән үз тавышым иде, ул озакламый дошманым белән йөзгә-йөз очрашасымны хәбәр итте.

Иртән, ниһаять, Берлинга кайта торган поездларның берсенә эләгә алдым. Купеда кысан, кем беләндер танышу, сөйләшү теләгем юк. Поезд кузгалуга, коридорга чыгып, тәрәзә каршына килеп бастым. Йөрешен кызулата барган поезд капма-каршы якка юнәлгән состав белән очрашты.

Кинәт касыгыма кемдер китереп төрткәндәй, өнсез калдым. Җанымны тәмуг уты көйдереп алгандай булды. Ни булды дисезме?

Мин Миңлебай Атнагуловны күрдем. Аның чырае каршыга килгән поезд тәрәзәсендә чагылып алды да шунда ук юкка чыкты.

Әмма хәтерем аның сурәтен сендереп өлгерде. Күзләрем алдашмый: чигәләренә чал йөгергән, авыр карашлы, маңгае җыерчыклы адәм — ул иде. Аның өстендә вермахт офицеры формасы. Дәрәҗәсен төгәл генә әйтә

алмыйм, жилкәсендәге погоннарын күреп өлгермәдем. Хәер, күрсәм дә берни үзгәрмәс иде, чөнки хәрби дәрәҗәләрне барыбер аермый идем.

Кеше хәтеренә таң калырлык. Тормышта шундый мизгел эчендә булып алган хәлләр житәрлек. Хәтер, алдан сизенгән кебек, аның вак-төягенә кадәр үзендә саклап калдыра. Андый хәлләр минем белән элегрәк тә булгалаган иде. Хәтерегездәме, кунакханәдә тәрәзәм аша ундүртенче каттан ташланган адәмне күреп калдым, авылда ә дигәнче Хәлил каршына котырган үгез килеп басты. Бу юлы да шулай булды. Миңлебай Атнагуловның портреты хәтеремдә ап-ачык булып уелып калды.

Мине дә күргәндер дип уйлыйм. Күз ачып йомган арада булган хәл аның өчен дә көтелмәгән булгангадыр, йөзендә үзгәреш сизелми калды. Тик соңыннан чыраенда мәңгегә катып калган мыскыллы елмаюы күз алдымнан китми йөдәтте.

Аннары ни булдымы? Купега әйләнеп кердем һәм өске киштәгә менеп яттым да йокыга талдым. Уянганда, Берлинда идем инде.

Берничә көн буе Вернер белән булган хәлләр турында сөйләштек, кайда хата җибәрүебез хакында баш ваттык. Тегеләй йә болай иткән булсак, дип үкенү хисләре кичердек, тик терсәкне тешләп булмый, шуңа үзебезне кулда тотарга тырыштык.

Озакламый Вернер Миңлебай Атнагуловның украин партизаннарына каршы Идел-Урал легионының 827нче батальоны составында Көнбатыш Украина территориясенә җибәрелгәнен ачыклады.

Аның алманнарга ярый алуына аптырыйсы юк: алманчаны су кебек эчә, дөрес, сәер гадәтләре бар-барын, әмма алары алманнар тарафыннан хуплап каршы алынгандыр, мөгаен.

— Минем аны куып тоту мөмкинлегем бармы? — дигән соравыма Вернер:

— Юктыр, — дип җавап бирде. — Моның өчен сугыш барган территориягә үтеп керергә кирәк, ведомство тарафыннан исә әлегә андый сәфәрләр каралмаган. Үз белдегең белән бару, — ай-һай, — диде.

— Нишләргә соң миңа?

— Көтәргә. Берәр җае чыкмый калмас.

Комиссиядә эшләвемне, лагерьларга йөрүемне дәвам иттем. Моннан тыш Көнчыгыш ведомствода татарча арадашлык итү эшенә җәлеп иттеләр. Шулай итеп, вакыт, сизелмичә, су кебек ага торды. Беркөнне Вернер миңа 827нче батальонның Голландиягә күчерелүе турында хәбәр итте.

— Хәзер үк шунда китәм, — дидем мин, ашкынып.

— Сабыр ит, — дип тыярга маташты мине Вернер, — башта барысын да ачыклыйм. Дуамалланып эш чыкмас, тиешле кәгазьләр җайлау өчен берәр сылтау табылмасмы?

Ике атна чамасы энә өстендә утыргандай булдым. «Күпме еллар көтәргә туры килде, — дип сөйләндем үз-үземә. — Дошманым моңарчы кул житмәс арада булды. Менә, ниһаять, эзенә төштем. Ул — кул сузымында гына. Чирек гасыр әүвәл биргән антымны һаман үти алмыйм. Миңлебай Атнагуловның әлегә кадәр җирдә нык басып йөрүенә — мин, бары тик мин генә гаепле. Аны һич туктата алмыйм, шуның аркасында йөзләрчә гомерләрнең киселүенә сәбәпче булам».

Башка көтәр тәкатем калмагач, кулыма чемоданымны алып, вокзалга киттем. Касса янына килеп басуга, кемдер җиңемнән эләктерде. Артыма борылдым — Вернер икән.

— Анда Миңлебай юк, — диде ул.

— Кая киткән?

— Берәү дә белми.

Вернер яна гына 827нче батальонның Бред шәһәре тирәсендә урнашуы хакында мәгълүмат алган икән. Әмма легионерлар исемлегендә Миңлебай Атнагулов дигән кешене тапмаганнар.

Бред шәһәре. Голландия. Атнагулов. Шушы өч сүз арасында адашкандай булдым. Таба алачакмынмы эзләгән кешемне, әллә болганчык суда үзем батып каламмы? Голландия шәһәренең исеме соравыма җавап булып ишетелгәндәй булды. Саташкан кешедәй торуымны күрептер, Вернер:

— Беләсенме, сине үчең йөртә. Син хәзерге вакытта үзенә-үзең хуҗа түгел. Акылыңа кил! Калган гомереңне шуңа багышларга уйламыйсыңдыр бит? — диде.

Без Фридрих-штрасседагы яраткан кафебызга киттек. Килеп туган хәл буенча фикер алыштык.

Вернер миңа болай диде:

— Европа буйлап әйләнеп чыксаң да, син аны куып тота алмаячаксың. Нигәме? Чөнки хәзергә аның сәгате суккан мәл, аңлыйсыңмы? Әлегә ул кул җитмәслек, иблис кебек борынын теләсә кая тыга ала.

Аның белән килешми чарам калмады. Уйлаша торгач, Миңлебай Атнагуловның исем-фамилиясен үзгәртүе дә ихтимал, дигән нәтиҗәгә килдек. Исемне алмаштыру мәсьәләсе, бәлки, поезд тәрәзәсеннән мине күреп, куркыныч янавын аңлаганнан соң тугандыр. Тик бер нәрсәдә килештек: без дошманыбызны бәяләп бетермәгәнбез. Аның бездән качар исәбе бөтенләй булмаган, үз вакыты суккан чак икәнен белгәнгә, үзен хуҗа сизеп йөрүендә дәвам иткән. Атнагулов ул вакытта Төньяк Белоруссиядә урнашкан 1нче Көнчыгыш-мөселман СС полкына билгеләнгән булган. 44нче елның августында бу полк Варшава баш күтәрүен бастыруда катнашачак. Һәм без шунда тимер тәре белән бүләкләнгән солдат һәм офицерлар исемлегендә оберштурмфюрер Миңлебай Атнагуловның да исем-фамилиясен күрәчәкбез. Нинди батырлыгы өчен икәнлеге, шәт, аңлашыладыр, дип беләм.

Сугыш тәмамланып, ике дистәләп ел узгач, бер тантаналы мәҗлестә катнашырга туры килде. Шул уңай белән анда бер скрипкачы чакырганнар. Өстәлдәш күршеләрем аның аеруча тантаналы очракларда гына катнаша торган танылган виртуоз башкаручы икәнен әйттеләр. Чынлап та, уйнавы искитмәле иде, залдагылар аңар көчле алкышлар яудырдылар. 35 яшьләр тирәсендәге бу кеше белән мине нидер бәйли шикелле тоелды.

Кичә ахырында башларына киткән кунакларның берсе рояль артына утырды. Бармакларын житез генә клавишлар өстеннән йөгертеп алды да, илһамланып, Бахның «Чакона»сын уйнап җибәрде һәм үзенә кушылырга чакырып, скрипкачыга башын селкеде. Скрипкасын җайлап ияк астына урнаштырып маташкан җиреннән, ул кинәт кенә агарынды да чыгып китте. Кызып алган кунаклар яна танышлары белән гәп куерта, алар ягыннан чыркылдап көлгән хатын-кыз тавышлары ишетелә — аның китүен игътибарга алучы булмады да бугай.

Мин балконга чыктым. Скрипкачы, култыксага таянып, җем-җем утлар белән балкыган Истанбулны күзәтә. Ул миңа борылып карады, йөзе элеккечә агарынган. Кулымдагы коньякны суздым. Ул сүзсез генә алды да стаканны авызына каплады. Аннары сигаретын кабызды. Янәшә басып, төнге Истанбулга карап торабыз. Шаян җил чәчләребезне тузгытып уйный.

— Дөньяда сез беркайчан да эшләмәм дигән нәрсә бармы? — дип сорады ул миннән. — Яисә үлем янап торганда гына эшләргә батырчылык итәсез?

— Бик күп. Мәсәлән, хәзерге минутта аска сикерер исәбем юк.

— Мин дә сикермәс идем. Бернәрсәгә карамастан эшләмәячәкмен

дигәнем — бөтенләй икенче нәрсә, — дип сөйләп китте ул. — Бу хәл 44нче елда Варшавада булды. Безне — төрле яшьтәге берничә дистә ир-ат, хатын-кыз, бала-чаганы — бомбадан саклану урынынннан чыгуга ук камап алдылар. Якындагы бинаның стена буена тезделәр дә автоматларын төзәделәр. СС офицеры бармагы белән ымлап мине үз янына чакырды. Башта эшнең нәрсәдә икәнен аңламадым. Аннары гына искәрдем: скрипкама күзе төшкән икән. Ул миңа уйнарга кушты. Кыска һәм боерулы тон белән ике генә сүз әйтте: «Бах. Чакона». Скрипкамны футлярдан алып, уйный башладым. Шулвакыт офицер стена янындагыларга атып җибәрде, аңар башкалары кушылды. Аңыма килеп уйнавымнан туктап калдым. Әмма офицер пистолетын борын төбендә уйнатты — уйна! Эти-әнием, сеңлем һәм башкаларның музыка астында әкрен генә җиргә авуларын күреп торган хәлдә, уйнавымны дәвам иттем. Әле дә исемә төшкән саен тәннәрем чымырдап китә. Миңа кагылмадылар.

— Шуннан бирле, — диде ул, — минем беркайчан да Бахның «Чакона»сын уйнаганым булмады. Аны уйнауга караганда өске каттан сикерү — җиңелрәк булыр иде, чөнки бу музыка яңгыраганда үземне өстемә мең каргыш яуган кебек хис итәм.

Ул сүзсез генә сигаретын суырды. Аннары:

— Бу вакыйганың дәвамы да бар. Мәхәббәт тарихы турында тыңлыйсыгыз килмиме? — дип сорады.

— Әйе-әйе, әлбәттә, — дидем мин.

— Һәркемнең үз мәхәббәт тарихы була торгандыр, — дип сөйләп китте ул. — Акылымны җуяр дәрәҗәдә гашыйк булдым. Сөйгәнем дә шул ук хисләр белән җавап кайтарды. Безгә — 20ләр тирәсе. Икебез дә яшьләр, матурлар идек, безгә карап, нинди күркәм парлар, дип сокланалар иде. Кыскасы, август ахырына туй көне билгеләдек. Ул җәйдә симфоник оркестр составында концертлар белән күп йөрдем. Һәм шул чакта бәхет кошымны кулдан ычкырдым. Ул миңа хыянәт иткән. Һәм бер генә тапкыр түгел. Бу турыда ишеткәч, күз алларым караңгыланды. «Дөресме?» — дип сорадым сөйгәнемнән. «Әйе», — диде ул. Тик бу бәланең башы гына әле. Чын-чынлап яратуым хакына мин аны кичерергә дә әзер идем. Бәхетсезлегемә, ул башканы яратуы турында әйтте: «Кичер, — диде ул, — бернәрсәне дә үзгәртеп булмый». Ярсыдым, үз-үземне белештермәс хәлгә килдем. Башта ниятеннән кире кайтарырга маташтым, ә соңрак инде янарга ук тотындым. Елый-елый, телемә нинди сүз килсә, шул сүзне әйтеп сүгендем. Аннары буарга ябыштым. Ул каршы торып маташса да, әкренләп хәле бетте, бераздан бөтенләй тынып калды. Әмма мин кулларымны бушатырга ашыкмадым. Шулчак гаҗәпләнүдән күзләрем шар булды: сул кулымның бармаклары, ниндидер көй уйнагандай, кызның муенында бии башлады. Ритм һәм көйне тотар өчен, бармакларымның хәрәкәтләренә йотылдым. Шайтан алгыры! Бахның «Чакона»сы икән. Варшавадагы хәлләр кабат хәтеремдә янарды, теге СС офицерының шыксыз чырае күз алдыма басты. Өстемә салкын су сипкәндәй булды. Кулларымны ычкындырдым да: «Гафу ит, зинһар, кичерә күр. Сөйгәнең белән бәхетле бул», — дип тәкърарладым. Ул, йөткерә-йөткерә, әкрен генә торды, аңына килгәч, мине җәлләп елап җибәрде: «Мескенем минем, мескен малаем!» Бераздан кочаклашып, кечкенә балалар кебек, икебез дә үкси идек.

Скрипкачы нидер уйлангандай аз гына тынып торды да, тагын дәвам итте:

— Картлыгымда мине нерв авырулары көтеп торуы ихтимал. Сул кулым нечкә гриф буйлап хәрәкәт итәр, ә бармакларым әлеге дә баягы шул шомлы көй ритмына селкенер. Моның белән көрәшү инде авыр булыр.

Ул, кечкенә утларга карап, тынып калды. Шунда гына башыма сукты: безне курку, җан әрнүе һәм куралмау тойгысы берләштерә икән бит.

Бу вакыйга турында Вернерга сөйләргә җыендым. Чөнки ул да теге вакытта авылда, онытмаган булсагыз, скрипкачы хәлендә калган иде. Әмма соңга калдым, бу вакытта Вернерның дөнья белән хушлашуына дүрт еллап узган иде. Минем ана бер генә сорау бирәсем: Миңлебай Атнагулов уйнарга мәҗбүр иткәннән соң, «Ай сонатасы»н тагын берәр мәртәбә уйнадыңмы-юкмы? — диясем килгән иде.

Юктыр дип уйлыйм. Рояль янына якын килде микән әле. Ул бит соңга таба сынлы сәнгать белән мавыкты.

Язмыш йөзебезгә кызыллык китергән елларны телгә аласым килмәсә дә, уйларым кабат шул чорга әйләнеп кайтты. Минем һич кенә дә бер-берсеннән ерак торган ике субстанцияне — кеше хәленә керә белү белән СС һәм Көнчыгыш ведомство кебекләр хакимлек иткән дөньяны бергә бәйлисем килми. Әмма башка алманнар кебек үк, Вернерның да намусына каршы барып дигәндәй шулай эшләми чарасы юк иде. Шунадыр, андый чакларда, җанына бушану эзләгән шикелле, кулына пумаласын алды ул. Мине остаханәсенә чакырып, чираттагы табигать күренешен тәкъдим итте, ә мин исә йөрәгемә якын шул урыннардан күзем алмый йотлыгып карап тордым.

Үземә еш кына шундый сорау бирәм: Вернер үзенең элекке укучысына үч саклады микән? Кайчандыр шәкерте укытучысына сабак биргәнен кичерә алды микән? Мөгаен, ул да скрипкачыдан ким газапланмагандыр, тик бу турыда авызын ачып әйткәне булмады.

Шулай да Вернер үч алырга теләдеме-юкмы икән? Юктыр, рәссам кеше үчлекле була алмый. Шулай булгач, бер генә юл кала — мина булышу.

Шулай итеп, балачакта бергә уйнап үскән иптәш кайчан да булса үзен сиздерми калмас дип, уңайлы очракны көтәргә генә калды. Аны эләктерү уе әкренләп сүнә барган саен, үземне газап утларына салдым: аның эзенә төшү өчен барысын да эшләдемме дип хафага төштем.

Ниһаять, көннәрдән бер көнне Вернер мина сөенечле хәбәр житкерде. Франциядә урнашкан Идел-Урал легионының берничә батальонына җибәрергә Көнчыгыш ведомствода төркем туплый башлаганнар икән. Ике уйлап тормаслык итеп: «Мин анда эләгергә тиеш», — дидем. Вернер исә мине бармаска үгетләргә тотынды: «Беренчедән, бу сәфәр бик куркыныч, чөнки анда сугыш бара, — диде ул. — Икенчедән, Миңлебай Атнагуловның андалыгын берәү дә кистереп әйтә алмый». Тик мин сүземнән кайтмадым: «Кул кушырып утырганчы, барып, үз күзләрең белән күреп кайту — яхшырак», — дидем.

Алга таба хикәяләвем үзем теләмәгән якка юнәлеш алыр дип куркам. Тормыш юлым да сәеррәк күренергә мөмкин. Хәзер төп сызык — үч, калган вакыйгалар шуның ышыгында барачак. Әдәбиятта да шундый алым кулланыла бит: алгы пландагы игътибарны җәлеп итә торган вакыйгалар артында тагын да мөһимрәкләре яшеренгән була. Билгеле, тормышта алай булалмый, анда төп һәм ярдәмче сызыклар булмаган шикелле, алгы-арткы планнар да юк. Соң чиктә барысы да бердәй әһәмиятле, әмма без һаман да беренчелеккә ашкынабыз, вакыйгаларны ниндидер өлешләргә бүлеп маташабыз. Нишлисең, бу — безнең яшәешебез. Әгәр хикәямдә барысы да үч алу белән бәйләнгән икән, моңа үзем генә гаепле, моның алгы-арткы планнары кайда, аларның кайсы мөһимрәк, дип хөкем итү — анысы сезнең эш.

Шулай итеп, теге төркемгә эләктем дә Франциягә китеп бардым. Анда ни өчен тикшерүләр үткәрергә булганнар соң? Эш менә нәрсәдә: Украина

һәм Белоруссия партизаннарына каршы сугышырга теләмәгән күпчелек легион берләшмәләре Франциягә күчерелә. Совет пропагандасыннан ераклаштыргач, алар үзләрен яхшы яктан күрсәтерләр дип ышаналар. Мин катнашырга тиешле тикшерүнең максаты оештыру эшләрендәге кимчелекләрне күрсәтү, отчетлар төзү, шулай ук легионда сугышчан рухны ныгыту була. Билгеле, болар бар да — сафсата. Йөзләгән, меңләгән легионерларны очраттым, тик аларның йөзләрендә бернинди бирелгәнлек, бурыч, җаваплылык дигән төшенчәләрне искәрмәдем. Аларның тонык күзләренә туган яклары турында сүз башлаганда гына нур кунып ала иде.

Тик мине бары тик берәүнең генә чырае кызыксындыра. «Очрашу ничек булыр?» — дигән сорау белән баш ватам. Мөгаен, аның белән исәп-хисапны өзү өчен мөмкинлекләр күп булыр. Хәрби җинаяте өчен дисең дә — вәссәлам. Берәү дә кем гаепле, кем юк икәнен исбатлый алмаячак, өстәвенә, мин Көнчыгыш ведомство вәкиле бит.

Тик өметләнүем тагын бушка китте: Миңлебай Атнагулов бу вакытта Варшавада Бах музыкасы астында җирле халыкны җәзалап йөргән. Бернишләр хәл юк, әлегә аның сәгате суккан чак. Үлемгә дучар ителгән поляклар башы, тәмуг уты өстеннән йөргән, СС офицерының кара формасын кигән, күзләре канәгатьлек алудан елтыраган Миңлебайга күңелләре төшенке, сүлпән, өметләре сүнгән ватандашлары арасында ни калган, ди?

Бер сүз белән әйткәндә, язмыш тагын бер кат минем белән шаярырга уйлады. Җитмәсә, мин аны Франциядә эзләп йөргән көннәрдә ул, һич уйламаганда, Берлинга килеп чыккан. Вернер миңа менә нәрсәләр сөйләде. Бу хәл Көнчыгыш ведомствосы залында була. Татарча арадашчылык итү вәкилләре утырган утырышлар залына СС баш идарәсенең берничә кешесе килеп керә. Аларның башлыгы — СС Көнчыгыш төрки хәрби берләшмәсенең булачак командиры штандартен-фюрер Һарун әл-Рәшид була.

— Әмма иң кызыклысы, — диде Вернер, — СС офицерлары арасында элекке укучым Миңлебай Атнагулов та бар иде. Мин аны шунда ук танып алдым.

Ул да таныгандыр, билгеле. Вернер үзе әйтмәсә дә, шул чакта Миңлебайның чыраенда катып калган теге мыскыллы елмаюын күз алдыма китердем.

— Аралашырга ничектер җай чыкмады. Хәер, мөмкинлек булса да, үзең беләсең, аны читләтеп үткән булыр идем, — дип өстәде ул

Укытучым һәрвакыттагыча «алтын» урталыкны сайлагандыр дип уйлыйм. Шулай да бик нык дулкынлану кичергәндер. «Ай сонатасы»н исенә төшереп, бармаклары тартышып киткәндер.

Ул тагын болай дип аңлатты. Аның элекке укучысы СС баш идарәсенә очраклы рәвештә алынмаган. Нәкъ шул вакытта көнчыгыш иреклеләреннән берләшмәләр төзү турында карар кабул ителгән. Варшава баш күтәрүен бастыруда батырлыклар күрсәтеп, күкрәгенә тимер тәре таккан Миңлебай Атнагулов оешмада ышаныч казанырга өлгергән. Көнчыгыш легионнары Гитлерның өметен акламаганга, СС ише структура бу эшкә җитдиерәк карар дип санаган.

Шуннан соң Вернер Миңлебайны башка күрмәгән. Һәм очратырга теләге дә булмаган. Һәрхәлдә, ул миңа шулай дип сөйләде.

Тик күңелемнең бер почмагында, Вернер аны очратырга теләгәндер, бәлки Берлин урамнарының бер чатында, кесәсендәге пистолетының сабын калтыранган куллары белән кысып, көтеп торгандыр дигән уй пыскып ала. Тик, әйткәнемчә, рәссам гомерендә дә үч алачак кеше түгел.

Миңлебай Атнагулов Берлинда озак тоткарланмый. Төрки халык эшләре буенча белгечлек ана бара торган эш түгел: көннәр буе кабинет саклап утыру, отчет төзү, хатлар язу һәм башка төрле канцелярия эшләре белән шөгыльләнә торган кешеме ул! Анын коточкыч вәхшилекләргә, үтерешкә сусаган жаны моңа түзә алмас иде.

Берлиннан кай тарафларга юнәлүе турында төгәл генә әйтүче булмады. Мина килеп ирешкән хәбәрләргә караганда, Һарун әл-Рәшиднең якын ярдәмчесе сыйфатында ул башта Словениягә, аннары Төньяк Италиягә киткән. Бу Һарун әл-Рәшид житәкчелегендәге оешма бик ашыгыч рәвештә төзелсә дә, нинидер мөһим сугыш хәрәкәтләрендә катнашмый. Гомумән, бу берләшмәнең язмышы бик томанлы, сугыш ахырына таба анын карамагына жибәрелгән солдат һәм офицерлар бөтенләй эзсез-нисез юкка чыккан.

Миңлебай турында әле дә кем нәрсәләр генә сөйләми. Ана кагылышлы документлар да сакланып калган. Мәсәлән, кайсыдыр вакыт аралыгында вәхшилеге белән аерылып торган бер үлем лагеренда начальник урынбасары булып торуы билгеле. Моннан тыш тагын берничә лагерьда үзенең пычрак эзен калдыруы мәгълүм.

Аны күргән-ишеткән кешеләрнең уенча, ул спиртлы эчемлекләр белән артыгын мавыккан. Еш кына алман офицерлары белән лаякыл булганчы эчкән. Сугыш тәмамланып килә, сагышын шнапс белән басмый нишләсен? Никадәр әйләндерсәң-тулгандырсаң да — ул үз илен сатучы, хыянәтче, ә бу исем анын «батырлыклары» янында бер дә матур янгырамый.

Элеккеге әсирләрнең берсе менә тагынниләр сөйләде:

«Без, берничә татар, үзебезнең барак янында сөйләшеп тора идек. Күрәсең, тавышыбыз катырак чыккандыр, монарчы күзгә-башка чалынмаган СС офицерын жәлеп иткәнбез. Ул безнең янга килде. Каршыбызда аягында көч-хәл белән басып торган кеше ватандашыбыз дигән уй башыбызга да килмәде. Бер сүз дәшмичә сәер генә итеп карап тора бу, ә без андый очракта тиеш булганча үрә катабыз. Офицер кесәсеннән пистолетын чыгарды да стена янына басарга ымлады. Үзегез беләсез, боерыкны үтәми булмый, барып тезелдек. Билгеле, монын төбендә ни ятканы барыбызга да аңлашыла, әле ике көн элек кенә исерек алманнар поляк әсирләрен атканнар иде. Бу безгә: «Жырлагыз!» — дип әмер бирде. Югалып калгангамы, ни теләве башыбызга тиз генә барып житмәде. Ул кабатлады: «Жырлагыз!» Иң тетрәндергәне — офицернын саф татар телендә әйтүе булды. Анын карашыннан бәрелгән боз салкынлыгыннан куырылып, жырларга мәжбүр булдык, дөресрәге, Ибрай башлап жибәрде. Борынгы татар халык жырына без дә кушылдык. Жырыбыз көчәйгәннән-көчәя барды. Офицер кымшанмый-нитми тынлап торды. Кайталмас жиргә китүебезгә төшенеп, инде анын күзләренә туры караудан курыкмадык. Жырыбыз ахырына якынлашып, иң югары ноктасына житкәндә, һич көтмәгәндә офицер борылды да китеп барды. Без исә ансыз рәвештә сузуыбызны дәвам иттек. Аннары, исән калуыбызга шаккатып, бер-беребезгә караштык. Мин офицернын жанын күргәндәй булдым: аннан әйтеп бетермәслек сагыш бөркелә иде. Артыннан йөгереп барып, юатырга да уйлаган идем, тик иң соңгы секундта нидер тыеп калды: ул бит — СС офицеры. Бу хәлләрне читтән карап торган бер иптәшем соңыннан болай дип сөйләде:

— Лазареттан кайтып килешем иде. Каршыма күзе-башы тонган офицер килә. Ярый әле, искәрерлек хәлдә түгел иде. Күзләреннән яшь тама, үксүеннән иңбашлары дерелди иде. Ир-атлар шулай тыелгысыз елыйлар дип күз алдыма да китергәнем булмады. Ул пистолетлы кулы белән күз яшьләрен сөртә иде — аңлыйсызмы?

— Исереккә сәбәп кенә булсын, аларда күз яше арзан, — диде кайсыдыр.

— Юк, — дип каршы төште иптәшем. — Монда бүтән нәрсә. Буасы ташыган, күрәсең.

— Бәлки нервлары какшагандыр?

— Белмәссең.

Икенче бер лагерьдагы әсирнең сөйләгәннәрен дә житкерим.

— Үзеннән алда куркыныч даны йөрде аның. Хәер, ул чорда андыйларга кытлык булмады шикелле. Бу СС офицерының яраткан җөмләсе бар иде. «Яһүдне үлемнән бары тик таланты гына коткара ала», — дип кабатларга яратты ул. Билгеле, башка лагерь начальниклары яһүдләргә карата үтә мәрхәмәтсез кыланганда, аның бу җөмләсе күңелдә ышаныч тудыргандыр. Бервакыт без офицерның сүзләрен эше белән раславының шаһитләре булдык.

Лагерьга чираттагы әсирләр төркемен китерделәр. Терезиннан дип хәтердә калган. Араларында бер малай да бар. Әти-әнисеннән аерылган, ялгыз. Карашында курку белән өметсезлек чагылган бу баланы булдыра алганча якларга, сакларга тырышалар. Малайның үзе белән скрипкасы да бар. Хәер, анысы гаҗәп түгел, Терезиннан килүчеләр арасында музыкантлар еш очрый иде. Алар, гадәттә, юлга чыкканда үзләре белән инструментларын да алалар. «Беркатлылар», — диештек. Әйтерсең, аларга биредә музыка белән шөгыльләнергә мөмкинлек тудыралар. Әсирләрне баракларга тараттылар. Көтмәгәндә үсмер — озын, ялыктыргыч юлдан соң арыган булганмы, әллә берәр нәрсәгә абындымы — егылды да скрипкасын кулыннан төшереп җибәрде. Малайны авыру дип белделәр, ахры — ә андыйлар белән санашып маташмыйлар, чир тараталар дип, шунда ук атып үтерәләр — сакчыларның берсе мылтык көпшәсе, итек башы белән төрткәләп, малайны торгызмакчы булды. Малай йөзен куллары белән каплап, хәленнән килгәнчә сакланырга тырышты. «Бетте», — дип уйларга да өлгермәдек, көтелмәгән хәл булды. Теге СС офицеры сакчы каршына килеп, пистолетын аның маңгаена терәде. Бар да шок хәлендә катып калдык. Малай исә тиз генә торды да, скрипкасын эләктереп, иптәшләре артыннан йөгерде. Офицер револьверын төшерде дә сакчыга алман телендә каты-каты итеп әйтеп куйды. Мәгънәсе безнеңчә менә болайрак. Ник итегең чистартылмаган? Ни өчен каешың бушаган? Гомумән, бу нинди кыяфәт? Герман армиясе өчен хурлык! Сакчы, оятыннан җир тишегенә керерлек булып, үрә катып тора. Офицер лагерь идарәсенә таба китеп барды. Каршына икенче бер офицер килеп, аны юлыннан бүлде. Мин бу вакытта идарә каршындагы газонда үлән кыркып маташа идем, шуңа бу сөйләшүне ишетеп тордым.

— Ул малайда талант бар дип уйлыйсыңмы? — Сорау мыскыллы тонда яңгырады.

— Әйе, күзләреннән күренеп тора, — дип кырт кисте беренчесе.

— Американлылар кулына эләккәч, юмартлыгың бәяләнер дип беләсеңме әллә?

— Анысы минем эш. Ычкын каршымнан!

Моңа охшаш истәлекләрне күп ишеттем. Кайберләрендә Миңлебай Атнагуловны шунда ук танып алдым.

Тагын берсен Белградта, тәрәзәсе Дунайга караган фатирда тыңладым. Хуҗа хатын эчемлек тәкъдим итте, ләкин сәламәтлегемне сылтау итеп баш тарттым. «Мин тотып куям әле, — диде ул һәм чокырына аз гына коньяк койды. — Күргәннәр турында аек баштан сөйләп булмый». Күпме түбәнсетү, кимсетү аша узарга туры килгән аңа. Әмма ул салкын канлылыгын җуймаган хәлдә, башыннан үткәннәр турында сөйләп китте:

— Без бу лагерьга иптәш кызым Бранка Рахимич белән эләктек. Безне партизаннар белән элемтә тотуда гаепләделәр. Дөресе дә шулай, икәү бер

яшерен оешмада идек. Лагерьда Бранкага сез кызыксынган кешегә охшаган СС офицерының күзе төште. Ул иптәш кызымны авыр эшләрдән азат итте, башта кухняга урнаштырды, соңрак каядыр башка хезмәткә күчердеме. Бранка көнозын күзгә-башка чалынмады. Төннәрен дә бaрактан чыгып югала башлады. Беребез дә артык сорау бирергә базмадык. Әмма бу хәл дәвам иткәч, түзалмадым:

— Бранка, ничек син шул алман белән шулай булдыра аласың, — дидем.

— Ә ул алман түгел.

— Кем соң?

— Сиңа нәрсәгә ул?

Әлбәттә, минем аңар андый сораулар бирергә хакым юк, чөнки сүз башны саклап калу турында бара, һәм һәркем, ничек булдыра ала, шулай үз гомере өчен көрәшә иде. Тик көннәр узган саен, аның күзләрендә гыйшык уты ныграк дөрләвен күрдем.

— Бранка, янган утка сикерәсең, шуны бел! — дигән сүзләремә җавап кайтармады. Ул, дөрестән дә, мәхәббәт упкынына чумган иде. Аны күралмас дәрәҗәгә життем, берсендә хәтта аңа ташланып, битләрен тырнарга маташтым. Безнең әрләшүне сакчылар күреп калган һәм мина шәп кенә эләкте. Теге СС офицеры белән йөзгә-йөз очраштым. Ул шундый итеп карады, минем урында башка берәү булса, җир тишегенә кереп югалыр иде, билләһи. Ә минем югалтыр нәрсәм калмады. «Барысын да кичерерләр дип беләсеңме?» — дидем. Ул дәшмәде. «Житәр вакыт, син боларның барысы өчен дә түләячәксең әле», — дип дәвам иттем. Ул мыскыллы көлемсерәде дә: »Киләчәгем пуля сызгыруына тиң. Аны берәүнең дә куып тотканы юк әле», — диде. Аннары күзеннән очкыннар чәчрәтеп: «Яле, кәнтәй, нәрсә тоярсың икән? — дип, авызыма пистолет көпшәсе тыкты. — Ничек, оҗмах чатырлары күренмиме?» — дип акырды. «Әйт әле, анаң белән минем арада нинди охшашлык бар?» — дигән соравына башым түнеп киткәндәй булды. Ни дип җавап бирергә дә белмәдем, хәер, теләсәм дә булдыра алмас идем, авызымда пистолет көпшәсе бит. Ул җавап көтеп тормастан: «Әниең сиңа тормыш бүләк иткән, ә минем бүләгем — үлемең булыр. Шулай булгач, әниең белән мин арадашчылар булып чыгабыз», — дип, пистолетын бугазыма кадәр батырды. Мин чыдый алмыйча укшырга тотындым. Ул борылды да китеп барды, ә мин җиргә бөгелеп төштем. Исән калуыма барысы да гаҗәпләнде. Шуннан соң мин аңа Бранка күзләре белән карарга тырыштым. Аңарда ниндидер дәһшәтлелек белән бергә үзенә тартып торган көч бар иде. Ә мажаралар яраткан Бранкага нәкъ шундыйлар ошый да. Иртәме-соңмы башыма житкәнен көттем, әмма ул мине тынычлыкта калдырды, мөгаен, иптәш кызым үзенә каратудан файдаланып, аны кире күндергәндер.

Хатын сигаретын кабызып, башын кәнәфи артына ташлады. Бер-ике суыргач, сөйләвен дәвам итте:

— Шул вакытта күзләремә карап әйткән сүзләрен еш исемә төшерәм. Үтерүче белән корбан арасында ниндидер аңыбызга буйсынмый торган бәйләнеш бар. Хәзер күп нәрсәгә башка күзлектән карыйм. Теге кешене дә аңлый башладым шикелле. Ул үзенең куркыныч язмышлы адәм икәнен белгәндер. ССка, нацист идеологиясенә, билгеле, төкереп биргән ул. Үзенең иблис юлыннан бара биргән, ә җәзасы аның юлы белән кисешкәннәргә төшкән.

— Шайтан алгыры! — дип кычкырып җибәрде башына киткән хатын. — Менә ничек борып була бит, ә. Явызлык белән очрашабыз да соңыннан ниндидер ярашканлык эзләргә тотынабыз. Яки киресенчә, кызганабыз

дип, мәрхәмәтле булып кыланабыз да, вакытлар узгач, аның бер тиенгә тормаганын аңлыйбыз. СС офицеры урыслар килергә бер атна калганда юкка чыкты. Аның белән бергә Бранка да югалды. Озак вакытлар иптәш кызым турында бер хәбәр дә булмады, инде исән калды микән, дип шикләнә дә башлаган идем — сугыш бетеп, ике айлар узгач, Бранка кабат Белградта күренде. «Кайда югалдың?» — дигән соравыма: «Икенче лагерьга күчерделәр, союзниклар килгәнне шунда көтеп алдым», — дип җавап бирде. Озак та үтмәде, ул Миланга — икетуган апасы янына күчеп китте.

Хатынның хикәясе мине, әлбәттә, битараф калдырмады. Тик Миңлебай Атнагуловның ул чордагы тормышы мәгълүм иде, шуңа әллә ни яналык тапмадым. Мине аның күзе төшкән, өстеннән серле рәвештә идарә итә алган Бранка Рахимич кызыксындырды. Һәм бернигә карамый аны эзләп табарга карар кылдым. Миланда гомер сөргән икетуган апасын барып таптым, әмма шигем расланды: Бранка моннан да китеп барган иде.

— Ул минем янымда ел ярымлап яшәде, — диде апасы. — Аннары Америкага китте. Ике ел элек Мехикодан раштуа белән котлап язган открыткасын алдым, шуннан бирле хәбәр-хәтере юк.

Миңлебай Атнагуловның үзе белән ниләр булды икән? Сугыш ахырында эзен югалтканнан соң ниләр майтарган? Кемдер аны Һарун әл-Рәшид белән Испаниядә күргән. СС офицеры формасын штатский киемгә алыштырган, имеш. Аннан соңгы язмышын берәү дә әйтә алмады.

Сугыш истәлекләренә чумып, кабат шул дөньяга әйләнеп кайттым. Миңа бит халык ләгънәтен алачак кара көчләр ягында булырга туры килде. Аны ул чорда яшәгән, җаны аша үткәргәннәр дә ахырына кадәр аңлап житкерә алмый. Гаепләләр бармы ул чорда һәм алар кемнәр? Гаепләләр билгеле, меңләгән, йөз меңләгән, диярсез. Алай булалмый, дип каршы төшәр берәрсе. Бар шундый кешеләр, алар үзләренең нәрсә эшләгәннәрен дә белми, андыйлар — күпчелек. Әмма кара эшләргә аңлап баручылар да җитәрлек. Гомере буе икенче бөтендөнья сугышы тарихын өйрәнгән бер хезмәттәшем болай дигән иде:

— Беләсеңме, Ходай Тәгаләдән ни сорыйм? Тәмугка озатуын.

— Ник?

— Гитлер белән сөйләшер өчен башка мөмкинлек булмаганга.

Галимнең өметсез, шул ук вакытта тәэсирләндергеч омтылышы өчен кичерик. Әмма мин фикеремне тагын бер тапкыр кабатлыйм: ул коточкыч вакытны ахырына кадәр аңлау мөмкин түгел.

Хикәямнең төп сызыгыннан читкәрәк киттем шикелле. Атнагуловка күп урын бирүем аңлашыладыр: хәйләкәр, үзенә тартып торган кеше буларак, ул үзенә игътибар иттерә белә. Тик мин үз язмышым турында да онытмыйм әле. Монысы минем өчен отышлырак, чөнки үзем белән булган вакыйгалар турында сүз бара. Нindider хата, ялгышлыклар бар дип тапсагыз, алар ике сәбәп аркасында булырга мөмкин. Беренчесе — дөресен сөйләмим булып чыга, тик мин моның мәгънәсен күрмим. Ялган сөйләр өчен шундый озын монолог башлар идеммени? Икенчесе — кыскача эчтәлектәге вакыйгалар аек акылы булмаган кеше тарафыннан сөйләнә дип нәтиҗә ясарсыз. Әмма бу шулай ук дөрес түгел, димәк, миңа ышанырга кала.

Янә кырык дүртенче елга әйләнеп кайтам. Мин элеккечә Франциядә, бар тырышлыгымны җигеп, дошманым шәүләсен эзәрлеклим. Тикшерү тәмамланып килә. Комиссия белән соңгы пунктка килдек. Бу татар легионы берләшмәләренең берсе, дөресрәге, Клермон-Ферран шәһәре тирәсендә урнашкан рота иде. Иртәгесен Көнчыгыш легионнар белән идарә итә торган штаб урнашкан Нансига китәргә, ә аннан Берлинга кайтырга тиешбез.

Көн кичкә авышканда, шундый хәл булды. Солдатларның юынгычлары

янынннан атлаганда башыма, шәхси үчләрен алуны күктәгеләргә тапшырганнар дөрес эшли, ахры, дигән уй килде. Туктадым да, җавап ишетергә теләгәндәй, өскә карадым. Күктә салмак кына бөдрә болытлар йөзә. Күзләремне түбән төшерүем булды — каршымда басып торган Җамалый Рәсүлевны күреп алдым. Исегездәдер, Хорол лагеренда дошманым белән бер исем-фамилиядә йөрүче акылы авышкан берәү янына алып барган иде?

— Таптыңмы? — дип сорады ул.

— Юк.

Беренче карашка бу очрашуга аптырарлык берни юк сыман. Ротада танышлар җитәрлек, чөнки әсирләрне үз кулларым белән легионга теркәдем. Әмма бу кешенен көтмәгәндә килеп чыгуын нәрсәгә юрарга да белмәдем.

— Син монда ничек эләктең? — дип сорадым.

— Башкалар кебек үк.

Мин Хорол лагереннан китүгә, ул да легионга язылган икән. Дошманым артыннан Ромныга ашыкканга, бу минем катнаштан башка эшләнгән.

Сөйләшүне яныма якынлашкан дневальный бүлдерде, штабка чакырганнар икән. Анда баргач, Нансига кузгалачагыбызны искәрттеләр. Дүртебезне автомобиль көтеп тора, ә беребезгә, урын җитмәү сәбәпле, лагерьда куна калырга туры килә, диделәр. Башкаларның монда төн уткәрү теләге булмаганга, үзем калырга булдым.

Төнлә күземә йокы кермәде. Әйләнгәләп-тулгангалап ята торгач, түзмәдем, торып йөреп керергә уйладым. Тышта кап-караңгы, ул үз эченә нәрсәнедер яшергән шикелле. Әгәр шунда таба атласам, күзгә күренмәс юл аша теләгән җиремә илтер кебек.

Якында гына сөйләшкән тавышлар ишетелде. Җамалый Рәсүлев белән ике легионер икән. Алар, җирдә яткан бүрәнә өстенә утырып, әлүмин кружкадан чәй эчәләр иде.

— Утыр, — дип тәкъдим итте Җамалый. Кружкага термостан чәй агызды да миңа сузды. Кырык дүртнең караңгылык канат җәйгән төнендә дүрт татар Төньяк Франциядә чәй эчеп утырабыз. Теләсә кайсы чәйнең, әле яфракта килеш, хәтере була. Ә бу чәйнең хәтере әлеге мизгел белән кисешкә. Шул турыда уйлап утырганда, кинәт җил исеп куйды, тозлы тәменнән аның Атлантика җиле икәнен аңладым. Күк йөзенә йолдызлар сибелгән. Баш өстендә генә берсе, артыннан җемелдәвек эз калдырып, җиргә атылды.

— Йолдызлар чәйгә атылган төн, — дип куйды берсе. Берәр шагыйрьнең шигырь юллары булдымы — анысын төшенмәдем.

Әрәмәләр арасыннан ниндидер кош тавыш бирде. Легионерларның берсе аңа чутылдатып җавап кайтарды. Ул да түгел, куаклар эчендә кыштырдаган тавышлар ишетелеп, шәүләләр шәйләнде. Кошка охшатып чутылдау шартлы сигнал булган икән.

— Без инде китәргә әзерләнгән идек, тик күңелем киләсенне сизенгәнгә, тоткарландык.

Шулчак артта шау-шу, аяк тавышлары ишетелде. Лагерь ягыннан безгә таба бер төркем кеше килгәне күренде. Алманнар иде, ахры. Җамалый шул якка таба атып җибәрде. Шунда ук җавап та кайтардылар. Ике арада атыш башланды.

— Йөгердек! — дип боерды Җамалый Рәсүлев.

Куе куаклар эченә кергәч, безне, Җамалый белән алдан килешенгәнчә, француз партизаннары каршы алды. Җылы җәйге төн, Атлантика ягыннан тозлы җил исә, күктән йолдызлар атыла. Ниһаять, тоташ түгәрәк эченнән чыгуымны, алда әйткәнемчә, өске катка тин ин астагысында булуымны аңладым. Тиздән без аланга килеп чыктык, француз телендә дәшсәләр

дә сүзнең нәрсә турында барганына шунда ук төшендем, чөнки кешелек дөньясы телләре, куәтле җилләр кебек үк, бер-берсенә якын, аларның нигезендә икенче берәүне ишетергә теләү ята.

Хикәямнең бу урынында тукталыш кирәк. Ни өченме? Бераз тын алып, гомеремнең алдагы өлешенә көчү өчен. Сез аңлаганча, кырык дүртнең җылы төнендә Җамалый Рәсүлев һәм аның ике иптәше белән маки отрядына кушылдык. Аннан соң менә ниләр булды. Сугыш ахырына кадәр француз каршылыгы отряды сафларында сугыштым. Гомеремнең нәкъ шул өлеше минем өчен аерата кадерле булса да, аңа артык күп вакыт бүлалмыйм. Менә ни өчен: үзем телимме-теләмимме, хикәяләвемә төп юнәлеш бирүче булып үч алу тора. Миңлебай Атнагулов исә, минем белән бәйле әлеге вакыйгаларга бәйләнеше булмаганга, югалып торырга мәҗбүр була. Сезнең игътибардан төшеп калмас өчен, онытылмас вакытлар турында бер-ике авыз сүз белән чикләнәм. Мин кабат, авыл ирләре белән Кара урманга киткән мәлдәге кебек, иркенгә чыгу хисе татыдым. Караңгы төн безне үч эченә яшерде. Биек кыя артыннан тәгәрәп Ай килеп чыкты, һәм йөрәкне чеметтереп туган авыл искә төште. Мин килеп эләккән отрядта татарлар — элекке Идел-Урал легионерлары шактый иде.Сугышта гадәти хәл саналса да, Җамалый Рәсүлев белән юлларыбыз аерылуны авыр кичердем. Соңрак аның Тулуза янында барган сугышта һәлак булуын ишеттем.

Кемнәрдәдер миңа карата ышанмау хисе туарга мөмкин. Элек алманнарга хезмәт итүемне юар өчен генә партизаннар ягына чыккан бу, дип уйларлар. Уянган намусын басмакчы булгандыр, дип әйтерләр. Бер яктан шулай да булсын, ди. Әмма мин күңелемдәген яшермим: ул төндә үземне Җамалый Рәсүлев белән мине үзе артыннан әйдәкләгән билгесез бер көчкә ышанып тапшырдым.

Макиларга килеп кушылган элеккеге легионерларга да шулай каш астыннан карыйлардыр. Сугыш тәмамланасын чамалап, Җиңү көнен партизан сафларында каршы аласылары килгән, ягъни җәзалаудан үз-үзләрен шулай сакларга теләгән дип уйлыйлардыр. Бу хакта болай дип әйтәсем килә: нигә соң алайса алар, тормышларын куркыныч астына куеп, хәрби корал складларын, поездларны шартлаттылар, яисә Җамалый Рәсүлев кебек батырларча һәлак булдылар? Күбесенең күкрәкләрендә Франциянең югары бүләкләре тагылган. Әмма туган илгә кайткач, аларның бүләк-казанышларына карап тормый-нитми кабат лагерьларга — монысында инде сталинныкына сөрделәр.

Әйдә, тормышның бу этабын йомгаклап, бераз тын алыйк.

## V бүлек

Сарман Биги кабат чәй яңартты. Онытмаган булсагыз, чәй безнең каһарман тормышының аерым мизгелләрендә еш телгә алына. Мәсәлән, кырык дүртнең «чәйгә йолдыз егылып төшкән төн»е. Аерым персонажлар белән бәйле рәвештә дә күренеп ала. Әйтик, үзенең үткәне һәм киләчәге белән сөйләшүче Зариф карт чәйнең сорты турында сөйләнә. Яки чәйнең хәтере барлыкка ышанган Бату Сакаевны искә төшерик.

Сүзсез генә чәй уртлыйбыз. Поезд Казан ягына ашкына. Юлдашым белән безне аның хикәясе генә түгел, чәй дә бәйли. Күрәсең, Сарман Биги чәй мәсьәләсендә яхшы белгеч, сөйләгәннәренә охшаш авызны бөрештерә торган ачысын сайлаган. Ул мине тәмам үзенә каратты, аның истәлекләрен юл буе тыңларга әзер идем. Яңа гына пешерелгән чәй янында, тәгәрмәчләрнең бер ритмда тукылдавын тыңлый-тыңлый, юлыбызны дәвам иттек.

— Туган якларга житәбез, — дидем мин. — Ниләр кичерәсез, Сарман ага?

Бәлки сорауны бирүем урынлы да булмагандыр, тик әңгәмәдәшемнең кичерешләрен белү теләге журналистлык гадәтемә сеңгән.

— Белмим, — дип җавап бирде ул уйчан гына. — Өйдә булмавыма алтмыш елдан артып китте. Төшләремә менәр кат кереп йөдәтеп бетергән урыннарны йөреп чыгармын. Ничек тәэсир итәсен күз алдыма да китерә алмыйм.

Берникадәр вакыт юлдашым үзалдына карап, уйларына чумып утырды. Бүлдерергә кыймадым, чөнки аның дәшмәгән кешене бүлдерү сөйләүчене бүлдерүгә караганда мең тапкырга мәгънәсезрәк дигән сүзләре колагымда яңгырап тора.

Озак та үтмәде, Сарман Биги янә сөйләп китте:

«Хикәям никадәр генә мавыктыргыч тоелмасын, ахыры күренгән калкулыкка менәргә вакыт җитте, дип уйлыйм. Ахыры дигән сүз мине һәрвакыт уйга сала. Ул туктап калу котылгысыз дигәнне аңлата шикелле. Шул ук вакытта ахыр чик дигән мәгънә дә салынган кебек. Телебездә ул сүз еш очрый. Мәсәлән, таякның ике башы — чиге бар. Кеше гомере дә ике чиктән тора. Бер уйлаганда, аларда охшашлык юк кебек, тик шунысы бар — кайсы яктан карыйсың бит. Менә таякның башы, яки ахыры дибез. Киресенчә дә әйтеп була. Әйтәм бит, ничек карыйсың. Тагын кирәкмәгән якка кереп барам, ахры. Күп сөйләшсәм, түбәсе кыйшая башлаган моның диярсез тагын. Ә минем максатым — тормыш юлым турында сөйләп бушану. Алга таба мондый фәлсәфәдән читкәрәк китәргә тырышырмын.

— Юк-юк, күңелегездә ни бар — сөйләгез, — дидем мин.

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт. Эш анда гына түгел, вакыт кыса, озакламый аерылыр чак җитә.

Сарман Биги чынаягындагы чәен йотып куйды да дәвам итте.

— Әлегә кадәр бәян иткән тормыш юлым турыдан-туры яшәү урыннарым белән бәйле иде. Башта Россиянең урта полосасындагы кечкенә генә авыл, аннары Төркия, Германия, Франция. Әкренләп хикәямнең ахырына җитеп киләм. Язмышым тагын кай урынга бәйләп куяр? Хәзергә бер генә шәһәрне дә, илне дә төгәл генә атый алмыйм.

Исегездәме, сезнең белән роман язу турында сөйләшкән идек. Мөгаен, үзем очлап чыгалмам, бәлки идеям берәр каләм иясен кызыксындыра алыр. Әйткәнемчә, роман шәһәр яки авылга кагылышлы юл күрсәткеч формасында язылырга тиеш. Үзем тотынсам, сүз дә юк, туган авылым Айны сайлар идем. Сюжет сызыклары урам буйлап өйдән өйгә, персонаждан персонажга күчә барыр иде. Урамнар кисешкән чат — иң әһәмиятле урын, анда төп геройлар яши. Ким дигәндә, ике урам буйлап барасың, аларның исемнәре ешрак телгә алына. Нәтиҗәдә роман геройлары ниндидер магик күппочмаклык хасил итә. Шул авылда яшәгәнгә, аның кешеләре күңелгә якын, безгә монда иркен, уңайлы. Әйтерсең лә күктә очып йөрим. Планета авылыма әйләнә. Романымның көньяктан төньякка бара торган сюжет сызыгы көнчыгыштан көнбатышка юнәлә торганы белән кисешә. Персонажлар бер-берсенә әле якынаялар, әле ерагаялар; кайсылары үзара таныш, ә кайберләре бер-берсен күргәннәре дә юк, тик без аларның һәммәсен дә беләбез. Араларыннан кайсыларындыр яратабыз, ә кайсыларындыр күралмыйбыз — шунсыз чын әсәр була алмый. Бар нәрсәне геройлар белән бергә кичерәбез, җил безгә аларның дулкынланган тавышларын китереп ирештерә. Алар төрле телләрдә сөйләшсәләр дә, чынбарлыкны күрсәтергә тырышалар. Без аларны аңлыйбыз, чөнки барыбыз өчен дә уртак нәрсәләр: тормыш-яшәеш, мәхәббәт һәм үлем турында сөйлиләр.

Хәлбуки, эш ахырга таба барганга, тормышымның тагын бер кисәген — Икенче бөтендөнья сугышыннан соңгы егерме елны сикертеп үтмичә

булмый. Сәбәбе шул: беренчедән, бу өлештә Миңлебай Атнагуловның катнашы юк; икенчедән, язмышымда әллә ни яңалыклар булмаганга, сезнең өчен күңелсез тоелыр дип уйлыйм. Шуны гына әйтим: ул вакытларда фәнни эшчәнлек белән шөгыльләндем. Бөтен дөнья буйлап йөреп, лекцияләр укырга туры килде, аннан тыш, конференция, симпозиум һәм башкаларда катнаштым. Тик, әйткәнемчә, болары турында сөйләп тормаска исәп. Шулай да гомернең кайсыдыр өлеше никадәр генә бертөрле, артык игътибар итмәслек кебек тоелмасын, кайчакта хыялларны таң калдырырлык, йә яңа хакыйкать табарлык мизгелләре була. Бервакыт Һамбург рестораннарының берсендә ул чакта бик азларга гына таныш «Битлз»ны тыңладым. Шул вакытта җаным телгәләнүен белсәгез, ә бер-ике елдан шулар авызыннан кешелеккә «All you need is love!» дигән мөрәҗәгатьне ишеттем.

Шулай итеп, гомеремнең егерме еллык өлешен үткәреп җибәреп, хикәямне дәвам итәм.

Алтмышынчы еллар башында күп вакытымны Көньяк Америкада үткәрдем. Ул елларда фәнни кызыксынуым колачы тагын да киңәйде: көньяк америкалы индеецлар теле белән төрки телләрнең охшашлыгы темасы мавыктырды. Шуңа күрә юлларым Боливия, Чили, Аргентина, Перуга алып килде. Кешелек дөньясы телләре үзара якын тора дип әйткән идем инде. Кайчандыр борынгы индеецлар яшәгән шәһәрләр урнашкан тирән тар үзәннән барганда, яисә серле корбан чалу йолалары башкарылган кыя ташка күтәрелгәндә, үземне юкка чыккан цивилизация токымыннан кебек хис иттем. Бервакыт яшерен урыннарның берсендә аяк киемемне саласым килде, яланаяк калгач, табаным аша йөрәгемә менеп җиткән ниндидер тирбәнеш, калтырау тойганым исемдә — әйтерсең җир мине үзенеке итеп кабул итте. «Дөрес, — дидем үз-үземә, — индеецлар белән безнең ата-бабаларыбыз уртак». Әмма шунысы кызыклы: төркиләр белән дә, индеецлар белән дә бернинди уртаклыгы булмаган төрле илләрдән килгән коллегаларым да бу урында нәкъ шундый ук хис кичергәннәр икән. «Мөгаен, ул кешеләрне туганлаштыра торган аерым урындыр», — дип, бу турыда кунакханә портьесы — өлкән яшьтәге мексикалы белән дә уртаклаштым. Гаҗәпкә, ул: «Җир шарының теләсә кайсы урыны — шундый, дип кенә әйтте дә: — менә ачкычларыгыз, иртәгә сезне ничәдә уятасы», — дип өстәде.

Кыскасы, тулаем эшкә йотылганга, мин илдән-илгә күчү белән бәйле теләсә нинди уңайсызлыкларны кичерергә әзер идем. Монда килүемнең икенче сәбәбен дә әйтим. Берчак Перуда тауларга илтә торган автобусны көтеп станциядә утырам. Башка кабарлык эссе көн. Көндезгә кызулык аша калдырып китәсе шәһәрнең сызыклары шәйләнә. Җиңелчә изрәп, йокымсырап киткәнмен. Кинәт башымнан: «Ни калган миңа монда — бөтенләй икенче ярымшарда?» — дигән уй сызылып үтте. Озак көттерми җавабы да табылды. Минем алда — еракта ата-бабаларыбыз шәүләләре, җанга ярашлы яшерен тирбәлешләр, хәрәкәтләр сизелеп торган, кешелек дөньясы телләрен якынайта торган дулкынландыргыч очсыз-кырыйсыз киңлекләр икән бит. Тик боларның артында йөрәк сыкраганны хәтерләткән бер кара нокта бар — ул вакытлыча онытылып торган үч алу теләге.

Кырык еллар узуга карамастан, Кара урманда яңгыраган антым һаман да тынгылык бирмәде. Сугыш тәмамлангач, Миңлебай Атнагулов белән азмы-күпме бәйләнешле хәбәрләрне җентекләп тикшереп бардым. Тик ул кабат эзсез-нисез юкка чыкты.

Тиешле җәзаларын алган элеккеге СС башлыклары һәм аларның ярдәмчеләре исемлегендә дә табылмады. Әллә, чынлап та, Вернер фикеренчә, аны кара формадагы үтерүчеләр котылыр урын тапкан латин америкасы илләреннән эзләргә кирәктер. «Безнең Миңлебай, бернинди

шик тудырмыйча, кайдадыр Боливиядә, яки Уругвайда ранчо хуҗасы булып ятуы ихтимал», — дигән иде ул. Бик мөмкин, чөнки Минлебайның лагерьдагы сөяркәсе Бранка Рахимичның эзе дә шул тарафларга китеп югала бит — икетуган апасына язган соңгы открыткасы Мексикадан җибәрелгә Вернерның шиген көчәйтә түгелме? Бер уйлаганда, алар нигә дип бергә булырга тиешләр әле? Житмәсә, Европаны икесенә ике вакытта ташлап китәргә туры килгән. Шулай да бу фикергә ике куллап ябыштым.

Үч алуны тормышка ашыра алмавыма микән, соңгы елларда мине оялу, читенсенү хисләре биләп алды. Бәлки бер философ « үч алырга ниятләүче юкка күптән савыгыр һәм төзәлер ярасын кузгата» диюе белән хаклыдыр? Уйлап та ахырына житкерә алмаганга борчылам, ахры. Ни булса да, бу тойгы калдырырга уйламады. Әгәр берәрсе ялгышлык белән минем чемоданны ачып караса, аның төбендә яткан күптәнге ике фоторәсемне күреп алыр иде. Беренчесендә — СС формасы кигән адәм басып тора. Кем икәне әйтмәсәм дә аңлашыла торгандыр. Бу фоторәсем мина сугыш тәмамланып бернечә ел узгач, француз каршылык отрядындагы дусларым ярдәме белән килеп иреште.

Икенчесендә — 18 яшьләрдәге сөйкемле кыз — Бранка Рахимич. Белградка баргач, апасыннан сорап алып, күчермәсен эшләткән идем.

Үземне бер детективтагы үтерешләр чылбырын тикшерүче, үзе дә аңламыйча шулар рәтендә йөрүче каһарман белән чагыштырам. Аермабыз шунда — мин әлегә үтерергә генә җыенам. Бу илләрдә тоткарлануым да — Минлебай Атнагуловны эзләп табу өчен икәненә, ниһаять, төшендем. Шуңа тагын да активлаштым. Әлеге фоторәсемнәрне шунда яшәгән халыкка, такси йөртүчеләргә, метрдотельга һәм асрауларга күрсәттем. Билгеле, Минлебайны мондый юл белән эзләү — юкны бушка авыштыру. Тик мин очраклылык буласына ышанычымны югалтмадым.

Латин Америкасына килүемнең сәбәбен үч алуга гына кайтарып калдырмавыгызны телим. Чөнки индеецлар телен өйрәнү элеккечә игътибар үзәгендә кала бирә, ул эшкә баш-аягым белән жигелдем дисәм, дөресрәк булыр. Бу ике сәбәп мине шушында ниндидер күренмәс җепләр белән бәйләп тота. Шунысы да бар, еш кына без кирәкмәгән жирдә яшерен мәгънә эзләргә яратабыз. Мин исә юлларым кайчан да булса кирәкле урынга китереп чыгармый калмас, дигән уй белән үземә язылган юлдан тайпылмаска булдым.

Ул арада эзләвемнең чикләре тарайганнан-тарая барып, ахырда Аргентина гына торып калды. Ни өчен Аргентина? — дип кызыксынырсыз. Ул елларда мина ярдәм итәрлек кешеләр белән, шул исәптән нацистларны эзәрлекләүче Симон Визенталь белән хәбәрләшеп тордык. Моннан тыш, Буэнос-Айрес шәһәре янында Адольф Эйхман кулга алына. Әнә шул хәбәрләр нәкъ менә бу илгә китерде. Латин Америкасына китергән сәбәпләрнең иң мөһиме булып, шулай да, индеецларның кечуа телен өйрәнергә теләвем кала бирә. Озак вакытлар шул телдә аралашучылар яшәгән Перу һәм Боливиядә тордым, ә хәзер исә мине Төньяк Аргентинада яшәгән аз санлы кечуа халкының жирле сөйләше кызыксындыра башлады.

Озакламый Килья районына барып чыктым. Беренчедән, бу телдә сөйләшүчеләр шушында сакланып калса, икенчедән, «килья» сүзе кечуадан тәржемә иткәндә Ай сүзен аңлатуы үзенә жәлеп итте. Онытмаган булсагыз, Россиянең урта полосасында урнашкан туган авылым шул исемне йөртә. Әле дә хәтеремдә, бу охшашлыкны белүгә, йөрәгем сулкылдап куйган иде.

Сез, мөгаен, минем сөйләвемдә бик күп туры килүләрне күрәсездер. Әйе, тормыш туры килүләрдән тора, һәм, ихтимал, без аны үзебез шулай тартып китерәбездер. Күктәгеләргә еш кына бер үк үтенеч белән инәләбез,

һәм ахырда алар түзә алмый — без сораганны үти. Ә бәлки туры килүләр бөтенләй юк нәрсәдер, без үзебез дә сизмәстән язмышыбыз төйнәлгән урынга — вакыйгалар сәер рәвештә бер-берсенә тәэсир итә торган аерым зоналарга ашыгабыздыр да, шуны туры килү дип атыйбыздыр?

Кильяга барып житү өчен шактый вакыт кирәк булды. Яшем баруы да үзен сиздергәндер, юлдагы уңайсызлыклар да — алары житәрлек булды — сәламәтлегем какшап китте. Бер кунакханәдә, агуланып, янып, саташып, атнага якын урын өстендә аунарга мәҗбүр булдым. Шул саташулы көннәремнең берсендә, шыбыр су эчендә ятканда, «озакламый дошманыңны очратачаксың» дигән тавыш ишеттем. Бу — минем киләчәктән яңгыраган үз тавышым иде.

Савыккач, көчем арта барганын сизеп, әйләнә-тирәне урап кайтырга уйладым. Таң беленеп кенә килгән вакыт. Үзәнлек буйлап бара торгач, елгага барып тераләдем һәм ярына утырып озак кына хәл алдым. Елга ашыга-кабалана таудан агып төшә дә, юашланып, җай гына юлын алга таба дәвам итә. Аның төшләремә кереп йөдәткән шикелле кара-кучкылт суына карап утырганда, башыма бер уй килде: әгәр дә үлемсез булсам, дошманымны, һичшиксез, табар идем, чөнки мәңгелектә иртәме-соңгы ниятләгән уй тормышка аша. Әмма мәңгелек һәрбер аерым язмыш эчендә булырга тиеш. Шуңа күрә Миңлебай Атнагуловны очратмый калуым мөмкин түгел. Бу уйда ниндидер тузга язмаган мәгънәсезлек тә, шул ук вакытта аерым бер инанганлык та бар. Үз уйларыма бирелеп, агымсуга карап шактый озак утырдым. Аннары карашымны еракkарак күчердем: елга башта туры гына ага да, аннары сулга авышып, еракtан күренеп торган тауларга таба китә икән.

Шунда кинәт башка сыймый торган хәл булды. Йөрәгем күккә кадәр сикергәндәй булды да, каршымнан исәпсез-хисапсыз үлгән, әле туарга өлгермәгәннәрнең җаннары үтеп китте, үз җаным да иртәме-соңмы барачак мәңгелеккә ашты.

Нәрсә булды дисезме? Каршымдагы табигать күренеше гаҗәеп дәрәҗәдә туган авылым Айны хәтерләтте. Әнә хатын-кыз күкрәкләрен хәтерләткән ике калкулык, еракка китеп югалган елга, калкулык итәгеннән күтәрелгән Кара урман. Дөрес, урманның агач, үсемлекләре тропик урманныкы, елгасы безнекенә караганда көчлерәк агымлы, ике калкулык та биегрәк, текәрәк. Бу охшашлыкта — тулысынча булмаса да — кешелек дөньясы телләренең уртаклыгы чагыла кебек.

Ничә еллар читтә йөреп, Төньяк Аргентинада тапкан «туган авылыма» атламый хәлем юк дип, шул якка киттем. Көне буе бардым. Кул сузымында гына күренгән таулар атлаган саен ерагая гына бардылар. Мондый күренеш — рәшә — турында ишеткәнегез бардыр, бәлки. Әмма юл миңа бернинди кыенлык тудырмады, вакыт узганы сизелмәде дә. Көн кичкә авышып, кояш ике тау артына качуга, болай да тел-теш тидермәслек матурлыкка шәфәкънең ал төсмере дә килеп кушылды. Минем инде кире борыласым килмәде.

Бераздан кояш күмелеп, эңгер-меңгер төште, һәм тауларга хас булганча, тирә-якны бик тиз арада карангылык чорнап алды. Әлегә кадәр озата барган елга, читкәрәк авышып, тавышы әкренләп тоныклана барды. Ә мин исә, юнәлешемне үзгәртмичә, атлый бирдем. Юлдашым — елганы югалткач кына, көтелмәгән сәфәремнең авырлыгы сизелә башлады. Инде ничә мәртәбәләр үз-үземне битәрләп биргән сорау кабат калыкты: үч алу теләге мине тагын кая китереп тыкты инде? Йә Ходам, нишлим мин җирнең бөтенләй икенче ярымшарында? Бер карангылык икенчесен алыштыра, алда тагын ниләр күрәсем бар икән? Бәлки монысы авызын ачып йотарга

әзерләнгән карангылыктыр? Бу юл мине кайларга китереп чыгарыр? Үлемем көтеп тора мәллә, төгәлрәге — үзем белән очрашаммы әллә? Әйтәләр бит, үлеменне каршылаганда көзгедәге шикелле үзенне күрәсең дип. Тик никадәр шүрләтсә дә, юлымны бүлмәдем.

Алда утлар җемелдәгән кебек тоелды. Бу миңа көч өстәде һәм мин туп-туры утларга таба юл тоттым. Ул да булмады, автомобиль тавышы ишетелде, аның фарасыннан төшкән яктылык агачлар өстеннән шуышып үтте, димәк, кайдадыр якында гына шоссе үтәргә тиеш, дип уйладым. Дөрестән дә, берникадәр вакыттан аякларым асфальт катылыгын тойды. Фарадан сирпелгән яктылыкка коендырып, тузан уйнатып тагын бер автомобиль узды. Юлның икенче ягында тәрәзәләре балкып утырган кафега тартым бина күренде. Якынрак килгәч, су тавышы кабат янарды, димәк, елга кабат мине эзләп тапты. Безнең авыл карты Вафа бабай мондый очракта, аккан су юлын таба, дигән булыр иде.

Юл буендагы кафе кызыл балчыктан салынган ике катлы бинадан гыйбарәт. Почмаклары —әллә җил, әллә киек җанварлар эшеме — шактый ашалган. Ишекне ачып кердем. Эчтә җанлылык хөкем сөрә, күзләрне ачыттырып тәмәке төтене йөзә, кәһвә һәм кыздырылган ит исе аңкый. Өстәлләр тирәли төс-битләре белән гаучоны хәтерләткән кешеләр утыра. Күбесенең башына киткән, кайсыларыдыр карта суга, сыеграк буынлылар борыннары белән өстәлгә төртелгән. Эчемлек тәэсиреннәндер, һәрберсенең йөзенә сугышырга әзер тору рәвеше чыккан. Әгәр куркыныч яный-нитә калса, берсе дә үзен кулда тотар дәрәҗәдә түгел. Керми хәлем дә юк, беренчедән, башка барып сыеныр җирем юк. Икенчедән, минем ике сугыш кичерүемне онытмагыз, өченчедән, ни өчендер бу кешеләргә күз салу белән туганнарым кебек якын күрдем. Болар үз атларының гаярьлегенә ышанган, озын-озак күчеп йөргәндә атлары белән туганлашып, аларның төшләрен күрергә гадәтләнгән; ат өстендә йөргәнгә, аяклары камыт, йөзләре җилдән ашалып тупасланган, тырпайган колаклары башкалар ишетә алмаганны тотарга сәләтле минем өчен үтә кадерле кешеләрем шикелле тоелды.

Бу кешеләр, мөгаен, якын-тирәдә урнашкан авылдандыр, аларның чираттагы кич утыруларыдыр. Юл буенда урнашканга, монда кереп чыгучылар җитәрлектер — миңа игътибар-фәлән итүче булмады, алай гына да түгел, күз салучы да күренмәде, бар да бәйрәм итүләрен дәвам итте.

Өстәл янына утырдым да, ашарга китерүләрен үтендем. Тамакны туйдырып, сусынны кәһвә белән баскач, тирә-ягымдагыларны күзәтер хәлгә килдем. Әллә ни үзгәреш сизелми, бары бер ир-ат гитарада җинелчә көй чирткәли башлаган. Шулай да күзгә ташланып тормаган бер нәрсәне искәрдем: вакыйгалар агышына елганиндидер фон бирә шикелле, аның тавышы мондагы шау-шуны басып, үзенең барлыгын сиздереп тора сыман тоелды.

Бармен — ул шушы кафенең хуҗасы да булып чыкты — кәһвә кирәкмиме, дип сорады. Яше шактый өлкән бу кеше кафедагылардан кай ягы беләндер аерылып тора. Йөзе борынгы бер телнең язуын хәтерләткән җыерчыклар белән чуарланган. Башта ул миңа, башкаларга караган кебек, карашын житез генә йөгертеп үтсә, кечуа телендә дәшүем аны гаҗәпкә калдырды. Өстәвенә, кафеда утыручылар үзара испан телендә аралаша иде.

— Бу таулар, — дидем мин, — хатын-кыз күкрәген хәтерләтә.

— Ә сез игътибар иттегезме, бер күкрәк чак кына сулга авышкан? — дип кызыксынды ул.

— Әйе шул. — Тауны янә күз алдыма китердем.

— Хатынымның күкрәге нәкъ шундый, — диде кафе хуҗасы.

«Ватанымдагы ике калкулык белән Кильядагы ике тау татар теле белән

кечуа теле кебек охшаганнар, — дип уйладым мин ул чакта. — Ә табигать аерыла, сүзләр дә шулай ук».

— Мөгаен, хатыныгыз бик чибәрдер, — дидем мин, кызыксынып.

— Әйе-әйе. — Ул җанланып китте. — Чыннан да, ул бик гүзәл. Тик еллар үзенекен итте, ә яшь чагында аңа тиңнәр булмады. Бездә, кечуа индеецларында, шундый ышану бар: юлыңда матур хатын-кыз очратсаң, таулар юкмы дип, тирә-ягыңа каран, диләр. Әгәр тау күрәсең икән, тукталып та торма. Чибәр хатын — тауның рухы, ул сине үзенә карата һәм башыңны ашый. Кайчандыр монда килеп-китеп йөрүче гаучо хатынымны шушы ике тауның рухы дип саный иде. Аны күрүгә, атларын камчылары белән яра-яра, тизрәк китеп югалырга тырыштылар. Менә нинди иде ул!

Ирләрнең күпчелеге үз хатыннарын күкләргә чөя, әмма, нигәдер, танышымның сөйләве мине ышандырды. Бераз елга тавышын тыңлап торганнан соң:

— Бу елганың тавышы үзгә, — дидем.

— Ирләр тавышы ул. Әйбәтләп тыңласагыз — төшенерсез.

Мин аның белән килештем.

— Бу — ир-ат елга, — дип өстәде кафе хуҗасы. — Аның ташлары да тупас, очлы, ярлары керентеле-чыгынтылы, ә агышы ирләр холкы кебек кызу, үз дигәнен итүчән.

Үз авылым елгасын күз алдыма китердем: аның борылышлары хатын-кыз гәүдәсенең бөгелешләре сыман салмак, ярлары хатын-кыз җилкәсенә охшап сөзәк, тавышы тыныч, сабыр. Яраткан кызым Фатыйма исемә төшеп, үзәгем өзелгәндәй булды, ул бит теге вакытта мине елгага тапшырды, эчке сиземләве белән аның мине коткара алачагына ышанды.

— Минем өем янынннан хатын-кыз елга ага, — дип нәтиҗә ясадым. — Ә яраткан кешем күптән бу дөньядан китте.

Кафе хуҗасы сүзсез генә карап торды да, миңа яхшы таныш җөмләне ычкындырды:

— Нишлисең, Аллаһы Тәгаләнең һәрберебезгә үз язганы.

— Безнең авыл карты да шулай дип әйтә иде.

— Башка картлардан да күбрәк белүче аксакаллар бар.

Ул кулына стакан алды, аны салфетка белән җентекләп сөртте.

— Мин монда күптәннән яшим. Гомеремне шушында очлармын дип ышанам. Бу ике тау арасында сергә бай җир асты дөньясы бар, диләр, тик анда үлгәннән соң гына эләгеп була.

— Бездә үлгәннәр үз аланнарына күчә.

— Мәетләргә дә төрле язмышлар хәстәрләп куелган, димәк. Тагын кәһвә китеримме?

Мин каршы килмәдем. Кәефенә ошадыммы, ул күңелемне күрергә әзер иде. — Кәһвәгез искиткеч, — дидем мин. Истанбул кәһвәханәләрендә йөри торгач, бу эчемлекнең асылына төшенгән идем инде. Мактау сүзем аның йөрәгенә май булып яттымы, ул да:

— Сез безнең телдә бик әйбәт сөйләшәсез, — дип хуплап куйды.

Миңа рәхәт булып китте. Үземнең телләр өлкәсендәге фәнни эзләнүләрем хакында сөйләдем, монда шул сәбәп белән килеп чыгуымны өстәдем. Тирә-якларга йөреп, шул телдә аралашучылар белән очрашуны планга керткән идем, хәзер нәкъ менә шуларның берсе белән сөйләшеп утырырга насыйп булды. Кечуа теленең бу җирле сөйләше мине аеруча кызыксындыра иде. Кафе хуҗасы сүзләремне ихластан тыңлады һәм ярдәм итәргә сүз биреп, мине куандырды. Аннары без хәзер кешеләргә берничә телне белергә кирәклеге турында озаклап әңгәмә кордык. Тик арада барыбер үзеңә якын тел була, диештек.

— Үз-үзең белән сөйләшкән тел — иң якыны, — диде әңгәмәдәшем.

Аның белән килешми мөмкин түгел. Шул җөмлә уйларымны еракларга алып китте. «Тормыш үз-үзең белән аралашудан торырга тиеш. Бердәнбер һәм дөрес хакыйкать тик шунда гына туа. Тикмәгә генә Зариф карт үткәне һәм киләчәге белән сөйләшкәндә башка берәүгә түгел, нәкъ менә үзенә мөрәҗәгать итмәгәндер. Юкка гына гомеребезнең иң соңгы мизгелендә без кабат үзебез белән очрашмыйбыздыр, үзебезне көзгедәге шикелле ап-ачык күрәбез, чөнки үлем — безнең образ, үзебез ул», — дип уйладым.

Яна танышым, күрәсең, ялгызымны гына калдырырга кирәклекне аңлагандыр, үз эшләре белән мавыкланды. Күпләргә җитенкерәмәгән әдәплелек хас иде бу адәмгә.

Ул арада кафедагылар таралышты, тик берсе генә янагын өстәлгә куеп, изрәвендә булды.

— Бәлки аны уятыргадыр? — дип сорадым.

— Йокласын. Бер-ике сәгатьтән уяна да, тыныч кына чыгып китә ул, — диде хуҗа, мондагыларның гадәтләрен аңлап бетергән кыяфәттә.

Кафега өлкән яшьтәге кара тутлы ике хатын кереп, җыештырына башлагач, мин дә кузгаласы иттем.

— Минем өчен берәр бүлмә табылмасмы?

— Әлбәттә. Икенче катка менегез дә, теләгәнен сайлагыз!

— Бер-ике көнгә.

— Хет бөтенләйгә.

...Бүлмәмнең ачык тәрәзәсе янына килдем. Таң сызылып килә, каршымда хатын-кыз күкрәкләрен хәтерләткән таулар шәйләнә. Кафе исә берсенең итәгендә үк утыра икән. Таң беленүен хәбәр итеп аста елга шаулый.

Арыган булсам да, никтер күзгә йокы кермәде. Кабат: «Шайтан алгыры, бөтенләй таныш булмаган җиргә ничек килеп чыктым соң?» — дигән сорау белән үз-үземне битәрләдем. Кылт итеп янарак кына кафе хуҗасының авызыннан чыккан җөмлә хәтеремә төште: «Аллаһы Тәгаләнең һәркемгә үз язганы». Вафа бабайның яратып әйтә торган сүзләрен җирнең икенче ярымшарында бөтенләй башка берәү кабатлый, әйтерсең минем өчен мөһим саналган түгәрәк кысыла бара. Җитмәсә, телләрнең аз гына булса да охшашлыгына киная дә бар түгелме? Әле алай гына түгел, туган авылыма охшаган урынга килеп чыгуым — бик гаҗәп.

Менә хәзер тәгәрмәчләр тукылдавын тыңлап барганда гына тагын кайбер нәрсәләргә төшендем. Ул чакта түгәрәк тоташмаган, бары тик ишарә, ым гына булган икән. Һәр язмышка салынган мәңгелеккә ишарә.

Әгәр танышыңа охшаган кешене очратсаң, озакламый үзе белән дә күрешәсең, диләр. Минем Кильяга килүем дә соңрак булачак вакыйгага кереш сыманрак килеп чыккан. Болар турында фикер йөртеп, мин ниндидер түгәрәкләрне күз алдымда тотам. Бу минем предметны фаразлау, яисә вакыйгаларга искәрмә бирүем түгел, кайбер күренешләрне кайчакта аңлатып та булмый. Урта гасырда яшәгән кешеләр туп-туры барып та шул ук урынга килеп чыгуны төшенмәгән, чөнки Җир шарының түгәрәк булуын белмәгәннәр. Без дә кайчакларда тормыш агышын аңлап бетермибез. Безнең баш җитмәс өлкәдә нәрсәдер аңлатырга маташу өчен, «Җир шары — түгәрәк» дигән сыман аксиома кирәк. Мин бернинди тәгъбирләүгә алынмыйм, бәлки «Аллаһы Тәгалә бар ул!» дип кенә котылырмын. Үзем дә кайчандыр Вафа бабай куллары ясаган көймә төбендә, Аллага тапшырып, ачык океанга чыгып ирек алган кеше буларак, «Күктәге көчләргә ышанырга кирәк» дигән ишарә ясармын.

Мин үзебез тоташтырган түгәрәкләр турында сүз башладым. Шуны искәртәсем килә, бу түгәрәкләр берсе эченә берсе салынган булуы да мөмкин.

Тик иң соңгы һәм мөһим түгәрәкне без икенче дөньяга күчкән вакытта, үзебезгә якынаеп, үзебезне күзгедә күргәндәге мәлдә тоташтырабыз. Хәер, бәлки мин дөрес сөйләмимдер. Урта гасырда яшәүчеләр Җир шарының түгәрәк булуын аңламаган кебек, миңа да төшенү өчен нидер җитеп бетми шикелле.

Тәрәзә каршында басып, таң атуын күзәтәм. Аста елга шаулый, яктыда аның кара-кучкылт суы, тупас, очлы ташлары ачык күренә.

Бераздан йокларга яттым, төш мине шунда ук кочагына алды. Беркайчан булмаганча мин үземә якынайдым, җаным елга белән берләшеп каядыр читтән ашты.

Кыска, әмма каты йокыдан күңелем күтәрелеп уяндым. Торуга, үрелеп тәрәзәдән карадым. Кояш әле күтәрелеп кенә килә. Куаклар каплаган тау бите, өскә күтәрелгән сукмаклар уч төбендәгедәй күренә.

Кафега төштем. Хуҗа үз өстәле янында иде инде.

— Безнең яшьтә йокы алмый, йокы яшьләргә тансык, — дип каршы алды ул мине.

Өстәлләрнең берсе артына килеп утырдым. Баштарак битараф күренгән хуҗаның йөзе ачылган. Бәлки моңарчы аның белән озаклап сөйләшүче булмагандыр, ул минем белән яхшы мөгамәләдә. Иртәнге аш китереп бирде дә, тәрәзә янына барып басты.

— Без нигә хатын-кызлардан башка яши алмыйбыз икән? — дип мыгырданды. — Серле, аңлаешсыз затлар.

Мин исә ник тота-каба хатын-кызлар турында сүз кузгатты соң бу дип аптырап калдым. Бераздан бар да ачыкланды: тәрәзә аша ялгыз хатынның кафега якынлашуы күренде.

Карашымны сизеп:

— Бик чибәр хатын, — диде ул. — Бездә күпләр аңардан шүрли. Минем хатыным кебек, аны да бу ике тауның рухы дип саныйлар. Бу табигый. Чибәрлек вакытлар узу белән тоныклана, аңа алмашка икенчесе килә.

Хуҗа үз өстәле янына килде. Мин исә көнемне ничек үткәрәсемне күзаллап, капкалавымны дәвам иттем. Тикшерүләрне башлар өчен, бу җирлекнең картасын тапсам, шәп булыр иде, дип уйладым. Кунакханәдә калган әйбер-караны китертү өчен машина да табасы бар. Юк, монда килүем тикмәгә булырга тиеш түгел, монда мине эчке сиземләвем тартып китерде.

Ишек тавышы ишетелде, кафега теге хатын керде. Хуҗа өстәле янына килеп, хуҗа белән кирәк-яраклар турында сүз башлады. Ике шешә шәраб белән тагын нәрсәдер сорады. Башта ул миңа яны белән торды, бераздан әкренләп борылды, аның йөзен күрүгә авызыма китергән чәнечкем һавада асылынып калды. Әйтерсең йөрәгем туктап калды һәм шул мизгелдә кабат күз алдымнан үлгәннәр һәм туасыларның җаннары үтеп киткәндәй булды, ул да булмады, йөрәгем урыныннан кубып, күкрәк читлегеннән чыгардай булып ярсырга тотынды. Миннән берничә генә адым ераклыкта басып торган хатын — Бранка Рахимич иде.

Еллар үзенекен иткән, бу теге чактагы Бранка түгел иде инде. Сүз дә юк, чемоданым төбендә яткан фоторәсемдәге кыздан күпкә калыша. Әмма берничә минуттан ашыга төшкәнемне аңладым. Йөзенә тутырып карагач, аның хәзер өлгергән хатын-кыз матурлыгына ия, чибәрлеге каршы җенестәгеләрнең күз явын алырлык икәнлеген күрдем. Әгәр чыннан да тауларның рухы бар икән, алар үзләренә лаеклы кыяфәтләне тапканнар.

Шулай итеп, Бранка кул сузымында гына нәрсәнедер оныттым ахры дигәндәй басып тора, ә мин өстәл артында утырган килеш аны күзәтәм. Очрашу минем файдага, чөнки хатын минем кемлегем турында белми. Ниһаять, сәгатем сукты, — дидем мин, куанып.

Ишек ябылуга, хуҗага сорау арты сорау яудырырга тотындым. Ул исә аптырау галәмәте күрсәтмәде, киресенчә, хуплады бугай: «Теләсә кайсы хатын-кыз үзеннән соң эз калдыра, — диде, — ә чибәрләрнең эзе аеруча озак саклана». Ул аның тауның аръягында урнашкан йортта яшәве, үзеннән күпкә өлкән ире барлыгы турында әйтте. Тик анысы бик сирәк күренә, кеше белән аралашырга яратмый икән. Гадәттә кирәк-яракны хезмәтчеләре сатып ала, ара-тирә Бранка үзе дә килгәли икән. «Монда кайчаннан бирле яшиләр?» — дигән сорауга: «Ун еллар чамасы, — дип җавап бирде. — Элек Кордовада яшәгәннәр, ә менә анда каян килеп чыкканнар — берәүгә дә мәгълүм түгел. Океан артыннандыр, мөгаен, чөнки испанчалары чамалы».

— Ни белән шөгыльләнәләр?

— Йортларыннан аз гына түбәндәрәк ранчолары бар.

Әлеге хәбәрләрне тагын бер кат башымнан үткәрү өчен миңа күпмедер вакыт кирәк иде. Әдәп белгән кафе хуҗасы моны аңлап, ялгызымны гына калдырды. Ул арада кафега кешеләр килә башлады, чиелдап туктаган автомобиль тавышы ишетелде.

Сезне нәрсә турында уйлавым кызыксындырадыр. Иң беренче тел очыма Миңлебай Атнагулов исеме килде. Ул — хикәямнең төп мотивы, ничә еллар буе артыннан эзәрлекләгән кешем. Минем өчен рәшәгә, еракта шәйләнгән өрәккә әверелгән кеше кинәт тере булып күз алдыма килеп басты. Балачак сукмакларын бергә таптаган, уенчык гильотина уйлап тапкан, үз мәчеләрен җәзалап үтергән, элеккеге кызыл комиссар һәм СС офицеры Миңлебай Атнагулов хәзер кайдадыр монда — якында гына, мин хәтта аның мыскыллы елмаюын күрәм шикелле.

Ул монда — табигать куенына елышкан таулар артында. Җирле сөйләше туган телемә, каршыдагы ике тавы авылымдагы ике калкулыкка охшаган җирдә. Хәер, кайда булсын инде ул? Миндә булган җирсү анарда юкмыни? Планетадагы бар урыннан ул шушысын сайлаган, ана сөлек кебек ябышкан, йөрәге богауланган, хәзер ул моннан бер адым да читкә чыкмаячак, үлемен дә, мөгаен, монда каршыларга әзерләнәдер. Яраткан хатын-кызы ике тауның рухына әверелгән, ранчосында атлары биешә, җайдаклары безнең авыл ир-атларына охшаган — тагы ни кирәк? Мин юкка гына бирегә магнит белән тарттыргандай килмәгәнмен, димәк. Икебез дә монда, шулай булгач очрашу котылгысыз.

Менә шундый уйлар узды минем башымнан. Эшкә керешкәнче, иң беренче итеп хәрәкәт итү планы төзергә булдым. Киңәшләшер өчен кафе хуҗасыннан да кулай кеше тапмадым. Кеше-кара азайган вакытны чамалап, аңардан бу җирлекнең картасын табарга ярдәм итүен сорадым. Ул исә:

— Бу җирлекне күзаллау өчен тауның берсенә менү дә җитә, — дип җавап бирде. — Аннан бар да: якын-тирәдәге авыллар гына түгел, ерактараклары да уч төбендәгедәй ачык күренә, — диде.

Тау түбәсенә алып менә торган юлны күрсәтте, ни эшләргә җыенуым белән кызыксынды. Аңа әйләнә-тирәне тикшереп, карап чыгасымны әйттем.

Бернича көн якын-тирәне өйрәндем, дөресрәге, Миңлебай Атнагулов йорты урнашкан территорияне күзәттем. Өенә илтә торган һәр юлны, һәр сукмакны җентекләп карап чыктым, кирәк була-нитә калса дип, чигенер өчен җайлы урыннарны билгеләдем. Ранчодагыларда шик уятмас өчен бик сак кыланырга туры килде. Чәнечкеле куаклардан тырнаттырып, ташлар артына посканда, француз партизаннары сафында алган тәҗрибә ярап куйды. Тик шикләрем юкка булды, күрәсең. Миңлебай мине күрә калган очракта да ерактан танымас иде. Ә йөзгә-йөз очрашу турында уйлыйсы да юк — һәр адымым үлчәнгән.

Көндәлек сәяхәтләремдә вакыт-вакыт җирлеләр дә очрады. Шушындый матавыкта да кечуа телен өйрәнүгә омтылышым югалмауга үзем дә гаҗәпләндем. Алар белән әңгәмәләр кордым, кесә дәфтәремә тегесен-бусын теркәп куйдым. Һәм шулай итеп монда килүем берәүдә дә шик уятмады дип беләм, өстәвенә, кафе хуҗасыннан да тел өйрәнүем турында ишетми калмаганнардыр. Эш арасында алып барган фәнни тикшеренүләрем житди нәтиҗәләрен дә бирде әле: соңрак берничә журналда кечуа һәм төрки телләрдән алынган кайбер сүзләрнең чагыштырма таблицасын бастырып чыгардым. Димәк, бу мине Латин Америкасына китергән ике сәбәпнең дә бер үк дәрәҗәдә икәнен күрсәтә.

Беркөнне шулай, аякларым талгач, туфрагы җылынган җир өстенә ятып, күзләремне күккә төбәдем. Елга шавына колак салып үткәннәр турында уйландым. Шул көнне, ниһаять, эзләгән кешемне күрдем. Эңгер-меңгер төшкән вакыт. Ул ранчосыннан өенә кайтып килә иде. Кечуа индеецлары әйтмешли, кешене йөрешеннән генә түгел, һавада калдырган эзеннән дә танып була. Анда бар да сызылып кала: үткән гомере дә, кылган гамәлләре дә, хәтта әти-әнисенең шәүләләре дә. Сукмак буйлап атлаган адәм — кайчандыр бер туфракта аунап үскән авылдашым Миңлебай Атнагулов иде. Каршы тау түбәсендә басып торам, йөрәк Бранка Рахимични күргәндәге кебек ярсып тибә. Дошманым мине абайламый, ә үзе яктылык төшкән әйләнә уртасында калган шикелле — һәр хәрәкәте аермачык, алай гына да түгел, мин хәтта аның бөтен гомерен — хәзергесен һәм үткәнен үтәли күрәм кебек. Күз алдымнан балачагы — әле ныгып та житмәгән куллары тудырган яман эшләре, тәмуг уты иркәләгән үсмерчагы, җыерчыкларына крематорий көлләре сырышкан житлеккән чоры — бер-бер артлы үтеп китте. Миңлебай хәзер тулаем минем кулда, бу юлы качып котыла алмас — чөнки минем сәгатем сукты.

Алдагы көннәрне аның көн тәртибен өйрәнүгә багышладым. Иртән иртүк ранчога китә, көндез тамак ялгарга кайта, бер-ике сәгать черем иткәннән соң, кабат ранчога кузгала, караңгылык куергач, шул ук юлдан өенә атлый — һәр көнне шулай. Хәзер минем алда иң кыены — аның белән очрашу урынын сайлау. Юлның һәр өлешен жентекләп тикшергәннән соң, андый урын да табылды: бер яктан тауларга таба таш стена менә, ә юлның икенче ягы кискен рәвештә аска төшеп китә. «Шушында йөзгә-йөз килербез, ә калганы күктәгеләр ихтыярында, алар ничек хәл итә — шулай булыр», — дип фикер йөрттем.

Сүз дә юк, гомеремне куркыныч астына куюым бәхәссез. Колагымда «дошманыңа тешең үтмәс» дигән сүзләр кабат яңгырап үтте, димәк, дошманым белән соңгы очрашуым булуы да ихтимал. Хәтеремдә янәдән Миңлебайның үз авызыннан ишеткән: «Минем киләчәгем пуля сызгыруына тин, ә пуляны куып тотканнары юк әле» , — дигән җөмләсе яңарды. Хәзер дә ул күзләремә туп-туры карап шул сүзләрне кабатлаган кебек тоелды. Күкрәгемне тутырып ачы сулыш алдым, һәм үземне бер аягым белән теге дөньяда басып торгандай хис иттем. Нәрсә соң бу — куркумы? Һичшиксез. Миңа таныш кешеләр арасыннан курку белмәс бары тик берәүне генә хәтерлим. Һәм нәкъ менә шул кеше белән очрашырга җыенам.

Шулай итеп артка юл калмады. Ялгышлык җибәрмәс өчен, тагын бер-ике көнемне күзәтүгә сарыф иттем. Миңлебай көн тәртибен үзгәртмәде: ранчога барды һәм кайтты. Аңа карап: алманнарга хас төгәллек моңа да күчкән икән, дип уйлап куйдым.

Уйлаганымны тормышка ашырасы көндә көндез кафе хуҗасы белән гадәткә кергән әңгәмәбезне башлап җибәрдем. Мондый сөйләшүләр көннән-көн безнең арабызны якынайтты. Тик ул көнне әңгәмәне үземә кирәк якка бордым:

— Хәтерлисеңме, сиңа яраткан кызым турында әйткән идем?
— Бу дөньядан китте диден түгелме?
— Аны үтерделәр.
Ул дәвам итүемне көтте. Әмма мин дәшмәгәч:
— Монда килүеннән сәбәбе аның үлеме белән бәйлеме?
— Әйе.

Хужа күзен төбәп нидер уйлагандай итте дә, ярдәмче бинага китте. Бераздан кулындагы мылтыгын миңа сузды:

— Ал, сиңа коралсыз ярамый.

Билгеле, кул астында мылтык булу — миңа көч өстәде.

Әкрен генә карангылык инде, бар нәрсәгә нокта куяр сәгать якынлашты.

Кулыма мылтык тотып, очрашу урынына барып бастым. Исәбем буенча Миңлебай Атнагулов менә-менә күренергә тиеш. Йөрәгем читлектәге кош сыман бәргәләнә: каты-каты итеп тибә дә туктап калгандай була. Кинәт кенә үземне билгесезлек алдында яклаучысыз калган малай кебек хис иттем. Тагын бер мизгелдән ни булыр? Мине алда ни көтә? Коточкыч хәлме? Әллә, киресенчә, тагын да куркынычрак, әмма гадәти бер нәрсәме? Сукмак буйлап миңа таба кемнең шәүләсе якынлаша? Бәлки бер ярым аршын буйлы, куркыныч янаган теге хатын — албастыдыр? Үткәнемә бәйле җан иясеме? Кылган гамәлләрем өчен җавап алырга тиешле газраилдыр? Бәлки бу әҗәлемдер, йөзгә-йөз очрашып, көзгедәге кебек үземне күрәчәкмендер?

Берни сизенмәгән шәүлә әкрен генә якынлашты, юлының кем тарафыннандыр киселүен күреп, икеләнеп туктады.

Миңлебай Атнагулов. Менә ул каршымда басып тора һәм бераздан үзе дә мине танып ала. Тик аның йөзендә гаҗәпсенү сизелми. Хәер, аны элек тә шаккатыруы кыен иде. Ул, мөгаен, иртәме-соңмы үзен эзләп табачакларын күз уңында тотып, вакыйганың мондый борылыш алуына үзен алдан әзерләп килгәндер. Аның төс-кыяфәте шактый үзгәргән, еллар үзенекен иткән — крематорий көле утырган җыерчыкларына яңалары өстәлгән.

Кайсыдыр мизгелдә күз алдымнан аның балачагы, ачык тәрәзә янында, бирелеп, «Ай соната»сын тыңлаган вакыты чагылып китте. «Менә ничек, әле берничә минут кына элек үземне куркак, ялгызак малай дип хис иткән идем», — дигән уй сызылып үтте. Ни генә дисән дә, безне балачак берләштерә иде. Ә хәзер туган авылымның ике калкулыгына охшаган тауның бер урынында икебезнең беребез гомере белән хушлашырга тиеш.

Бер-беребезгә карап сүзсез генә басып торабыз. Әйтәсен инде үзен күргәнче үк әйтеп бетергәнмен ахры, чөнки аны искә алмаган бер көнем дә булмады диярлек.

Ә ул, мине таныгач:

— Бу синме, Сарман? — диде.

Нәкъ шул мизгелдә карангылык канатын җәйде. Тауларда гына шулай кинәт дөньяны караңгылык басуы турында әйткән идем инде. Бер сүз әйткән арада тирә-юнь кап-караңгы була да куя.

Дошманымның бит-йөзе тоныкланды, шулай да аның иреннәрендә катып калган мыскыллы елмаюын сизәм. Барып төртелер урыны калмаса да, ышанычсыз, елмая, чөнки ул куркуның нәрсә икәнен белми.

Мылтыгымны күтәреп, көпшәсен күкрәгенә төзәдем. Мөгаен, аның кесәсендә пистолет-фәләне булмый калмагандыр, тик ул хәзер барыбер миннән алда атарга өлгермәс иде. Бәлкем, юк тадыр. Ул очракта мин коралсыз кешегә атарга тиеш булам. Хәер, үземне аклар сәбәп бар: йөзәрләгән коралсыз кешеләрне үтергәндә, Миңлебай: «вөҗданым кушмый» — дип тормады.

Шулвакыт һич уйламаган хәл булды. Әгәр аз гына яктырак булса, аның кечкенә генә хәрәкәте дә игътибардан читтә калмаган булыр иде, күзләренә карауга аның ни кылырга җыенуы аңлашылыр иде. Менә нәрсә булды: Миңлебай Атнагулов, мыскыллы елмаеп, кинәт кенә кырыйга тартылды да кара кучкылт су агып яткан елгага ташланды. Мин исә тәтегә баса да алмый калдым. Әгәр миңа таба атлаган булса, ике дә уйламый аткан булыр идем, әмма вакыйганың мондый борылыш алуы югалып калырга мәҗбүр итте. Ә ул икеләнеп-нитеп тормыйча упкынга сикерде.

Беренче уем: «Тагын ычкынды!» — булды. Тик бераздан салкын акыл белән исәпләгәч, аның исән калу мөмкинлеге булмавын ачыкладым. Бу урын миңа таныш. Әгәр ул суга егылган булса, азмы-күпме өмет калыр иде, тик моннан елгага кадәр сикереп булмый. Ул, мөгаен, яр буендагы ташларга килеп төшкәндер.

Тереме-үлеме икәнен үз күзләрем белән күрми күңелемә тынычлык иңмәде. Елгага төшү өчен тауны әйләнеп чыккан сукмак буйлап атларга туры килде, шуңа шактый вакытымны югалттым. Ярый әле, таулар артыннан тәгәрәп чыккан ай зәңгәрсу яктылыгын сибеп, юлымны яктыртты.

Миңлебайның гәүдәсе ятарга тиешле урынга килдем. Елга ун метрлар читтәрәк ага; ул, кабатлап әйтәм, анда кадәр берничек тә сикерә алмый. Ай яктысында яр буен җентекләп тикшерсәм дә, гәүдә табылмады. «Кая китәр икән, егылганда канатлар үсеп чыкса гына инде», — дип уйладым. Куаклар сирәгәеп, алда агачлар, куе тропик үсемлекләр башлана. Әгәр дә могҗиза булып исән калган булса, ул шунда — куелыкка таба шуышкандыр. Урман эченә кердем. Кап-караңгы. Бары ботаклар арасыннан, качышлы уйнаган шикелле, айның саран яктысы гына күренгәләп ала. Минем уемча, Миңлебай ерак китәргә тиеш түгел. Хәер, аңардан теләсә нәрсә көтеп була, канга манчылып яткан җиреннән миңа пистолетын төзәве дә ихтимал. Серле кыштырдаулар, тавышлар тулы караңгылык эченә атлавымны дәвам иттем.

Кайсыдыр мизгелдә янәдән бәйләнеп йөдәткән сорау калыкты: «Йә Ходам, монда, дошманымның корулы көпшәсе каршында, кап-караңгыда ни калган соң миңа? Әгәр юлымның соңгы адымнарын атлыйм икән, моны бәяләүче табылырмы? Күпме еллар эзәрлекләгән дошманымнан маңгаема пуля алыр өчен килдемме мин монда?»

Тик аякларым мине тыңларга теләмәде. Бу турыда искә алганда әле дә каз тәннәре чыга. Кинәт якында гына бүре улавы ишетелде, аңа үкергән тавыш кушылды. Мин, икеләнеп торганнан соң, кире елгага таба киттем. Яр буеннан барганда, кабат ишетелгән бүре улавы миңа үткәнемнән нәрсәнедер хәтерләткәндәй тоелды. Елганың кара кучкылт суына карауга кылт итеп исемә төште: мин инде бу елганы ярты гасырлар элек бер тапкыр күрдем ләбаса. Ул чакта дошманым Миңлебай белән балалар гына идек. Су анасының көзгесендә күрдек бу табигать күренешен.

Артымда ике кешенең сулыш алганын сиздем. Борылдым, әмма берәүне дә күрмәдем. Аннары гына башыма житте: болар — Хәлил белән Фатыйманың рухлары, алар да теге вакытта ул вакыйганың шаһитлары иде бит. Көзгедән караган картинаны тәмамлау өчен бирегә килгәннәр. Без Миңлебай белән көзгедәге шашкын суга карап торганда, Фатыйма белән Хәлил яныбызда басып торды. Исегездә булса, азагы ни белән бетәсеннән куркып, Фатыйма көзгене тартып алган иде. Дәвамы исә монда булып чыкты. Миңлебай белән мин катнашучылар: мин шашкын су янәшәсеннән атлыйм, ә ул кара урманда җан биреп ята. Кабат бүре улавы ишетелде. Әйе, тагын бер катнашучы үзенең дөньяда барлыгын искәртергә ашыга.

***

— Иртәгә китәм, — дидем кафе хуҗасына, мылтыгын кайтарып биргәндә.

— Кирәге чыкмавы әйбәт булган, — диде ул. Башта коралдан атмавымны кайдан белгән дип гаҗәпләнсәм, сонрак аңладым: ату тавышы яңгырап монда ишетелми калмас иде.

Ул төнне тынычлап йокладым. Икенче көнне кафеда мине көтүчеләр елга буендагы агачлыкта бүреләр өзгәләгән ир-ат мәетенә тап булганнар, дигән хәбәр каршы алды. Мәетнең кемлеген ачыклый алганнар, ул — ранчо хуҗасы, кирәк-яраклар алырга кафега кергәләп йөргән теге матур хатынның ире булып чыккан, диделәр.

Соңгы елларда бүреләрнең күренгәне булмаган. Бу аерым төр — кызыл бүре яки агуарачай, тагын озын яллы дип тә йөртәләр икән — бүреләр бик сирәк очракта гына кешегә ташланалар икән. Ни өчен бу адәмне өзгәләгән — бер Ходай гына белә, дип аптырашты халык.

Бары тик мин генә эшнең хикмәте бүренең исемендә түгеллеген белә идем. Кара урманда ант бирешкән төн, ирләрнең күзендә биешкән ялкын телләре, һәр сүзгә сизгер тырпайган колаклар — бар да исемдә.

Шул көнне юлга чыктым. Хатын-кыз күкрәген ( берсе аз гына сулга таба авыш) хәтерләткән таулар ераклашканнан-ераклаша барды, бераздан Килья дип аталган урын тәмам күздән югалды. Рейс автобусы мине Кордовага китерде һәм мин Буэнос-Айреска бара торган поездка күчеп утырдым. Күнелдә бушлык. Монда килүем алда булачак мөһим вакыйгага кереш, әзерлек булып чыкты, димәк. Тиздән, бик тиздән туган авылым туфрагына басачакмын. Түземсезлек белән сәгать, минутларны саныйм.

Берничә көнемне Буэнос-Айреста үткәрдем. Хезмәттәшләрем белән очрашасы, китапханәдә үземне кызыксындырган материаллар белән танышасым бар иде.

Миңлебай Атнагуловның үлеменнән соң, жилкәмнән тау төште, дип саныйсыздыр. Ә тормышымнан үч алу теләге югалгач, хикәямнең төп каһарманы төшеп калыр дип кызыксынуыгыз кимегәндер. Тик күпкә түзгәнне азга гына түзегез — ахырга күп калмады.

Буэнос-Айрес аэропортында Бранка Рахимичны очраттым. Бу илдә, күрәсең, аны инде берни тоткарламыйдыр. Самолетта урыннарыбыз янәшә диярлек туры килде, ул бер рәт аша гына алда урнашты. Карашым аның матур кыяфәтенә төште һәм миндә ямьсез теләк уянды: аны үземнеке итәсем килде. Кыргый дала кешеләре сыман. Алар да җиңелгән дошманнарының хатыннарын көчләгәннәр, һәм шунын белән чын җиңүчеләр икәнлекләрен, эшкә ахыргы нокта куелуын аңлатырга теләгәннәр. Тик бу узгынчы хис бер мизгелдә кабынды да, шунда ук юкка чыкты.

Кильяда булган хәлдән соң күнелемдә ниндидер бушлык, упкын дип әйтимме, югалту хисе хасил булды. Шуңа охшаш халәт тормышыңнан бар бәлаләреңнең башында торган кеше юкка чыкканда була. Һәм ул кешенең тормышыңа тикмәгә генә килеп кермәвенә, киресенчә, төп рольләрнең берсен уйнавына төшенәсең

Миңлебай Атнагуловның тәвәккәл адымын кабат хәтеремдә яңартам. Нәрсә теләде ул? Котылып калыргамы? Әйе, дип уйлыйм. Хәлне чамалап, югалтыр нәрсәсе калмавын аңлаганга тәвәккәлләгәндер дип саныйм. Аның кебек курку белмәс җанга бу ике тиен, бер акча кебектер.

Бәлки максаты бөтенләй башка булгандыр: котылгысыз эшне үзе үк тәмамларга уйлагандыр.

Ул очракта икенче сорау калка. Исән калдырмасымны белә торып, ник бу адымга барды икән? Җавап бер генә: кулымны каны белән буямавымны теләгән.

Кем белә, хәзерге вакытта аның рухы да өрәкләр аланына юнәлгәндер. Иртәме-соңмы, яхшы кешеме ул, әллә бер кабахәтме — бар да өйләренә әйләнеп кайта. Атлантик океан өстеннән очканда, шулар турында уйландым.

Кайсыдыр бер мизгелдә самолет белән нидер булып алды: башта жинелчә генә селкеткәләде, аннары, кемнендер көчле куллары шаярткандай, як-якка чайкалды. Салондагы дулкынланган халыкны стюардессаның сабыр тавышы тынычландырды. Шулвакыт очраклы рәвештәме, Бранка Рахимич артына борылды һәм безнең күзләребез очрашты. Гәүдәм буйлап ниндидер калтырау узгандай булды һәм мин аның элекке дошманым өстеннән серле хакимлеген үземдә тойгандай булдым.

Озакламый самолет турайды, шунда башыма бер кызык уй килде: әллә Минлебайның өенә ашыккан рухы очкыч юлы белән кисешеп алдымы икән? Бәлки аңа башка бик күп рухлар да өстәлгәндер: иртәме-соңмы барыбызга да туган якларга кайтасы бит.

Иллюминатор тәрәзәсеннән тышка күз салдым. Безнең аста Атлантик океан җәелеп ята, бик теләгәндә хәтта аның аерым дулкыннарын күрергә була.

Шушы урында юлдашымның хикәясе тәмамлана. Сизгәнсездер, телгә оста иде ул. Хикәясенең соңгы ноктасын да океан сүзеннән соң куйды. Ә мин моны үземчә аңладым. Җир йөзендә диңгез дулкыннарына, чаткыларын сибеп дөрләгән учакка һәм тагын нәрсәгәдер — анысын оныттым — күпме карасаң да туймыйсың. Минем дә юлдашымны тыңлаган саен тыңлыйсым килде. Аның сөйләве дулкын, яисә ялкынланган учакка тиң иде.

Өстәвенә, ул тыңлаучыны җәлеп итәрдәй алымнар куллана белә. Белеп әйтүем, үзем дә һөнәри эшчәнлегемдә шуңа омтылам. Хикәянең төп сызыгы булган үч алу теләген генә алып карыйк. Хәер, сөйләүче алдан ук аның кыланышларына вакыт-вакыт нәрсәдер юнәлеш бирүен искәртеп куя. Тик аның оста алымы, алдыбызда картинаның алгы ягы гына түгел, ә тагын да мөһимрәк — игътибарны тулы көченә эшкә җиккәндә генә аңлап була торган арткы ягы да бар.

Яки менә хикәянең азагын карыйк. Профессор соңгы җөмләсен әйтә һәм аның бары тик хушлашырлык кына вакыты кала. Карале, дибез без тел шартлатып, хикәясе дә тәмамланды, вакыт та чыкты. Бары тик тел осталары гына шулай туры китерә ала. Радиожурналист буларак, мин аны шулай бәяләдем. Бездә дә тапшыруның тәмамлау вакыты билгеле, һәм син әйтәсе килгәненне шул арага сыйдырырга тиешсең. Юлдашым вакыт агышын күздә тота белүчеләрдән, шуңа сөйләү барышында теге яки бу вакыйганы өстәү, йә киресенчә төшереп калдыру аңар кыенлык тудырмый. Ул Зариф карт кебек үзенең киләчәге һәм үткәне белән аралашты һәм, күрәсез, хикәяләү аңар тулысынча буйсынды.

Шулай итеп, юл аягына соңгы чынаяк чәебезне эчтек һәм ул, хушлашып, үз тукталышында төшеп калды. Башка аны очратканым булмады.

Сарман Бигине магнитофон язмасына яздырып бардым һәм соңгы җөмләсен тәмам иткәч, Rec клавишына бастым. Бу — минем хәзергә журналистлык бурычым тәмамланды дигәнне аңлата. Әмма профессорга, шактый авыр чемоданын күтәрешеп, төшәргә ярдәм итүем анда язылмаган. Туган авылына кайту өчен аңа әле автобуска утырырга, йә юлаучы машина тотарга туры киләчәк.

Поезд кузгалды, мин урыныма утырып, кассеталарны тәртипкә китерә башладым. Бер-икесе яздырылмыйча буш калган. Кулыма тоткан килеш: «Ә аныкы майлаган кебек булды», — дип уйладым. «Соңгы җөмлә, бер чынаяк чәй, сау бул — бу минем тукталышым».

Өйгә кайткач, кассеталарны шкафка куйдым һәм оныттым. Тик минем бер яхшы ягым бар, дип әйткән идем бугай, беркайчан да язмаларны чыгарып ташламыйм, архивыма берәүне дә якын китермим, егерме ел эчендә тормышымда хатын-кызлар булмады түгел, шкафымда тәртип урнаштырырга теләүчеләре дә очрады. Кассеталарның шулай озак ятуына бары тик үзем гаепле. Күрәсең, аларны искә төшерергә сәбәп чыкмагандыр. Аерылышканда, тормышымда булган вакыйгаларның, авылыма кагылышлы риваятьләрнең онытылып, эзсез югалмавын телим, дигән иде карт. Тик кайчакта эш барышында сирәк очрый торганга әйләнәсе әйберләр турында оныта торган гадәтебез бар шул.

Менә хәзер Сарман Биги сөйләгәннәр калкып чыгар вакыт житте. Ничек дисезме? Кыскасы, егерме ел элек яздырылган тасмаларга әйләнеп кайтырга туры килде. Мин инде эшчәнлек өлкәмне үзгәртеп, документаль кинода эшли башладым. Авыл жирлегендә төшерәсе булганга, карта алып караштырып утырганда, Ай авылына юлыктым. Шунда ук күз алдымда хатын-кыз күкрәкләрен хәтерләткән ике калкулык, шул ук исемне йөрткән елга һәм Кара урман гәүдәләнде.

Кассеталарны тыңлау теләге уянды. Иске магнитофонымны — ярый әле ашыгып чыгарып ташламаганмын — кабыздым да баш-аягым белән дигәндәй шул вакыйгалар эченә кереп чумдым. Картның сөйләвен бөтенләй икенче күзлектән чыгып бәяләдем, икенче пландагы аерым моментларны да тотып алдым. Әйтерсең, мин үземнең үткәнем белән аралашам. Дөресе дә шул — кассетада минем тынлык саклавым да язылган.

Ай авылына баруым турында чак кына соңрак. Хәзер сәфәрдән соңгылары турында бер-ике авыз сүз әйтеп китәсем килә. Игътибар иттегез микән, карт сөйләгән вакытта укучы онытмасын дип, еш кына кабатланды, шуңа мөхәррирлек гадәтемә тугры калып, кайбер урыннарын кыскартырга мәжбүр булдым. Минем сөйләвемдә исә моның кирәге юк, чөнки укучы дулкынланмый гына бер-ике дистә битне кире кайтып укый ала. Нәтижәдә шактый күләмле кулъязма килеп чыкты һәм мин, укып чыгып, фикерләрен житкерсеннәр дип, язманы кайбер танышларыма бирдем. Бәяләр төрлечә булды.

Тарих фәненә бәйләнеше булган танышым картның сөйләвендә төгәлсезлекләр күп булуы турында әйтте. «Татар авылында (картның туган авылы күздә тотыла) яшәүчеләр ул сурәтләгәнчә сугышчан, горур була алмый, — диде.— Шулай ук кылычлары булу да дөреслеккә туры килми. Гомумән, корал тоту тыелган, чөнки хакимият күтәрелешләрдән курыккан, — дип өстәде. —Тимерче корал эшли алган, тик аны да урыс милләтеннән куйганнар һәм авылныкылар белән сүз берләшмәсеннәр дип күзәтү астына алганнар. Бату Сакаев шикелле ау мылтыгы тотарга берәүгә дә рөхсәт ителмәгән. Синең картың, — диде танышым, — үзенекеләрне ничек күрергә тели, шулай сурәтләгән».

Ә икенче берсе — әдәбиятчы, — киресенчә, булырга мөмкин дип бара. Казаклар катлавына караган татарлар күз уңында тотылгандыр, ди. Тарихта андый татарлар да очрый икән. Алар кылыч белән оста эш иткәннәр, менә дигән жайдаклар булганнар, аларга ау белән шөгыльләнергә рөхсәт ителгән. Иң беренче чиратта хәрби хезмәткә аларны алганнар. Карт хикәясендә дә бар бит ул, авыл ирләрен алып киткән кара-кучкылт шашкын суны исегезгә төшерегез.

Өченчесе — рәссам дустым, мәсәлән, үзе өчен шактый кызыклы мәгълүматлар тапты. Тик кайчакта карт күзгә төтен жибәрә дигән тойгы кала, диде. Сөйләүче нииндидер аңлаешсыз ишарәләр белән, ымнар белән безнең ихтыярга буйсынмый торган әллә нинди серле өлкәләргә,

юлларга алып керә. Болар, ничектер, бернинди плансыз, аныксыз рәвештә башкарылган.

Дүртенчесе болай диде: «Без тормышта да бу өлкәләр белән шулай аңышмый, системасыз рәвештә аралашабыз бит. Бервакытта да алардан ни көтәсен белмибез. Карт ничек күргән, шулай сөйләгән».

Сарман Биги, чыннан да, үзеннән өстәгәнме, яки алдашканмы дип, шактый озак баш ваттым. Әйткән гыйбарәләреннән берсе исемә төште: «Тормыш һәм уйдырма — игезәкләр. Аларны чагыштыру — игезәкләрнең кайсысы кайсына охшаган дип чагыштыру кебек үк мәгънәсез эш». Әгәр ул нәрсәдер өстәгән икән — куркырлык урын юк.

Тик колагыма кемдер, бөтен сөйләгәннәр дә дөрес, дип пышылдыйдыр кебек.

Чират сәфәрнең үзенә җитте. Ниһаять, юлдашымның авыз суын корытып сөйләгәннәрне үз күзләрем белән күрдем. Әйткәнемчә, Ай авылы безнең төшерү картасына кертелде.

Җылы бер кичтә студиянең микроавтобусына төялеп, шоссе буйлап элдертәбез. Инде бернichә тәүлек тоташ диярлек эшләдек, бүгенге көн дә тәмамланугa бара. Тәрәзәдән басу-кырлар, агачлыклар сәлам биреп кала, һавада машина артыннан чыккан тузан бөтерелә. Район үзәгенә барып куна калырга уйлаштык. Көтмәгәндә юл читендә Ай авылының күрсәткеч билгесе чагылып калды, аннары хатын-кыз күкрәкләрен хәтерләткән ике калкулык күзгә ташланды. Йөрәгем урыныннан куптымыни? Әгәр хәзер нидер эшләмәсәм, нәрсәнедер кулдан ычкындырырмын шикелле сәер халәт кичердем.

Шофердан туктавын үтендем. Йөзләрендә сорау сизелеп торса да, берәү дә авыз ачмады: режиссер, гадәттәгечә, чираттагы съемка өчен туры килерлек ландшафт караштыра дип уйладылар бугай. Машинадан чыктым. Алдымда картның төшләренә кереп йөдәткән табигать күренеше. Төшләрдә, карт әйтүенчә, бер үткән тагын да үткәндәгесе белән бутала. Өстәп әйтим, бу күптәнге үткән — чит-ятныкы да булуы ихтимал.

Гадәти булмаган халәтемә тиздән нидер сизенү тойгысы да өстәлде: монда миңа ниндидер хәбәр җиткерергә тиешләр. Шундый мөмкинлек булганда, башкалар белән китеп барсам, тиле булырмын, дип калырга ниятләдем.

Берәү дә гаҗәпләнмәде, режиссерларының сәер кыланмышларына күптәннән инде бар да ияләнде. Палатка, ябынырга ямпа, термос белән чәй, ашау-эчү әйберләре калдырдылар, иртән унынчы яртыда шушында очрашырбыз дип сүз куештык. Микроавтобус артыннан күтәрелгән тузан болыты теләр-теләмәс кенә юлга төшәлде. Ә мин исә кырыйга төштем дә авылга карап киттем. Булган хәлне аңларга кирәк иде. Шулай итеп, каршымда — Ай авылы, ике калкулык, елга. Баеп барган кояшның ал нурлары калкулыкны сергә ураган. Авыл уч төбендә кебек күренә торган урында басып торам икән. Мөгаен, карт та үзенең истәлекләрендә авылына шушы төштән карагандыр, дип уйлыйм.

Миңлебай Атнагулов та шушында басып торгандыр. Исеме белән дәшкәч, күз яшен йотып китеп барганы исегездәме?

Хәлиулла Камалиев та шушында тезләнеп, туфракны үпкәндер. Бабасының каберенә пес итеп, соңыннан кичерү алган солдатны хәтерлисездер?

Шашкын су алып китәр алдыннан ир-атлар, бер мизгелгә тын калып, авыллары белән бу җирдә саубуллашкандыр.

Исән кайтканнары, куанышып, монда басып торганнардыр.

Табаннарым җирдән күтәрелгән ниндидер җылылык сизделәр.

Палаткамны яр буендагы таллар янына коруны дөрес дип таптым. Тыныч та, җайлы да урын. Елгадан җиңелчә генә салкынлык бөркелә, вакыт-вакыт

кыр ягыннан йомшак, назлы жил хәл белеп китә. Караңгылык куерды. Коры ботаклар җыеп, учак тергездем. Озак кына учак өстендә биешкән ялкын телләренә карап утырдым. Күптәннән ялгызлык рәхәтен татыганым юк иде. Картның, тормышта үз-үзен белән аралашу кирәк, дигәне искә төште.

Учак тыныч кына ялкын бөркеп яна. Караңгылыкка чумган агачларның шәүләләре шәйләнә. Елга янына ук килеп, озак кына кара-кучкыл суга карап, агымсу белән кеше җаны арасында нииндидер уртаклык бар, дип уйландым. Су һәр җирдә үз юлын таба. Карт та, ниһаять, өенә кайтыр юлны тапты.

Яр буенда басып торганда, картның сөйләвен озакка сузмый кәгазьгә күчерергә дигән уй килде. Кайткач та тотынырга сүз биреп, палаткага кердем һәм йокларга яттым.

Күпме йоклаганмындыр, кинәт уянып киттем. Керфекләрем башка йомылмады. Палатканың ишек япмасының ачык калган ярыгыннан ай яктысы үтеп керде. Автобустан төшеп калырга өндәгән эчке сиземләвем тагын нидер буласын пышылдаган сыман. Тышта, караңгыда, мине көтеп торалар кебек тоелды.

Палаткадан чыгуга, нииндидер яшерен сер вәгъдә иткән төн мине үз кочагына алды. Төрле тавышлары, серле кыштырдаулары, шәүләләре белән ымсындырып, мине үзенә таба тартты. Төнне бүлеп, елга тавышы ишетелде.

Яр кырыйлатып салынган сукмак буйлап киттем. Бар нәрсә айның зәңгәрсу нурында коена. Тирә-юньгә сокланып барганда, каршыма килеп баскан Кара урманны шәйләдем.

Атлый торгач, сукмак су буена алып төште. Елга белән янәшә баруымны дәвам иттем, әйтерсең аның белән юлыбыз бергә килеп кушылды, бер-беребезне аңлап, бер бөтенгә әйләндек.

Бер урында елга тараеп, ике яры да аермачык күренә башлады. Аннары хатын-кыз гәүдәсе бөгелеше сыман, салмак кына икенче якка борылып, юлын дәвам итә. Мин дә аңа иярдем. Шулвакыт ай яктысында теге як ярда нәрсәдер ялтырап китте. Йөрәгем нидер буласын сизенеп, өшеп киткәндәй булды. Ни булса, шул булыр дип, юлымнан борылмадым. Якынрак килсәм, Су анасы икән. Ерактан ялтырап күренгән әйбер кулындагы тарагы булып чыкты.

Ул миңа таныш көзгесенә карап озын чәчен тарый, бармаклары суга тиеп-тиеп ала. Безне су аерып торганга, ул мине күрмәде, үз эшендә булды. Башымнан: «Әгәр күзенә карау мөмкинлеге туса, йөрәгем житәр иде микән?» — дигән уй йөгерде.

Су анасын калдырып, алга таба атладым. Аргы яр һаман да уч төбендәгедәй ачык күренә. Анда кешеме, әллә шәүләсеме шәйләнә. Ай яктысы йөзенә төшкәч, мин аны таныдым. Бу — Ай авылына нигез салучы Лотфулла Хәсәни иде. Артында аның белән бергә яңа урын эзләүчеләр. Алар сүзсез генә миңа карап торалар. Карашларының буш, салкын икәнен күреп, аларның өрәкләр аланыннан килүләрен аңладым. Үз кабиләдәшләренең ирекле булуын теләгән гаярь, фетнәчел Бату Сакаевны да күрдем. Тезләнергә теләмәгән, әмма башын саклап кала алган Бату. Тагын кем ул анда? Тумышы белән сугышчы Зәкәрия Камали, янында антларына тугры калып ат өстеннән төшми дошманны эзәрлекләгән тугыз иптәше. Менә бер-бер артлы урман ешлыгыннан әсәр каһарманым Сарман Бигине коткарам дип, туган туфракларына башларын салган ир-атлар чыга. Төрле вакытта шашкын су алып киткән башка ирләр дә күренде. Боларның барысының артында җыр яңгырый. Бу — Хәлил, аның кебек моңлы итеп башка берәү дә җырлый алмый.

Янәшәсендә — Фатыйма Сакаева. Яратып туймаган хатын-кызым. Кайчандыр Сарман Биги гомерен елгага ышанып тапшырган Фатыйма.

Юлымны дәвам итәм. Жыр көчәйгәннән-көчәя. Иң җаваплы мизгел якынлашуын тойган йөрәгем катып кала. Хәзер иң мөһим очрашу булачак. Үзем: «Чынлап та, мөмкин хәлме бу?» — дип уйлыйм.

Ниһаять, мин аны күрәм. Ул безне аерган су читендә басып тора. Карашында уй-фәлән сизелми.

— Менә очраштык та. Син, мөгаен, болай килеп чыгар дип көтмәгәнсеңдер? — диде ул.

— Әйе.

— Поездда очрашканнан соң, ике ел үткәч, дөнья белән хушлаштым. Туган авылымны кайтып күргәч, гомерем түгәрәкләре тоташкандай булды, күп нәрсәгә инде тыныч карый алдым.

Ул поездлагы кебек, дәшми генә карап торды. Аны бүлдерергә кыймадым, чөнки үлгәннәрне бүлдерергә ярамавын белә идем.

— Күрәсеңме, бу көймәне үз кулларым белән ясадым, — диде ул, аягы янында тирбәлгән каекка күрсәтеп. — Вафа бабайның дәресләре бушка китмәде.

Әз генә читтәрәк, биек тал ышыгында утырган Вафа карт килешүен белдереп башын селкеде. Ягымлы елмайган йөзенә карагач, йөрәкне чеметтереп, сүзләре хәтергә килде: «Теге дөньяда күңелсез дип каян алып әйтәсең?»

Еракта, куаклар янында, ялгыз, исемсез рух тибрәнә. Әлбәттә, хикәянең төп мотивларыннан берсе онытылган, аннан башка төп каһарманым берьяклы гына күренер иде. «Яхшылык белән яманлык — бер йөзнең ике яңагы» дигән җөмлә исемә төште.

— Миңлебай Атнагулов кайда?

Карт җавапка теге ялгыз рухка төртеп күрсәтте. Әйе, бар да туган якларына кайта, аларны өрәкләр аланы каршы ала.

Хәзер кызыксындырган сорауларны бирергә була, нигә әле шул форсаттан файдаланып калмаска? Менә ул, минем каһарманым, безне бары тик елга гына аерып тора.

— Поездда сөйләшүне хәтерлисезме? — дип сорадым мин. — Сез дөньяга килүем мине тетрәтте, дип башлаган идегез. Хәзерге хәлегездән чыгып, әйтегез әле: үлемегез дә тетрәттеме?

— Үзең кайчан да булса кичерәсе нәрсәне нигә дип сөйләп торырга.

Йөзенә чак кына елмаю чыкты һәм бу — аның минем белән хушлашуы иде. Ул борылды да өрәкләр аланына таба китеп барды.

Елга буеннан атлаганда, каршыма элеккечә рухлар калкып чыга торды, алар күбәйгәннән-күбәя бардылар һәм үземнең бөтенләй башка аланнарда яшәүчеләр янына килеп җитүемне белдем. Күз алдымнан элеккеге легионер Җамалый Рәсүлев чагылып китте, ул да, мөгаен, үзенең авылына кайткандыр. Чит-ят җирләрдә сыенып урын тапкан Мәхмүт Топчибаш, аның улы Исламбәк; алар артыннан серле йорт хуҗасы Гаяз бәй күренде. Онытылмас музыкант, рәссам алман Иоахим Вернер үтеп китте. Каршыма таныш һәм таныш булмаган шәүләләр төркеме килә һәм китә торды. Кайчакта алар Истанбул яисә Берлиндагы шау-шулы төркемнәрне хәтерләтте. Йә бөтенләй сирәгәеп, Кильяныкыларны искә төшерделәр. Алар тирә-якны тутырдылар: мәңгелеккә охшаш урын белән кушылдылар, очар кошларга әверелделәр, көл тузанына әйләнеп, өермәләр булып бөтерелделәр, аннары барысы бергә караңгы шашкын суга төшеп югалдылар. Мин инде булган хәлләрне аңларлык дәрәҗәдә түгел идем, әкертенләп килеп кушылган икенче бер аң миңа боларның төш кенә булуын искәртте.

Чынлап та, шул урында мин уянып киттем. Караңгы палатка эченә ябылып

бетмәгән ишек япмасы ярыгыннан таң яктысы үтеп кергән. Башымны сузып тышка күз салдым. Салкынча иртә, елга өстен җинел томан сарган.

Иртән авылга күтәрелдем. Озын-озак сәфәрдән әйләнеп кайткан Сарман Биги кичергән хисләр мине дә урап узмады. Тик бу — карт сөйләгән авыл түгел иде инде. Ихаталар саны кимегән, урамнар да авыздагы тешләр сыман сирәкләнеп калган. Монда көн күрүчеләрнең күбесе өлкән яшьтә, ә яшьләр, башка авыллардагы кебек үк, шәһәрне якынрак күргәннәр.

Җирле риваятьләр турында сорашкалап карасам да, белүче кеше табылмады. Кемнәрдер Сакаев, Камалиев фамилияләрен атаса да, аларга бәйле тарихны әйтеп бирә алмады. Кемдер мине авыл кешеләре күңеленә ачкыч ярата алмаган дип әйтә икән — нык ялгыша, чөнки әңгәмә кору осталыгы һөнәремә хас гадәт аша күнелемә сеңгән. Кыскасы, мин көткәнемә җавап табалмадым. Моннан тыш, карт сөйләве буенча калкулыкның итәгеннән башланып киткән Кара урманны да күрмәдем. Кайдадыр еракта, басу-кырлар артында, тар гына урман полосаларыннан гайре агачлык күзгә-башка чалынмады.

— Дөрестән дә, элек урман авылдан ерак түгел иде, — дип исенә төшерде картларның берсе. — Тик утызынчы елларда ук аны туракларга тотындылар. Ә сугыш вакытында бөтенләй бетерделәр. Нишлисең, бар да ягулыкка тилмерде шул.

Менә шунда миңа каһарманымның ничек кенә булса да авылы, тормышы һәм туган ягына кайтырга хыялланувы турында сөйләп калдырырга тырышуын аңладым. Аның сөйләгәннәре эзсез-нисез югала да ала иде.

Сарман Биги хикәясен ак кәгазьгә төшерү теләге алдыма котылгысыз рәвештә басты. Бернигә карамастан, эшләргә тиешмен, дигән уем тагын да ныгыды.

Ай авылында яшәүчеләрдән егерме еллар элек кайткан бераз гаҗәбрәк профессорны хәтерләүләре белән кызыксындым.

— Чыннан да, сәеррәк кеше иде ул, — дип сөйләде бер карчык. — Миндә торды ул. Көннәр буе әле елга буена, әле басу-кырларга чыгып югалды. Кичкә кырын капка төбендәге эскәмиягә утырып, көтү кайтканны күзәтте. Бервакыт ул миннән кайбер кораллар сорады.

— Нәрсәдер ясарга җыендың мәллә? — дим.

— Әйе, — ди бу. Сарайдан алырга куштым. Күршеләрдән такталар сатып алды да ишегалдында нәрсәдер ясарга тотынды. Башта аңламадым. Аннары гына көймәгә тотынуы мәгълүм булды. Көймә ясалып беткәч, кайнар сумала йөгертте. Зуррак малайлардан аны елгага кадәр алып барырга ярдәм итүләрен үтенде.

— Нигә бу? — дип кызыксынганнарга:

— Елгада, һичшиксез, көймә тибрәлергә тиеш, — дип җавап бирде.

— Карале, — диде карчык, — әгәр череп бетмәгән булса, каек хәзер дә шунда булырга тиеш. Каникулга кайткан балалар йөзәргә ярата анда. Язын кемдер кабат сумалалап куйды бугай. Хәер, бәлки бу — бөтенләй икенче көймәдер. Менә шуннан төш, үз күзләрең белән күрерсең.

Елга буена төштем. Мине көткән кебек, көймә яр кырыенда ята. Суга этеп төшердем дә, ишкәкче өчен ясалган эскәмиягә утырдым. Елга мине үзенеке итеп кабул итте.

Ишкәкләрне кулыма алдым...

**Рөстәм ГАЛИУЛЛИН** *тәрҗемәсе*



Әлфия
Ситдыйкова

# МИН ТОРМЫШНЫ ӨЗЕЛЕП ЯРАТАМ

***

**Сынар өчен яраткандыр Ходай,
Җиргә килгән һәрбер баласын.
Каш белән күз якынлыгы иткән
Яшәү белән үлем арасын.**

**Ялгышлар да булган, кем генә соң,
Хаталардан хали булалган.
Адәм белән Һаваны да Ходай
Җәннәт бакчасында сынаган.**

**Бу дөньяның барлык моң-зарларын,
Җыя-җыя йөрәк түренә,
Сындырмыйча сабыр канатымны
Менеп киләм гомер үремә.**

## Сыналу

**Ирегеңне әгәр чикләсәләр,
Бәйләсәләр аяк-кулыңны,
Йөрәк белән хисләр көрәшүе
Бикләп куя барыр юлыңны.**

**Кызган табага да утырганны,
Кайчакларда сизми каласың.
Кырыс тормыш сыный чыдамлыкка
Очар өчен туган баласын.**

## Китмә...

**Синең җан мәңгелек сусауда,
Минеке мәңгелек сәфәрдә.
Сусавың басарлык наз булып,
Уралыр идем мин җаныңа,
Иртәрәк очрашсак әгәр дә.**

Әлфия СИТДЫЙКОВА — *шагыйрә; «Йөрәгемә яфрак сыена», «Җанда кабынган учак» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Мин соңлап туганмы, әллә син
Килдеңме бу җиргә иртәрәк?!
Күңелем тартыла тик сиңа,
Син кабул итмисең бит, димә,
Китмә син янымнан үпкәләп.

## Хәтер дулкыны

Хәтер елгасында, Әнкәй, кат-кат
Чайкадыңмы ап-ак биләвемне?..
... Күз сулышын сизгәч кенә кызың
Аңлады шул олы йөрәгеңне.

...Мин дә бүген, Әнкәй, синең хәлдә –
Хәтер елгасының бер дулкыны.
Оныкларның биләүләрен чайкыйм,
Чыныктырыр өчен холкымны.

* * *

Бәхет нидә?! Әгәр кояш –
Балкып чыкса һәрбер таңда.
Сандугачлар гомер буе,
Сайрап тора икән җанда.

Үз аягың белән ныклап,
Басып йөрсәң туган җирдә.
Сөйләр сүзең үз илеңдә,
Сөйли алсаң үз телеңдә.

Балаларың кызартмаса,
Ил алдында синең йөзне.
Бәхетеңне саргайталмас,
Гомереңнең алтын көзе.

Ак хыяллар тулы дөньяң,
Капламаса кара болыт,
Яшәп була гомер буе,
Иң бәхетле Кеше булып.

## Эз

Туа кеше, әкрен генә
Офыкка таба бара.
Нәни генә йөрәгенә
Сыйдыра меңәр яра.

Уза гомер, сизелми дә,
Су кебек китә агып.
Күңел яшь килеш калса да,
Барыбер килә картлык.

Шагыйрь яши янып-көеп,
Киткәндә кала сүзе.
...Тагын Бер йолдыз атылды,
Сызылып калды эзе.

## Мин яшәргә килдем

Төртеп аудардылар, сикереп тордым,
Бирешмәдем дошман сүзенә.
– Мин яшәргә килдем! – диеп дәштем
Туры карап язмыш күзенә.

Сындырырга теләп ничәмә кат,
Сугып екты язмыш аяктан.
– Мин яшәргә килдем!.. Катгый сүзем
Яңгырады кабат–кабаттан.

– Мин яшәргә килдем! Шушы сүзем
Яңгырап тора бөтен тарафтан.
Ишет язмыш! Ничек кыйнасаң да,
Мин тормышны өзелеп яратам!

***

Кашкарыйлар сулып ята,
Ак кыраулар куенында.
Кем җиңелә, кемнәр җиңә
Яшәү – көрәш уенында.

Кемдер чишмә булып ага,
Тау–ташлардан басылса да.
Кемдер ава башын тотып,
Әз генә җил кагылса да.

Битарафлык тамыр җәя,
Яшәү – көрәш уенында.
Кашкарыйлар сулып ята
Ак кыраулар куенында.

## Теләк

Җәбергә, золымга юлыктым
Тормышның катлаулы юлында.
Тик һәрчак өметем кабызган,
Ялкынлап янучы шәм булды
Аруны белмәгән кулымда.

Татыдым хыянәт ачысын,
Алдандым ничә кат тормышта.
Ышаныч җуймыйча, барыбер
Соң тиен акчамны кайчакта
Суздым мин дусларга бурычка.

Игелек орлыгы туфракка
Күмелсә шыта ул гөл булып.
Китсәм дә, бу җирдә яшәгән
Гомерем саклансын хәтердә,
Мәңгегә өзелмәс җыр булып.

Кави
Нәҗми

# МИҢЛЕБИКӘ КОДАГЫЙНЫҢ КАЙГЫСЫ

1

Урамнар буш. Өстә кар кибәннәрен күтәреп болытлар өелгән. Йортларның түбәләренә, стеналарына ябышкан кырау елтыры йомшак кына итеп күзне кытыклый. Урамнарны аркылы-торкылы кисеп озайган тимерчыбыклар ап-ак кабык белән капланган.

Иртәнге сәгать җиделәр булгандыр. Чиркәү каршындагы сары буяулы, дүрт катлы таш йорт алдына халык җыела башлады. Күбесе авылныкылар. Корымсаладан да байтак булырга охшый. Хатын-кызлар да бар. Кайберәүләрнең кулларында ямаулы капчыклар, тырыслар, төеннәр күренгәли. Барысы да нәрсәдер көтәләр. Ишегалдындагы агачлар артында тагын нindидер йортлар бар. Ул йортларның тирән кое төбеннән бәрелгән күләгә төсле салкын тәрәзәләре, бер ягына будка куелган җиз рәшәткәле ишеге крестьяннарның башларында әллә нинди шикләр, әллә нинди авыр уйлар тудыралар. Аларның язмышларын, үлем куркынычы белән каплап, кулына учлаган суд бүген шунда булачак.

1905 елда алпавыт урманыннан рөхсәтсез агач кисүләрнең, Тәүгилдиев усадьбасына кул сузуларның үчен бүген шунда кайтарырга уйлыйлар. Кое төбендәге караңгы салкынлык кебек тәрәзәләр артында, әнә шул будкалы ишектән кереп китә торган урында, бүген, йөзләрчә аналарны тилмертеп, йөрәкләрне тетрәтеп, суд карары чыгарачаклар.

Бүген кояш яктысы күзгә күренмәс булыр.

Бүген ап-ак кар өсләрендә биегән кояш нурлары инәгә әверелеп, йөрәкләрне үтәдән-үтәгә чәнчеп, иләк төсле ясап чыгарлар.

Бүген — авыр көн.

Бүген — 1907 елның 13 декабре...

Йөз алтмыш чакрымлык җирдән өстерәлеп бирегә килгән, сакалына, мыегына боз токмачлары каткан әнә шул карттан сорагыз. Атасы, бабасы кыйналган, үзе кыйналган, эттән алынып эткә салынган һәм бүген суд залына китереләчәк ике улыннан да аерылачагын алдан белгән бу карт күпне белә...

2

Кайчандыр, бу йорт артындагы бакчада граммофоннар уйнатып, самавырга лимон кабыклары салып, шау-шу белән, уен-көлке белән кичәләр уздырганнар...

Япон сугышы вакытында йортка лазарет урнашкан. Тирә-якка ачы исле дару сөреме тараткан бу йорт бишенче елларда бөтенләй бушап кала. Көннәр берсе берсен элеккечә алыштыра баралар. Эшчеләрнең кузгалышы зур

бер катылык белән бастырыла. Уку йортларында тынычлык урнашкандай була.

Алпавытларның, морзаларның дачалары тирәсендә ялкыннар сүрелгәч, кисәүләре күмергә ташылып, көлләрен җил тараткач, авыллар, шәһәрләр буйлап «акылга утырту», «тынычлык урнаштыру» көннәре килде. Буш калган таш йортка явыз көче һичбер нәрсә белән чикләнмәгән суд урнашты.

Көндез әллә нинди кайгыларны, әллә никадәр әрнүләрне, очы-кырые булмаган катылыкны суырган бу тәрәзәләрдән кич белән эчпошыргыч ут шәүләсе сузыла. Узучылар ул шәүләгә карамаска тырышалар. Кыраулы агач ботаклары арасыннан урамга текәлгән бу шәүлә әллә нинди ачы тойгы булып күзгә төртелә. «Тагын үтерәләр... Тагын киләчәктәге язлардан, шул язларга бәйләнгән өметләреннән кемнәрнедер мәңгелеккә аералар...» дигән авыр уй ми эчендә яна башлый.

Менә шуңа күрә капка төбендәге крестьяннар, хатын-кызлар кайгылы, карлыккан тавыш белән: — Тизме китерерләр икән?..

— Ничек итеп китерерләр икән?.. — дип сораштыралар. Кемдер аларга сузып кына җавап кайтара:

— Китермәсләр дә, күрсәтмәсләр дә.

Тик бу сүзләрнең авырлыгы йөрәкләргә утлы күмер булып төшкәнче, чиркәү янындагы тыкрыктан атлы конвоирлар килеп чыктылар. Башларына саргылт бүрек, өсләренә кап-кара шинель кигән солдатлардан берсе алданрак чабып килде дә:

— Артка чиген!.. Артка!.. Урамның аръягына, мар-р-ш! — дип, тупас җикеренеп, халыкны куа башлады.

Крестьяннар чиркәү алдынарак елыштылар, һәркем, куллары, аяклары богауланган тоткыннарга текәлеп, үз кешесен табарга тырыша, тик казаклар гына тыгызлыйлар. Рәтләп күрер хәл юк.

Капка ачылды. Керделәр... Ябылды. Капканың бирге ягына озын мыеклы, кызыл борынлы стражник чыгып басты.

— Якын килмәгез!

— Ярар, ваш висбарут...

— Барыгызның да паспортлары әзерме?

— Әзер, ваш висбарут...

— Урыныгыздан кузгалмагыз, кайчан керәсен үзем әйтермен...

— Була, ваш висбарут...

— Ә син, мәчет карты, нәрсәгә монда килдең?

— Ике улым, ваш висбарут...

— Улым, имеш, сукыр чирмеш! Улың булса, тәүфыйклы тоталар аны... Хәзер инде менә нәрсә... Багана бар. Баганада дилбегә. Дилбегәне муенга... һәм ка-пут!..

Бу сүздән хатын-кызларның йөрәкләренә тигәнәк кадалгандай була. Алар һичбер чара белән төзәлмәслек төпсез кайгы эченә чумганнар да авыр итеп сулыйлар, авыр итеп уйлыйлар.

— Ирләребезнең төрмәләрдән төрмәләргә йөрүләренә елдан артык... Хәзер инде үлем куркынычы һичбер кайчан булмагандай якын... Бүгенме, иртәгәме аларны асарлар. Ә өйдә... бала-чага авыру. Азык кыш уртасына кадәрле генә... Имана түлим дисәң бөтенләй ач-ялангач калырга туры килә... Бу уйларның тезмәсен капка артыннан шалтыраган чылбыр тавышы өзде.

3

Йокымсырап торган стражник сискәндергеч тавыш белән кычкырды:

— Әй, кем анда, халыкны үз тирәнә җыйнап торма... Хәзер кертә башлыйм... Туган тиешле кешеләрне генә кертәм!..

Халык, бу сүздән шатланып, капкага ябырылды. Ләкин бердән кереп китә алмады. Стражник берәм-берәм генә, паспортларын, документларын тикшереп кертә. Гомердә үз кулына кәгазь тотмаган хатын-кыз тагын тышта калды. Аларның күбесе шуңа гарьләнеп, шулкадәр ерактан килеп тә кертмәүләренә аптырап ялварырга, күз яшьләре белән еларга тотындылар. Стражник алардан көлә генә:

— Их, каргалар, чәүкәләр... Их, мин сиңа әйтим, ачык авызлар, ни пычагыма дип бире килдегез... Нәрсә инде күзеңнән сарымсак суы сыккан буласың. Үзең болай карап торырга чибәр генә күренәсең. Кияү табылмас дип кайгырырлык түгел... Ә монда эләккәннәрне барыбер җибәрмиләр. Аларга дигән мунчала бавы бер атна элек ишеп куелган...

Крестьяннар, озын таш баскычлар буенча атлап, үзләренең якын кешеләрен күреп калу өчен суд йорты коридорына кергәндә, судьялар киңәшергә чыкканнар, гаепләнүчеләр дә күренмиләр иде. Бер сәгать чамасы вакыт узганмыдыр, юкмыдыр — кизүдәге комендантның тавышы яңгырады:

— Гаепләнүчеләрне скамьяга! Шагом марш! — Сакчы солдатларның үткен йөзле кылычлары артына ияреп, авыр богаулар сөйрәп, алар уздылар... Бик күпләрнең йөрәкләре бердән кысылып китте. Озын коридор эчендәге һава җитмәстәй булды. Кайберәүләрнең бугазларыннан иректе-ирексез:

— Улым, бәгърем... Нишләдең син?.. Шулай ук безне ялгыз калдырасыңмыни? — дигән тавышлар яңгырап, сулкылдау, үксү өннәренә күмелде.

Солдат киемендәге берәү:

— Тыныч кына торыгыз, суд килә! — дип кычкырды да түреңдә яшел сукнолы өстәл күренеп торган зал ишеген ачты. Аннан күкрәк турыларына ялтыравыклы билгеләр тегелгән суд членнары керделәр. Уң як кырыйдан дүртенче — бу судта шаһит булып катнашучы алпавыт Тәүгилдиев иде.

Хәзер алтын-көмеш бизәкләр белән түшен каплап, төннәрен рестораннарда, көннәрен суд залларында уздыручы салмак гәүдәле, куе кашлы, калын иренле бу морзаның халыктан талап җыйган байлыгы хисапсыз зур.

Корымсала авылыннан уналты чакрымдагы Зәңгәр күл буйлап Тәүгилдиевнең бакчалары, умарталыклары, ташпулатлары, иген складлары тезелеп киткән. Бу җирләр аның бабасына Пугачёв явына каршы көрәше өчен Әби патша тарафыннан бүләк ителгән диләр. Шул җирләрдә Тәүгилдиевнең өч буыны рәхәтләнеп гомер уздырган. Ә дүртенче буынның тынычлыгын бер яктан Корымсала, икенче яктан Куликовка крестьяннары бозганнар.

...Төн иде, төнә — караңгы, болытлы. Болытлар, ерткыч кошлар төсле, бер-беренә канатларын бәреп агалар. Болытлы төн Зәңгәр күл ярына сузылган таш юлны җилкәләренә нәрсәдер күтәргән кешеләр белән бергә күмде. Чирек сәгать үтмәгәндер, Тәүгилдиев утары өстенә ялкын күтәрелде. Ут яктысында йөзләрчә крестьяннарның ачулы йөзләре, кулларына тоткан балталары, сәнәкләре, өч ат җигелгән повозкада Тәүгилдиевнең иске күпер өстеннән ни бар көчкә чабып үтүе, тагын әллә кемнәрнең әллә ни эшләүләре, тоташ күләгәгә әверелеп, бер-бер артлы биеп уздылар.

Бүген менә шуның үчен кайтаралар.

**4**

Бүген суд членнары арасында утырган баш шаһит Тәүгилдиев — «мәңгелек тынычлык урнаштыру», «патшага буйсыну», «законны һәрбер хәрефе белән үтәргә тырышу», «гаеплеләргә җәзаның иң катысын сайлау» турында шулхәтле кызып сөйләде ки, прокурор үзе таң калды.

Судьяның кулында ниндидер кәгазь күренә. Крестьяннар, тыннарын да чыгармыйча, шул кәгазьгә төбәлделәр...

Менә хәзер бер ел буенча көткән өметләренең нәрсә булып чыкканы күренәчәк. Менә хәзер йөзләрчә аналарның йөрәк сиртмәләрен сузып килгән көчнең соңгы тартуы булачак. Бу тартудан бик күпләрнең, бәлки, барысының да өметләре, теләкләре, ышанычлары җилгә очачак.

...Шомлы кәгазь өстендәге хәрефләр, тавышка әверелеп, суд залы буенча дуылдый башладылар.

Менә ул — озак айлар буенча көтелеп, төрмә стеналары арасында суккаланган ашкынуның соңгы чиге!

Менә ул — ми эчендә игәүләнеп, ата-аналарны акылдан яздырган кайнар тойгыларның төпләнер җире!

Үз артындагы таянычның көчле булуына ышанган тавыш белән, баш судья төрле күренешләрне тезеп узды.

— Менә авыллар... Крестьяннары патша язган законга буйсынмаганнар: фәлән алпавытны талаганнар. Фәлән урманны ташыганнар, Тәүгилдиевнең утарын яндырганнар. Стражникларны кыйнаганнар... Законның ... нче һәм ... нче статьялары буенча...

Крестьяннарның колак төпләрендә таныш исемнәр төркеме тезелеп китте. Берләнбер, якыннан-якын, сөйкемледән-сөйкемле исемнәр...

Тагын статьялар, тагын гаепләр... Тагын исемнәр...

Адәм йөрәге күтәрмәслек куркыныч сүзләр җыентыгы бугаз кимерчәкләрен көйдерә башлады. Ә судья элекке салкынлыгы, элекке килбәте белән укый бирә, тезә бирә. Тик тойгыларның алмашынып торуын да, «җәза» дигән сүзнең куркынычлы билгесен дә тоткыннарның күзләреннән очратып булмый. Куликовка авылының озын Даниласы белән Корымсала Хисамие бик әтәчләнеп әйтелгән сүзләрне дә елмаю катыш уздыралар. Уралдагы Чусовой заводында эшләп, япон сугышында яраланып авылга кайткач, крестьяннар хәрәкәтенә катнашкан Хисами, үзенең судка хәтле үк үлемгә хөкем ителүен белгәнмедер, әллә башка берәр сәбәп беләнме, судьяларга бер дә исе китми. Төрмә түрәләре дә аны асар өчен суд узганны гына көтәләр. Ләкин ул, көчле каравыл уртасына алынган килеш, төрмәдән чыгып, суд залына килгән чагында да үзенең ярсып көрәшергә көче барлыгын сиздерде. Чигә тамырларының бүртүеннән, йөрәктәге ялкынның күз аркылы сибелеп торуыннан — ниндидер кискен адымга әзерләнүен, тоткыннарча тормыш ярыннан батырларча үлем ярына таба бөтен халыкка күренерлек күпер сузарга теләвен төрмә башлыгы, бәлки, тоймагандыр. Ләкин ул нәрсә юлда бик ачык күренде. Тик сакчыларның чамадан тыш тыгыз елышулары гына бу омтылуга чик куйды... Менә бүген төн уртасында багана төбенә урындык куячак палач белән окружной суд мулласы гына аның үлем алдындагы карашларын үзләренә төбәлдереп китәрләр... Тик бу үлемнең бушка югалмаячагына, аның турында пышылдашып кына булса да сөйләүләренә ул ышана. Шул ышаныч белән ул үлем карарын тыңлый.

...Үлем карарын укыган тавыш, соңга таба тагын да салмаклана төшеп, исемнәрне, фамилияләрне суза-суза тезде дә азаккы юлларны очлы кадаклар белән суккан төсле яңгыратып бетерде.

— Җир биләүчеләргә һәм хөкүмәткә килгән зарарларны Корымсала, Мукловка, Куликовка, Юкәле авылларыннан түләтергә, суд расходларын гаепләнүчеләрнең семьяларыннан түләтергә... Нибарысы алтмыш бер гаепләнүче... Шулардан унҗидесе каторгага, утыз икесе төрмәгә... Калганнарын...

Багана бар... Баганада бау кисәге... Аны менә болай итеп элмәклиләр дә муенга кидертәләр...

... Суд 13 декабрьдә булды. 15ендә төрмәдәгеләрдән беренче төркемне астылар.

Карангыда палач белән кемдер сөйләште:

— Утларны сүндер, киемнәрен үзенә ал!

Шул ук көнне калганнарын Себергә озаттылар.

Ләкин алар арасында Хисами юк иде. Ул, каторгага хөкем ителеп, судтан төрмәгә кайтышлый, караңгы тыкрыктан борылган чакта, капкасы бикле ниндидер ишегалдына сикереп төште. Аның артыннан күпме атсалар да тидерә алмадылар. Бу ишегалды Кабан күленә чыга икән. Әллә шунда ташланган, әллә бүтән бер якка йөгергән. Суга чумган төсле югалды...

Уналтысында Корымсала крестьяннары, чаналарга төялеп, юлга чыктылар. Кар бураннары артында аларны салам түбәле кыйшык өйләр, елаудан күзләре шешенеп беткән балалар, нәрсә белән чикләнүе билгесез авыр тормыш көтә. Чана табаннарының юл өстендәге карларны шыгырдатып чыжлауларына кайсыныңдыр кыю тавышлы җыры аралашты:

— Сөрсә сөрсеннәр Себергә!..

Тик ана җырлап бетерергә ирек бирмәделәр. Төрле яктан әллә ничә тавыш берьюлы Тәүгилдиевнең тау астындагы яшел мәчетле имениесенә таба йодрыкларын төеп кизәнделәр:

— Сөреп бетерә алмассың безне!

## 5

Кышкы давыл, тәбәнәк өйләрне кар көртләренә күмеп, авыл буенча бөтен авырлыгын салып атлаганда, ул кайтты.

Төрмәдән качып, полиция күзеннән яшеренеп йөргән улы, крестьяннар белән бергәләп җир өчен, ирек өчен көрәшкән Хисами кайтты. Исәнләшеп чыгарга гына дип кайткан Хисамины күргәч, куркудан, сагыштан мие тонып беткән Миңлебикәнең башы боз астында калгандай булды. Хисами:

— Әнкәй! Хәернисаны уятма, йоклый бирсен. Мин бары бер генә кич кунам. Тышта бүген бәйдәге эт тә тормас, шундый салкын... Менә бу төргәкне эчендәге хаты белән Юкәтау тегермәнендә эшләүче Васильев дигән егеткә тапшырырсың, иртәгә үк тапшырырсың... Кемнән, дисә, Хәсәннән, диген. Хәзер минем исемем шулай йөри, әнкәй. Моны үзең генә бел!.. Ә менә бусы сиңа кәшимир яулык. Сагынганда түсем итеп ябынырсың. Бусы Хәернисага чәч бавы. Берәр заводка кереп эшкә тотынсам, зуррак бүләкләр дә җибәрермен. Сезне дә үз янымa алырмын. Ә хәзергә бер дә кайгырмагыз. Мин бераз ятып йоклап алыйм. Бер атнадан бирле йокы күргәнем юк. Берүк таң атканчы уята күр... Мукловкага җәяүләтә, аннан ат белән стансага,—диде дә җылы мич башына менеп ятты.

Миңлебикә, илдәге авырлыклар турында, үзенең кайгысы турында сөйләп, Хисаминың ничек качуын, тотсалар ни эшләтәчәкләрен сораштырып, Хисами йокыга киткәнче әллә никадәрле хәбәрләр тезде...

Хисами йоклый. Авыр итеп, саташып, мыгырданып йоклый. Ә карчык төннең төн буе сагалап чыкты. Ул бу төнне, төрмә стеналарының эзе басылган ач яңакларга, колак артына бөдрәләнеп төшкән кара чәчләргә текәлеп, алтмышлап язның килүен-китүен күргән күзләрен улыннан ала алмый уздырды. Чикерткә тавышыннан да, кырдагы буранның тәрәзәләргә китереп сипкән кар бөртекләреннән дә шикләнеп, улының яныннан китмәде...

Әле күптән түгел генә шундый тигез, шундый тулы шатлык белән бу өйдә йоклаган Хисаминың бүгенге йокысы ярым саташу эчендә үтә. Әле күптән түгел генә Корымсаланың иң матур кызы булган Әтүк (Гайшә) белән яратышып, тиздән туйлары көтелгән таза егет бөтенләй сулып, көзге чәчкә кебек шиңеп йоклый.

Миңлебикә таң атуын зарыгып көтмәде. Ул бу төннең, бердәнбер төннең, мөмкин кадәрле озаккарак сузылуын, Хисаминың уянмавын теләде... Таң ата башлагач та уятмады. Иртәнге яктылык билгеләре җиргә сибелгән солы төсле, тәрәзә аркылы идәнгә таралгач кына, таң шәүләсе, кайгылы тойгы булып, сәке өсләренә, мич алларына яткач кына, Миңлебикә, улына юынырга дип, комганга җылы су салды... Менә тагын бер генә чүмеч... Тагын бер генә чүмеч... Җылы су белән мичнең арткы кырыенда утырган чуенга гына сузыласы... Аннан соң комган да тулыр... Аннан соң...

Нәрсә эшләргә икәнен уйлап бетерә алмады, терсәк буыны катып калгандый булды. Чүмеч идәнгә төшеп, Хисамины уятты. Комган мич алдына авып, читкә өелгән көлләрне камырга әверде... Ә тәрәзә төбендә, тышкы ишек янында, ачулы аяклар тупылдап, кар шыгырдады:

— Ачыгыз!.. Ишетәсезме, юкмы... Сезгә әйтәләр бит. Канальялар, көттермәгез!..

Бу тавышлардан Миңлебикәнең теле сакауланды, йөрәге тибүдән туктагандай булды... Айнырга өлгергәнче, ишекнең элмәге төбеннән үк каерылып, урядник белән тагын кемнәрнендер күзләре чекрәйде. Миңлебикә боларның һәрберсен аерым итеп күрә дә алмады. Алар белән бер авыз сүз сөйли дә алмады. Аның күзенә аларның барысы да тоташ коелган зур бер куркыныч машина кебек тоелды. Шул арада урядник килеп Хисаминың якасына да ябышты.

— Эләктеңме, крамола! Патша дошманы! Төш әйдә... Ягез, егетләр, нәрсә карап торасыз? Бәйләгез үзен! Кулларын арткарак каер!.. Менә шулай. Кесәсен кара! Бер-бер әйбер юкмы? Ә син, карчык, монда тыгызлап йөрмә. Урынында утыр!

Урядникның бу сүзләрендә әллә нинди җирәнеч мактану да, чирканыч масаю да бар иде. Әллә нинди куркынычлы төшләр күреп шабыр тиргә баткан Хәерниса да бу тавышлардан сискәнеп уянды:

— Абый, жаным, — дип, Хисамига ташланды.

Ләкин аны тупас куллар бик тиз артка этәреп сәкегә утырттылар.

...Миңлебикәнең уйлары яңадан элекке эзләренә төшә башлады. Соңгы айлар эчендә уйларга да кыймаган күренешләр тезмәсе, бердәнбер улының туунннан алып бүгенге хәленә кадәр булган күренешләр күз алдында куышып үттеләр. Курку да, кызгану да, Хисами өчен ялварып йөрүләр дә...

— Тагын төрмә...

— Тагын тоткынлык... — дигән сүзнең ми буенча сызылып үткән утлы җебенә уралдылар.

Элекке аптыраулар, куркулар урынына, нининдер тынычлык белән үзен-үзе кулга алып, улын киендерә башлады:

— Ашыкма, бәгърем! Менә бу шәлне муенына ура, менә бу ипине кесәңә сал.

Ләкин урядник, җикеренеп, аларның арасына басты.

— Күп телеңә салышып торма, карт дурман! Әйтәләр сиңа, улың патша дошманы, дип... Аңларга кирәк.

Хисамига шәлне урарга да ирек бирмәделәр. Чикмәненең төймәләрен дә каптыра алмады. Билбавын да онытты. Шул килеш аны, кораллы солдатлар арасына алып, чанага салдылар. Миңлебикә чана артына ябышырга теләгән иде, аягына мылтык сабы белән бәреп, карга ектылар. Ул шунда авып, сыкрана-сыкрана, кемнәргәдер йодрык күрсәтеп калды. Хәерниса, аягына тишек киез ката эләктереп, өстенә атасыннан калган кыска тунны бөркәнеп чыкканда, Хисами да, атлы солдатлар да басу капкасыннан чыгып баралар иде инде.

## 6

...1910 елның кышы үтеп, яз житте. Эссе көннәр башланды. Хисамидан һаман хәбәр юк. Миңлебикәнең тормышы ут эчендә, куркыныч төшләр уртасында уза. Көннәрдән бер көнне ул старостага бара, кинәшеп карый. Староста бер генә юанычлы сүз дә әйтмәгәч, писарь Сәйдәшевкә бер каз илтеп:

— Шәһәргә бар! — дигән кинәшне алып кайта.

Миңлебикә үзенең яшь чакларын шәһәрдә уздырганга күрә, бу киңәш аның күңеленә бердән кереп утыра. Ләкин элек, кыш көне төргәк илтеп биргән Юкәтау Васильевына барып, аңарга да үзенең уен әйтмәкче була. Эзли, эзли, таба алмый. Юкәтаудагы фельдшер очрап, Васильевның полициядән качып йөрүен, бик шикле кеше икәнлеген сөйли дә:

— Үзең карчык кеше... Үзең фетнәчеләр артыннан йөрисең. Әгәр дә сау башыңны авыру ясыйсың килмәсә, аны эзләмә. Алар яхшылыкка илтмәсләр, — ди.

Шуннан соң гына, авылга кайтып, Хәерниса янында өй сакларга дип ахирәтен, Хәйрибә исемле тол карчыкны калдыра да шәһәргә юнәлә.

Шәһәр ерак. Шәһәр зур.

...Бик күп бусагаларны, бик озын урамнарны таптый торгач, Миңлебикә әби окружной суд йортына барып керде. Көя ашап бетергән шәленең бер почмагын бөтәрли-бөтәрли, үзе белән бергә алып барган тылмач шәкерт аркылы шундагы адвокатларның берсенә үтенечен сөйләп бирде. Башта Миңлебикәнең күзенә бик ягымлы күренгән бу адвокат көмеш савытыннан кыйбатлы папиросын чыгарып, авызына капты да төтенен Миңлебикә өстенә җибәрде:

— Хәлегез җитәрмедер, юкмыдыр, монда эш биш йөз тәнкәсез барып чыкмас, — диде.

Шәһәргә алып килгән бөтен акчасы биш тәңкәдән артмаган Миңлебикә өчен мондый сумманы ишетү таяк белән башка суккандай булды.

— Кайда инде ул безнең иште хәерчеләргә биш йөз тәңкә! Андый акчалар кулда булса, Хисами да төрмәгә эләкмәс иде.

Адвокат, әбидән эш чыкмаслыгын сиздемедер шунда, күршедәге бүлмәләрнең берсенә кереп югалды. Шул арада тагын берәү күренде. Бусы алтын төймәле мундирдан. Тылмач итеп яллаган шәкертнең: «Сез окружной судта эшләмисезме?» — диюенә каршы: — «Әйе, ни йомыш?..» — диде. Йомышның нәрсәдә икәнен әйткәч, башын гына чайкады. Булмаса, төрмәгә барып Хисами белән күрешергә рөхсәт кәгазе бирелсә икән, дип ялваргач:

— Бирелмәс! — диде дә, шул арада ишектән кергән яшь кенә бер кызга башын иеп, култыклап алды, һәм алар чыркылдаша-чыркылдаша югарыга менеп киттеләр.

Миңлебикә шул сыны белән катып калды. Аның башында төрле сукмакларга бүленеп йөгергән уйлар төркеме үзара тиңләшеп, көчләрен чагыштырып уздылар.

— Төрмә үзенең серләрен читкә чыгарырга яратмый торгандыр шул. Төрмә йөз еллар буенча үз эченә җыелган шомлы күренешләрне, канлы хәбәрләрне ныклап сакларга күптән өйрәнгәндер шул...

— Шулай да... кайсы вакытны сораучысына карап яки юатырга, яки кырт кисеп «үтерелде» дип әйтергә, яки «чит шәһәргә күчерелде» дип алдарга мөмкин бит. Нигә миңа хәзер шулай итмәскә? Миңлебикә өч җавапның өчесенә дә риза, чыгарга да әйтергә иде:

— Син, карчык, кайгырма! Улыңны чыгарырлар. Патшаның баласы туса икән, дип теләктә тор. Аның баласы тугач ук манифест чыга. Шуннан

соң патша Хисамины төрмәдән чыгарырга кушар. Ә хәзер авылына кайт та өеңне җыештыр!

— Син, карчык, монда йөрмә дә, сорама да. Улыңны үткән атнада ук астылар.

— Улың бу төрмәдә түгел шул. Аны фәлән шәһәргә күчерделәр, барсаң, бәлки, очратырсың...

Миңлебикә бу өч төрле җавапның кайсын булса да алып китәргә тели. Тик бер генә минутка Хисамины күрәсе иде. Ишеккә юнәлгән бер яшь кенә егеттән дә шул турыда сорады. Анысы да шул ук җавапны әйтте:

— Рөхсәт юк! Не полагается!

Шуннан соң гына аптырауның соңгы чигенә җиткән Миңлебикә әлеге тылмач шәкерткә:

— Мә инде, булмаса, улымның рухына ясин укырсың, — дип, егерме ике тиен акча бирде дә соңыннан шулай диюенә үкенә-үкенә урамга чыкты.

Тагын аның алдыннан шоп-шома юргалар, чуар киемнәр, күп маллы кибетләр, чуар киемле кешеләрне төягән трамвай вагоннары агарга тотынды. Бу тизлектән, бу өзлексез йөрешләрдән аның уйлары бөтенләй чыгырыннан чыктылар. Юлда клиндер сатучы бер хатын очрап, бәйләменә ун тиен сорады. Миңлебикә, һичбер исәпләмичә-нитмичә, нәрсә эшләгәнен үзе дә аңламыйча, клиндерне алды. Бугаз төбенә төйнәлгән төеннәрнең катылыгыннан, күздән тамган яшьләрнең ачылыгыннан арчыла алмыйча, елау аралаш юл буенча клиндер кимереп барды да капка төбендәге эскәмиягә утырды. Күз алдына атасының кайчандыр шушы шәһәрдә күн заводында эшләвен, ярминкәгә барып, таш курчак алуларын тезеп уздыргач, тагын кузгалды.

Кешенең башы бер әйләнсә әйләнә икән. Һичбер нәрсәнең рәтен-чиратын табар хәл юк. Миңлебикә белән дә шулай. Йөри-йөри дә йә вокзалга, йә базарга барып чыга.

Базардагы нindidер бер карт белән сөйләшә башлагач, монда якында гына, Мещанский урамда округжной суд мулласының барлыгы беленде. Мулла үзе төрмәдәге агай-эне халкына кәлимәишәһадәт укыта икән. Бу хәбәрне ишеткән төнне Миңлебикә йоклый алмады. Йөрәге яртылаш тынычланса да, шул мулланы тизрәк күрергә теләү тойгысы бөтен гәүдәгә китте.

— Әгәр дә ул табылса...

— Әгәр дә аның абыстаен күрсәң... Мин бит ул абыстайның аяк астында туфрак булырга да риза... — дигән уйлар, бәхет кошы эзләгәндәге ашкыну бөтен ми ятьмәләрен урап чыктылар.

Абыстай белән ничек күрешү, күпме садака бирү, ничек итеп сөйләшү, хәзрәтнең үзенә шул хәлләрне аңлатып кәгазь яздыргач, ул кәгазьне шәлнең кайсы почмагына төенләү, улы Хисами белән кочаклашып күрешү турында төн буенча план корды да шул планның киңлегенә, барып чыгардай булуына куана-куана таң аттырды. Иртә белән:

— Намазга торганнардыр инде. Хәзер үк кузгалганда да ярар. Хәзрәт үзе сәгать җиделәрдә мәчеттән кайтса, таман гына була, үзенә тапшырдым, Ходаем... — дип, урамга чыкты.

## 7

Урамнарда рәтләп кеше йөргәне күренми. Тик дворниклар гына, бөтен тирә-якны тузанга батырып, капка алларын себерәләр. Яхшы фаэтоннарның да, трамвайларның да тавышы ишетелми.

Миңлебикә озак барды, көтелгән күрешүдән йөрәге ярылырдай булды. Менә яшел түбәле, ике этажлы таш йорт. Әллә нинди ялтыравык челтәр

белән бизәлгән сары капканың уң ягында — әлеге карт әйткән матур ишек... Әнә шул ишеккә беркетелгән ап-ак сөяк төймә... «Бисмилла» әйтеп, баш бармак белән басарга да, аннан тәнгә таза гына, көр генә, ачык чырайлы гына абыстай килеп чыгар. Кулында тәсбих булыр, аягында чәмчәле, бизәкле читек. Башында кәшимир яулык. Үзе бик йомшак тел белән, вәкарь белән генә сөйләшер. Садаканы алгач, озак кына итеп Хуҗа Әхмәт Ясәвигә багышлап дога кылыр һәм:

— Бик исән-сау гына йөрисенме? Бала-чагаларың бик сәламәт кенәме? Кичә әле мулла, Корымсала Минлебикәсенен улын япканнар икән, дип сөйләшкәч, шулхәтле кызгандым инде. Шулхәтле ялындым инде. Әйтмәгән сүзем калмады. Син бер дә кайгырма. Кая әле бишмәтенне салып утыр. Тиздән үзе дә кайтыр. Хәзер аш хәстәрлим. Ачыккансындыр. Шуннан бергәләп Хисами янына китәрбез, — дип әйтер төсле тоелды.

Минлебикә әнә шулай уйлады. Шулай уйлап, өч мәртәбә «бисмилла» әйтеп, түгәрәк кнопканы уң кулының баш бармагы белән әкрен генә басты. Йөрәге тагын да ныграк тибәргә тотынды. Ләкин җавап юк. Бер ярты сәгать үткәнмедер, юкмыдыр, әллә теге янлыш әйтте микән, дип шиккә калса да, тагын кнопканы басты. Тагын җавап юк.

— Әллә басарга түгел микән?.. Туктале, тартып карарга кирәк әҗәтканаңы! — дип, тырнагының очын кертеп, тартмакчы булды. Тартылмады. Шуннан соң бер-бер артлы ишекнен үзен дөбердәтергә тотынгач кына, югарыда ишек ачылганы ишетелеп, кемдер йокы аралаш ачулы тавыш белән мыгырданып кычкырды:

— Хту там? Нәмәстә кирәк? Мулла спит...

— Мин бу... әйе... Хәзрәт абзый мәчеттән кайтмады микән, дигән идем.

— Юк, юк. Барганы да юк... Кайтканы да юк, — дип, бик нык шакылдатып ишекне япты.

Минлебикә көтәргә дип баскыч төбенә утырды. Утырды да:

— Болар коткармаса, кем коткарыр... Хисами өчен елап-елап гафу сорармын башта. Аннары садака бирермен. Яки элек садака биреп, аннары гафу сорармын. Боларда гына инде өметем... — дип уйга батты.

Эченнән бөтен белгән догаларын кабатлады. Менә бервакытны зур капканы ачтылар да, бик яхшы экипажга җигелгән ат тотып, кучер чыкты. Парадный ишек төбенә туктады. Озакламыйча югарыда тагын ишек шыгырдап, берәү, тамагын кыра-кыра, баскычтан төшә башлады. Миңлебикә урыныннан торып:

— Бу кем булыр икән? — дип, бохар чапаны кигән, башына чалма чорнаган, кулында таяк, аягында читек-кәвеш булган хәзрәтне күз алдына китереп бастырды...

Парадный ишек зыңгылдап ачылды. Ләкин аннан: «Ишекне бикләргә онытма! Жулик бик күбәйгән ди, ишеттеңме... Жуликлар бик күбәйгән ди... Газизәне уятма, йокласын. Ул болай да кичәге танца вечереннан сәгать дүрттә генә кайтты», — дип, куян тизлеге белән шыгырт-шыгырт килеп чыгып та китте.

...Шулай итеп, соңгы өмет тә җимерелде. Муллага, түрәләргә текәлгән соңгы ышаныч та җыерчыклы бит буйлап тәгәрәүче ачы күз яшьләре белән бергә йотылды...

*1926*

# КҮКРӘГЕНДӘ ШИГЪРИ САГЫШ

РӨСТӘМ МИНГАЛИМГӘ 75 ЯШЬ

Үзе белән таныш каләм иясен иҗаты, каһарманнары белән чагыштыру, янәшә кую, алар арасында рухи якынлык, охшашлык яисә аерма эзләү табигый алым дип саныйм. Чөнки һәр олы сүз остасы чорны, аның мең калыплы проблемаларын сурәтләүгә, бәягә үз дөньясы, менәзе, холкы, уй-кичерешләре аша килә. Һәр әдәби әсәр артында борчылу-сөенечләре, өмет-хыяллары белән иҗатчы шәхесе



тора. Димәк ки, халык күнелендә урын алуга дәгъва иткән иҗат фантазия, йөгәнсез хыял җимеше генә булмыйча, авторның йөрәк җылысын, акыл җегәрен, көчен, иманын, ышанычын үзенә сендерә икән. Бу фикерләр Татарстанның халык шагыйре, Тукай бүләге иясе шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалим иҗаты турында уйланганда килде. Татар поэзиясендә хасил булган, безнең көннәрдә дә дәвам иткән сыйфат үзгәрешен иҗатка алтмышынчы елларда язгы ташкын шикелле чәчрәп торган көч-дәрт белән килеп кергән буын белән бәйлиләр. Озак еллар дәвамында тәнкыйтьтә биш исем гел бергә йөрде: Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Г.Рәхим, Р.Гаташ. Чынында башлангыч чор эзләнүләрендә аларны якынлаштырган үзенчәлекләр шактый иде: остазларга, мираска янача мөнәсәбәт, эзләнүләр киңлеге, фикерне кыска мәйданда әйтүгә омтылыш, метафорага, җегәрле сүзгә өстенлек бирү... Бишесе дә иң югары әдәби дәрәҗәләргә ирешкән шагыйрьләрнең иҗатлары арасында охшашлыкка караганда аерманың саллырак булуын күреп, сөенеп куям. Хикмәт һәр җитлеккән шигъри әсәрнең нигезендә индивидуальлек ятуда гына түгел, ә талантның әдәбият тарихында һәр сүзе, җөмләсе, тын алуы белән үзе булып калуында. Башкортстанда туып-үскән Р.Гаташ, Р.Мингалим кебек туган төбәгенә мөрәҗәгать итеп, «Сорама, Камышлы», дип мөрәҗәгать итә алмаган шикелле, югары иҗтимагый урыннар биләгән, депутат статусларында йөргән Р.Фәйзуллин, Р.Харис юбиляр кальбеннән төшкән мондый юлларны яза, каләмнәреннән төшсә дә бастыра алмыйлар:

*Ышанмагыз Русиянең*
*— Яратам! — дигәненә.*
*Ярата белми*
*Русия ул –*
*Көчли генә белә.*
(«Табут хәтле алтын»)

Табигый сәләтләре ныгыган, көч вә куәт ала барган саен, «60 нчы еллар егетләре» арасындагы аерма ачыграк төсмерләнә барды, татар шигъриятенә яңа темалар,

аһәннәр, бизәлеш моннары өстәлә торды. Һәркайсының шигъри йөзе, кабатланмас үзенчәлекләре чагылган шигырьләрен, Р.Фәйзуллинның «Сәйдәш»ен, Р.Харисның «Рәссам»ын, Р.Мингалимнең «Ике авыл арасы»н яисә «Иртәгә»сен укыганда, шәхси яңачалыгы түгел, ә эчтәлекнең юнәлеше, фикер җегәрен ача белү, психологик киеренкелек, чорның катлаулы мәсьәләләрен, иҗат кешесе образын лирика чаралары белән җанландыра алу, сурәтләү ысуллары үзенә тарта.

Рөстәм Мингалим араларында яше белән иң өлкәне, тормыш-яшәеш мәктәбен узу микъдарыннан иң тәҗрибәлесе иде. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә килгәнче ул Бөгелмә авыл хуҗалыгы училищесын тәмамларга, Казакъстанның Күкчәтау өлкәсендә тракторчы вазифасында чирәм җирләрне сөрергә, берничә ел «ипиле як» — Ташкент заводларында слесарь, станоклар көйләүче, янә Бөгелмәсенә кайтып, йөк ташучы, нефтьчеләрдә электр җиһазларын көйләүче булып эшләргә өлгерә. «Эзләр» исемле беренче җыентыгы университетны тәмамлаган 1967 елда китап укучыга ирешә, шагыйрьне хуплап Роберт Әхмәтҗанов, Р.Харис дәртле рецензияләре белән чыгалар.

Берничә елдан соң ул Сибгат Хәкимнең игътибарына һәм хуплавына лаек була, ягъни олуг шагыйрьнең фатихасын ала («Әнвәр Давыдов эзе буйлап», 1971). Р.Фәйзуллин, Ш.Маннапов, Р.Миннуллин, А.Хәлим кебек таләпчән каләмдәшләре гаҗәпләнү һәм сөенү хисләре белән уртаклашырга ашыгалар, Р.Мингалимне яңа чор эзләнүләр буразнасын ерып баручыларның берсе итеп таныйлар.

Р.Мингалим иҗаты гражданлык пафосы, дөньяга тәнкыйди карашы, масштаблы фикерләве, бай сурәтлелек чаралары һәм сүзгә игътибарлы булуы белән үзенә җәлеп итә. Аның иҗат диапазоны шактый киң. Ул табигать матурлыгы белән тәэсирләнә («Сары көз», «Быелгы кыш»), гомернең аккан сулардай тиз узуы өчен сыктана («Китәселәр»), Казанга мәдхия җырлаганнан соң («Без җырлаган көйләр»), аның татарча сөйләшә торган шәһәр булып китә алмавы өчен гарьләнә («Җизле йөгән, җирән атың») һәм, әлбәттә, нәрсә турында язса да үзәктә татар халкының ачы язмышы, өстендә кара болыт шәүләсе асылынып торган ана телебезнең киләчәге борчый. «Елаучылар» («Буйсындырылган илләр-халыклар хәленә бер караш») исемле тирән фәлсәфи эчтәлекле шигырендә, чынлыкта барлык буйсындырылган халыклар язмышын Дәрдемәнд иҗатында яңгыраган символлар аша чагылдыра. Кол халыкларның күз яшеннән океан туган, шул океанга хәсрәт төяп кораб килгән:

*Кораб килгән кәрван-кәрван кайгы төяп,*
*чын кайгыны елаучылар шунда күргән:*
*тавышлары, тормышлары, тарихлары –*
*су өстендә чүп шикелле йөзеп йөргән.*

Шул ук вакытта лирик зат төшенкелеккә бирелми, бүген кимсетелгән, изелгән, сытылган милләтнең яшәешенә киләчәккә дәшеп олы үткәне дәртләндереп тора. Р.Мингалим — метафорага, пластик детальгә өстенлек бирүче шагыйрь. Иркен, иркәле форманы үстерә. Сәләтенең әлеге үзенчәлеге «Иртәгә», «Минем дәүләт», «Күк астында» кебек поэмаларында, «Еракларда», «Хәзер», «Сиңа нәрсә җитмәгән», «Җыр язып, ул көй чыгарган», «Кешелек белән сөйләшү» һ. б. шигырьләрендә ачык күренә. Вакыты белән шигырь прозага барып тоташа, тезмә белән чәчмә арасында чик югала.

Р.Мингалим шигырьләрендә фикер, җегәрле деталь, рационалистик башлангыч өстенлек итә дигән идек. «Булма», «Иллә мәгәр», «Сабыйлар күлә», «Җинаять», элегрәк язылган «Гел» шигырендә Акмуллалардан килгән хикмәтле сүз, яхшы мәгънәсендәге дидактик фикерләү традицияләре үстерелә.

*Шагыйрь булсаң,*
*Ике төрле фәлсәфәгә*
*Уртак булма.*
. . .

*Шигырьләрдә*
*Бабай булсаң,*
*Бул син әйдә, –*
*Малай булма.*
(«Булма»).

Кискен фикергә, төгәл бәяләмәгә, афористик төгәллеккә өстенлек бирү, проза алымнарын куллану Р.Мингалим шигырьләренә лиризм, шәхес хисләрен чагылдыру осталыгы җитми икән дигән нәтиҗә ясауга этәрми. «Сорыйлар», «Әнкәйне хәтерләү», «Сорама, Камышлы», «Тумый калган балага» шигырьләрендә моң, сагыш, кичерешне үсештә тасвирлау үзенә җәлеп итеп тора. Катлаулы фәлсәфи юнәлешле «Шигъри сагыш» (1967) хис-тойгының фикергә үрелеп үсүенә мисал була ала.

Бөтен иҗат дәвере буенча Р.Мингалимне озата баручы, хәтта ээзәрлекләүче мотивларның берсе, бәлки, иң мөһимедер — сагыну мотивы. «Яна-яна киткән торналар» (1969) «Сабырлык алам хәзер» (1973) кебек шигырьләренең үзәгендә яткан «Сагынмый килдемме? Сагынып килдемме?» — сораулары үзәк өзгеч сентименталь мәгънә алып үстереләләр. Лирик каһарман өчен сагыну-сагышның иң югары үре шигъри сагыш дигән идек. Нерв үзәген тәшкил иткән, үткән белән хәзерге, яшәү белән үлем арасында торган «сагыш» ул шагыйрь үзе икән — «Мин тик еллар күкрәгендә / Яралган шигъри сагыш». («Шигъри сагыш»).

Кеше рухы кинлекләре, тормыш муллыгы турында уйлану-борчылу, сөенү нәтиҗәсе буларак туган «Беләм», «Җинаять», «Ялгыз карчык», «Укытучыларыма», «Ни күрсәң дә» кебек шигырьләрдә сурәтле фикерләү индивидуальлеге ачык сизелә. «Ялгыз карчык»та тормыш фаҗигасенә, кеше язмышына төшкән авырлыкны йөрәге аша уздыра белү әсәрнең ышандыру көчен арттыра:

*Ире дә югалган аның,*
*Уллары да югалган.*
*Аларны эзләр өчен тик*
*Зур-зур күзләре калган.*
*Һәм бара ул эзләгәнен*
*Таба алмасын белеп.*
*Бара ул инде яңадан*
*Тураймаска бөгелеп.*

Табигый интонация, лирик гомумиләштерү алымы — Р.Мингалим өчен тормыш катлаулылыгын, кеше хисләре тирәнлекләрен сурәтләү юлында иң ышанычлы алым. Р.Мингалим иҗатының буеннан-буена үстерелә килгән, лирикасыннан сәхнә әсәрләренә күчкән үзәк мотивларның берсе — хакыйкать эзләү. Бу юнәлеш балаларга атап язылган «Әй, кояшым» (1966), «Ә сәгать келт-келт итә» (1967) һәм «Эзләр» (1968) мәҗмугалары басылып чыкканчы ук язылган, үзенә җан биргән, кендек каны тамган җир белән кеше гомеренең яме, хикмәте, яшәү белән үлем арасындагы чик турындагы бәхәскә корылган «Җиргә бер сүз» шигыреннән үк оеткы ала:

*Каберлекләр белән кадер-хөрмәт*
*Арасында эшем бар әле.*
*Ике аралыкта торасың дип*
*Син көләргә миннән кыйма Җир.*

Хакыйкатькә омтылу юлында «соңгы тукталышны» табып булмавын аңлаган хәлендә дә, аның лирик каһарманы мотлак дөреслекне эзләвен дәвам итә.

*Бардыр чын йөзе тормышның,*
*Тик мин аны күрмәдем.*

*Аның йөзе минем алда*
*Һаман торды үзгәреп.*
(«Бардыр»)

«Кешелек белән сөйләшү» (1968), «Кешелек өлгергән чакта» (1973), «Тормыш чаба» (1991-1997) кебек әсәрләрендә лирик зат дөньяның барышы турында уйлана, бәхәсләшә, иҗтимагый явызлыктан котылу юлларын эзли. «Бөтен бәхетлене...бөтен бәхетсезне» үз иткән, сөйгән зат җиһан хәсрәтләрен йөрәгә аша уздыра, дан өчен сугыш ачып, күпме гомерләрне өзгән кабихларны хурлык тактасына кадаклый. Р.Мингалимнең лирик герое еш кына үз-үзе, шигырьләре белән бәхәсләшә, җан азыгы булырдай затлы сүзнең кеше язмышындагы, рухи дөньясындагы урыны турында уйлана:

*Йөрәгемне өлеш-өлеш*
*Сезгә бирмәдемме мин?*
*Ярсу җаным җылысына*
*Сезне төрмәдемме мин?*

— диюенә, үҗәт шигырьнең дә «җавабы» әзер: «Дәрәҗә бирдек». Фани дөньяда алынган мактаулы исемнәрнең кыйммәтен автор үзенчә бәяли: «беләм ачы дөреслекне — исем гомер түгелен» («Шигырьләрем белән сөйләшү»).

Тормыш-яшәешнең кадерен белү, аларга шундый ихтирам, күрәсең, тиләлек күренешләренә, нисби детальләргә игътибарны көчәйткән, үстергән. Без инде күнеккән, көндәлектә игътибар да итмәгән төшенчәләрне шагыйрь әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрә. Әйтик, «җанлы» төсмерләре, җемелдәвек сурәт борылышлары белән «җил» һәм «вакыт», татар шигъриятенең гасырлар түрендә туып, хәзерге поэзиядә дә киң кулланылган образлар Р.Мингалим иҗатында күп төрле функцияләрне «өсләренә» ала. «Русия киңлегендә» (2000) җилне ул очы күренмәгән «мәңгелек уй» һәм «җан» дип атый да, җилләрне уйларын уртаклашырга үз янына чакыра. «Туфрактан түгел бугай без, җилләрдән яралганбыз» дигән бәхәсле дискурсын калкытып куюы да, лирик каһарманга Русия киңлекләрендә яшәүче кавемнәргә бәя бирү өчен кирәк икән: «Урысча сибелгәнбез дә, татарча таралганбыз».

Әнисенә һәм үзенә багышланган «Үтәли җил» шигырендә җил — ялгызлык символы. Җил образына мөрәҗәгать итеп, аны таңгача сөйләшеп утыруга чакыру кеше гомерендә була торган иң фаҗигаи мизгелне искә төшерү, күңел кылларына чиертеп алу өчен кирәк икән.

Фикерен символлар, кабатлана килгән ачкыч сүзләр ярдәмендә калкытып куйган әсәрләрендә Р.Мингалимнең шагыйрь буларак аерылып торган үз йөзе, үз өслүбе тулы ачыла. Бер яктан , ул кичерешне, хисне фикер эчендә «яшерә», бу алым тормыш трагизмын тулырак чагылдырырга мөмкинлек бирә, икенче тарафтан, аның өслүбе җыр, артык спай ритм калыбына сыймый... Драма алымнары, проза казанышлары юлларны бүлгәләүне, тыныш билгеләрен күбрәк куллануны укучының зиһен эшчәнлеген уятуга юнәлтүне таләп итә. Шул сыйфатлары белән генә дә Р.Мингалим өслүбен башкалар белән бутавы кыен. Шагыйрь олы дөнья проблемаларын йөрәгә аша уздыра, алар турында үзенчә һәм масштаблы итеп яза белә. Бу яктан «Җинаять», «Сабыйлар көләләр» шигырьләре, «Иртәгә» поэмасы игътибарга лаек. «Нәкъ унбиш ел», «Уздылар», «Борчулы минутта» шигырьләренең үзәгендә экзистенциаль сагыш, үткәнгә фәлсәфи караш, гомернең кадерен белүгә чакыру ята.

Р.Мингалим шигъриятен берничә сүз белән генә аңлатуы кыен. Аның поэзиясе шактый катлаулы, сыгылмалы, самими. Ул — риторикага, ясалма куппылыкка каршы, публицистик шигырьләр язуны да кулай күрми, аның ритмикасы җыр өчен дә артык килешеп тормый, Р.Мингалим шигырьне, тормышның үзе шикелле, табигый яшәтергә омтыла. Бизәкләрне сайлап, нечкә иләк аша уздырып, эчтәлек агышына буйсындыра белә. Башка шагыйрьләрдән кайсы ягы белән аерылып тора дип сорасалар, әйтелгәннәргә өстәп, фикерләү, дөньяны күрү үзенчәлегенә хас контрастлылык, кылану дәрәҗәсенә барып җиткән төрле яссылыкларда яткан

төшенчәләрне капма-каршы кую, дияр идем. Безнең чорда фән һәм техника тормышның барлык өлкәләренә, шул исәптән шигъри фикерләүгә, сурәтлелек алымнарына тирән үтеп керә, интеллектуаль башлангычны, динамизмны көчәйтә. Чор кешесенең эшенә, фикерләү рәвешенә якынлык — заманга якынлык, шуның бер чагылышы дигән сүз.

Тормышта һәр көнне, һәр сәгатьтә туа килгән яналыклардан курыкмыйча, заман рухы, чор сулышы белән яшәгән шагыйрь туктаусыз яңа төшенчәләр һәм яңа мохитлар белән таныша һәм бу танышлык күп очракта шәхесне сурәтләү чараларын яңартуны, камилләштерүне сорый, төрле өслүб юнәлешләре арасында торгызылган ясалма киртәләрне алып ташлый. Кешенең рухын, тирән кичерешләрен, «җан диалектикасын», фикер хәрәкәтен ачу максаты белән язылган шигырьләрдә төрле яссылыкта яткан әйберләр үзара аралашалар, кушылалар. Мәсәлән, нефтьчеләр, химиклар, машина ясаучылар тормышына, шәһәр ритмын сурәтләүгә багышланган шигырьләрдә «сандугач моңы», «каеннар рәте», «чишмә сафлыгы» кебек образлар бик табигый яңгыраса, авыл тормышын, игенче хезмәтен олылап язылган шигырь, поэмаларга, җырларга галәм, дөнья хәлләре турында фәлсәфи, публицистик уйланулар килеп керә. Бу сыйфат Р.Мингалимнең Чаллы шәһәрен төзүчеләргә багышланган «Күз карасы» поэмасында, «Казан аэропортында», «Минем яшьлек», «Нәкъ унбиш ел үткәч», «Шпаллар», «Килә тезелеп машиналар» кебек шигырьләрендә ачык күренә. Шулай да Р.Мингалимне урбанистик поэзия тарафдары итеп бәяләү дөрес булмас иде. Ул язарына азыкны хәзерге чынбарлыктан чумырып алса да, төп игътибарын лиризм, моң ярдәмендә кеше кичерешләрен ачуга юнәлтә. Бу сыйфаты аның поэмаларына да хас: «Иртәгә», «Минем дәүләт», «Күз карасы», «Күк астында». Аларда шагыйрьнең лирикасында алып барган эзләнүләренә нәтиҗә, йомгак ясала. Поэмалар арасында мәгълүм уртаклык бар: бу — лиризмның көчәюе, сурәтле фикерләүнең катлаулануы, күләмнең кыскаруы. Шуның өстенә авторның үз шәхесе белән тыгыз бәйләнгән лирик герой үзәк фигура булып бара, шигъри деталь гомумиләштерүгә юл ача.

Р.Мингалим «шигырь һәм шагыйрь» проблемасы хакында күп яза: «Булма», «Шигырьләрем белән сөйләшү», «Яшь шагыйрьгә», «Карт шагыйрьгә».

*Үзем теләп алдым шундый һөнәр,*
*Хәзер, дәрвиш кебек, көн-төн барам;*
*«Шигырь генә миндә, кемгә кирәк?*
*«Шигырь бирәм!» — диеп хәбәр салам.*
(«Шигырь генә»)

Р.Мингалим остазлары Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан, С.Хәким, Ә.Давыдов алдында баш ия, аларга шигъри һәйкәл куя. «Язучы һәм тормыш» темасына язылган әсәрләре арасында әдәбиятта тирән эз калдырып арабыздан киткән шәхесләргә багышламалары аерым урын тота («Шагыйрь Илдар Юзеевка», «Калуыбыз кирәк булса да»). «Өзелеп яратсак та дусларны, Берәм-берәм жирдән китәрбез...», — ди ул Хәсән Сарьянга багышланган «Калуыбыз кирәк булса да» әсәрендә. Араларында якташы, остазы — Әнвәр Давыдовка багышланган «Сорама, Камышлы» (1968) иң унышлысы саналырга лаеклы. Тирән сагыш, көенү авазы, хатирәләр, шигъри моң Ә.Давыдовны элек белмәгән укучыны да битараф калдыра алмас. «Матбугат йортына сыймыйча тавышы жиргә жәелә иде», уе бик зур иде. Кешеләргә таба һаман килде һәм көтмәгәндә-уйламаганда шундый шәхес «Кинәт гаип булды». Ә.Давыдов кебек дөнья, халык турында уйлап, яшендәй яшьнәгән кеше юкка чыга алмый. Метафорик аллегория исемне мәңгеләштерә: «ул югалды безнең / күңелләргә кереп».

Бөтен иҗади гомере дәвамында мөкиббән китеп, җае чыккан саен хөрмәтен сиздереп яшәгән остазы — Тукай. Турыдан-туры аңа багышланып язылган шигырьләре күп булмаса да, әдәби мохит әгъзаларына бәя биргәндә, рухи дөнья катлаулыкларын сурәтләгәндә ассоциатив фикерләү үзәгенә Тукай таяныч ноктасы, кинәшче, арадашчы буларак килеп керә. Өлкәннәрнең рухын олылауны, буыннар

алышынуын экзистенциаль сагыш дәрәҗәсенә күтәргән «Сагыну» (1983) шигыре Р.Мингалим иҗатында аерым урын били.

*... Үзәкләр өзелә тора,*
*Кемнедер сагындыра.*
*Сагындыра Тукайларың,*
*Җәлилләр истә тора.*

Шигырьнең кичереш дәрәҗәсен билгеләүче «сагыну дәрьясы» бөтен татар шигъриятен, аның талантлы вәкилләрен, якташларын тәсбих төймәләредәй бер җанлы җепкә тезүче үзәк дәрәҗәсенә күтәрелә. Сагыну хисенең чишмә башы — Хәтер. Шуңа да, күбесен үзе күрмәсә дә, иҗатлары буенча якты, кадерле шәхесләрне сагыну төрле буын сүз осталарын якынлаштыручы символ дәрәҗәсенә күтәрелә.

Р.Мингалимнәр буыны фәлсәфи лириканы үстерүгә, тарих-заман-вакыт кебек төшенчәләрнең эчтәлегенә, фәлсәфи мәгънәсенә үтеп керүгә зур көч куя. Р.Фәйзуллин, Р.Харис иҗатларында да бу төр мисаллар тулып ята. Р.Мингалимнең бу мәсьәләләргә үз карашы бар. «Сез» шигырендә ул кеше язмышы турында уйлануын кинрәк җирлеккә күчерә: кеше чакрымнар, вакыт һәм буыннар аша атлый.

Р.Мингалим иҗатының үзенчәлекле төре — мәхәббәт хисенә, мәхәббәт чыганагы — «дәрт чүлмәкләре» — хатын-кызга багышланган шигырьләре. Бу темада да шагыйрь үзгәрә, үсә, татлы агудай кичерешне, изге хатирәләрне сурәтләүнең яңа юлларын барлауны дәвам итә. «Иделдә», «Өч урында» шигырьләрендә мәхәббәт сөенечен чагылдыруның нигезендә — үзенә һәм сөйгәненә, мәхәббәт сагышына ироник мөнәсәбәт ята. Шул төр шигырьләрне эченә алган бүлек «Яратам әллә ничек» дип атала. Аның интим лирикасы тормыш драматизмына сизгерлеге, кеше кичерешенә нисбәтән нәзакәтлелеге, олы күңеллелеге белән аерылып тора. Лирик геройның тойгылары кешене күтәрә, сафландыра: тормыш мәшәкатьләрендә, дөнья ваклыкларында югалып калмаска, дөреслеккә, ахыр хаклыкка таянырга, кеше кичерешләренең муллыгына ышанырга өйрәтә.

*Су сипсәм дә, ялкын үсте,*
*Үсте гел кызыл чәчәк.*
*Синең юллар минем янга*
*Киләчәк ул, киләчәк.*
(«Кызыл чәчәк».)

Чынбарлыкны хисси кабул итү, һәр вакыйга-күренешнең эчке мәгънәсен ачу сәләтенә ия булган, үз шигъри интонациясен, кабатланмас өслүбен тапкан шагыйрь буларак танылгач, 1970 елларның икенче яртысында Р.Мингалим драматургиягә мөрәҗәгать итә. Балаларны могҗизалы дөнья белән таныштыру аша фикерләү дәрәҗәләрен баеткан, уйларга, кичерергә өйрәткән «Урман улы Зурмөгез» (1975), «Сихерләнгән урман» (1981), «Шүрәлеләр үч алмый» (1982), «Сәер кешеләр, батыр малай һәм артист попугай» (1988) әкият-пьесалары курчак театрында зур уңыш белән куела. «Сихерләнгән урман» әсәре Мәскәүнең Үзәк Курчак театры репертуарына да керә. Халык иҗаты мотивларына таянып язылган, яисә яшәешнең, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы, четерекле якларын үзенчә яңгырата, яңача күреп иҗат ителгән пьесалары балалар күңелендә үз урынын ала. Р.Мингалим яшь буынның рухи дөньясына да юл таба. Табигать күренешләрен, хайваннар тормышын мөлаем юмор, шуклык, шаянлык, фикер һәм сүз уйнату аша автор яшь дусларын олы дөньяны танырга, аңларга өйрәтә, аларга тормыш-көнитеш, әхлак кагыйдәләрен сеңдерә.

Драматургия җанры белгечләре А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров кебек галимнәр Р.Мингалимнең олылар тормышын, психологиясен яңача сурәтләгән «Мин сине шундый сагындым» (1978), «Кире уйларга соң инде» (1978), «Тау астында илле бүре» (1979), «Өченче бүлмәдә эт яши» (1980), «Кунак кызы гел килмәс»(1984), «Әгәр булса борчуларын» (1986), «Сабый туды» (1988) исемле комедия һәм

драмаларының заманча эчтәлекләре, фәлсәфи тирәнлекләре, татар драматургиясенең реалистик көчен модернистик алымнар белән тулыландырып, кеше зиһененең тирән катламнарына үтеп керү, үз-үзенә ироник бәя бирү алымнарын киң куллану (исемнәре үк шуңа киная ясый) аша драма сәнгатебезнең офыгын киңәйтүен билгеләп үтәләр.

Р.Мингалимнең иҗади дөньясы тормышның үзе кебек бай, шәхес кичерешләре кебек катлаулы. Ул үзенең хыял-уйларын, йөрәк серләрен, әхлакый нәтиҗәләрен тиз генә, гади генә ачып сала торган шагыйрь түгел. Чөнки бу шигъри дөнья күп еллар буена аерым сүзләр, образлар, җөмләләр ярдәмендә төзелгән. Ә алар артында еллар чалымы һәм реаль шәхес тора. Бу шәхеснең рухи дөньясын аңлауга шактый кыйммәт бәя — чирек гасырдан артык вакыт түләнгән. Иң шатлыклысы шул: Р.Мингалим поэзиясе, драматургиясе бу олы хакка, бәягә лаеклы. Еллар заяга үтмәгән. Халык күңеленә үтү юлларын эзләүгә багышланган.

***

Дөнья мәшәкатьләре, милләт гаме, теленең киләчәге өчен борчылып яшәгән олуг әдибебез Рөстәм Мингалим инде дистә елдан артык җанлы әдәби процесста катнашудан мәхрүм, яңа гасыр ел йомгакларында, корылтайларда аның һәрдаим дөреслек яклап яңгыраган тавышы ишетелми. Аралашуны, дуслар эчендә кайнауны, авылларга чыгып йөрүне яраткан шагыйрьнең олы җанлы ярдәмчесе, киңәшчесе, ак канаты, пар канаты, сөекле Илүсәсе («Яратам әллә ничек») генә һәрдаим янында. Исән чакта (Тукайча, акча барда) дус-ишләр, мәҗлестәшләр күп булса да, актив тормыштан читләшергә мәҗбүр ителгән кеше акрынлап ялгызлыкка дучар була шул. Тормыш мантыйгы шундый, берәүне дә гаепләп булмый.

Инсульт дип аталган иң явыз чиргә юлыккан, аягын кистерү кебек тәмуг газапларын кичергән Рөстәм, һәммәбезнең гөнаһларын ярлыкый-ярлыкый, шигырьләр дә язгалый, «кытыклары»н да бастыра. Нәрсә яшәтә соң адәм баласын? Якын кешесенең йөрәк җылысы белән бергә аны фани дөньяда тотып торган көч — иҗатка мәхәббәт һәм үз халәтенә ирония белән карый белүе, дип фаразлыйм.

Шагыйрь, драматург Р.Мингалим татар халкына хас үҗәтлек , сынмас-сыгылмас рух бөеклеге, физик батырлык, язмыш сынауларына баш бирмәү үрнәкләре күрсәтеп, ялгызлык касәфәтен җиңеп, 75 еллык гомер бәйрәмен арабызда уздыра.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

**Редакциядән.**

*Каләмдәшебез, халык шагыйре, драматург, Г.Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Мингалимне гомер бәйрәме белән ихластан тәбрик итәбез, күңел тынычлыгы, иҗат шатлыгы теләп калабыз.*

# ТАЛӘПЧӘН ТӘНКЫЙТЬЧЕ

Хәзерге татар әдәби процессында барган үзгәрешләр, аның үсеш үзенчәлекләре турында сүз барганда күпләр әдәбият галиме, тәнкыйтьче, педагог Рифат Сверигин исемен телгә ала. Бу аңлашыла да, чөнки сүз сәнгатебезнең асыл сыйфат-үзенчәлекләрен ачып-аңлатып, төп тенденцияләрен, аннан да бигрәк киләчәк перспективаларын, аерым әдипләр иҗатындагы табыш-яңалыкларны үз вакытында тоемлап, күреп алып укучыларга житкерүчеләр күп түгел. Рифат абый Сверигин — шуларның берсе булып, үзенең акылы, әдәбиятны гаять тирән аңлау сәләте, объективлыгы һәм принципиальлеге белән хөрмәт казанган шәхес. Менә ул үзенең бөтен аңлы гомер юлы аша килә.

Рифат Хәсән улы Сверигин 1932 елның 1 августында Татарстанның Байлар Сабасы авылында туып-үсә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Берничә ел укытучы, мәктәп директоры булып эшли. Фән-гыйлем дөньясына омтылыш аны Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына алып килә. Монда аспирантура тәмамлый, байтак еллар фәнни хезмәткәр булып эшли. 1972 елдан ул Казан дәүләт педагогика институтында: өлкән укытучыдан профессор дәрәҗәсенә кадәр хезмәт юлы үтә, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче буларак танылу ала.

Әдәбият белеме дигән фәнгә Р.Сверигин якташы Фатих Хөсни иҗатын тикшерү аша килә. 1968 елны дөнья күргән «Фатих Хөсни» дигән китабы бүген дә фәнни-теоретик кыйммәтен югалтмаган житди хезмәт булып тора. Ф.Хөсни 1950-60 елларда шактый киң танылу алса да, аның иҗат серләрен өйрәнү мәсьәләсе читтәрәк калып килә. Р.Сверигин әлеге фәнни эшкә алынып, Ф.Хөснинең иҗат кинлеген, әсәрләрендә тудырылган әдәби дөнья серләрен, димәк ки, иҗат стилен, аны әдип итеп таныткан сыйфат-үзенчәлекләрен ачуга килә. Тәнкыйтьче әдипне психологизм остасы буларак ача. Беренчеләрдән булып Ф.Хөсни әсәрләрендә үзгә бер аһәң, лиризм, табигыйлек, юмор булуына басым ясый. Иҗатында милли яшәеш торгызылу, халыкчан тел, детальләр байлыгы, метафорик тәсмерләр һәм аеруча яшәеш максатлары, теләк-омтылышлары, каршылыклы характерлары белән сурәтләнгән образлар — барысы да аны проза остасы итеп таныта дигән нәтиҗәгә килә.

Алдагы елларда Р.Сверигин замандаш әдипләрнең иҗат портретларын тудыру эшенә алына. Ә.Еники, Г.Бәширов, А.Расих, Р.Төхфәтуллин, А.Гыйләжев һ.б. күренекле прозаикларга багышланган мәкалә-язмаларында XX гасырның икенче яртысы татар әдәбияты турында тулы бер күзаллау булдырыла. Галим-тәнкыйтьче төп игътибарын әдәбиятның тормыш-чынбарлык белән бәйләнешенә, авторларның иҗат лабораториясенә, тел-стиль табышларына, киң планда сәнгати сурәтләү үзенчәлекләрен ачуга юнәлтә. Әлеге эзләнүләр нәтиҗәсе буларак «Яңа герой һәм яңа алымнар» (1985) җыентыгы һәм Ф.Хатипов белән берлектә язылган «Әмирхан Еники» (2009) монографиясе дөнья күрә.

Әдәби җәмәгатьчелек Р.Сверигинны хәзерге татар прозасын системалы тикшереп-өйрәнеп килүчеләрнең берсе дип таный. Аның мәкаләләре тирән эчтәлеге, сүз сәнгатенең эчке хасиятләрен белеп, аңлап язылулары, фикер ачыклыгы, объективлык, нәтиҗәләренең дәлилле булуы белән игътибарга лаек. XX гасыр ахырында язылган «Туксанынчы еллар әдәбияты» (1999) мәкаләсендә ул чор әдәбиятының йөзен билгеләүче берничә әдип иҗатына хас сыйфатларны билгели. Берсе — Ф.Яруллин

— «һәрвакыт үзе булып — халык, милләт, җәмгыятебезне борчыган, заман, тормыш проблемаларын йөрәге аша үткәрүче, кичерүче һәм сынмас, буйсынмас рухлы олы шәхес»; икенчесе - М.Юныс — «хөр фикерле, югары хәзерлекле, кыю, гадел һәм дөреслекне яклаучы гали зат»; өченчесе - Ә.Баянов - «проза, лирика, драма күренешләренең үзенчәлекле үзара үрелеше, прозасындагы мәгънәле шигърият, әдәби детальләр һәм символларның функцияләре, юмор бизәкләре» белән аерылып торучы әдип. Галимнең «Нурзилә новеллалары...», Ф.Яруллинга 65 яшь тулу уңае белән язылган «Аны беләбезме?» мәкаләләре, үзе таләп иткәнчә, «әсәрләргә эстетик җәһәттән якынлашып, алардагы сәнгатьчә гүзәллекне бәяләү, образлы фикерләрне авторның әдәби осталыгы, кулланган стиль-сурәтләү чаралары белән, тормыш күренешләрен үзенчә художестволы итеп яктырту осталыгы белән бәйләнештә аңлату» рухында язылган. Аерым әдипкә, әдәби чорга, еллык күзәтүләргә бәйле хезмәтләрендә без зәвыклы укучыны, таләпчән тәнкыйтьчене күрәбез. «Үткән ел прозасына бер караш», «Гасырлар чатында», «Яңа замана, яңа геройлар» язмаларында тәнкыйтьче әсәрләргә бер-ике җөмлә белән, әмма күп сыйдырышлы бәя бирә, кирәк урында итагатьле генә саллы сүзен дә әйтә. Аның өчен авторитет-дәрәҗәләрдән бигрәк сәнгать әсәренең эчке хасиятен ачу кыйммәтрәк. Бәя бирү критерийлары итеп мавыктыргыч булуны, образлылыкны, фикер тирәнлеген ала һәм тәнкыйтьнең бурычларын да эстетик кыйммәтләрне ачыклауда күрә.

XX гасыр ахыры — XXI гасыр башы Р.Сверигин өчен иҗтимагый формацияләр һәм гасырлар алышыну чоры гына түгел, бәлки 60-90 нчы еллар прозасының йөзен билгеләгән, аның горурлыгы булган Г.Бәширов, Ә.Еники, Ф.Хөсни, А.Расих, М.Мәһдиев, Г.Ахуновларның мәңгелеккә күчүе белән тулы бер дәвер тәмамланган вакыт буларак та әһәмиятле. Тәнкыйтьче совет чорында прозабызның милли йөзен шактый югалтуын, үзгәртеп корулар дип аталган болгавыр заманда кайбер яуланган позицияләрдән чигенүен дә таный. Әнә шулар яссылыгында ул соңгы еллар әдәбиятындагы төп тенденцияләрне барлый. В.Имамов, С.Шәмси, А.Хәлим, Ф.Бәйрәмова, В.Нуруллин, Ф.Садриев, Н.Гыйматдинова һ.б. хикәя-повесть-романнарын зәвыклы тәнкыйтьче, таләпчән укучы буларак тикшерә. Ул әдипләрнен чор-заман проблемаларын оста тоюларын, яңалыкка омтылуларын тотып ала.»Соңгы берничә елда татар прозасының аеруча кыйммәтле ачышлары милләт җанлыларның аңнарын-күңелләрен кузгатырдай, күптәннән борчылса да, һаман да әйтелә алмаган уй-мәсьәләләрне үткәннәр һәм бүгенге көн сулышы белән кушып, аралаштырып яктырту юнәлешендә булды», — дип яза. Соңгы елларның бер үзенчәлеге итеп үткән тарихка игътибар артуны һәм, иң мөһиме, әдипләрнең эзләнүләре тарих сәхифәләрен дөресрәк, объективрак яктырту һәм аларны әдәби-сәнгати үзләштерү юнәлешендә тирәнәя баруны саный. Ә инде хәзерге прозада үзен борчыган мәсьәләләр буларак әсәрләрдә көчле рухлы заман геройларының аз булуын; җитди проблемаларны сәнгатьчә формага салуда әдәби осталык җитмәүне; үткән чорларны каралтып күрсәтү белән мавыгуны; штамплар кысасыннан, элеккеге әдәби алымнарның эчпошыргыч бертөрлелегеннән арына алмауны һ.б. күрсәтә.

Татарстан Язучылар берлегенең Җ.Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты Р.Сверигин, эстетик тәнкыйть тарафдары буларак, сәнгатьнең актив, тәэсирле көченә тирән ышану белән яза, шуңа язмаларын матурлыкның, яхшылыкның, дөреслекнең мәңгелек булуы идеясе иңләп үтә. Үзенең яшәеше, хезмәтләре, эш-гамәлләре белән әлеге кыйммәтләрне яклаган һәм саклаган, бу көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтүче галим-тәнкыйтьче Рифат абый Сверигинга саулык-сәламәтлек, җан тынычлыгы, иҗат шатлыгы теләп калабыз.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

# ХАКЫЙКАТЬ ЭЗЛӘП

Безнен әдип халкы һәм галим-голәмә купшы сүзләр кулланырга, арттырыбрак сөйләргә ярата. Башкаларның ижатларына, әсәрләренә бәя биргәндә дә шулай. Янәсе берсенең ижаты шаулы диңгезләргә тиң, икенчеләренең — тинсез дәрьяларга...

Ә менә язучы Нурислам Хәсәнов ижаты хакында сүз йөрткәндә, әлеге чагыштырулар, метафораларның һич кирәге юк. Киресенчә, бу очракта күз карашыңны ерак офыкларга, киң дәрьяларга ташламыйча, әйләнә-тирәнә, көн дә үтеп йөри торган сукмакларына төбәсәң, хәерлерәк булыр сыман. Бу әдип үз тирәлегеннән, яшәгән төбәгеннән, күргән-белгәннәреннән бик ерак китмәскә, аерылмаска тырыша. Әлбәттә, моның өчен шул табигый күренешләргә үтә дә җитди, тәфсилле караш та кирәк була. Китапларын укыганда иң әүвәл әнә шул ягымлы җитдилекне, һәр күренешкә сизгер игътибарлылыкны тоясың — аларга ияреп бу әдипнең ижат стихиясенә кереп киткәнеңне үзең белми дә каласың...

Кайчандыр әдәби әсәрләрнең асыл кыйммәте дип тормышчанлыкны, язганнарда тормыш дөреслегенең һәрвакыт урын алып торуын төп критерий дип саныйлар иде. Бүген исә әдипләрнең ижатларына бәя биргәндә бу факторны үзәккә куймый башладылар — яңа алымнар муллыгы, ассоциатив, метафорик сурәтләр белән эш итү осталыгы һ.б. алгы планга чыгып килә бу заманда.

Әлбәттә, боларның һәркайсы да үз урынында булганда, үз чамасын саклаганда, барысы да кирәк, аларны бер-берсенә капма-каршы куясы да түгел. Тик Н.Хәсәнов әсәрләрен — повестьларын, хикәяләрен, лирик парчаларын — укыганда нәкъ беренчесе — тормыш күренешләрен, бизәкләрен әдипнең булганынча, дөрес итеп сурәтләве күңелгә аеруча хуш килә. Н.Хәсәнов ижатының бу кыйммәтле ягы, чыннан да, тормышның үзеннән, шәхси биографиясеннән, белгән-кичергәннәреннән үк килә торгандыр.

Нурислам Габдулла улы Хәсәнов Теләче районындагы Шәтке авылында 1941 елның 1 мартында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Матур Мишә буйларының гүзәллеге яшьтән күңеленә нык уелып, эзләрен салган ахры — аннан шәһәргә китеп, гомере башка тарафларда үтсә дә, туган җире, туган яклары аның өчен изге һәм якын булып яши бирә. Бу бүген дә шулай — ул табигате, уй-фикерләре белән һаман да шул авыл кешесе, авыл малае булып калган, Шәткесеннән бүген дә аерылмый — кайткалап йөри. Авылы да үзе дөньяга фатиха биреп чыгарган улы белән горурлана ала.

Бәлки Н.Хәсәнов тормыш сукмакларын таптаганда реалист язучы булырмын мин дигән максатны үз алдына куймагандыр да. Әмма аның биографиясендә ул юллар, ул сукмаклар үтелмәгән булса, без, мөгаен, бүген аның ижат казанышларыннан мәхрүм калыр идек. Ул, бик яшьтән шәһәргә китеп, һөнәр училищесенә укырга керә, аннан зур завод казанында кайный — башта слесарь, аннан крановщик булып эшләп йөри, Совет армиясендә Казахстан якларында өч ел хезмәт итә. Читтән торып укып, техникумны, институтны тәмамлый, инженерлык хезмәтен үзләштерә. Соңрак бу олы тәҗрибә, күргән-белгәннәр, әлбәттә, әсәрләрендә әдәби сурәтләр, образлар буларак җанланачаклар.

Аның беренче әдәби язмалары — шигырьләре, нәсерләре, очерк-хикәяләре — узган гасырның алтмышынчы елларында ук күренә башлый. 1981-1991 елларда Н.Хәсәнов Татарстан радио-телевидение үзәгендә — редактор, инженер, аннары Татарстан Язучылар берлеге каршындагы Әдәбиятны пропагандалау бюросында әдәби хезмәткәр һәм озак еллар дәвамында «Теләче хәбәрләре» дигән төбәк газетасының баш мөхәррире вазифаларын башкара. Мондый олы тормыш һәм журналистлык тәҗрибәсе, ниһаять, сиксәненче елларда матур әдәбиятка да күчә. 1982 елда эшче яшьләр тормышын сурәтләгән хикәя һәм нәсерләре тупланган «Энҗеләр балкышы» дигән беренче җыентыгы басылып чыга. Сиксәненче еллардан башлап ул тормыш

күренешләрен киңрәк инләгән, катлаулы кеше язмышларын чагылдырган повестьлар язуга керешә. Авыр язмышларны, кешенең тирән эчке кичерешләрен психологик планда гәүдәләндергән «Бәхилләрме йөрәк?» (1985), «Язмышың сыналганда» (1987), «Ак балык» (1988) повестьлары укучылар тарафыннан бик жылы каршылана. Туксанынчы елларда боларга автор каләменең тагын да үткенләнә, фикеренең кыюлана, тематикасының киңәя-тирәнәя баруын күрсәткән «Тәкъдир»(1990), «Инрәү»(1998), «Жан авазы»(2000) кебек әсәрләре килеп өстәлә.

Язучы хикәяләренең үзенчәлеген беренчеләрдән булып Гомәр Бәширов күреп ала. «Кичеккән күке моңы» хикәясеннән алган тәэсирләре турында ул болай яза: «Укый торгач, хикәядән күңел түренә үтеп кереп, рухи дөньяның нечкә кылларын чиртә торган нindидер бер ягымлы, йомшак жылылык сирпелә башлавын сизәсең... Автор сүз һәм гыйбарәләрне, аларның тәмен белеп кенә, нәкъ үз урынында куллана, тормыш детальләрен күрә белә, аларны укучы күңеленә үтеп керердәй итеп әйтеп бирә».

Әнә шул ягымлы, йомшак жылылыкның иң кадерле затлар — әти-әнине, әби-бабайларны, якын туганнарны хөрмәт итү рәвешендәгеләре үзеннән-үзе аңлашылса, авторның тормышка, яшәешкә, Ходайның һәр бирмеш көненә, һәртөрле жан ияләренә, табигатькә сокланып, яратып яшәве барыбызны да ваемсызлык һәм илтифатсызлык чиреннән арындыру һәм хәтта кисәтү теләге булып та ишетелә.

Янәшәдә генә тормышның авыр, драматик, хәтта фажигале хәлләре сагалап кына тора. Нурислам Хәсәновның каләме бу турыда да искәртә — көндәлек тормышның сорылыгына кереп батарга яисә юк-бар уңышларның рәхәтлегенә тирбәлеп яшәмәскә өнди, чөнки әйләнә-тирәбездә башкалар фажигасе... «Без шәхси язмышларыбызның заман белән йөз ертып талашкан елларын кичерәбез,— дип язды бу ижатны бик яхшы белгән һәм дөрес аңлаган әдип Барлас Камалов. — Жәмгыять аяусызлана һәм саңгыраулана барган саен, кешеләрдә эгоистлык һәм хөсетлек арта төшә... Нурислам Хәсәнов шушы тискәре күренешләргә кылыч күтәрә».

Әдип повестьларының берсен «Хакыйкать хакы» дип атаган. Чыннан да, ул үзе дә, геройлары да һәрчак дөреслекне яклап, шуны раслап йөрүчеләр рәтендә. Әлеге фикер бик эзлекле рәвештә башка әсәрләрендә дә үткәрелә — кызыл жеп булып бөтен ижаты буенча сузыла. Кеше язмышларын тасвирлаганда үз иманыңны тыңлау, хакыйкатьне иң элек намус хөкеме бизмәненә салып үлчәү зарурлыгы алга сөрелә. «Гаделлек — күңел энжесе, ул бәһасез, сатылмый да, — дип яза автор бу турыда. — Аны ата-бабаларыбызның газиз жаннары гасырлар буена эзләгән. Гаделлек хакына, мең газаплар кичереп, тормышның тирән катламнары актарылган, утлар-сулар кичелгән... Кемнәрдер хакыйкать тантанасын татый алмый якты дөньядан китеп тә барганнар. Әмма бу буыннарның хаклыкны табар өметләре нарасый балаларның, газиз оныкларның мөлдерәмә баккан күзләренә күчкән, хакыйкать зарурлыгы намус хажәтенә әверелгән... Аның кадере бернинди үлчәмнәргә дә сыймый. Каттый чикләр, авыр сынаулар узган, жаннары гаделсезлек кичергәннәрнең күңел түрләрендә иман нуры булып та балкый ул. Тормышның сират күперләрен үткәндә, язмышың кыл өстендә калганда, дөреслек, хаклык бердәнбер таянычың да, өметең дә. Кыерсытылган жаннар, хөкемдарлар бизмәненең хаклык, дөреслек ягына авышуын, иманнарына тугры калуын тели хакыйкать сакчысы...» Әдәби-документаль повестьта үзен изге эшкә — хакыйкатьне яклауга багышлаган юрист Минзөфәр Мәүләтшин тормышы күрсәтелә. Бу чыннан да биографик фактлары үзгәртмичә диярлек әдәби яссылыкка күчерелгән образ. Икенче бер очракта исә, автор хаклык, гаделлек темасын бөтенләй башка әдәби чаралар аша хәл итәргә омтыла һәм бу юлы да уңышка ирешә. Сүз әдәби чаралар муллыгы һәм төрлелеге белән прозабызга зур яңалык алып килгән «Жан авазы» повесте турында бара. Автор тормышчан һәм хыялый, фантасмагорик алымнарны бергә кушып, аралаштырып, гаять тә тәэссирле әсәр ижат итә алган. Әлеге повесть Н.Хәсәнов ижатында гына түгел, гомумән, хәзерге татар әдәбиятында үзенә бер урын алып тора. Аның төп хикмәте — яна форма алымын куллануда гына да түгел. Автор үзенә бер ысул белән гаять көчле нәтижәгә ирешә — илдәге, жәмгыятьтәге тискәре күренешләрнең асылын күрсәтә, төпле анализ ясый, бигрәк тә бүгенге армиядәге житешсезлекләрнең төбен-тамырын ачып сала.

«Нурислам Хәсәнов тормышның фаҗигале якларына җентекләп тукталып, гыйбрәт алырга чакыра» дип кенә узсак, җавап тулы ук булып бетмәс шикелле. Мөгаен, язучы «башта кечкенә булып кына тоелган ялгышлар, битарафлык, илтифатсызлык, күрәшәсе җирдә күрәшми калу кебек нәрсәләр һәркемнең язмышына кара эзләр сала, фаҗигаләргә, бәхетсезлеккә китерә» дип әйтергә дә тели торгандыр. Моның шулай икәнлеге «Инрәү», «Тәкъдир», «Бәхилләрме йөрәк?», «Инешләрдә — гомер агышлары» повестьларында да бик ачык чагыла. Мондый әсәрләрнең үзәгендә гел яктылыкка, дөреслеккә, гаделлеккә омтылучы герой тора. Күп очракларда нәкъ шушы сыйфатлары белән ул әдипнең үзен дә хәтерләткәндәй була. Ана адәм балаларының иң яхшы, иң күркәм сыйфатлары тупланган. Ул үз күңеленә халык акылын, фигылен, күркәм гореф-гадәтләрен сеңдергән. Туган илен, туган телен яратучы бу зат гел матурлыкка, гүзәллеккә сокланып, шуларга сусап яши. Ул табигатьнең үз баласы, аның күңеленә һәрбер тереклек иясе якын, хәтта аларның телләрен дә аңлый, аларның үз телләрендә сөйләшә сыман. Менә әсәрдән бер өзек: «Тургаем!...Зәңгәр күктә бер нокта булып эленеп калдың да кырлар, тугайлар өстенә тылсымлы моңнарыңны түгәсең. Шул моңнарыңа сихерләнеп тын калдым... Кайда син?.. Күренмисең дә, әллә кояш нурлары син менгән ноктада чагылып, күзләремне чагылдырамы? Өздереп сайравыңны тыңлап, җаным тел белән әйтеп бирә алмаслык ләззәт, яшәрү кичерә. Йөрәгем, яшьлегем тугаена ашкынган аргамак сымак, үткәннәргә кайтып талпына. Гүзәл сафлык бөркелгән көйләреңнән моң-сагышларым юылып ага...» Мөгаен, болай итеп дөньяга гашыйклар янсә чын шагыйрьләр генә яза ала торгандыр!

Табигать гүзәллегенә дә һәркем үзенчә табына, гүзәллеген дә үзенчә җырлый — берәүләр Һади Такташның урман турындагы үлмәс шигъри юлларын кабатлап күңелләренә ләззәт алсалар, икенче берәүләргә «урман-су» дигән гыйбарә якынрак. Ә Н.Хәсәновның поэтик карашы шул гыйбарәнең күбрәк икенче өлешенә, ягъни суларга, инеш-елгаларга төбәлгән. Мондый сайланышның сәбәпләрен бәлки җинел генә аңлатып та булмый торгандыр. Шулай да берәүләр бәлки җавапны бик тиз табарлар: «ник шулай булмасын, ямьле Мишә буйларында үскән егет бит ул» диярләр һәм мөгаен ялгышмаслар да. Инде үзебезгә калса, бу хәлне болайрак та аңлатып булыр иде кебек: автор өчен бу хәл, дөресрәге бу янәшәлек әдәби сюжетларда кеше гомеренең борылмалы агышларын поэтик һәм фәлсәфи тасвирлау өчен гаять отышлы һәм күңелләргә ятышлы мөмкинлекләр бирә һәм әдибебез алардан бик теләп, уңышлы файдалана алган. Аккан сулар, инешләр, гомер агышлары, кайтмас яшьлек моңнарына кушылып, халык җырларына ингән ич... Шуңа охшашлыкны Н.Хәсәнов иҗатында да күзәтеп була. Нәкъ шул рәвештә әдипнең «Инешләрдә — гомер агышы», «Ак балык» әсәрләренә шигърилеккә якын торучы фәлсәфи хасиятләр килеп керә. Бу кечкенә повестьларга катлаулы драматик язмышлар сыйган — шул язмышлар аша халкыбыз күргән-кичергәннәренең тарихтагы фаҗигале эзләрен дә күреп була.

Нурислам Хәсәнов — бүгенге татар прозасында нык каләмле, ачык юнәлешле, кабатланмас характерлы стильгә ия булган сирәк язучылардан берсе. Шулай да үтә сабыр, тыйнак, ашыкмас табигатьле язучыбыз бүген җәмәгатьчелек игътибарыннан читтәрәк кала сыман. Ул, һичшиксез лаеклы булса да, иң алдагы рәтләргә чыгам дип ашкынмый да бугай. Тәнкыйтьчеләребез дә аны «күтәреп алабыз» дип тә, «селкеп салабыз» дип тә тормыйлар. Хәер, селкеп салып анализлау тәнкыйтьтә бездә инде күптәннән юкка чыкты. Бу иҗат әллә каян "мине күрегез" дип кычкырып тормый, ул үзенә җентекле якын килүне, текстка һәм сүз артындагы мәгънәләргә игътибарны, төшенергә теләп карауны сорый; бу иҗат яшәешне, тормыш агышын аңлап, гыйбрәтләр һәм сабаклар ала белүчеләргә төбәлгән.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Нурислам Хәсәновның туган халкына, туган җиренә әйтәсе изге теләкләре, сүзләре бик күп әле. Ул кешеләрнең күңелләре тагын да матуррак булуын тели, үз каләмен тик шуларга багышлый, армый-талмый аларга хезмәт итә.

**Рифат СВЕРИГИН**

# СЕБЕР ЮЛЫ СЕРЛӘРЕ ЯКИ ТАРИХИ ТАБЫШЛАР

Һәр төбәк үзенең танылган кешеләре белән дан тота. Балтач районы Карадуган авылында гомер кичергән, якын араларда гына сиксән яшен тутырган Бакый Шәймулла улы Зыятдинов — кайберәүләр уены-чыны белән әйткәнчә, «халык академигы» — әнә шундый шәхесләрнең берсе. 1950 елдан башлап кырык дүрт ел буе укытучы, шунын утыз биш елын мәктәп директоры булып эшләгәннән соң, ул үзенә шундый ук тынгысыз шөгыль таба: авылда үзе үк оештырган ике музейга житәкчелек итүгә алына. Байдан калган борынгы таш һәм кирпеч бинаның беренче катын «Муса Җәлил», икенче катын «Себер юлы тарихы» музейлары били. Соңгысын ачканда ул чактагы район башлыгы Марат Әхмәтов: «Бу музей эшли торган музей булсын иде», — дигән иде. Бакый абыйсына — әтисенең күптәнге якын дустына һәм хезмәттәшенә карата мондый сүзләрне әйтмәсән дә ярый, билгеле, чөнки анын эзләнүчән холкын, барлы-юклы музей экспонаты саклап гамьсез генә көн үткәрмәячәген район башлыгы гына түгел, бик күпләр яхшы белә. Шулай да Бакый Зыятдинов эзләнүләренең яна бер юнәлеш алуы — бу төбәк һәм авыллар тарихы турында китаплар язып бастырырга тотынуы — көтелмәгәндәрәк килеп чыга.

Егерменче гасырнын азаклары иде бу. Татарстанның Милли музее житәкчелеге, урыннардагы филиалларына чыгып, ел саен бер эшлеклесен хөрмәтләү һәм эшен кинрәк даирәгә таныту гамәлен башлап жибәргән икән. Чираттагы кичәне Карадуганда үткәрергә булалар. Аңа әзерлек йөзеннән, гадәт буенча, әлеге музей эшлеклесе үз хезмәтләре турында бәләкәй генә булса да бер китап язып чыгарырга тиеш икән. Бакый Зыятдиновның «Себер юлы серләре» исемле беренче тәҗрибә китабы әнә шулай туды. Язмаларнын байтагы әзер, бер тапкыр район газетасында чыккан иде инде. Шундагы мәкалә исемнәре үк авторнын кин карашлы булуын, «кеше булган кешенең һәрнәрсәдә эше бар» икәнлеген дәлилләп тора: «Кумәк милек яки Такташның «бергәлек аты», «Хаж сәфәреннән кайткач», «Бабаларынны беләсенме?», «Татар конгрессы: фикерләр, уйлар», «Табышлар һәм әрнүләр». Ә инде «Себер юлы» исемле мәкаләсе исә бу китап өчен махсус языла. Язмада «Әби патша юлы» салыну тарихы татар халкынын фажигале үткәненә тыгыз бәйләп бәян ителә һәм бу үзенчәлек Бакый Зыятдиновнын алдарак дөнья күрәчәк китапларының да үзәгендә ята.

«Явыз Иван гаскәре Казан ханлыгын басып алгач, — дип яза китап авторы, — ана Себерне яулау өчен мөмкинлек туа. Рус байларын Уралнын, Себернен иксез-чиксез байлыклары кызыктыра. Себерне колонизацияләү юллардан башка мөмкин булмый. Уралда руда чыгару, металл кою эшләре башлана, ә аны үстерү өчен Уралны һәм Себерне Санкт-Петербург, Мәскәү һәм үзәктәге башка шәһәрләр белән тоташтырган ышанычлы юллар кирәк».

Казан тирәләре, ягъни, элекке татар биләмәләре рус дәүләте өчен тынычсыз, хәтәр саналганга (чөнки Казан ханлыгы туздырылса да, буйсынырга теләмәгән халык төркемнәре үзләрен сиздереп торганнар әле), әүвәлге Себер юлы, бу якларны урап узып, әйләнгечтән салынган була, ул Санкт-Петербург, Мәскәү, Түбән Новгородтан сон Яранск, Котельнич, Хлынов (Вятка), Соликамск, Туринск аша гына Екатеринбургка бара. Әлеге юл, урау һәм озын булуы өстенә, урманнар һәм сазлыклар аша уза. 1735 елда Себер рудниклары идарәчесе В.Н.Татищев юлны Казан (бу шәһәр инде тәмам руслашып «тынычланган» була) аша үткәрү

киръклеген, аннан үтсә, 409 чакрымга кыскарачагын һәм унайлырак жирләрдән узачагын билгеләп, Сенатка хат яза. Билгеле, Татищев мондый фикерендә ялгыз булмый. 1762 елда патшалык итә башлаган Екатерина II бу ниятне гамәлгә ашыра. Петербургтан Казан-Арча-Карадуган аша уза торган Себер тракты ул заманда «Беренче категорияле башкала юлы» дип аталган һәм Россиядә ин әһәмиятлеләрдән саналган. Шул юл буендагы Карадуган авылында эшли торган музей да — үз төрендә иллә бердәнбер.

Тагын дистә елдан якыннары каршында «әдип» булып китәчәк Бакый Зыятдиновнын (2010 елдан ул Татарстан Язучылар берлегенен шәрәфле әгъзасы) бу беренче китабы, һич уйламаганда, шактый жинел туа. Анын шундый хыялын белүгә, Түнтәр мәктәбендәге дусты һәм һөнәрдәше (икесе дә физика-математика укытучылары, икесе дә төбәк тарихы белән бик кызыксына), ул чакта районнын компьютер белән эшләү остасы Рәфхәт Зарипов язмаларны жыеп биткә салуны үз өстенә ала. Авторнын якташы һәм дусты, тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинов китапнын рецензенты булырга бик теләп ризалаша. Ниятенә чынлап керешкәч, матди ягы да хәл ителә. Шул уныш Бакый агада үзе яшәгән төбәкнен үткәнен, авыллар тарихын тирәнтенрәк өйрәнеп, зуррак әзерлек белән, аерым-аерым китаплар чыгару теләге уята. Шөкер, илнен төрле-төрле архивларыннан эзләтеп кайтартылган, «төньяк башкала»га чаклы үзе барып алып кайткан бик күп борынгы документлар мона шактый мөмкинлек бирә иде инде. Дөрес, берни дә жинел табылмый анысы, авылларнын аерым еллардагы халык санын алу документлары гына да төрле-төрле архивларда сакланган була. Аларнын күчермәләрен эшләп жибәргән өчен генә түгел, эзләткән өчен дә азмы-күпме акча түлисе. Мондый чакларда инде Бакый Зыятдиновнын, мәктәптә эшләгән елларында ук формалашкан, эзләгәнен тапмый, сораганын алмый калмый торган холкы ярдәмгә килә.



«Мәгърифәтле Таузар иле» дип исемләнгән икенче китабын автор үзенен туып-үскән авылына багышлый, мөхәррире — тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинов. Китапнын башында ук Бакый ага, күп кенә тарихчыларнын хезмәтләренә таянып, «Таузар», «Таузар иле» атамасынын килеп чыгышын тикшерә. Монда «Таулар» сүзенен, аваз күчешләре аркасында, Таузар атамасына әверелү ихтималы үзәккә куеп карала. Болай гоманларга нигез дә бар: авыл, чыннан да, урләр чолганышында утыра. Шул ук вакытта авыл исемен «таулар»га бәйләү бик ышандырмый да. Беренчедән,табылган һәм китапта бирелгән ин беренче мәгълүматтан бирле авыл исеме Таузар, Тоузар шәкелендә генә язылып килгән. Димәк, «Таулар» исеме белән кайчан гына яшәгән икән сон бу, дигән сорау туа. Икенчедән, 1678 елгы документтан да, Иван Болтин төзегән «Казан өязенен 1602-1603 елгы язу кенәгәсе»ннән дә күренгәнчә, бу якларда Товзаров фамилияле кешеләр дә яшәгән. Бәлки авыл атамасы Товзар исемле кешедән киләдер? Китапта язылганча, авыл янында Кирәмәт тавы дигән урын бар икән. Кем белә, Таузар исеме дә, бәлки, әнә шул кирәмәтле токымнан, борынгы чирмешләрдән калгандыр? Әйе, бик кечкенә тоелган гамәл — авыл исемен анларга һәм анлатырга омтылу гына да тарих өйрәнүчедән галәмәт зур тырышлык, эзләнү, фикерләү сорый икән. Шуна күрә бу эшкә теләсә кем алынмый да.

Бакый Зыятдинов бәянында авылнын исеме бәхәслерәк калса да, анын кешеләре, ул кешеләрнен мәгърифәтлелеге тулысынча ачылып беткән диярлек була. Монда да авылнын һәр кешесе язмышы ил, халык тормышына бәйләп, бүтән сала һәм кала кешеләренен дә зиһенен баетырлык итеп языла. «Ленинград блокадасын өзү өчен сугыш 1125 тәүлек буе бара, — диелә китапнын «Исәнме, бабай...» дигән гыйбрәтле очеркында. — Бу сугышта 2 миллион 700 мен кеше һәлак була. Таузар егете Ганиев Хажи — шуларнын берсе». Аннары Хажинын кыз оныгынын бабасы сугышкан якларга, анын каберен эзләп баруы, күнеленнән бабасы белән сөйләшүе, ана хисап бирүе бәян ителә. Оныкнын сугыш кырларында ятып калган бабасын эзләп баруы,

мөгаен, тирә-якта бердәнбер очрактыр һәм бу вакыйга да Таузарларның үзгәлеген күрсәтәдер. Сүз уңаеннан әйткәндә, сугыш каһарманнарына һәм шәһитләренә искиткеч ихтирам белән каравы, аларга мөнәсәбәтенең һичкайчан үзгәрмәячәге Бакый аганың һәр китабында ярылып ята.

Таузарны бу якларда күптәннән «Укытучылар авылы» дип йөртәләр. Санаганнар: кечерәк кенә авыл илгә алтмыштан артык укытучы биргән. Шуларның икесе — педагогика фәне докторы, тагын икесе — Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзалары. Таузарлылардан ике кешегә Россиянең, берничәсенә Татарстанның атказанган укытучысы исеме бирелде. Китап авторы Бакый Шәймулла улы Зыятдинов бу исемнәрнең икесенә дә ия, орден-медальләр белән дә бүләкләнә. Төрле-төрле гыйльми дәрәҗә алган Таузар балалары һәм оныклары дистәләр белән исәпләнә. Шулар арасында КФУ проректоры, икътисад фәннәре докторы, профессор Марат Сафиуллин да бар.

Биредә беркайчан башлангыч мәктәптән югарырак уку йорты булмаса да, Таузар халкы элек-электән ерак авылларга йөреп булса да урта белем алган, мәгърифәткә, яктыга омтылган (кечкенә генә инешләренә тирә-якта беренче электр станциясе корып эшләтүләре дә яктыга омтылудандыр). Көчле омтылыш ияләренең берсе — Хөсәен кызы Мәчтүрә үрнәген җылы итеп сурәтләүгә китапның берничә бите багышланган. Мәчтүрә, тирә-якта беренче булып, 1937 елда ук Казан дәүләт университетын тәмамлый. Хөсәеннекеләрнең шуннан соңгы югары белемлеләрен, алар кылган игелекле гамәлләрне санап бетерерлек түгел. Карадуганга мәһабәт мәчет салдырып, аны үз акчаларына эшләтүләре генә дә ни тора! Зыятдинныкылар токымы да авылда иң зыялылар, дистәләгән кешесе — академиктан башлап фән кандидатына кадәр гыйлем ияләре. Китапта үзе бер ил булып яшәрлек бу ишле нәселнең бик куе «ябалдашлы» шәҗәрә агачы бар. Борынгы бабалары Айбулаттан (аннан элеккерәк ике буын да табылды инде) башлап, Бакый улы Булатка кадәр унбер буын! Хәзер Булат белән Фирая гаиләсендә биш бала үсә. Ходай кушса, бу гаиләгә «Ана даны» медале киләсе көннәр дә ерак түгелдер. Таузарның бер кызы Татарстан Президентының үз кулыннан шундый бүләк алган иде инде.

Нәүбәттәге китабында Бакый Зыятдинов күршедәге Хәсәншәех авылын, аның хезмәт яратучан кешеләрен якын һәм үз күреп сурәтли *(«Рәхмәт сиңа, Хәсәншәех!» Казан, «Идел-Пресс», 2006, 432 б.)*. Авыл зур, тарихы бай, китаптан-китапка тәҗрибәсе дә арта барган тарихчыбыз колачларын киң салып йөзепме-йөзә генә. Бу авылның үзгәлеге китапның бүлек исемнәреннән үк аңлашылып тора: «Хөрмәтле гаиләләр», «Каһарман авылдашлар», «Мәшһүр авылдашлар» һ.б. Хәсәншәехка хөрмәт белән карау өчен шушылар гына да җитеп ашкан булыр иде, бәлки, ләкин китапта бу авылдан чыккан 53 укытучының һәм төрле университетлар, академияләр тәмамлап югары белем алган 57 кешенең дә исем-фамилияләре бар. Берәмтекләп эзләгәннәр һәм тапканнар, чөнки тарих булып киләчәккә каласы китап өчен берсе дә артык түгел. Тагын бу авыл җырчы-педагог Люция Хәсәнованы, коенечебезгә, арабыздан бик иртә киткән искиткеч талантлы актер Әдһәм Хаҗиәхмәтовны (Марат Әхмәтов белән бер үк шәҗәрә «яфрагы») биргән, күренекле дәүләт эшлеклесе Камил Исхаковның әнисе Илһамия ханым да Хәсәншәех кызы. Боларны санап чыгу җиңел булса да, эзләп табу һәм китап каһарманы булырлык мәгълүмат туплап язуның кыенлыгын аны эшләп караган кеше генә аңлыйдыр. Мәшһүрлекнең дә тамырларын тирәннән казып ачасы бит. Бакый ага Татарстан Премьер-министры урынбасары — авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтовны нәкъ шулай «ача». Илгә игелекле, кешегә мәрхәмәтле бу зур шәхеснең күп күркәм сыйфатлары аның әби-бабаларына, бигрәк тә гомерләре буе укыту-тәрбия тармагында эшләгән әти-әнисе Готыф абый белән Сара апага нык бәйләнгән. Марат әфәнденең абыйлары, апасы һәм сеңлесе дә шундый ук эшлекле һәм кешелекле булу бер дә юктан түгел, димәк. Готыф абыйның 1950 елларда, Карадуганда колхоз рәисе вакытында, бердәнбер җиңел машинасын бер авыру белән сырхауханәгә җибәреп, үттай урак өстендә кыр буйлап комбайннан-комбайнга җәяү йөргәнен хәтерлим әле һәм шуннан соң башка бер генә рәиснең дә мондый гадилек-галилек күренешен кабатламаганын беләм.

Камил Исхаковның әнисе ягыннан нәсел тамырларына «сәяхәт» тә кызыклы һәм

гыйбрәтле тарих ача. Менә 1854 елның җәе. Мулла Габдулла улы Мөхәммәтгариф, Түнтәрнең данлы Гали ишан мәдрәсәсендә белем эстәп һәм егерме яшендә указ алып, Хәсәншәехнең икенче мәхәллә мәчетенә имам итеп билгеләнә. Аның Газиз атлы улы 1922 елда Югары Кенә мулласы Борһанетдин хәзрәтнең Нәкыя исемле кызы белән никахлаша. Әмма, дөньялар болгангач, яшь гаилә авылдан китәргә мәҗбүр була һәм Казан тирәсенә урнаша. Ләкин татарның зыялы, мәгърифәтле катламына ул чорда килгән коточкыч фаҗига Газизне дә читләтеп узмый — мулла улы булганы өчен генә аны 1937 елда кулга алалар һәм атып үтерәләр. Умарталар асрап һәм бүтән кәсепләр белән үз көнен үзе күргән хөр фикерле һәм тирән белемле Борһанетдин бабаларын да утызынчы еллар башында кулак хуҗалыклары исемлегенә кертеп каһәрлиләр. Газизнең Илһамия, Сәйдәш һәм Рауза исемле балалары кала. «Әти-әнием мина һәм энемә исемне Салих Сәйдәшев кинәше белән куштырганнар», — дип искә ала Илһамия апа, чөнки затлы токым баласы, үзе дә бик зыялы Газиз Абдуллин композитор белән дә, бүтән күренекле шәхесләр белән дә дустанә аралашып яшәгән була.

Бакый ага Кенәбаш авылы тарихын хатыны, шул авыл кызы Мәдинә Зыятдинова белән бергәләп яза *(«Тау башына салынгандыр...». Казан, «Идел-Пресс», 2009, 272 б.)*. Дөрес, Мәдинә ханым аның бүтән китапларында да берәр-икешәр язма белән катнашып килде, истәлекләр табышты, шулай да исем-фамилиясенең китап тышлыгында күренгәне юк иде әле. Китапның чыгымнарын да аз-азлап шушы авыл кешеләре күтәрде.

Кенәбаш тарихын өйрәнә башлаганда авылдашларыннан берәү Бакый агага:

— Хәсәншәехтагы кебек күренекле шәхесләре дә юк, бу авыл турында ни генә язарсың икән инде, — дигән иде. Бакый Зыятдинов «язарына азык» тапмыймы соң? Аннары бер нәрсәгә күптән инанган иде инде: авыл тарихы — танылган шәхесләр тарихы гына түгел, ә бәлки анда яшәгән һәр кеше тарихы, бу тарихта һәркем кадерле. Шәҗәрәсеннән өзелгән бүгенге буын өчен бигрәк тә мөһим бу. Арабызда беренче буын бабаларыннан ары беркемне белмәүчеләр һәм шул хәлләреннән бик канәгатьләр никадәр! Шуңа күрә Бакый Зыятдинов һәр китабына 1716 елдан башлап халык санын алу мәгълүматларын һәм мулла метрикәсе күчермәләрен кертә, шулардан файдаланып шәҗәрәнне ничек төзергә икәнен мисаллар белән аңлата. Халкы бераз уянсын да уйлансын гына. Кәенечебезгә, әле күп меңнәрчә авылның мондый әзер мөмкинлектән мәхрүм икәнен дә истә тотарга кирәк.

Ә күренекле дип зурланырлык һәм киләчәк буыннар да укыйсы язма тарихка кереп калырлык кешеләр, һәр авылдагы кебек, Кенәбашта да байтак. Менә Бакый ага үзе дә «Асыл нәсел» исемле очеркын «Һәрбер авылның йөзен билгеләүче нәселләр, буыннан-буынга ихтирам белән искә алынучы шәхесләре була» дип башлый. Аннары и кинәнә язып... Сүзе Сәйфетдинов Хәйретдин токымы хакында аның. Укыган саен хәйран кала барасың: мәшһүр Строгановлар кебек (аларны да татар токымыннан диләр), бу нәсел турында күп серияле нәфис фильм төшерерлек ләбаса. Урман хуҗалыгында эшләүләре генә дә 200 елга якын. Әле нинди уңышлы эшләр! Хәйретдин бабай утыртып үстергән, күбрәге затлы нарат агачыннан торган урманнар ике мең гектарга җиткән. 1937 елда ул питомникта бер гектардан 2 мең үсенте алу планын 10 мең итеп үти. Тәҗрибәсен бөтен республика өйрәнә. Урманчыларның I Бөтентатар корылтае аңа «Хезмәт Герое» исеме бирүне югары дәүләт органнарыннан сорарга дигән карарга килә. Бу тәкъдим, Татарстанның бөтен җитәкчелек баскычларында хупланып, Мәскәүгә җибәрелгәч кенә «сүндерелә», чөнки Хәйретдин, динемнән аерылмыйм дип, фиркагә кермәгән була.

Китапта Сәйфетдиновлар гаиләсенең 1926 елгы фоторәсеме бар. Хәйретдин белән Фәхриҗамалны дүрт якларыннан дүрт баласы — бер кызы һәм өч улы урап алган. Әтиләре үрнәгендә илгә-халыкка никадәр игелек кыла алырлар иде болар! Әмма егетләрнең өчесе дә фронтка китеп һәлак була, кызлары Зәйнәпнең дә канаты каерыла: ирен, Югары Кенәнең тырыш нәселеннән булган Икрам Ганиевны (аның әтисе Ибраһим Балтачта - ярлылар комитеты, Арчада кантон җитәкчесе, Оренбургта татар театрын оештыручыларның берсе була) Фәйзулла Туишев кебек һөнәрдәшләрендә зур өметләр уяткан атказанган гармунчыны сугыш алдыннан гына тиран Сталин «тегермәненә» салалар. Зәйнәп белән Икрамның кызлары Гөләндәм, аның ире Марс

һәм уллары Марат Мәскәүнең спортчы-альпинистлары арасында танылган гаилә. Ә Хәйретдиннең Галәветдин исемле шәһит улының улы Риф танылган галим, тарих фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт университетында кафедра мөдире була. Риф кызы Диләрә шунда ук доцент, тарих фәннәре кандидаты.

Буыннан-буынга урманчылыкта тырышып эшләгән Гыйльметдиннең дә (Хәйретдиннең бертуган энесе) ике улы сугышта һәлак була. Яшь чагында аттан егылып имгәнгәнлектән сугышка алынмыйча, хезмәт армиясе белән чикләнгән һәм исән калган Гарәфетдине гомер буе ата-бабасының урманчы һөнәрен дәвам иттерә. Хәзер Гыйльметдиннең нәсел дәвамчылары арасында филология фәннәре кандидаты да, хөкүмәтнең 100 мең сумлык бүләгенә ия булган укытучылар да, Татарстанның Муса Җәлил исемендәге бүләген алган актриса да бар.

Хәйретдин бабай токымы, әле генә телгә алынган альпинист Марс аша, шушы авылның гаҗәеп язмышлы мөхәммәтгалимнекеләр белән дә кушыла. Галим бабай үзе ватандашлар сугышы барган ачлык елларында, хатыны һәм ике улы белән ризык эзләп киткән җиреннән, Харьков вокзалында үлеп кала. Аның үсмер Мөхибулласы, йөри торгач, Мәскәүгә кадәр кайтып, заводка урнаша, тырыш хезмәте белән таныла, Кенәбаш кызына өйләнә, 1934 елда уллары Марс туа. Әтисе сугышта һәлак булган, әнисе төрмәгә утыртылган Марсның күргән-кичергәннәре, тома ятимлек тә сындыра алмаган көчле рухы үзе бер роман язарлык. Мәскәү политехника институтын тәмамлаган вакытта ул альпинист та булып өлгерә. Кенәбашка кайтып, Хәйретдин бабай оныгы Гөләндәмгә өйләнгәч — икәүләп, уллары Марат тугач — гаилә белән разрядлы альпинистка әвереләләр. Җир шарында Марат яуламаган тау түбәләре юк дияргә була. 1996 елда өч кешедән торган Россия командасы (Марат — Абрамов Черный) Көньяк Америкадагы Акокагуа тавының 6960 метрлы иң югары урынына иң кыска вакытта — җиде тәүлектә күтәрелеп, дөньяны шаулата.




Әтиләре ачлыктан егылып үлгәндә Харьковта калган үсмерләрнең икенчесе Мөхәммәтвәли дә, йөри торгач, Мәскәүгә килеп, төзелештә эшли, аннары сугышта катнашып, сержант дәрәҗәсендә батырларча һәлак була. Аның бердәнбер кызы Галимә кече яшьтән очучы булырга хыяллана, Калугада махсус мәктәп тәмамлап, МИ-1 вертолетында һавага күтәрелә. Бераздан МИ-8дә оча башлый, ә 1969 елда еракка очу буенча дөнья рекорды куя. Алар Төмәннең төньягында нефтьчеләргә йөк ташыйлар, югары көчәнешле электр баганалары урнаштыралар. Шулай 1988 елга кадәр эшләп, Галимә һавада очу вакытын 9 мең 200 сәгатькә җиткерә. 1970 елда «Советская женщина», 1971 елда «Азат хатын» журналлары тышлыгында кем дисәгез — очучы киемендә Кенәбаш оныгы Галимә Галимова балкып утыра. Әйе, тәвәккәллеге, эштә унганлыгы белән генә түгел, чибәрлеге белән дә заманында җирне-күкне бизәгәндер бу кыз. Әнисе шушы авылныкы булган Казан кызы, унсигез яшьлек Гөлназ Сәләхова да 1991 елда халыкара «Нәүрүз чибәре» конкурсында беренчелеккә чыгып, Австралия белән Америка кыйтгалары арасындагы татар егетләрен әсир иткән иде. Хәзер ул гаиләсе белән АКШта яши. Китапта Гөлназның әнисе Нурисәнең бертуганнары белән төшкән фоторәсеме бар. Бер оя балалары гына булсалар да, бөтен Татарстаннан чибәрлек бәйгесенә җыелган кызлар дип уйларлык аларны.

Кенәбаш тарихыннан соң Бакый Зыятдиновның «Классташлар» исемле китабы басылды, аның артыннан ук Карадуган һәм Арбаш авыллары тарихыннан «Себер юлы буйлап: Карадуган Арбаш авылы тарихыннан сәхифәләр» китабы дөнья күрде. «Классташлар»ны авторнын 1948 елда Балтач урта мәктәбен бергә тәмамлаган 29 сабакташына мәдхиясе дияргә була. Китап бу мәктәпнең төзелү, ачылу тарихын да эченә ала, анда сугыштан соңгы авыр елларда эшләгән укытучылар турында да мәгълүмат бирелә, 29 кешенең тормыш юлы аша нык ихтыярлы, якты карашлы, максатчан бер буынның бик мәгънәле яшәеше күз алдына килә. Үзәктә — Балтач кешеләре арасыннан беренче профессор, бердәнбер СССР Дәүләт премиясе лауреаты,

Россия Ракета-артиллерия фәннәре академиясе мөхбир-әгъзасы Габделфәрт Вәлиев. Аның янәшәсендә (алар хәтта бер үк Казан химия продуктлары фәнни-тикшерү институтында шактый вакыт бергә эшләгәннәр) илнең зур химия төзелешләрендә җуелмас эзе калган инженер-җитәкче, профессор, Халыкара информатика академиясе академигы Габделбәр Гарифҗанов. Сыйныфташлар арасыннан тагын берничә мәктәп директоры, күренекле укытучылар (икесе РСФСРның атказанган укытучылары) үсеп чыккан. Китапның соңгы битен япкач, классташларның зур-зур хезмәтләре белән танышудан тыш, Габделфәрт Вәлиев ирешкән бәхетле язмышның тагын бер күркәм ягы турында уйланмый калмыйсың: аның хатыны Әнисә ханым һәм улы Рахман, мәрхүмнең истәлеген яд итеп һәм сабакташларын хөрмәтләп, менә шушындый китап яздыру ниятенә киләләр. Китапның барлык чыгымнарын Рахман үз өстенә ала.

Бакый Зыятдиновка Карадуганның үткәнен бик озак эзләнеп язарга туры килә, чөнки аның тарихын тирә-якта иң катлаулылардан дияргә мөмкин. Авылның берничә елгы халык санын алу мәгълүматлары бөтенләй табылмады. «Казан өязенең 1602-1603 елгы язу кенәгәсе»ндә бу авыл турында «Королованская пустошь» дип кенә телгә алына, димәк, Явыз Иван патшаның басып алу, буйсындыру сугышларыннан соң Карадуганның исеме һәм буш җирләре генә калган була. Бүтәннәрдән дә ныграк туздырылуының сәбәбе ачык билгеле түгел. Бәлки монда авылның юл өстендә булуы сәбәпчедер. Борынгы рәсми документларда — 1782 елгы дүртенче һәм 1795 елгы бишенче сан алу мәгълүматларында — Карадугандагы йомышлы татарларның элекке морзалар нәселеннән булуы әйтелә. Бәлки алар үзләрен рус түрәләрнең ачуын китерерлек бәйсез тотканнардыр? Авыл халкына кырын карашның соңгы гасырларга кадәр дәвам иттерелүе дә болай уйларга җирлек бирә.

«Язу кенәгәсе»ннән күренгәнчә, авылның буш җирләрендә яна керәшеннәрдән тол хатын Пелагея Денисовна һәм аның ике улы белән Шабулат Шанчюрин хуҗалык иткән, тәгәлрәге, алар Шушма елгасының ике ягыннан, Ширә инеше буеннан һәм Чәткәнә үзәненнән 550шәр чүмәлә печән чабып алганнар. Ул печәнне, мөгаен, Казанбаштагы һәм Түбән Мәтәскәдәге хуҗалыкларына ташыганнардыр, чөнки Карадуганда каралты тотып терлек асраулары хакында берни әйтелми. Пелагеяның бу авыл тарихындагы роле шунда, ул Карадуган исеме белән янәшә иң борынгы язма истәлеккә кереп, авылның керәшенлә чорын башлап җибәргән. Монда ике диндәге татарларның бергә яшәве 1881 елга кадәр барган. «Карадуган кешеләре чукынмаган, бирегә керәшеннәрне читтән китереп утыртканнар», — дип сөйләгән иде бервакыт авылга килгән мәгълүм тарихчы Габделбәр Фәйзерахманов. Шулайдыр, чөнки әле генә телгә алынган халык санын алу мәгълүматларында мондагы керәшеннәрне «ясаклылар» дип язганнар. Димәк, алар бирегәге морза нәселле йомышлы татарлар белән бер тамырдан булмаганнар. Чит дин кешеләре белән мәҗбүри катнаштыру да авылны җәзалауның бер алымы булгандыр, күрәсең.

Карадуганның тарихтагы үзгәлеге аның гомер-гомергә зур корбаннар авылы булуында. Октябрь түнтәрелешеннән соң бөтен таза тормышлылары таланып, йорт-җирләре туздырылып бетерелгәч тә, Яңа икътисади сәясәт азмы-күпме тернәкләндергән җиде гаилә башлыгын 1932 елның 9 маенда Татарстан АССРның ОГПУ өчлеге «контрреволюцион төркемдә катнашкан, дини коткы тараткан өчен» хөкем итә. Аларның бишесен өчәр, берсен биш елга концлагерьга, берсен ике елга хезмәт белән төзәтү лагерена озаталар. Концлагерьга хөкем ителгәннәр арасында авылның соңгы мулласы Билал Хәсәнов белән күптән түгел оешкан «Мәгариф» колхозының иң беренче рәисе Закир Габсәламов та була. Билал хәзрәттән элгәрәк эшләгән мулла Минһаҗетдин Йосыпов, авылдан китеп барганлыктан, ул вакытта исән-имин калса да, советка яла ягуда гаепләнеп, 1937 елның 5 августында кулга алына һәм атып үтерелә. Ике гаиләдән — Сәмигулланыкылардан һәм Шәрифнекеләрдән — бишәр улның Бөек Ватан сугышында һәлак булуы белән дә бу авыл тирә-якта бердәнбер. Шәрифнекеләр — бер үк көнне концлагерьга озатылган Закир (төркемдә иң яше) һәм Фатих Гыйззәтуллин (иң олысы) белән бер үк шәҗәрәдән. Фатихның да ике улы, бер энесе сугышта башларын салган.

«Себер юлы буйлап...» китабында дин галиме, педагог Габдулла Бубиның «Буби мәдрәсәсенең кыскача тарихы» дигән хезмәтеннән бер өзек китерелә. «Бубига

мөселманнардан иң элек күчеп килгән адәмнәр Казан губернасы Кара Дуван авылыннан Сөләйман һәм Габдулла исемендә ике кеше булмыштыр. Боларның туган һәм үлгән вакытлары һәм Бубига тәгаен генә кайчан килүләре мәгълүм булмаса да, Бубига килеп утырулары 1730 елларда булырга кирәк», — диелә анда. Галимә А.Х.Мәхмүтова аларның Бубига килү сәбәпләрен «көчләп чукындырудан качу булгандыр яки сәүдә белән килеп, төпләнеп калганнардыр», — дип фаразлый.

Чынлап та, ирексезләп чукындыру хәвефе, керәшенлек Карадуган өстендә берничә йөз еллар эленеп торган, боларга тагын җирләрен тартып алу, егерменче гасырда сөрелү афәтләре дә өстәлгән. «Себер юлы тарихы» музее «төньяк башкала»дан авылның 1795 елда Казан межа конторасы эшләгән бик сыйфатлы харитасын кайтартты. Уналтынчы гасырдан ук (бәлки тагын да электәндер) Карадуганныкы саналган Чәткәнә үзәне белән ике арадагы бөтен җирләр бу харитада авылның икенче ягындагы Түбән Ядегәр белән Югары Ядегәрнеке дип ап-ачык язылган. Карадуганның башка урында җирләре юк, димәк, нинди дер гаебе өчен ул берара бөтенләй җирсез калдырылган булган. Ә бит вәзгыять кабатланып тора. Ун-егерме еллар элек бөтен район төзелешенә таш, кырларына известь чыгару өчен карьер кирәк булгач, аны ачарга болай да аз җирле Карадуган кырыннан башка урын тапмадылар. Карьер һаман җәелеп, авыл басуын аркылыга инли бара. Аннары ташын чыгарып, «пустошь»ка калдырылган ялан чит бер фермерның зур гына дуңгыз фермасын урнаштырырга «унай» дип табылды. Таузар авылының җирен кисеп чит хуҗалыкка бирү дә үзәге Карадуганда булган «Игенче» кооперативының алдагы тормышына каты сукты.

Властьларның авылны христианлаштыру өчен ачыктан-ачык көрәше XIX гасыр азакларында гына сүрелә. 1881 елның 23 июлендә керәшен авылы Апазның христиан динчесе Александр Миропольский, Казан губерна идарәсенә рапорт язып, Балтач волосте Карадуган авылы крестьяны Тихон Григорьевның, татарча Мостафа исеме белән, диндәшләрен мөселманлыкка кайтырга өндәп йөрүе турында хәбәр итә. «Мин баш коткычы Григорьевны каты җавапка тартуыгызны сорыйм», — дип яза ул. Юкса, янәсе, Казан һәм башка губерналарның керәшеннәре мөселманга күчеп бетәчәк, шулай итеп, христианнарның һәм Россия хөкүмәтенең дошманнары көчәячәк, Мөхәммәт өммәтендәгеләр күптәннән мона омтылалар икән. Мөселманнарның Рус хөкүмәтенә буйсынуы, рус башлыкларына хөрмәте дә вакытлы, мәҗбүри гамәл генә, беренче җай чыгу белән каршы күтәреләчәкләр, дип кисәтә Миропольский.

Нәкъ шул чорда Казан Дини консисториясе дә губерна идарәсенә хат язып, Карадуганда яшәгән ун керәшен хуҗалыгының мөселманлыкка кайтуын хәбәр итә, моның сәбәпләре итеп, беренчедән, христиан диненнән баш тарткан өчен кулга алынган Әзәк авылы кешеләренең иреккә чыгарылуы, икенчедән, Карадуганда законсыз төстә мәчет салынуы күрсәтелә. Консистория губерна идарәсеннән әлеге мәчетне тиз арада юк итү турында боерык бирүен сорый. Бу гаугалы эшкә тора-бара Казан хөкем палатасы, губернаның жандарм идарәсе һәм дәүләт полициясе департаменты катнашып китә. Әмма Казан өязенең полиция идарәсе кушуы буенча Карадуганга килеп тикшерү уздырган пристав бу авылдагы җамигъ мәчетенең инде күптәннән эшләп килүен, хәзерге мәчет бинасының, тузган элеккесе урынында, 1865 елда ук салынуын, мулла Мифтахетдин Хәсән улы Йосыповның (Сталин җәлладлары аттырган Минһаҗетдин хәзрәтнең әтисе) 1857 елдан бирле шушы вазифаны башкаруын, монда мөселманнарның Миропольский язганнан шактый күбрәк булуын ачыклый. Эчке эшләр министрлыгының Казан губерна идарәсе, шушы тикшерү нәтиҗәсенә таянып, күп еллар эшләгән мәчетне ябу мәгъкуль булмас, бу эшнең мөселманнар арасында рәнҗү һәм чуалышлар чыгаруы бар, дигән унай карарга килә.

Бакый Зыятдинов китабында Карадуганның фаҗигале үткәне гасырлар буе кысылуда, хокуксызлыкта яшәп тә йөзен югалтмаган бөтен татар халкы тарихына тыгыз бәйләнештә бәян ителә. Кечкенә генә җай чыгып, язмыш кояшы азга гына елмайса да, бу халык зур эшләре, рухи җегәре белән таныла алган. Ә Бакый ага һаман эзләнүдә...

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# ҮЗ ЗАМАНЫНЫҢ КАҺАРМАНЫ

Егерменче гасыр. Татар әдәбияты. Гомәр Бәширов. Бу сүзтезмәләр бер-берсен тутырып табигый янгырый шикелле. Дөрес, үткән гасыр татар әдәбияты тарихында бөекләр шактый: Тукай, Такташ, Ибраһимов, Тинчурин, Җәлил, Кәрим (Фатих)... Сонрак чордан тагын дистәләгән исемнәрне санарга мөмкин. Әмма шунысы бар: ни кызганыч, аларның дөньядагы яшәү язмышын тулы бер гасыр белән бәйләү кыен. Кайсылары яшьли вафат, кайсылары төрмәләрдә черегән, кайсылары сугыш корбаннары... Һәрхәлдә яшьләре буенча илледән узганнары сирәк. Бәхетебездән, Гомәр Бәширов, йөзьяшәр ил агасы булып, тулы бер гасырның алтын баганасы булып кала алды. Ходай биргән саулык-сәламәтлек белән дә, олуг шәхес кимәлендә дә, акыл иясе буларак та.




Безнең халыкта талантлы кешеләр күп булган. Кайсы шәп шагыйрь, кайсы хикәя-повесть остасы, кайсы артист-драматург дигәндәй... Ә менә чын мәгънәсендә әдипләр сирәк. Зур әдип булу өчен теге яки бу жанрда маһир булу гына җитми әле. Аның өчен чын зыялы, гыйлемле, милләт язмышын һәрдаим онытмаучы, гамәлен таланты белән раслый ала торган, шул җөмләдән сәясәтче дә була алу кирәк. Гомәр ага Бәширов нәкъ менә шул сыйфатларга ия шәхес иде.

Без, моннан ярты гасыр элек әдәбиятка килгән буын, шул чордагы совет әдәбиятының горурлыгы саналган шәхесләр белән нык кызыксына идек. Күрәсең, үзебез дә шундый үрләргә омтылганбыздыр инде. Кемнәр иде сон ул шәхесләр? Кайберләрен генә саныйм: М.Шолохов, А.Твардовский, А.Фадеев, М.Кәрим, украин М.Бажан, казах М.Ауэзов, эстон Ю.Смуул, литвалы Э.Межелайтис, кыргыз Ч.Айтматов, әзәри С.Рөстәм, үзбәк Г.Голәм... Шулар арасында түрдә Гомәр ага Бәширов та бар иде. Зур горурлык иде безнең өчен. Таяныч иде.

Хәзерге яшьләрнең ул чордагы совет әдәбияты үрнәкләренә үз карашлары бардыр. Беләм, тәнкыйть белән дә карыйлар. Табигый хәл. Әмма үзләре шул заманда яшәп иҗат итсәләр нишләгән булырлар иде икән? Минемчә, Гомәр Бәширов шул чор (ә еллар бик катмарлы!) мөмкинлекләреннән чыгып, милләт файдасына максимум эшләргә тырышкан фидакарь шәхес. Кемнәргәдер «Намус» романындагы Нәфисә образы ясалма булып тоелырга мөмкин. Онытмыйк: Нәфисәләр берничә буынны тәрбияләде. Начарга тәрбияләмәделәр бит! Шунысы мөһим.

Әгәр әдипнең иҗатын чын-чынлап бәяләргә теләсәң, аның «Туган ягым – яшел бишек», «Җидегән чишмә», «И язмыш, язмыш», «Гыйбрәт» кебек әсәрләрен яңадан укып чыгарга кирәк. Биш томлыгын укысаң тагын да яхшырак. Хәзер алар рәтенә Гомәр аганың яңа китабы – «Күнел дәфтәре» өстәлә*. Алтмыш ике ел буена теркәлеп килгән бу көндәлек язмалар әдипнең иҗатын

Гомәр Бәширов. Күнел дәфтәре: көндәлек язмалар (төзүчесе З.Бәширов). Казан. Татар. кит. нәшр., 2011. – 464 бит.

һәм эшчәнлеген дөрес бәяләр өчен иң ышанычлы чыганак булыр. Гомумән, озак еллар буена көндәлек язып бару олы әдипләргә хас бер сыйфаттыр. Әдәбият тарихыннан Л.Н.Толстой, Ф.М.Достоевский, И.Г.Эренбург көндәлекләрен искә төшерә алабыз. Әдипләрнең кичергәннәре, уйланулары, күңел түрендәге ихлас фикерләре күрәсең аларның әдәби әсәрләренә, публицистик мәкаләләренә сыеп бетмәгән, яисә дөньяга чыгарырга әле иртә дип саналган. Шуңа күрә дә безгә ул язучыларның көндәлек язмалары аеруча кыйммәтле.

Кызганыч, яңа буын язучылары арасында көндәлек алып бару гадәте бетеп бара шикелле. Һәр үткән көн хәлләрен елъязма рәвешендә теркәп барган Гариф Ахунов, Аяз Гыйлажевлар, иҗатлары белән бергә, бу яклары белән дә сагындыра башлады. Көндәлекләрне эпистоляр жанрның бер төре дип тә исәпләргә буладыр дип уйлыйм. Көндәлек ул – Вакыт агышына мөнәсәбәт, күңел бушату, үзенчә бер хикмәти тынычлану... Әмма, бу гамәл, асылда, зур максатка юнәлтелгән: кайчандыр, кемнәрнеңдер бу язмаларны укуына, бу факт-күзәтүләрнең кемнәргәдер кирәк булачагына ышану. Кыскасы, киләчәккә хатлар алар...

Миңа байтак еллар Гомәр ага белән аралашып яшәргә туры килде. Әйткәнемчә, ул бик олпат, һәр сүзен үлчәп сөйләшә торган, һәм күпмедер дәрәҗәдә сак кеше иде. Шулай да, яшь аралары шактый күп булса да, күңеле түрендә яткан кайбер фикер-серләре белән уртаклаша иде. Мин моны 60нчы еллар ахырында язучыларның Әлмәт бүлегендә житәкче булып эшләгәндә яхшы тойдым. Ул Әлмәткә еш килгәләп йөрде. Озак-озак әңгәмәләшкән чаклар булды. Заман өчен шактый ук четерекле темаларга да сөйләшеленә иде. Әйтик, ничек итеп Г.Ибраһимовның реабилитацияләү тарихы (бу эштә Гомәр ага җеп очын тотып торган кеше), Г.Исхакый тормышы һәм иҗаты, Һ.Атласи эшчәнлеге һ.б. Күрәсең, мине ышанычлы дип санагандыр инде. Бик әһәмиятле дәресләр булды алар минем өчен.

Гомәр Бәширов 50-60 елларда Республика житәкчеләренең беренче бишлегенә кергән кеше иде дип беләм. СССРның Югары Советы депутаты. Россия Язучылар Союзы житәкчеләренең берсе, Татарстан Язучылар оешмасының рәисе. Халыкара абруйлы язучы... Үткән чорда татар әдәбиятын дөньяга күрсәтүдә ике этап булды дип уйлыйм. Берсе – 50 еллар башында Г.Бәшировка һәм К.Нәҗмигә Сталин (Дәүләт) премияләре бирү факты. «Намус» һәм «Язгы җилләр» әсәрләре дистәләгән чит телләргә тәрҗемә ителде, дөньякүләм таралыш алды. Икенче – М.Җәлилнең әдәбиятка яңадан кайтуы һәм дәүләти зур исемнәр бирелүе. Бу тарихи вакыйгада да Гомәр ага Бәшировның роле зур булды.

Шунысын да өстәп әйтәсе килә: Казан үзәгеннән 15ләп чакрым ераклыкта Аккош күле дип йөртелә торган җирдә язучыларның иҗат йортлары бар. 60 еллап дәвердә анда татарның зур язучылары, шагыйрьләре, драматурглары яшәгән, халык хәтерендә калырлык бик күп әсәрләр иҗат ителгән. Әле бүген дә биредә бер төркем язучылар яши, эшли, традицияләрне дәвам итә. Бу иҗат йортларын да бит Гомәр ага нигезләгән. Аның тырышлыгы һәм дәрәҗәсе белән булдырылган алар. Бөек әдипнең иҗтимагый-гражданлык эшчәнлегенең бер дәлиле.

Гомәр ага Бәшировнең көндәлек-хатирәләр китабы да безнең рухи тарихыбызда Аның тоткан зур урынын, һәм дә югарыда әйтелгән фикерләрне өлешчә раслый дип уйлыйм.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

# ГАСЫРЛАР ИЛЧЕСЕ

Кешелек җәмгыяте һәрвакыт алга бара. Бу табигый, чөнки бер урында тору халәте юк. Бер урында торыйм дисән дә, артта калмас өчен, алга барырга кирәк. Гасырлардан гасырларга күчеп килүче язма әдәбиятыбыз да еллар иләгеннән төшеп калмый. Чын асылын җуймыйча, вакыт каршылыкларына бирешмичә яшәү сере — аның гуманистик асылында, гадел кеше образын яшәеш өлгесе итеп алуда, тормыш белән бәйләп бирүдә, иманлы булуда. Коръән тәгълиматы белән бик тыгыз бәреккән борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятының нигезендә гадел кеше һәм гадел идарәче образларын




үзәккә куеп тасвирлау, илаһи төшенчәләр белән эш итү һәм адәм балаларының әрнүле күнелен ихлас идеаллар белән яктырту, Аллаһ биргән гомерне тискәре күренешләр күләгәсеннән саклап яши белү тора.

Язма мирасыбызга чор-дәверләрнең аяусыз җилләре, кырыс сынаулары аша үтәргә туры килә. Шул чакларда имгәтелеп, тамырларына зыян килсә дә, үзәге нык булу сәбәпле, исән кала, тернәкләнә. Ерак гасырлар аһәненең кыйммәтен тоемлаучы фидакярләр тырышлыгы, намусы белән ул яклана, саклана һәм алдагы буыннарга тапшырыла. Ил өстендә кара шәүлә булып имансызлык, битарафлык куерганда да язма мирасыбыз рухи таяныч булып алга чыга. Фикерләрем профессор Хатыйп Миңнегуловның «Гасырлар арасында уйланулар» исемле китабын укып чыккач туды дисәм, ялгышмамдыр, мөгаен. Тирән уй-фикерләргә, фәлсәфи җирлеккә корылган мәкаләләргә, бай язмаларга уралган әлеге хезмәт чын мәгънәсендә авторның күнел түреннән чыккан илаһи хисләрен җыеп, туплап бирә. Кирәкле мәгълүматлар аша әдәби ядкярләрнең асылын, мөһимлеген тагын да ныграк тоя, сиземли барасын. «Ачы тәҗрибә авазы»дип исемләнгән башламнан ук, профессорның шәхси тормыш вакыйгаларын сурәтләп бирүе аша, укучы белән араны якынайтучы эчкерсез сөйләшүгә тап булабыз. Язу өслүбенең болай борылыш алуына, шәхсилектән әдәбилеккә баскыч кына икәнен белгәнгә, кызыксынуыбыз көчәя генә. Бик күпләр белгән профессорның да әле без белеп бетермәгән яклары барлыгына инана: соклана, гыйбрәт ала, нәтиҗәләр ясый. «Университетны тәмамлагач, аспирантурага керү мөмкинлеге булмады. Мине Сарман якларына эшкә билгеләделәр. Анда ике ел мәктәп директоры, ел ярымлап партия райкомы хезмәткәре булып эшләргә туры килде. Шулай итеп, фәнгә багышланасы өч ел ярым вакыт янә башкага сарыф ителде, — дип яза Хатып абый, тормыш борылышларынын иң әһәмиятле якларына басым ясап.— Галим исемен алырга теләгән һәр кеше, кагыйдә буларак, утыз биш-кырык яшькә кадәр фән докторы дәрәҗәсенә ирешергә тиеш. Гадәттә, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре арасы биш-ун ел була. Ә ул минем унтугыз елга сузылды...1991 елның 28 ноябрендә, ягъни илле өченче

Хатыйп Миңнегулов. Гасырлар арасында уйланулар. Казан. Татар. кит. нәшр., 2010. – 320 бит.

яшемдә генә яклауга ирештем». Акыллы киңәш тә, дустанә мөнәсәбәт тә, тормыш ачысының гыйбрәтле кыйпылчыклары да чагыла бу башламда. «Шуңа да мин яшьләрнең, безнең озын, кыек-мыек, гайре табигый юлларны кабатламыйча, фәнгә мөмкин кадәр турырак, тизрәк килүләрен теләр идем», — дип «ачы тәҗрибә авазы»н безнең хөкемгә тәкъдим итә.

Әлеге хезмәт Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов турындагы биографик белешмә белән ачылып китә. Анда галимнең тормышы һәм фәнни эшчәнлеге яктыртыла, ирешкән уңышлары, хезмәтләре бәян ителә. Аларның һәрберсе тынгысыз хезмәт һәм маңгай тирен тамызып иҗат итү нәтиҗәсендә бирелгән. Х.Миңнегуловның фәнни эшләре Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстанның Дәүләт бүләге лауреаты һ.б. исемнәр белән искә алынган икән, димәк, профессор һәм әдип үз тормышында төп максатына ирешкән дигән сүз бу.

Хатыйп Йосыповичның кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре, күпчелек хезмәтләре Борынгы һәм Урта гасыр, XIX йөз татар әдәбияты, аның Шәрекъ сүз сәнгате белән бәйләнешләрен өйрәнүгә багышланган. Дөрес, ул башта Алтын Урда белән мавыга, тик аның уңышлы гына барган эше аерым затларга ошамый һәм Хатыйп аганы Алтын Урда белән мавыгудан тыялар. Аерым чакырып сөйләшүләр, әңгәмәләрдән соң ул Алтын Урда тематикасын калдырып, башка мәсьәләләр, текстологик эшләр белән шөгыльләнергә мәҗбүр була.

Китапның керешендәге «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре» исемле мәкаләсендә дә автор элеккеге рухи мирасыбызны өйрәнү хакында сүз алып бара. Ул аларны аерым кимчелекләре, җитешсезлекләре белән бергә карый. Тик «...соңгы вакытларда үзебезнең күпьеллык гыйльми мирасны санга сукмыйча, башкалардагы фәнни хезмәтләр, фикер-күзәтүләр, -измнар, чит-ят термин-атамалар белән кирәгеннән артык мавыгу, алардагы «ачыш-казанышлар»ны безнең филология фәненә механик күчерергә омтылыш көчәйде», — дип борчылуын да белдерә.

«Гасырлар арасындагы уйланулар» берничә бүлектән тора. «Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты» бүлегендә генә дә авторның ундүртләп мәкаләсе урын алган. Аларның һәрберсе җан авазы, җан сыкравы аша язылган. «Урта гасыр әдәби мирасын өйрәнү» белән башланып киткән мәкаләсендә Хатыйп абый бу чорны өйрәнү авырлыклар тудырса да мәктәпләрдә җентекләп тукталырга кирәклегенә төшендерә. Моңарчы җитәрлек игътибар да булмаган бу өлкә, чынлап та хәзер ныклап өйрәнелә башлады, укыту программаларында сәгатьләр саны да арттырылды. Дөрестән дә, урта гасырлардагы әдәби геройлар укучыны рухи дөньялары катлаулы һәм бай булудан бигрәк, әхлак сафлыгы, гомумкешелек кыйммәтләренә тугрылыгы белән җәлеп итә. Профессор инануынча, «урта гасыр әдәби мирасы — халкыбызның гасырлар буе тупланган күңел хәзинәсе, акыл тәҗрибәсе, фәлсәфәсе. Аны өйрәнү укучыларга эстетик, әхлакый, гуманистик, милли тәрбия бирүгә көчле йогынты ясый». Татар тормышында һәм аның иҗтимагый фикер үсешендә Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» әсәре аерым игътибарга лаек. Автор аның язылу тарихын, идея-эчтәлеген, проблематикасын бөтен нечкәлеге белән сурәтли. Аны «Тормыш дәреслеге» дип атый. «Мәхмүт Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»ына бәйле дә автор күзәтүләренә киң урын бирелгән. Әсәрнең ничек сакланып калуы укучылар өчен дә кызыклы. Шулай ук Колшәриф, Мөхәммәдьяр иҗатларын барлап, Казан ханлыгы чорына, аның ханы Мөхәммәд Әмингә дә тукталып үтә. «Мөхәммәд Әминнең татарча язылган рәсми хаты, ягъни бетеге, Хәким Бирде исемле илчесе аркылы 1506 елда Польша хөкемдары Александрга җибәрелә. Ул безгә 1928-1939 елларда Гаяз Исхакый тарафыннан Берлинда гарәп хәрефләре белән татарча чыгарылган «Яңа милли юл» журналы (1930.№3) аркылы таныш. Мөхәммәд Әминнең бу хат-бетеге белгечләрдә һәм җәмәгатьчелектә билгеле бер кызыксыну тудырып, гыйльми тикшеренүләрдә мөһим бер чыганак булып хезмәт итәр», — дип белдерә Х.Миңнегулов.

Үз чорының танылган әдипләре Габделмәннан Рахманколый (1858-1908), Таҗеддин Ялчыгол (1768-1838), Муса

Акъегетзадәнен (1864-1923) түгәрәк даталары унаеннан язылган тирән эчтәлекле язмаларда да мәгълүмат тулып ята. Автор билгеләгәнчә, М.Акъегетзадә үз халкындагы аерым кимчелекләрне дә күрә, әмма ул, кайбер авторлар кебек тәнкыйтъ белән артык мавыкмый, аларны бетерү юллары турында уйлана. Мәсәлән, хәерчелек юлына баскан Мохтар кәсепкә керешә, үз тырышлыгы белән байый. Пәйгамбәрнең «кем ижтиһад итәр, ул табар» хәдисе юкка гына әсәрдә китерелмәгән. М.Акъегетзадә, гомумән, тырышлык, тәвәккәллек, эшлеклелек, белем-һөнәргә ия булуны инсаннарның яшәү принцибы рәвешендә аңлый. Язмадан аңлашылганча, күп кенә әдипләрдән үзгә буларак, Муса Акъегетзадә бер генә әдәби әсәр яза һәм шуның белән тарихка кереп кала. «Хисамеддин менла» — аның тәүге дә, ахыргы да әсәре.

Хатыйп ага күренекле тарихчы, әдип, рухани, педагог, журналист, библиограф, археограф Ризаэддин Фәхреддингә аеруча хөрмәт, үзгә бер олылау, соклану белән мөрәҗәгать итә. Мәкаләсендә әлеге шәхесне башка халыклар белән үзара бәйләнешләр, әдәбиятта дини, дөньяви мотивлар чагылышы йогынтысында тикшерә. Элгәреләребезнең тикшеренүләренә, язганнарына үтә сак һәм хөрмәт белән карый.

«Янә Тукай турында» дигән бүлектә Х.Миңнегулов Г.Тукай иҗатына яңа төсмер, яңа сурәтләр өсти, табышлары белән уртаклаша. Мөһаҗирлектә гомер кичерүче милләттәшләребезнең бөек шагыйрь хакындагы язмаларын, фикерләрен тәкъдим итә. Шигъриятебез пәйгамбәренең иҗади мирасын халыкчанлык төшенчәсенә нисбәтле бәяли. Тукайның Санкт-Петербург каласына булган сәяхәтенә туктала. Бөек шагыйребез биредә унөч көн генә булса да, «ак томаннар иле»ндә шагыйрь иҗатына бәйле хатирәләр эзсез калмый. Бүген исә, бу калада әдипкә һәйкәл куелу — шагыйрь истәлекләрен мәңгеләштерү — инсаният җырчысына булган олуг хөрмәтне күрсәтә, тугрылыгыбызны раслый. Санкт-Петербург төбәге татарларындагы милли аңның чагылышын раслый, туган тел проблемаларына игътибар итә.

«Тукай энциклопедиясе»нә материаллар туплауда да Х.Миңнегулов күп тырышлык куя. Шул нисбәттән шагыйрь иҗатындагы жанрлар әлеге хезмәттә дә чагылыш тапкан. «Баллада», «Васыятьнамә», «Газәл», «Дидактик әдәбият», «Мәдхия», «Мәрсия», «Рубагый», «Лирика»кебек төшенчәләргә дә тулы һәм төгәл аңлатма бирелгән. Шигъри шәкелләр һәм чаралар да автор игътибарыннан читтә калмаган. Хатыйп аганың «Татар энциклопедиясе»н төзүдә катнашканын белә идек. Үз эшчәнлеген ул биредә дә уеп калдырган.

Китапның өченче бүлеге «XX йөз әдәбияты һәм фәне» дип атала. Биредә сүз Гаяз Исхакыйның әдәби эшчәнлеге белән бәйле. Тууына 130 ел тулу унае белән язылган мәкаләдә бөек әдип иҗатының милли асылы ассызыклана, иҗат методы ачыклана. Исхакый белән бәйле проблемаларга да тукталып: «Г.Исхакый образы әдәбиятта, сәнгатьтә бөтенләй диярлек гәүдәләндерелмәгән. Театрларыбыз да аның иҗатына бик сирәк мөрәҗәгать итә. Кайбер зыялыларыбыз Г.Исхакый пьесаларыннан һаман кимчелекләр эзли. [...] Ә кайда истәлек такталары? Һәйкәле юклыгын әйтеп тә тормыйм инде... Хәтта Казан —Чистай юлындагы Яуширмәнең Исхакый туган авыл икәнлеге дә күрсәтелмәгән«, — дип борчыла Х.Миңнегулов. Гаяз Исхакый һәм Финляндия татарлары мөнәсәбәтендәге язмада бәян ителгәнчә, «...Инкыйраз» авторының «Финляндиядә» исемле күләмле мәкаләсендә бу мәмләкәтнең сәяси бәйсезлек өчен көрәше, шул чордагы эчке тормышы, андагы милләттәшләребезнең хәл-әхвәле тарихи-мәдәни контекстта, гаять үтемле итеп яктыртылган.

Г.Ибраһимов иҗатына әтрафлы бәясе белән дә Х.Миңнегулов татар әдәбият белемгә җитди өлеш кертә. Сәяси система корбаны булган Г.Ибраһимовның сәяси, иҗтимагый һәм әдәби эшчәнлеге әтрафлы бәяләнә. Күпләгән милләт әһелләренең, татар язучыларының остазы булган шәхеснең гаҗәеп бай, күләмле мирасы, катлаулы, күпкырлы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге янадан-яңа тикшеренүләр өчен дә җирлек һәм чыганак ролен үти.

Олуг мөгаллим һәм әдәбиятчы Габдрахман Сәгъдинең тууына 120 ел тулу унаеннан бәян ителгән язма юбилярның тормыш һәм иҗат юлын яңа штрихлар

белән баета. Аның иҗатын үз иткән һәм хәерхаһлы мөнәсәбәттә булган фән әһелләрен һәм Г.Сәгъдигә кагылышлы якланган диссертация авторын, бастырылган китапларын безнең хөкемгә тәкъдим итә. «Әдәбият — заман көзгесе» исемле мәкаләдә традиция һәм новаторлык мәсьәләләре кузгатыла. Әдәби барыш һәм методологик принципларга ачыклык кертелә. Галимнәребезнең монографияләренә игътибарлы карашын житкерә.

Х.Миңнегуловның Муса Җәлил турындагы уйланулары да кызыклы һәм гыйбрәтле. Фәлсәфи уйланулар белән башланып киткән мәкаләдә Муса Җәлил иҗатына тирән анализ ясала һәм чор белән аваздашлыгын дәлилләү үзәк урынны алып тора. Аның шигъри дөньясына әхлакый һәм фәлсәфи жирлеген ачыклауга киң урын бирелә. Хөрлек һәм хаклык жырчысының кадере һәм бөеклеге исбатлана, актив табигатьле, хезмәт сөючән, тереклекне, матурлыкны, тулы канлы тормышны яратучы, оптимист шәхес булуына тагын бер укучы игътибары жәлеп ителә.

Тарихның гаять катлаулы һәм афәтле елларында иҗат иткән Кави Нәҗминең иҗат портреты да автор тарафыннан гаять жете буяулар белән тасвирлана. Дөрестән дә, татарның бу чордагы яшәеше зыялылары язмышында аеруча ачык күренә. К.Нәҗми иҗаты да XX йөзнең беренче яртысындагы ил һәм халык тарихының үзенчәлекле бер елъязмасы кебек.

Х.Миннегулов — заман белән бергә атлаучы әдип. Ул кая гына сәяхәт кылса да шунда ук жылы тәэсирләре белән уртаклашырга ашыга. Теге яки бу вакыйга һәм күзәтүләрен дә һәрдаим вакытлы матбугатта яктыртып бара. Аның яңа басылып чыккан китапларга карата язылган бәяләмәләре дә шактый. Әлеге хезмәтендә дә Хатыйп ага соңгы елларда гына дөнья күргән басмаларга бәяләмәләре белән уртаклаша. Аеруча «Казан утлары» журналының күләмле мәҗмугасы — «Сүнмәс утлар балкышы»на әтрафлы бәя бирә. Шагыйрьләр Ә.Рәшитов, К.Булатова һәм прозаик А.Гыйләжев иҗатлары да авторның күзәтүләреннән читтә калмаган. Болар исә Буа, Әлмәт, Сарман төбәгендә туып чыныккан талантлы әдипләр — шигъри бәйгеләрдә, туган тел өчен изге көрәштә алдан атлаучы илһамчылар. Бу унайдан шунысын да әйтү урынлы булыр: Хатыйп Йосыф улы борынгы һәм урта гасырлар әдәбияты белгече булса да, аның житәкчелегендә хәзерге шигърият буенча да берничә кандидатлык диссертацияләре яклануы Хатыйп аганың шигъри жанлы һәм нечкә, сизгер күңелле зат булуын раслый. Аеруча бер жылылык белән ул шагыйрь Рәдиф Гаташ иҗатына туктала. «Рәдиф Гаташ иҗаты — затлы шигъриятнең матур бер үрнәге. Затлылык, татарга хас әдәплелек аның тел-стилендә дә, шәкли корылышында да, мәгънәви эчтәлегендә дә ачык күренеп тора. Шагыйрьнең сүзсурәтләре ничектер күңелгә ятышлы, рухи ихтыяжларга аваздаш», — дип яза ул иҗатташы, мәсләктәше хакында.

Бүгенге көндә тарихларга кергән һәм кереп калачак данлыклы Казан дәүләт университеты белән «Гасырлар арасында уйланулар» китабын укып таныша аласыз. Бигрәк тә сүз күпләребезгә очар өчен канат куйган, тормышта үз урынын табарга юнәлеш биргән университетның татар теле һәм әдәбияты бүлеге хакында бара. Күпләрнең тормыш һәм иҗат юлы барлана. Университеттан соңгы эшчәнлекләре яктыртыла. Татар дөньясында үз урынын алганнарны туплап, матур хатирәләр, жылы истәлекләр белән үреп бирә. Татар факультетының үткән юлы — татар халкы язмышы белән охшаш иканлегенә төшендерә автор. Дөрестән дә, тарих кабатлана диләр бит...

«Чордашларым, гыйлемдәшләрем» исемле бүлек — әлеге китапның иң мәртәбәле һәм шул ук вакытта Кеше дигән затка карата кулланылган иң нечкә хисләрен белдерүче бүлекләренең берсе. Монда кешенең үзенә, бер-берсенә карата кылган гамәлләренең асылы да, жаваплылык хисенең көче дә, тормышта һәм яшәештәге кеше кадере — барысы да автор күзәтүләрендә һәм уйлануларында укучы хөкеменә тәкъдим ителә. Бу бер дә сентиментальлек яки тирәяктагыларга ярарга тырышу түгел, бәлки чын йөрәктән, ихлас күңелдән язылган тәгъбирләр жыелмасы, фикерләр тупланмасы, үз вакытында әйтелгән олуг рәхмәт хисләренең чагылышы. «Халкыбызда һәм, гомумән, кешеләрдә һәрчак хупла-

на, хөрмәт ителә торган сыйфатларның берсе — җаваплылык. Ягъни адәм баласының үз вазифасын, үзенә тапшырылган эшне намус белән җиренә җиткереп башкаруы. Андый кеше, башкалардан бигрәк үз-үзенә таләпчән була, шәхси эш-гамәле белән бүтәннәргә үрнәк булып тора, аларга әхлакый йогынты ясый, үз хезмәтенең иҗтимагый әһәмиятен тоеп эш итә. Мансур Хәсән улы Хәсәнов эшчәнлегендә мин әнә шул җаваплылык сыйфатының аеруча күркәм бер гәүдәләнешен күрәм», — дип яза Х.Миннегулов. Әйе, автор билгеләгәнчә, М.Хәсәнов — күпләргә үзенең яшәү, иҗат итү, кешеләрнең берберсенә карата матур мөгамәләсенең һәм җаваплылык хисенең эталоны булган бөекләрнең берсе. Якташы, азмы-күпме тигән ярдәме өчен генә әйтми Хатыйп ага аның хакындагы бу сүзләрне, ә тормышта бу сыйфатларның күпләрдә җитенкерәмәвенә борчылуын белгертә. М.Хәсәнов башлап йөргән, яки аның хәер-фатихасы белән башкарылган күп кенә эшләргә автор соклануын да яшерми. Андый даһиларны онытмаска чакыра.

Филология фәннәре докторлары Әхәт Нигъмәтуллин, Марсель Бакиров, Марсель Әхмәтҗанов турындагы җылы язмаларда да, Хатыйп Миннегуловка хас булганча, кешене хөрмәтләү, олылау, беренче чиратта кешелеклелеген, ихласлыгын бәяләү, аларга соклану һәм фән дөньясында яулаган үрләренә якын кешеләрдә генә булырдай куану, үз итү билгесе ярылып ята. Гыйльми эшчәнлекләрендә дәлиллеккә, мантыйклылыкка, гадилеккә һәм гаделлеккә нигезләнеп, миллилек тарафдары булырак танылучылар гына бу хөрмәтләүгә лаектыр, минемчә. Әле биредә исемнәре телгә алынмаган башка бик күп фән һәм иҗат әһелләренә дә әлеге хезмәттә урын түрдән бирелгән. Алар күп һәм аларны бер нәрсә — кеше хезмәтен күрү һәм бәяләү, кеше хезмәтендәге яңалыкны да үзенеке шикелле кабул итеп куана белү кебек матур сыйфатлар берләштерә.

«Сәфәрләргә йөреп гыйбрәт ал» бүлеге галимнең чит мәмләкәтләрдә булып кайтканнан соң туган кичерешләреннән чыгып язылган. Алар һәрберсе истәлек, хатирә һәм документальлек синтезларыннан гыйбарәт. Барысы да яратып һәм кызыксынып укырлык язмалар. Китапның ахырына якынлашкан саен Хатыйп аганың «кимлеген» белеп бетерергә дә мөмкин булыр иде. Тик «Хатыйп Миннегуловка — 70 яшь» — бүлек итеп аерым бирелмәсә, авторга карата әйтелгән җылы фикерләр китапка кермәсә, берьяклырак фикер формалашыр иде. Биредә аның хезмәттәшләре, укучылары фикерләре урын ала. Ул бу мактауларга үзенең хезмәте белән дә, исеме һәм җисмилеге белән дә лаек.

Китап ахырында бирелгән библиографик күрсәткеч, төсле фотографияләр дә хезмәтне бизи, тагын да масштаблырак, күркәмрәк итә. Йомгаклап әйткәндә, бу җитди һәм масштаблы хезмәттә әдәби мирасыбызның тамырлары, халыкара бәйләнешләре, татар сүз сәнгатенең үсеш баскычлары, язма ядкарьләре эчке закончалыкларында һәм әдәби-эстетик контекстта яктыртыла.

**Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

Фәндәс
Сафиуллин

# БӘЛӘКӘЙ ЧАК БӘЛӘКӘЙЛЕК ТҮГЕЛ УЛ

*Бала чак, Такташ әйтмешли, һәр нәрсәгә исең китеп дөнья белән танышып йөрү чоры. Тормышның һәр күренеше әле яңа чакта, беренче мәртәбә күргән, ишеткән һәр нәрсәне, һәр сүзне хәтереңә, күңелеңә сеңдереп йөргән көннәр өлкәннәрнең айларына, елларына тиң буладыр. Галимнәр раславынча, дөньяга килгән балада кешелек сыйфатларының гомерлек нигезе салыну, аның нәрсәгә дә булса сәләте, омтылышлары формалашуы 8-9 яшькә тикле генә дәвам итә. Аннан соңгы гомереӊ никадәр генә озын, тормыш тәҗрибәң никадәр генә бай булса да, бала чагыңда туплап, җаның, күңелең «киштәләренә» урнаштырып өлгергән хис-хәтер, акыл-аң хәзинәңне, кешелек үзенчәлекләреңне алыштыра да, артык үзгәртә дә алмыйсың. Шуңа күрәдер инде, бәләкәй чаклар бик еракта калган озын еллар булып, борынгы заманнар кебек хәтердә калалар. Ә олыгая барган саен еллар ваклана, «кыскара» баралар. Әгәр истә калырлык үзгәрешләр булмый торса, ул елларның үткәнен сизми дә каласың.*

*Озын гомер — озын хәтер дигән сүз ул.*

## Хәтерем кыйпылчыклары

Балачак хәтерем — минем иң кадерле гомерлек байлыгымдыр.

Хәтер капчыгымның төбендә бик иртә салынган, күп кеше ышанмаслык булып, сакланып калганнары да бар. Үскәчрәк, кайберсен әниемә сөйләгәндә, «Әллә шул да исеңдә калганмы?» дип гаҗәпләнә торган иде. Иң әвәлге хатирәләрем Мәлбагыш авылы белән бәйле. Азнакай районының шул авылында 1936 елның 17 августында мин дөньяга килгәнмен. Төп йортыбыз күрше Актүбәдә булган.

Әтием — башлангыч классларукытучысы. Әнием — колхоз батрагы.

Әтиемнен укытучылыгы да шул бер чама гына булгандыр инде — Мәлбагышта ТБУМ ны тәмамлаган «укымышлы» егет булгач, аны Бөгелмәгә бер елга укытучылыкка укырга җибәргәннәр. Шуннан кайткач, үзе укып чыккан мәктәпкә җибәргәннәр. Ә ТБУМ дигәне «тулы булмаган урта мәктәп» дигән сүз була. Ягъни булмавы — 7 сыйныфлы гына.

Мәлбагышта безгә яшәп торырга урын биргән Гайшә апалар өендә миңа бер яшь тулганчы торганбыз. Шул бер яшькә кадәр гомеремнең дә кайбер мәлләре хәтеремдә. Әниемнең мине бәләкәй арбага утыртып каядыр алып барганы истә. Ошап житмәде бугай ул арба: баш очы ябык, караңгы, аннан берни күренми. Курыкканмындыр, күрәсең. Беренче утыруым булгандыр инде. Аннан соң күп йөртсәләр дә, алары истә калмаган. Ул арбаларның әрҗәсен дә, түр ягындагы түбәсен дә юан юкәнең кайрысыннан, түгәрәкләп бөгеп ясый торган булганнар. Аның төзелешен үземнән калган шул арбаны тартып-сөйрәп уйный башлагач күргәнмендер инде.

Искәртеп китәргә оныта язганмын: мәктәп яшемә житкәнчегә кадәр мин «әтием», «әнием» дип сөйләшә идем. Урам малайлары да мине «әтием Фәндәс», «әнием Фәндәс» дип үртиләр иде.

Ул чорда «декретный отпуск», ясле кебек нәрсәләр авыл кешесенең әкиятләрендә дә булмагандыр. Әтием-әнием эшкә киткәндә мине әбиле күрше-тирәгә калдыра торган булганнар.

Дүрт аяклап йөргән чагымдагы «ясләләремнән» кайбер күренешләр хәтеремдә. Әнием мине күтәреп кемгәдер алып керде дә, аларның сәкеләренә утыртып чыгып китте. Ә сәкедә бәләкәй кызлар «чәй эчеп» утыралар. Алларында шешә — «самавыр», кулларында чынаяк ватыклары, шулардан «чәй» чөмерәләр, курчакларын «сыйлыйлар». Мина бернинди игътибар да, «чәй» бирүче дә юк. Тавышым чыккач кына искәрделәр мине.

Әнием мине тагын бер «яслегә» алып кергәндә, андагы сәкенең әйберләрен читкәрәк этәргәннәр, такталарын күтәреп маташалар. Ә сәке астында бер бәләкәй малай арт ягын тункайтып, кулларына йөзтүбән капланып йоклап ята.

Әтием каяндыр өстен кар каплаган киемнәре белән кайтып керде. Әнием матур зәңгәр пыяла савыттагы коймакларны мичтә пешеп яткан ипи янына куйды. Ә пыяла савыт шылт итеп, урталай ярылып, ике кырые ике якка ауды. Минем урыным нәкъ мич каршында иде. Янган утыннарның тере ялкыннары хәтердә.

Санап китсәм, хәтеремдә шактый күп алар — андый аерым, кыска күренешләр. Шулар арасында бер бик тетрәндергече дә бар. Анысын озынрак итеп хәтерлим. Бу хәтәр хәл 1937 елның җәендә булган. Әтием каяндыр ашыгып кайтып керде. Рамлы ике сурәт алып кайткан. Урындыкка басып, чүкеч белән стенага кадак кагып, шул сурәтләрне әнием белән элә башладылар. Мин үрмәләп әтием тирәсенә килгәндә шул рамнарның берсе, әтиемнең кулыннан ычкынныпмы, бавы өзелепме, почмагы белән минем башка килеп төште. Ачы тавыш янгыраганын хәтерлим — минеке булдымы икән, әниемнекеме — белмим. Әнием мине күтәреп алып, ак яулыгы белән башымны кысып каплады. Әтием ишекне бәреп чыгып йөгерде, тиз арада бер җигелгән атның арбасына аягүрә баскан килеш кайтып житте. Атны чаптырып, мине каядыр алып киттеләр. Башымны әнием кысып каплаган ак яулыкның битемә төшеп торган очындагы кызыл таплар хәтеремдә калган. Барып житкәнебезне, анда мине кем, ничек коткарып калганын хәтерләмим. Бәлки, аңымны җуйганмындыр. Әнием сөйләвенчә, ул авылның «дуктырына» барып житкәнче бер тавыш-тыным чыкмаган, аны шул бик куркыткан. Инде бик күп еллар үткәч, әниемне дә соңгы юлына озаткач кына бу хәлнең миңа житкерелмәгән сәбәбен, тарихын белергә насыйп булды. Үзе дә китәр алдыннан миңа аны әтиемнең сеңлесе Мәрзия апа сөйләп калдырды.

Әтием өстеннән әләк килгән булган. Бу турыда әтиемне кемдер шыпырт кына кисәткән. Мәктәп директоры булса кирәк. Анысын Мәрзия апа төгәл әйтә алмады. Кем генә булса да, бик тәвәккәл, кеше җанлы зат булган инде. Ул елны, ягъни 1937 елда авыллардан бик күп укытучыларны алып китеп атып үтергәннәр бит. Минем икенче туган авылым булып киткән Актүбәнең өч укытучысыннан икесен атканнар. Бер гаепсезгә. Аларның берсе, Тәрҗеманов Заһит абый, 1920 елда Актүбә авылы оешканда үзенең алты почмаклы бик матур йортын авылның түбән очында, аерым урында, инешебезнең биек яры башында урманга терәп салган булган. Житмәсә тагын аны калай түбә белән каплаган. Бөтен авыл салам түбәле, ә анарда — калай. Менә шул калай түбә, үзенең хуҗасының «контра» икәнен «раслап», совет хакимиятенә тагын бер «куркыныч» өстәгән. Хәзерге Россиягә татарның латин хәрефләре кебек. Икенче атылган укытучы Мортазин абыйның нәрсәсе совет хөкүмәтенә «куркыныч» булып күренгәндер, анысын белмим.

Донос житкерүче әтиемне нәрсәдә гаепләгәнен, бераз унайсызрак булса да, әйтәм инде. Миңа бер яшь туласы, шул 1937 елның җәендә әтием ата-бабаларыбыздан килгән бер мөселман йоласын үтәгән. Шуны районга житкергәннәр. Әтиемне кисәткәндә, районнан кемнеңдер киләсен әйткәннәр. «Бәлки, алып китүчеләр дә түгелдер, тикшерүчеләр генәдер. «Өеңдә бер-ике юлбашчыбызның сурәтләрен элеп куй», дип киңәш иткәннәр. Шуларның икесен әтием мәктәптән алып кайткан булган. Суга батканда саламга тотыну инде бу. Тикшерүләр булганмы-юкмы, анысын белмим. Булса да, НКВДдан түгелдер ул. Донос аларга ук барып житмәгәндер, күрәсең. Бәлки, минем башны ярган бәла эшне бераз кичектергәндер. Шул

хәлләрдән соң әтиемне тиз генә Мәлбагыштан шактый ерак урнашкан кечкенә бер авылга — Мәнәвезгә күчергәннәр.

Ул авылдан да хәтеремдә калган бер шомлы истәлек бар. Без күченеп урнашу белән бер коры, эссе көнне авылда янгын чыккан. Жил уңаенда урнашкан салам түбәле өйләр берсе артыннан икенчесе дөрләп кабына башлаганнар. Аларын мин күрмәгәнмендер. Хәтеремдә кешеләрнең кычкырышуы, йөгерешүе, ниндидер шатыртаган, улаган тавышлар гына калган. Тәрәзәдән әйберләр ыргыталар. Мине ишек алдына чыгарып утырттылар. Аннан әнием мине күтәреп алып каядыр йөгерде дә, әллә нинди яшел куаклар арасына утыртып калдырды. Бәрәңге бакчасы булгандыр инде. Өстә биектә каралы-аклы әшәке болыт агыла. Аның астыннан кызыл очкыннары чәчелеп бара торган ниндидер кара әйберләр оча. Мин шуларга карап тик кенә утырам. Без урнашкан өйгә янгын тимәгән. Салам түбәсен су сибеп ныклап чылатып өлгергәннәр...



Әтиемне аннары, уку елы башланганчы ук, Актүбәгә күчергәннәр. Анда бер ел укыткач, Мәсгут авылында, аннан Әлмәт районының Нәдер авылында укытты әтием. Ул чорда яшьрәк укытучыларны, чегәннәр кебек итеп, ел саен күчереп, бутап интектергәннәр. Контрреволюция оештырмасыннар дип курыкканнардыр инде.

Ә теге портретлар әтием белән бергә күченеп йөрделәр. Берсендә мыеклы, борыны өстенә тоткасыз күзлек элеп куйган абзый. Икенчесе кәҗә сакаллы, мыегы да бар, күзлеген колакларына эләктергән. Безгә кагылып үткән кайбер әбиләр, бабайлар: «Болары кемнәрегез була инде?» — дип сораганда, телем ачылгач, мин җавап бирә идем: «Монысы — Молотов Вячеслав Михайлович, бусы — Калинин Михаил Иванович», дип. Сонрак алар янына, әтием нигәдер Мичурин портретын да элеп куйган иде. Әтиемне сугышка озатып, әнием белән Нәдердән Актүбәгә кайтып киткәндә, алар өчесе дә шунда калдылар. Мичуринның исеме истә калмаган. Ә шулай да мин аның үзен онытмадым. 1956 елда безне, Саратов танк училищесы курсантларын, Белоруссияга практикага алып барганда, Тамбов өлкәсенең Мичурин шәһәре станциясендә поездларыбызны алыштырырга шактый озакка тукталган идек. Мичуринның атаклы бакчасын ашыкмыйча йөреп, күреп чыга алдым.

## «Сугыш башланган!»

Безнең буын — бәләкәй чакларыбыз сугыш уты белән көйдерелеп, бик күпләребез әтиләрсез калып, ятимлек дөньясында үскән балалар. Минем хәтеремдә дә иң тирән, әрнеп янара торган эзләрне сугыш һәм сугыштан соңгы еллар калдырды.

Сугыш башланган көнне ачык хәтерлим. Мина инде 4 яшь тә 10 ай. Без Әлмәт районынын Нәдер авылында торабыз. 1940-41 уку елында әтием шул авылның мәктәбендә укытты. 22 июнь — авылларда сабан туе булган көне. Рәхимсез Сталин заманында Татарстандагы татар авылларын хәзерге кебек сабан туен июнь башында, салкын яңгырлар астында үткәрергә указ белән мәҗбүр итмәгәннәр. Халкыбыз үзенең иң күркәм бәйрәме көнен үзе билгели алган.

1941 елгы Нәдер авылы сабан туе минем өчен бу матур бәйрәмебезне беренче мәртәбә күрүем иде. Ә онытылмаслык шомлы тәэсирне күңелемдә аның куркыныч хәбәр белән тәмамлануы калдырды. Әле генә уен-көлке бара иде. Әтием йөгерештә җинеп, бер тартма исле сабыннар алды. (Хәзерге «туалетное мыло» шулай дип атала иде элегрәк). Аны мәктәп кызлары чорнап алдылар, чыр-чыр килеп сикерешәләр. Әтием аларга шул матур сабыннарын өләшеп бетерде, әниемә берсе дә калмады. Аннан соң тагын ниндидер уенда өстәлгә куешлы бик матур көзге отты. Анысын

әниемә тоттырды. Шул вакыт бөтен халык кинәт тып-тын калды. Авыл ягыннан кемдер атка атланып мәйдан ягына чаба, үзе нидер кычкыра, сызгыра. Килеп житкәч, артык кычкырмыйча гына: «Сугыш башланган!» дип, тагын нәрсәдер әйтте дә, кирегә чапты. Халыкның тып-тын калып таралганын хәтерлим.

Әтиемне сугышка без ике мәртәбә озаттык. Мин әле ул «сугыш» дигән нәрсәнең ни икәнен дә, кайда икәнен дә белмим. Бәлки, өлкәннәр дә илгә нинди куркыныч афәт килгәненнәнә баштарак ышанып та житмәгәннәрдер, беренче китүчеләрне әле ничектер жинелрәк озаттылар. Әтиемнең алар белән китеп баруы истә калмаган. Кире әйләнеп кайтканын хәтерлим. Көлемсерәп кайтып керде. «Менә сезгә куян күчтәнәче» дип, өстәлгә жилкә капчыгыннан әнием пешереп салып жибәргән ризыкларны бушатты. Ә алар барысы да диярлек күгәргәннәр. Исән сыманнарын сындырып, аларының да күгәргәнлеген күреп көлешәләр, ә мин «куян күчтәнәче» көтеп утырам.

Биш яшьлек гомеремдә сәгатьләре-минутлары белән хәтеремдә калган көн — әтиемне ахыр мәртәбә сугышка озаткан көн булды.

Кире әйләнеп кайтуыннан ничә көннәр үткәндер, әтиемә «сугышка чакыру» кабат килгән. Аңа гына түгел, авылның бик күп ир-егетләренә. Әллә нинди авыр көн булды ул. Урамда балалар да, ә кич житкәч, капка төпләренә чыгып утыручылар да юк. Икенче көнне иртән урам буйлап жигүле атлар тора. Арбаларына абыйлар, апалар утыралар. Алар янында әбиләр, бабайлар, балалар. Әтиемне алып китәсе арбага без дүртебез утырдык: әтием, әнием, мин һәм безне илтүче абзый. Барыбыз да берьюлы кузгалып, Зәй елгасын суы сай урыныннан кичеп, Әлмәткә юнәлдек. Без барган саен юлчылар күбәя, башка яклардан да күп халык кузгалган. Әлмәткә кергәндә, атлы арбаларның, жәяүләп баручыларның башы-очы күренми иде. Китүчеләрне теркәү, туплау урыны «райвоенкомат» дигән урын. Иртәрәк килеп житкәнбез булса кирәк, әтием мине житәкләп каядыр алып китте. Бер кибеткә кердек. Киштәсендә бер бик матур уенчык үрдәк бәбкәсе күреп, шуна күзем төште. Үзе сап-сары, томшыгы, күзләре кара. Агачтан уеп ясалган булгандыр инде. Ул чорда баланың күңеленә ятышсыз, жансыз пластмасс уенчыклар юк иде бит әле. Бик кызыктым шул үрдәк бәбкәсенә. Әтием шуны алып бирер дип көтсәм дә, ул аны алмады, житәкләп кибеттән алып чыгып китте. Бераз үсә төшкәч, шуны искә алып әниемә сөйләгәч кенә белдем: әтием юлга дип алган акчасын да китәргә чыкканда өстәл тартмасына салып, калдырып киткән булган. Кибеткә кергәндә шуны онытып булгандыр инде.

Халык жыелган урынга барып житүебезгә, китүчеләрне тезеп бастыра башлаганнар иде. Исемен ишеткәч, әтием дә барып басты. Бик күп булдылар алар — ул көнне сугышка китүче әтиләр, абыйлар. Барлап бетергәч, барысын да яңадан тигезләп, әллә ничә рәткә бастырып тезделәр. Алларында озын, киң, тирән ниндидер котсыз чокыр. Шуннан чыккан кызыл балчык өстенә бер кеше чыгып басты. Башында матур кепка, билендә каеш. Жилкәсенә аскан сумкасыннан бер кәгазь чыгарып, тезелеп баскан ирләргә нидер акырып жибәрде. Тегеләр барысы да бер тезләре белән жиргә тезләнделәр. Балчык өеме өстенә баскан теге кеше кәгазеннән нидер кычкырып укый, ә тезләнгән әтиләр, абыйлар шуны еракта күк күкрәгән төсле гөрелдәп чыккан тавыш белән кабатлап торалар. «Присяга» дигән нәрсә булгандыр инде ул.

Теге кәгазь укылып беткәч, китүчеләрне юлга чыгарып тезә башладылар. Менә шунда башланды инде хушлашулар, саубуллашулар. Аны үзе күрмәгән, ишетмәгән кеше күз алдына китерерлек итеп сурәтләп булмый торгандыр. Кычкырып, үкереп елауларны хәтерләмим. Бөтен яктан сүзләрен аермаслык тоташ гөжләгән тавыш, аерым яңгырап киткән хатын-кызлар тавышы ишетелә.

Ниһаять, китүчеләр колоннасы кузгалды. Әтиләребезне жәяүләп Бөгелмәгә алып киттеләр. 60 чакрымлап атлыйсы, йомры ташлар жәйгән юл иде ул. Асфальтлысы ул чорда әле юк иде. Жәяүле, атлы озатучылар юл кырыеннан баралар. Жәяүлеләрнең аяк астыннан томан сыман тузан күтәрелә. Әтиемне 10-12 чакрым, Габдрахман авылына тикле, озата бардык. Авыл урамына бик күп кешеләр чыккан иде. Юлның сул ягындагы беренче йорт яныннан үткәндә мин кычкырып елап жибәрдем. Әтием

йөгереп килеп, «Ни булды, улым», дип сорагач, «су эчәсем килә» дидем. Әтием шул юл буендагы йорттан бер калай чүмечне тутырып су алып килде. Эчәсем дә килмәгәндер инде, бик озак итеп чөмердем мин ул суны. Хушлашканда әтиемнең миңа ни әйткәне нигәдер хәтеремдә сакланмаган. Соңгы истәлеге итеп миңа үзенең «Ворошиловский стрелок» дигән значогын биргәнен, аннары колоннага үз урынына йөгергәнен хәтерлим. Саклый алмадым мин әтиемнең соңгы бүләген. Актүбәгә күченеп кайткач, үземнән олырак бер малай нәрсә беләндер алдап алды да, кире бирмәде. Бала чагымнан ук кешегә тиз ышанып, җинел алдануымнан инде картайганчы да арына алмадым. Гомер юлымдагы бөтен күнелсез әйберләр, ялгышуларым шуннан гына булдылар кебек.

Исән-сау әтием белән мәңгелеккә хушлашкан көннең соңгы минутлары да бүгенгедәй күз алдымда. Еш искә алына торган көннәр онытылмыйлар инде алар.

Нәдергә, бушап калган өебезгә кайтып керү белән, әнием идәнгә җәелгән паласка авып, йөзтүбән капланды. Җилкәләре селкенеп-селкенеп китә, тавышсыз-тынсыз гына елый. Мин түргә узарга да кыймыйча, каушап, ишек бусагасына утырып калдым. Ишек яңагына сөялеп, шунда йоклап та киткәнмен.

1941 елның җәе. Төгәл датасын белмим. Әтиемә — 32, әниемә — 27, миңа тулыр-тулмас 5 яшь... Бу көн бәләкәй чагымның иң авыр, иң караңгы көне булгандыр.

Әйтеп үтәргә онытканмын: миннән соң туган ике кечкенә сеңелләрем инде юк иделәр. Яшәү, күрәсең, аларга насыйп булмаган.

Әтине озаткач та Актүбәгә кайтырга җыендык. Җыену дигәннән — артык мәшәкатьләнәсе дә юк иде инде: бер өстәл, дүрт урындык (аларның берсе әле дә исән), ике зур төенчек — берсендә савыт-саба, икенчесендә кием-салым. Барыбыз да бер арбага сыйдык. Мине озатырга бергә уйнап-тәгәрәп йөргән абыйлы-энеле күрше ике малай килделәр. Олырагы минем яшьтәшем Рәмзи. Кечерәге, бәләкәй Рәфис, күкрәгенә кысып зур кыңгырау тоткан. Андый кыңгырауны көтүдән качып йөри торган усал сыерның муенына тагалар иде. Шуны миңа бүләк итәргә җыена бу, ә аның үзенә дә бик кирәк икәне күренеп тора. Әнием аңа: «Рәфис, Актүбәдә безнең андый кыңгырау бар инде» дигәч, тынычланды бәләкәй дустым.

Безне Актүбәгә дә әтиебезне «сугышка алып киткән» абзый илтте. Кайтканыбызны хәтерлим, ләкин юлда булган бер кызык хәлне әнием сөйләвеннән генә беләм. Безне илтүче абзый кемгә кайтуыбыз белән кызыксынгач, әнием миннән: «Улым, кайсы әбиләреңә кайтыйк соң», дип сораган. «Ерак әбиләргә кайтыйк, аларның бакчасы зур, бәрәңгеләре күп була», дигәнмен. Әтиемнең әтисе Сафиулла бабай инде күптән вафат иде. Аның бакчасы, «якын» Сәҗидә әбиемә җитәрлек булса да, чынлап та башкаларныкыннан кечерәк булган. Ә әниемнең әтисе-әнисе, «ерак» Хәҗи бабам белән Хәерлебанат әбием шактый көр яшиләр иде. Аларга кайтуыбыз, әлбәттә, минем «кинәш» буенча булмаган. Аныңчы ук килешенгән булган. «Синең алда бакчалар, бәрәңгеләр турында сөйләшкән дә булмады бит, каян чыкты икән ул сүзең», дип әнием искә алып аптырый иде.

## Бәләкәй чагым Актүбәдә калды

Киң дөньяга күзем ачылган, сабыйчак хатирәләремне иң нык баеткан, җанымтәнем өчен йомшак һәм җылы оям булган төбәк — Актүбәм. Бик җыйнак, 40 хуҗалыклы гына, су буена бер яклы урам булып кына урнашкан авыл иде минем балачак Актүбәм. Кайсы авылга күченеп йөрсәк тә, без аннан аерылмадык. Еш кайта идек, җәй көннәремнең дә күбесе шунда үтте.

Актүбә XX гасырның 20нче еллары башында, совет заманында гына Азнакай районы җирлегендә оешкан авыл.

Татарстан хөкүмәтенең беренче җитәкчеләреннән берсе Кашаф Мөхтәровның бик кыю тырышлыгы белән шул елларда байтак кына яңа татар авыллары барлыкка килгән. Аның бу эшендә төп максат Идел, Кама буйларындагы Казан ханлыгын яулап алганда юк ителгән авылларны торгызу булган. Бөтен Татарстан буенча яңа авыллар төзүгә ирек бирү һәм ярдәм итү шул төп максатны ачыктан-ачык күрсәтергә

теләмәү булгандыр инде. Шул тырышлыгы аның гомерен өзгән, ике мәртәбә кулга алынып, соңгысында — 1937 елда атып үтерелгән.

Актүбәне Азнакай районының Мәлбагыш авылыннан бер төркем, Әлмәт районының Кама Исмәгыйль авылыннан икенче төркем бик эшчән, үткер ирләр — безнең бабайларыбыз, үз авылларыннан аерылып чыгып, ике ел эчендә матурлап төзеп тә куйганнар. Табигатьнең үзләре сайлап алган гүзәл бер почмагында, өч ягыннан урман төреп алган, күп чишмәле, зирек, шомырт урманы баскан инеш буендагы аулак урынга төпләнергә рөхсәт ала алганнар. Минем бер бабам — Хажи бабай, Хәерлебанат әбием белән балаларын, шулар арасында минем әнием булачак 8 яшьлек Сәмиганы да ияртеп Камыдан, икенче бабам Сафиулла бабай һәм Сажидә әбием, минем әтием булачак 13 яшьлек Миншакирны һәм башка балалары белән, Мәлбагыштан килеп Актүбә жирендә урнашканнар.

Әтием-әниемнең гаилә тормышы Актүбә жирлегендә башланган. Үземнеке дә шулай ук булды. Тормыш иптәшем, Камил абзый белән Кәримә апаның кызлары яшьтәшем Рәзинәм белән, бәләкәй чактан ук бергә, бер-беребезне күзәтеп үстек. Беренче класстан башлап жиденчене тәмамлаганчы бергә укыдык. Бер партада утырырга гына туры килмәде.

Без үскәндә әле искереп өлгермәгән гажәеп матур авылыбыз, аның урнашкан жиресуы үтеп йөрүче юлчыларны да туктатып сокландыра иде. Без, әтиләребездән аерылган сугыш еллары балалары, шул матур табигатебезнең кочагында иркәләнеп үстек. Хәрби хезмәттә, читтә яшәгәндә бик сагына идем авылымны. Хәзер дә искә алып юксынам, чөнки элекке Актүбәм юк инде... Дөрес, ул таралып-чәчелеп юкка чыкмады. Иске Актүбә хәзер 50 нче елларда урман-кырларны кысрыклап, жиләкле яланнарыбызны таптап калыккан нефтьчеләр бистәсенең бер урамы гына булып калды.

## Сугыш еллары һәм аннан соңраклары

Әкренләп, озакка сузылган, олысына да, кечесенә дә, барысына да рәхимсез кырыс «сугыш еллары» дигән тормыш башланды. Ул еллар һәм аннан соңгылары инде берөзлексез диярлек хәтеремдә. Барысын да бәйләп, ялгап язсам, бик күпкә китәр иде ул. Шуңа күрә бу язмамны аерым өзекләр төсендә генә, нәрсәләрне искә алырга дигән «исемлегем» буенча гына дәвам итәм.

Беренче чиратта, жаныма сеңеп калган бер кара көн күз алдыма килеп баса. Мина биш яшь ярым булгандыр. Сугыш башлануга шактый вакыт үтеп, салкын кыш килеп житкән. Жәй көне үк китеп барган әтиемнән дә, Әнвәр абыйдан да (әниемнең энесе) бер хәбәр юк. Әбиемнең аз гына, үзе әйткәндәй, «тын алырга» вакыты булган арада капка төбенә чыгып, яисә койма өстенә үрелеп, хәбәр көтеп юлга, авыл башына карап торганы хәтеремдә.

Беркөнне шулай иртән йокыдан уянгач, өйдәге ниндидер сәер тынлыкка игътибар иттем. Бабамның да ишек алдында шакы-шокы килгәне ишетелми, эчке яктан әбиемнең дә табак-савыты шалтырамый. Өстәлдә, иртән торуыма әбием мина әзерләп, өстенә ипи телеме каплап куя торган сөт савыты да юк. Түр якның ишеген куркып кына, әкрен генә ачтым. Ачтым да куркып калдым — әбием, бабам (бала чагымда шулай әйтә идем: «әбием», бабам» дип) икесе сәкенең ике ягында стенага сөялеп утырганнар, башлары иелгән, жилкәләре ингән... Тыныч кына, бер сүз дәшмичә елыйлар... Әбием башын күтәреп мина карап: «Әнвәр абыеңның үле хәбәре килде бит, улым», диде дә, күзләрен яулыгы белән каплап, үксеп елый башлады.

Кеше башына төшкән ачы кайгының нәрсә икәне шул көнне аңыма ныклап сеңеп калгандыр. Бераз соңрак, берничә хаты-хәбәре килгәннән соң, әтием дә Ленинград, Волхов тирәләрендә хәбәрсез югалды. 1942 елда һәлак булуы сугыштан соң гына ачыкланды. Ул орденсыз-медальсез рядовой солдат булып һәлак булган, ә Әнвәр абый лейтенант дәрәжәсенә житеп өлгергән иде.

Актүбәдә әнием хәрбиләштергән леспромхозга эшкә урнашты. Кышын, язын урман кисәләр. Иптәшләре, күпчелек, күрше урыс авылының эре гәүдәле маржалары. Мотопила дигән әйберләре юк. Кул пычкысы белән юан-юан агачларны аударалар.

Көнлек норма — һәр кисүчегә алты кубметр. Әниемнең пычкысы үзеннән аз гына кыскарак. Без, берничә малай, чаңгы тагып, урман аударганны күрергә баргач, безнең күз алдында кисеп аударган зур каен читкә тайпылып өлгермәгән бер марҗаны басты. Әле ярый ботаклы урыны туры килмәгән, кар да бик калын булган. Исән калды, атлы чанага салып алып киттеләр.

Яз үтеп юллар төшкәч, кискән имәннәрне шпал ясарга озаталар, каеннардан дегет, сумала куу башлана. Каеннарны ваклап кисеп-ярып, тракторларга, машиналарга ягулык итеп тә кулланып карадылар ул елларда. Бу саташып язуым түгел. Чынлап та машина-тракторларны утын ягып йөрергә дә «өйрәттеләр». Яннарына беркетеп куелган озын мичкә сыман «газогенератор» дигән нәмәрсәгә коры каен шакмаклары тутырып, көйрәтеп яндырсаң, шуннан машинаны эшләтерлек яна торган газ чыга икән.

Эшкә яраксыз «урманны» Бөгелмәнең госпиталенә һәм төрмәсенә утынга алып китәләр иде. Шуларны ташучы ике машина Актүбә малай-шалайларының барысының да хәтерендә калгандыр. Берсенең шоферы Нюра апа, безнең дус. Авылга кергәч тә машинасын туктата. Без йөгереп килеп «әрҗәсенә» менеп утырабыз. Радиаторына салырга су кирәк булса, чабышып алып киләбез. «Урманны» төягәч, аның өстенә менеп утырып кайтабыз. Хәзерге ГАИ булса, каты эләгер иде Нюра апага.

Икенчесе — Саша исемле бер явыз. Бөгелмә төрмәсеннән. Машинасы кап-кара төстә. Авыл аркылы үткәндә, туктату түгел, әкренәйтми дә машинасын, тавык-чебешне куркытып чаптыра гына. Бөтен куаныч тыкрык ягына борылганда әрҗәсенең артына ябышып, куллар арганчы бару. Төшеп калганда абынмыйча бик каты йөгерергә кирәк була. Юкса мәтәлләп тәгәрисең. Бер вакыт без моңа каршы, Нюра апа килми торган көнне, «диверсия» ясарга булдык. Килүенә шул тыкрык борылмасында тәгәрмәч эзләре турында ике чокыр казып, буадан ташып су тутырып куйдык. Безнең якта үзле балчык, су тиз генә китми. Максатыбыз — бу явызны «буксовать иттерү». Качып көтеп утырабыз моны, үч алырга өмет итеп. Килеп житте бу. Коры көнне юл өстендә нинди су булуын чамалапмы, бераз гына әкренәйтте дә машинасын, без салган суларны ике якка чәчрәтеп, чапылдатып үтеп тә китте. «Диверсия» барып чыкмады. Хәзерге заман булса, « В деревне Актюба предотвращена попытка террористического акта!», дип шауларлар иде. Соңрак барыбер үчен алдык тегенең. «Гранаталар» ыргытып жанына тидек. Ул «гранаталар»ны ясау да, куллану да бик гади генә. Коры көннәрдә юлларда, арба эзләрендә көлгә әйләнгән туфракны кул белән сыпырып жыеп, әрекмән яфрагына әйбәтләп төреп, «дошман» машинасының тәрәзәсенә тондырсаң, тузан болыты граната шартлаганнан ким булмый.

Сугыш елларының төрле кыенлыклары олысын-кечесен аермаса да, бала кешегә табигать барыбер бер өстенлек бирә. Бәләкәй чагында тормышның куркынычлы үзгәрешләрен, жан өзгеч күренешләрен тулысынча сизеп-аңлап бетерә алмыйсың. Чөнки бала кешенең яхшыны, начарны чагыштырырлык тормыш тәжрибәсе юк, бар күргәненне «табигый» итеп кабул итәсең. Тормышның башкача да булганын, башка төрле булырга тиешлеген дә әле аңлап, төшенеп житкермисең. Ул турыда, әкиятләргә ышанган кебек, хыялланасың гына. Бездән өлкән буынның, әтиләребез-әниләребез, әбиләребез-бабаларыбыз кичергән кайгы-хәсрәтнең, акылга сыймаслык гаделсезлекләрнең, авырлыкларның күбесен үзең күреп үссәң дә, аларны аңлап, янадан әрнеп кичерү соңрак килә икән шул. Анысы да, әгәр хәтерең исән-сау булса гына. Хәтерсезләргә яшәү күпкә жинелрәктер.

Сугыш һәм сугыштан соңгы Актүбә колхозы тормышыннан берничә күренешне искә алып китим әле.

Яз житкән. Сабанга чыгарга әзерләнәләр. Техника юк. Трактор урынына атлар да хатын-кызлар. Бераз печән өстәлгән, ваклап тураган салам ашап кына кышны чыккан атлар тәмам хәлсезләнгәннәр. Иртәнге якта яткан урыннарыннан кешеләр ярдәм итмичә торып баса алмыйлар. Минем бабам ат караучы иде, барысын да күреп беләм. Шул атларны күтәртеп бастырырга колхоз бригадиры дәшкән башка бабайлар да, олырак малайлар да киләләр. Ат абзарында ул бичара хайваннарны күтәртә торган бер корылма да була иде. Ул «спорт борыслары» дигән әйберне хәтерләтә. Аны яткан атның ике ягына бастырып куялар. Бер як киртәсенә киң озын

каеш бәйләнгән. Анын икенче очын атнын астыннан, күкрәге тирәсеннән үткәреп, икенче киртә өстеннән салындырып төшерәләр дә, берничә кеше шуна тотынып аска тарталар. Ат үзе дә тырыша. Торып баскач, ул әле дер-дер калтырап тора. Аңа бер чиләк жылымса суга нидер бутап эчәргә бирәләр. Шуны эчкәч, сабанчы хатын аны, йөгән кидереп, житәкләп, жир сөрергә алып китә. Ә ул хатын үзе ни ашап-эчеп, балаларына нәрсә калдырып киткән — анысын үзе генә белә. Бабам, шул атларны эшкә озатып кайткач, өстәл янында берүзе, бер сүз эндәшмичә озак кына утыра торган иде.

Урак өсте житкән. Халык карангыдан карангыга тикле басуда, кырда, ындыр табагында. Суктыргыч астыннан чыккан ашлыкны веялка аша үткәреп чистартырга, капчыкларга тутырырга, башка төрле ашыгыч эшләргә төнге сменага да калдыралар. Анысы ярты кило чамасы ипи хакына. «Веялка» дигән нәрсәне көне-төне әйләндерергә бер ат көче кирәктер. Аны ике хатын-кыз әйләндерә. Хәл алырга дип, шул үзләре чистарткан ашлык өстенә утырып, йокымсырап китә башласалар, наганын болгый-болгый акырып, «пулнамучный» килеп житә. Язгы сабан, чәчү, жәйге урак өсте житкәндә авылга районнан «районный уполномоченный» дигән бер бәндә килеп төшә иде. Тарантаска жигелгән яхшы ат белән. Сонрак елларда сугыштан кайткан Америка «виллисы» да күренә башлады. Нәрсәгә утырып килсә дә, билендә каеш, каешында наган, авызында шул наганнан атылган төсле янгыраган сүзләр.

Урак өсте бетте. «Уныш бирү» көне килеп житте. Еллык «эш хакын» түләүне «уныш бирү» дип әйтәләр иде. Колхозда акчалата түләү ишетелмәгән-күренмәгән нәрсә. Хрущев заманында гына башланды бугай ул. Ә теге елларда бөртекле ашлык яисә он белән «түлиләр» иде.

Кайсы ел икәнен белмим, без малай-шалайлар урамда шау-гөр килеп «клүкле» уйныйбыз. «Городки»га ошаганрак уен инде. Капка төбенә чыккан әбием мине чакырып алды да: «Улым, амбарда уныш бирәләр икән. Йөгереп кенә барып алып кайт әле», дип, башындагы яулыгын салып миңа тотырды. Монынчы урамда, йә ишек алдында әбиемне яулыксыз күргәнем юк иде. Йөгердем. Ат караучы бабамнын еллык «эш хакын», берничә кило арыш онын, әбиемнен яулыгына салып алып кайттым.

Бер тиен эш хакы алмый торган авыл халкынын жилеген суырган налоглар, заемнар — аларны ничек түләргә? Аны хәзерге заман кешесе, бигрәк тә шәһәрнеке, күз алдына да китерә алмый. Бер сыердан гына өч төрле налог: акчалата, сөт яисә май. Һәм ит! Сыерыннын ботын кисеп илтеп булмый бит инде. Димәк, бозавын үстереп суеп түлисен. Сарык суйсан, үзенә эчәген, үпкә-бавырын, башын, аякларын калдырып, түшкәсен базарга илтәсен. «Сталин заманында ел саен бәяләрне төшерәләр иде. Карточная системаны отменять иттеләр» дип лыгырдаучыларны ишетсәм, ачуымнан тешләрем кысылып, янак сөякләрем шыгырдый. Булсын иде әле авылларда шул «карточная система»!

Дәүләтне, фронтны икмәк белән туендырып та, ачлыктан, хәерчелектән үлгән балаларынын күзләрен йомдырган аналарны күз алдына китереп карагыз! Әйе, зур бакчалы Актүбәдә ачка үлүчеләр булмады булуын, ә үлем чигендә ачка интегүчеләр булды.

Бабайларыбыз Актүбәне төзегәндә кырыгар сутый жир бүлеп алып өлгергәннәр. Коллективизация чорында да, сугыш елларында да, моны ничектер искәрмәгәннәр. Хрущев заманында гына яртысын кистереп ташлап, алабута басуы ясадылар. Шул зур бакчалар коткарды безнен авылны. Дөрес, аларны тиешенчә эшкәртеп булмый иде. Сортсыз бәрәнгенен унышы да артык күп булмады. Колхозда ял көннәре юк, эш көннәре чиксез. Бакча казу кирәк белән. Бәрәнгесен колхозның көзге эшләре бетмичә юньләп ала да алмыйсын, салкын янгырлар астында пычрактан актарасын. Күмелеп, балчыкка буталып калганы да әрәм булмый иде. Ул өшеп, боламыксыман мәлжери. Язын кабыгын салдырып кына ташлыйсын да, табада кыздырып аласын. Шул була инде кәлжемә «котлеты». Безнен бакчалы авылнын «меню»ына да керми калмады ул. Яз житкәч, бәләкәй бакчалы күрше авыллардан кәрәк күтәреп, шул туныл жебегән бәрәнгеләрне үзләренә жыеп алу хакына гына бәрәнге бакчаларын казып чыгарга сорап килүчеләр була иде. Шуннан күз алдына китерә аласын инде ул авылларнын хәлен.

Ни гаҗәп, хәзерге заманда кәлҗемәгә әйләнә торган бәрәңгеләр юк. Яз көне бакча казыганда килеп чыкканнары да сентябрьдә алганнары кебек шылтырап торалар.

Авыл тормышыннан үзем шаһит булган тагын ике күренеш. Сугышның соңгы кышы ахырында булды бугай бу хәл. Кич белән, төнгә каршы әниемнең дус хатыны Газизә апа безгә очынып килеп керде. Үзе шаркылдап көлә, ә күзе шар кебек, карарга куркыныч. «Самига, мин үземнекеләрне ашатып-эчертеп тормыйча йокыга яткырырга өйрәндем!» дип кычкырып сөйләп китте. «Янган мичкә чуен белән су куям да, балаларны кайсын алдыма, кайсын яныма мич каршысына утыртам да, «менә хәзер аш пешә, менә хәзер бәрәңге пешә», дип көттереп утырам. Алар җылыдан эреп йоклап киткәч, илтеп салам» дип «мактанырга» кергән Газизә апа. Әнием аны озатырга чыгып, озак кына кайтмый торды. Газизә апаның алай шашынуы башка кабатланмады. Озакламый әтиләре Хай абзый да сугыштан кайтты. Алтын куллы кеше иде. Ике-өч елдан гаиләсе белән кайсы яккадыр, китеп бардылар.

Икенче вакыйга бераз соңрак булды, сугыштан соң. Елын төгәл хәтерләмим, 46нчымы, 47нчеме елның җәй көне иде. Без өч күрше малай: мин, туганнан туганым Индүс, өченче яшьтәшебез Фәнзәт белән аларның ишек алдында пәкеле уйнап утырабыз. Янибызда Фәнзәтнең әле мәктәпкә йөрмәгән энесе утыра. (Пәкеле уйнау — егермеләп төрле ысул белән пәкене җиргә кадатып уйнау). Капка алдына җигүле ат белән кемнәрдер килеп туктады. Аннан ике ят кеше килеп керделәр. Фәнзәтнең әнисен, Мөхәссәнә апаны, чакыртып чыгардылар. Бер кәгазьдән укып, налог түләмәгән өчен «недоимка» итеп, боларның кәҗәләрен алып китәргә килгәннәрен әйттеләр. «Недоимка» дигән куркыныч сүз, налог түләмәсәң, малыңны бирәсең дигәнне аңлата. Кәҗә безнең тирәдә үлән чемченеп йөри. Мөхәссәнә апа бер сүз дә әйтә алмыйча аптырап тора. Тегеләр эшләрен озакка сузмыйча, кәҗәне, муеныннан бау белән әләктереп, урам ягына сөйри дә башладылар. Мөгезеннән әләктерсәләр бер хәл иде. Кәҗә буыла, әллә нинди әшәке тавышлар чыгарып бакыра, бер адым да атламый. Барыбер, өстерәп алып чыгып, арбаларына салып алып киттеләр. Ияреп чыгып, күреп, карап калдык шул мескен кәҗәне алып киткәннәрен. Ишек алдына кире әйләнеп керсәк, анда Мөхәссәнә апа ауный-тәгәри җирне, ишек алды үләннәрен бармаклары белән тырмап елый. Аларның сыерлары да, сарыклары да юк иде. Әтиләре сугышта югалган. Ашарларына үстереп өлгерә алган бәрәңге дә, шул кәҗәнең сөте генә иде инде. Мөхәссәнә апа шул тетрәнүдән айный алмады. Акылыннан язды. Һәрвакыт урамда үзе белән үзе сөйләшеп йөри торган булып калды. Шул хәлендә дә, үлгәнчегә тикле үзен-үзе карый алды, беркемгә дә зарар китерерлек булмады. Ил буйлап санап чыксаң, хисапсыз күп булгандыр андый аяныч хәлләр.

Совет хөкүмәтенең кеменә кирәк булды икән сугыш ялгыз калдырган, еллар буе ипи ризыгы күрмичә дәүләтне, фронтны туендырган хатын-кызларны, сугыш ятим иткән баларны рәхимсез вакчыл явызлык белән талау. Төрле льготаларга алар иң беренче чиратта лаеклылар иде. Татарстан халык депутаты чагымда, Татарстан Югары Советының ветераннар комиссиясендә эшләгәндә шундый тәкъдимнәр кузгатып караган өчен сугыш ветераннары тарафыннан бик каты тәнкыйть сүзләре ишетергә туры килде мина.

Паспортсыз авылларда бер тиен эш хакы алмыйча, эш хакына эшләп тә түли алмаслык налоглар, бөтен авыл хуҗалыгы эшләрен бернинди техникасыз башкарып чыгу, үстергән уңышыңны бөртегенә кадәр дәүләткә тапшыру, ач утырган балаларына бер учка сыярлык бөртек алып тотылсаң, төрмәгә китү, «полномочный» надсмотрщиклар — болар концлагерь күренешләре түгелмени? Аларны сугыш алып килгән котылгысыз авырлыклар рәтенә кертеп аклап булмый. Сугыштан соң әле ничә еллар буе авыл тормышы шулай ач халыкны талау рәвешендә дәвам итте.

Хәзер тагын, авылларны «раскулачивать» итеп, аларны районнары белән яна алпавытларга, олы түрәләрнең кечерәк дус-ишләренә бүләк итеп, авыл халкын шуларның — төрле «ваминнарның» коллары иттеләр. Аларның явыз «пулнамочный»лары да Бериянекеләрдән ким түгел бугай.

Сугышта ирләрен, улларын югалткан авыл хатын-кызларын аеруча кимсетү, түбәнсетеп җәберләү безнең якларда гына булган хәл түгел ул. Аларның «солдатка» дигән гомуми кушаматлары да бар иде әле.

Үзем күргәннәрдән ераграк бер мисалны өстәмичә, бу темадан китә алмыйм. Чөнки анда минем бәләкәй чагым да чагылган. Зинһар, гаепләмәгез.

Татарстан халык депутаты чагымда мина Казаннын Һади Такташ урамында 12 кв.м. бүлмәдә өйләнгән улы, оныгы белән яшәүче бер ханымнын бик авыр эчтәлекле хаты килгән иде. Миннегөл ханымнан (яза башлагач, исемен дә әйтим инде) килгән ул хатны һаман саклыйм. Менә шуннан бер өзек:

«Бер бәхетсез, гел бәхетсез инде ул тормыш. Үземнен әтием Әбелкасыйм һәм Әгъзам абыем белән Мансур абыем сугышта хәбәрсез югалдылар. Хәбәрсез югалу кәгазе килгәч, әнине күп тапкырлар район үзәгенә чакыртканнары хәтердә. Әни аннан чыккач, мине кочаклап елый иде. Шуннан 23 км. җәяүләп, колхозга орлык ташый иделәр. Язгы сулар ага башлагач, берсендә кайтканда, Шушма аша чыкканда, боз ватылып, алар бата башлап, көянтәгә аскан орлык бодайлары су астына китә. Ә үзләре боз арасыннан чыгалар. Икенче көнне әни урын өстенә ятты. Ә авыл советыннан председательләр килеп, баткан орлык өчен, син халык дошманы дип, безнең булган сарыкларны алып чыгып киттеләр. Кәҗәбезне дә. Әле синен иреҥ дә, ике улын да безвести пропал, алар кайда, әйт дип кычкырдылар. Шуннан әни урын өстендә 7 ай ятып, корып, кибеп, безне дүртебезне калдырып, 1950 елда үлеп китте. Шуннан мин 13 яшемдә, мәктәпне ташлап, сыер саварга төштем...»



*Ф.Сафиуллин (сулда) әнисе һәм туганнан тугань, яшьтәше Җәүдәт белән 1947 елның көзе.*

Мин аларга торак шартларын яхшыртырга ярдәм итә алмадым. Көчем житмәгән, булдыра алмаган очракларым күп булды инде. Үземә килгән җавап-отпискаларны да аларга җибәрергә, йә үзләренә барып «аңлатып» маташырга батырчылыгым житмәде.

Актүбә «солдаткалары» да, Бөгелмә элеваторыннан Актүбәгә, 33 чакрымнан, бәләкәй чана тартып, орлык ташыдылар.

Педучилище тәмамлап бездән 10 чакрым Илбәк авылы мәктәбендә беренче елын укыта башлаган әниемнен сенлесе, 20 яше генә тулган Сәлимә апам да, үлемнән качып кайтканда язгы ташуга батып, берничә ай авырып ятканнан соң вафат булды. Татарстан авылларында бер бик куркыныч авыру күтәрелеп чыккан иде. Авылларда аңардан күп халык кырылды. Шәһәр халкына кагылмады бугай. Әллә кайлардан комиссияләр килеп тикшерсәләр дә, озак айлар сәбәбен таба алмадылар. Сонрак белделәр. Кар астында басуда кышлаган бодай башаклары үтергеч агулы булалар икән. Шуларны җыеп ашаган кешеләр борыннарыннан, авызларыннан туктаусыз кан китеп үлгәннәр. Башта аны йогышлы авыру дип уйлаганнар. Сәлимә апам да, авыл кешеләре гаиләләре, үзе укыткан балалары белән, жирләргә өлгерә алмыйча, кырыла башлагач, куркуыннан Актүбәгә кайтканда үлем баласенә эләккән.

Безнең авылны кан чиреннән бәрәңге житү коткарды. Бер генә кеше ул афәткә юлыкты. Сугыштан бер аягын өздереп кайткан бабамның энесе Хәким абзыйның улы Мәжит абыйны гына алып китте ул. Бераз ныгысын дип, анын өчен генә шул язгы бодайны җыеп, аңа гына ашаткан булганнар. Көз көне бер башак өчен дә төрмәгә утыруын мөмкин иде, ә яз житкәч тыючы да булмаган бит шул башакларны җыюны.

Безнең гаилә ачлык кичермәде. Без бераз гына шәһәрчәрәк тә яшәп өлгердек. Хәрбиләштергән леспромхозда урман кисүче әнием сугыш беткәнчегә кадәр ай саен «военный паек» ала иде. Ана, ничә кило булганын хәтерләмим, он да, ниндидер

«консервы»лар да кирә иде. Ә бер көнне Америка җибәргән йомырка порошогы алып кайтты. Теш порошогы кебек йомшак итеп төелгән, төсе сап-сары. Сөт белән бутап табада пешергәч, бик тәмле. Үсеп житкәч кенә белдем — ташбака йомыркасы булган ул. Куе яшел төстәге каты кәгазьдән ясалган тартмасы да истә калган. Аның тышкы ягы калын итеп, балавыз төсле әйбер белән сыланган. Пычакның арты белән бик жинел кырыла. Жылытканда бик тиз эри, учактагы утынга тамызсаң, бик әйбәт яна. Парафин дигән нәрсә булган икән ул.

Әниемнең паегыннан башка, бабамның умарталары бар иде. Ниндидер игътибарсызлык беләнме — белмим, безнең якларда умартага налог булмады. Тавык бугына, мичтән чыккан көлгә (колхоз басуларына ашламага) «местный налог» булды, ә умартага юк. Бабам шул «лазейка»дан бик яхшы файдаланып өлгерде. Кыш көннәрендә Бөгелмә базарында сатылган бал безне күп кыенлыклардан коткарды. Чабата ясап та сата иде. Колхоздагы эше дә бик «престижный» эш иде — 67 яшенә тикле ат караучы булды. Чапкан печәнне, кискән утынны безгә бәләкәй арба тартып ташырга туры килмәде. Базарга барырга да ат сорый ала иде.

Яз көннәрендә каен суына да без бик бай була идек. Урман кисүче әнием аны чиләк тутырып алып кайта иде. Колач житмәслек каеннарны аударганда, чиләгенне куеп кына өлгер. Самавырда кайнатып, чәй итеп эчә идек без аны. (Кисәтеп үтим әле: каен суы нык кайнап чыкса, сөт кебек күпереп ташый. Кайнаткычка аны тутырмыйча салырга, кайный башлау белән туктатырга кирәк).

Безнең гаиләнең тагын бер «өстенлеген» әйтеп үтим инде. Бабамның сугышта һәлак булган кече улы, әниемнең энесе Әнвәр абый авылыбызның сугыш корбаннары арасында бердәнбер лейтенант дәрәҗәсен алып өлгергән. Аның үлеменнән соң ай саен килеп торган пособие ул заман авылы өчен шактый зур байлык иде.

## Без иректә үстек

Без, сугыш чоры балалары, нинди кыенлыклар кичерсәк тә, күпме киләчәк мөмкинчелекләребезне югалтсак та, барыбер сагынып искә алырлык көннәрдән мәхрүм калмадык. Иректә, үзебезгә үзебез хуҗа булып үстек. Тукай әйтмешли, эшең беткәч уйнарга кайчан, кая чыгып китәсең, кайчан ни төстә кайтып керәсең — шелтә сүзе әйтүче юк. Өлкәннәрнең безнең белән шөгыльләнергә вакытлары да, көчләре дә калмагандыр инде. Яздан көзгә тикле урманда, «подножный корм»да. Кыш көннәрендә бишмәтең, бияләйләрең бозланып катканчы карда, бозда; чана-чаңгыда, тимераякта. Тимераяк дигәннән, анысы да үзенә күрә кызыклы иде: калын табанлы, кәкре башлы, каеш баулар белән беркетешле. Әлбәттә, барысы да «борынгылар» — сугышка кадәр ясалганнар. Авыл тимерчеләре ясаганнары да очрый иде. Аларны чабатага беркетү бик кыен, ныграк кыссаң, чабата яньчелә, кысып житкермәсәң, тиз какшый. Киез итеккә беркетү унайлырак, бигрәк тә салкын көннәрдә: какшый башласалар, бәке кырыена утырып, аякларыңны суга манчып аласың да, бераз көтәсең. Тимераяклар итек табанына шатырдап ябышып каталар. Минем беренче тимераякларым Ленинградтан килеп эләктеләр. Табаннары юка, башлары очланып ясалган. Буа (бездә — Бүә) өстендә шуарга әйбәт, ә сырланып каткан инеш өстендә атлаган саен төртелеп абынасың. Анысыннан бигрәк, аның тарихы унайсызланып искә ала торган булып калды.

Безнең авылга Ленинградтан эвакуацияләнгән берничә гаилә килеп урнашкан иде. Бездә — бер ялгыз Кузьма бабай. Искергән, тузган киез итекләрне, туннарны ямап төзәтергә бик оста иде. Түбән очта берәүләрдә әбисе, ике оныгы белән тагын бер бабай. Бик матур итеп каен тузыннан кәрҗин үрә, хәттә ватылган чүлмәкләрне дә тышыннан шул каен тузы белән тарттырып, сөт акмаслык итеп төзәтә иде. Оныкызы Люля эвакуациядәге гомерен безнең белән бергә малайларча уйнап үткәрде. Чын исеме нинди булгандыр, безнең өчен Люля булып калды инде. Татарчаны бик тиз өйрәнде. Эт кебек артыннан калмый ияреп йөри торган кәҗәсе бар иде. Кайберләребез: "Люля, кәҗән үлә" дип ачуын китерәләр иде. Әтисе сугыштан аксап кайтып, гаиләсен дә алып, күрше рус авылында урнашты. Берничә ел аннан килеп, Актүбә мәктәбендә өченче-дүртенче класс малайларына «военная подготовка» «укытып» йөрде. «Укыту» дигәне бик тә аңлаешлы иде. Безне жыеп урманга,

яланнарга алып китә дә, сугышлы уйнаганыбызны таягына таянып күзәтеп, дөресләп тора. Кананухин абыйның килгәнен көтеп кенә тора идек.

Тимераяклар тарихын оныта язганмын бит. Ленинградтан өч баласы белән килгән яшь кенә бер хатын да бар иде. Бик җиңелчә килгәннәр. Кышкы өс-баш, аяк киемнәре юк диярлек. Кыш буе өйдә генә утыралар. Әтиләре сугышта бомбардировщикта оча икән. Анысын без бик тиз белдек. Ул елларда безнең өстән, күктә, бик югарыда әллә нинди самолетлар үткәлиләр иде. Ул чакныкылар бит әле бик әкрен очалар иде, үрмәләп, шуышып барган сыман. Ә тавышлары хәзерге реактив самолетларныкы кебек шома гына гүләп китү түгел, ә дулкын-дулкын булып гөрелдәп, бер көчәеп, бер әкренәеп килә торган шомлы улау, үкерү. Менә шул тавышны ишетүгә теге өч бала йөгерешеп ялан тәпи ишек алдына чыгалар, сикерә-сикерә, кулларын болгап, «Папа! Папа!» дип кычкыралар. Әниләре чыгып кочагын җәеп, ул балаларны, өйгә алып кереп китә иде. Җиңелчә килсәләр дә, үзләре белән ботинкалы бер пар шәһәр тимераякларын алып килгәннәр. Балаларның берсенә аяк киеме булсын дип, тимераякны ботинкаларыннан кубарып алганнар. Әнием шуларны бәрәңгегә алыштырган. Куанмадым мин әниемнең ул бүләгенә.

Яз житүгә очучыбыз үзе кайтып житте, бер-ике көннән гаиләсен үзе белән алып китеп тә барды. Ә киткәнче, авыл бала-чагасын җыеп, «салют» ясап күрсәтте. Авылдан читтәрәк нишләптер ялгызы утырган бер багана әйләнәсенә әллә ничә сигнал ракетасын бәйләп куеп, аларның картон гильзаларына пәкесе белән кечкенә тишекләр уеп чыкты. Шул тишекләр өстенә, күкертле башларын терәтеп, шырпылар беркетте. Шырпыны сызып җибәрә, ракета оча: кызылы, яшеле, сарысы... Әкият дөньясы булды ул кич безгә.

## Куян баласы

Урманнан буш кул белән кайтмый иде әнием. Язның бер көнендә бер ятим куян баласын алып кайткан. Яна туган песи баласы кебек кенә. Үстердем бит шуны. Башта бөтереп төргән чүпрәкне сөткә манчып имезә идем, сонрак йомшак үлән кыякларын «кимерә» башлады, сөтне иркенләп эчәргә өйрәнде. Усак ботакларын кимерергә ярата иде. Чиратлап кучеп йөрүче авыл сепараторы бездә чакта, сөт аертырга килүчеләр сыйлап карыйлар, ә ул безнекеннән башка берсенекен дә эчми. Песи кебек булып үсте. Чакыру белән йөгереп килә, минем янымда йоклый. Кыш үтеп барганда тәртибе бераз бозыла башлады. Безгә кергән кешеләрнең аяк киемнәрен кимерә, үзебезнең тупсаларны да «ашый». Абзарның бер почмагына урын ясап чыгарган идек, төнлә үзенә юл ачып урманга качкан. Артыннан эзләп киттем. Карның өсте тыгызланган чак, шуңа күрә эзләре бер күренә, бер югала. Урман кырыеннан минем тавышны ишеткәч , чабып килеп чыкты. Каршы алырга чүгәләгәч, сикереп тезләремә менеп утырды. Күтәреп алып кайттым үзен. Тишекне ныклап ямап куйган булдым. Төнлә тагын чыгып качкан. Бу юлы урманга түгел, ә урамга. Шакир бабайның Сизгер исемле эте, авыл малайларының яраткан дусты, куянымны буып үтергән. Миңа шулай дип әйттеләр. Күрергә үзем бармадым.

Күп еллардан соң, мин Чехословакияда хезмәт иткәндә, шул куян тарихының дәвамы була язды. Ике улымны да ияртеп Миловице тирәсен йөреп кайтканда, күтәрелеп кенә килә торган арпа басуында калкып торган колакларыннан искәреп, бер куян баласын күреп алдык. Качарга җыенмый. Колакларыннан тотып күтәргәч, бәләкәй бала тавышы белән кычкырып җибәрде. Аягы имгәнгән булган. Өйдәге сый-хөрмәттән тиз арада терелде. Тик бик начар холыклы булып чыкты, ашарына биргәндә дә кулны тешләргә тырыша иде. Куян димәссең. Безне, әллә аның җирендә оккупантлар булганыбыз өчен, якын итмәде. Кроликлар үстерүче бер чех картына күрсәткән идек, «патриот» куянын ул үзенә алып калды.

## Сугыш бетте

Миңа 9 яшь туласы елның язында, беренче класста укып йөргәндә, сугыш бетте. Ул сөенечле көнне әбиемнең мине иртән йокыдан уятып әйткән сүзләреннән хәтерлим. «Сугыш беткән бит, улым. Силсәвиттән атлы хәбәрче килгән. Әнә,

кешеләр мәктәп ягына ашыгалар,» дип, аркамнан сыйпап әйтүе белән мин торып йөгердем. «Силсәвит хәбәрчесе» әбием мина житкергән ике сүзлек хәбәрне килгән кешеләргә кабатлап тора. Сталинны, партияны мактаудан артыгын өстәп әйтерлек яналыклары юк иде. Колхоз идарәсе, авылның аксакаллары халыкның күнелен күтәреп, олысын-кечесен, барысын да жыеп, мәктәп ишек алдында итле аш мәжлесе үткәрделәр. Ләкин кемгә ничектер, ә минем үземдә 1945 елның 9 май көне авыр тәэсир калдырды. Берәүләр сөенеп кул чаба, икенчеләре тавышсыз-тынсыз гына елашалар, кайсының шатлыктан авызы ерылган, кайсының башлары авыраеп түбән иелгән. Шуннан соң инде ничә дистә еллар үтсә дә, сугыш беткән көн минем өчен бәйрәм була алмады. Ул көнне мин иртәдән кичкә тикле нинди дә булса эш белән үткәрәм. Әтиемне бәләкәй малай кебек сагынып искә алам.

## Әтием турында Рәшит абый сүзе

Әтиемнең «тере» хәтерен саклап калучылар без бүген икәү генә. Икенчесе — 1939-1940 уку елында әтием Азнакай районының Мәсгут авылы мәктәбендә укытканда шул мәктәпнең директоры булган Рәшит абый Измайлов. Азнакайның бик абруйлы сугыш һәм хезмәт ветераны. 2004 елның май аенда «Татарстан яшьләре» газетасында аның әтиемнең истәлегенә багышланган язмасы чыкты. Фин сугышы башлангач, мәктәпнең бер-бер артлы ике директорын, башка яшь укытучыларын армиягә алып китәләр. Рәшит абый директор булып кала, минем әтиемне Мәсгут мәктәбенә физкультура укытучысы итеп жибәрәләр. «Хәл авырайганнан-авырайды, — дип яза Рәшит абый — ике сменага күчелде, лампалар юк, утын житми. Директор атка атланып Азнакайга керосин эзләп китә — барган саен буш кайта. Укытучыларның күбесе яшь кызлар, ә укучылары шаяннар, дәрес алып барырга ирек бирмиләр. Менә шундый вакытта физкультура укытырга син килдең, Шакир абый. Шатлыгымның чиге булмады. Алып чыгып китә идең егетләрне Мәсгутның Озы тауларына. Окоплар, траншеялар казый торгач, ак кар кара балчык белән буталып бетә иде. Кайткач укучыларның өсләреннән пар атып тора, үзең дә канцелярияга керү белән әйләндереп ташлый идең өстәлгә пар чыгып торган олы бүрегеңне. Шаян кызларның да башларыннан сыйпамадың физкультура дәресләрендә, укучылар армиядәге кебек тәртипкә өйрәнделәр. Дәресләрдә тынычлык урнашты, укытучылар да еламый башладылар».

## Соңарып тормышка ашкан хыялым

Бәләкәй чагымнан бик күпне хәтерләсәм дә, кем буласым килгәнне хәтерләмим. Юкса бит баланың үзенең дә: «Үскәч кем буласың килә?» дип сорашып тенкәсенә тияләр. Миннән дә сораганнардыр инде, жавабым да булгандыр, ләкин хәтеремдә аларның эзе дә юк. Беркем дә буласым килмәде микәнни? Ә шулай да, «музыка» дигән сүзне белмәсәм дә, жырны, музыканы бик кечкенә чагымнан ябышып ярата идем. Габдулла Тукайның «Бала белән күбәләк» шигырен көйләп, «жырлап» сөйләргә мине әтием телем ачылгач та өйрәткән булган. Әтием, әнием миңа кушылып жырлыйлар иде аны:

*«Әйт әле, күбәләк,*
*Сөйләшик бергәләп:*
*Бу кадәр күп очып,*
*Армыйсың син ничек?...»*

Минем бәләкәй чагым бәләкәй музыка дөньясында үтте дисәм дә артык күпертү булмас. Укытучы әтиемне кайсы авылга күчереп йөртсәләр дә, аларның һәрберсендә безнен патефон бердәнбере була иде. Ул чордагы радиосыз, телевидениесез тормышта патефонның нинди гажәеп әйбер икәнен хәзерге заман кешесе күз алына да китерә алмый. Әтием кая барса да яна «тәлинкәләр» алып кайта. Өйдә дә, әтиемнең мәктәбендә дә, кино килсә, халык жыелган арада анда да әйләндерәбез төрле жырларны. Әтием сугышка киткәч тә күп әйләндердем мин ул патефонны. Кайбер әйберләрне сатарга туры килсә дә, патефонга кагылмадык.

Ул караңгы елларда да кеше җыр-моннан, хәттә уен-көлкедән дә аерылмады. «Кичә бетте оныбыз, Бүген бетте тозыбыз, Бәрәнге дә бетеп килә, Үлсәк, бәхил булыгыз», дип тә җырлыйлар иде. Бер бик шаян җырның ярты куплеты гына истә калган: «Һаваларда очкан үрдәкләрнең Җиргә тамып бара майлары...». Менә мондый җыр да бар иде:

*«Атланып корчаңгы атка,*
*Киттек райвоенкоматка.*
*Безне күрегез!*
*Алдыбызда алабута,*
*Ашамыйбыз! Эч авырта.*
*Ипи бирегез!»*

Бу җыр бер патриотик җырның көенә пародия формасында җырлана иде. Актүбә халкында «Гайнижамал көе» дип атала иде. Чөнки аның бер куплетында менә мондый сүзләр дә бар иде: «Кайгырма, Гайнижамалым, Булган ачык-тишегенне үзем ямармын!»

Сугыш елларында да кеше берсеннән-берсе бизенмәде, үзара аралашып, ярдәмләшеп яшәде. Җыелып очрашулар, ашка йөрүләр дә дәвам иттеләр. Әнием чакырылган җиргә без өчәүләп бара идек: әнием, мин һәм патефон. Миннән башка аны эшләтә белүче юк иде чөнки. Бөтен нәрсәсе әзер булганда, аны әйләндереп җибәрү берни дә түгел. Ләкин, сугыш башлангач, шул гади генә аппарат өчен дә бер проблема килеп чыкты — энәләре бетте. Ни кибеттә, ни базарда юк. Ә алар бик йомшак тимердән ясалалар, тиз ашалалар, чөнки артык каты ясмә, артык очлы булсалар, тәлинкәне кисәләр. Искедән калганнарын бик саклап, оста итеп бабамның кырынгыч пәкесен үткенли торган кара ташта үткеннәргә өйрәндем. Патефон энәсен яссы итеп, кырлы итеп очларга ярамый, түгәрәк итеп кенә кирәк. Юкса патефон тәлинкәсен боза. Очлап бетергәч, очын ташка бастырып бер ышкып, уеп алырга да кирәк. Җырлар әйләнә торалар, ә мин энәләр үткенләп утырам. Хәзер яшьләрне музыка уйнатып биетүчеләргә мәгънәсе аңлашылмаслык яңгыравык исем таптылар. Миңа бер кушамат та эләкмәде. Бәләкәй чагымда үзем әйләндергән халкыбызның матур җырларын бик яхшы хәтерлим, хәзер дә бик яратып тыңлыйм. Кайберләрен әле шуннан соң ишеткәнем дә юк.

Ни үкенеч, музыка белән актив шөгыльләнергә бала чагымда миңа насыйп булмады. Беренче күргән-ишеткән бик оста гармунчым Җәмил абый булды. Тайсуган авылы егете. Сугыштан ике күзен дә югалтып кайткан. Актүбәгә, Газизә апаларга кунакка алып киләләр иде аны. Гармуны һәрвакыт үзе белән. Капка төбендә утырып уйнаган бер «концертын» да калдырмадым мин аның.

Өченче класста укыганда, 1947 елда, бозавыбыз Мишканы сатып, Бөгелмәдән яна тальян гармун алып кайтып бирделәр. Алганда тикшереп-карап тормаганнардыр инде, уйнап булмады аңарда. Баскан телләре кире ябылмыйлар, рәтләтер кеше дә юк авылда. Сандык төбенә салып куйдылар аны. Күп еллар үткәч, мин инде офицер булып Белоруссиядә хезмәт иткәндә аны сандыктан алып карасалар, гармуным «терелгән». Күрәсең, теге вакытта аның агачлары дымлырак булгандыр. Миңа хат язып, сатыйкмы дип сорагач, каршы килмәдем. Гармун кайгысы булмый инде яшь лейтенант башында.

Әнием белән Тайсуганга, сугыш беткән ел булса кирәк, кунакка баргач, мине гомерлеккә үзенә гашыйк иткән аккордеон дигән гармунны күрдем. Тайсуганда әниемнең апасы, сугышта ирен югалтып тол калган Хәмидә апабыз яши иде. Аның әтисез калган ике улы, минем туганнан туган дусларым — яшьтәшем Җәүдәт, бездән өлкәнрәге Сарыйм абый белән еш аралашып, якын дуслар булып үстек. Әнием белән килгән теге көнне алар мине клубка алып киттеләр. Анда нәрсәгә халыкның олысы-кечесе бергә куплап җыелганы истә калмаган. Ә залдан сәхнәгә менеп баскан егетнең күкрәгенә каешлар белән аскан искиткеч матур тавышлы ак төстәге аккордеоны бүген дә күз алдымда. Германиядән гармунчы солдат алып кайткан трофей булган ул. Шуннан соң әтиемнең сугыштан кайтуы турындагы

хыялларыма шундый аккордеон да алып кайтыр әле дигән өлеше дә өстәлде. Хыял хыял булып калды. Үсеп житкәч, олыгая башлагач, Германия белән сугышмыйча да аккордеон алырлык хәлем булса да, уйнарга өйрәнә башларга батырчылыгым житмәде. Булдырырмын дип үземә үзем ышана алмадым. 60 яшем тулып килгәндә, картая башлаган кешенең балалыкка кайта башлау чире булыпмы, аккордеонда уйнарга өйрәнү дәртем яңадан кабынып китте. Ике улыбызның берсе булса да өйрәнмәсме дип алып куйган, ә алар теләмәгәч, тик яткан бәләкәй аккордеонбыз бар иде. Утырдым шуны тарткаларга. Татарстанда депутат чагым, эштән кайту белән утырам-тартам. Иркенләп уйнарлык вакытым болай да әз калып килә дип, аны әрәм итеп ноталар өйрәнеп тормадым. Ә уйнарга өйрәндем тәки. Сәхнәгә чыгарлык булмаса да, үз-үземне юатырга, күңелемне күтәрергә бик ярарлык. Дус-ишләрем дә уйнавыңның рәте юк дип әйтмиләр.

## Кино мажаралары

Без бәләкәй чакларда авыл халкына кино күрсәтү шактый яхшы оештырылган иде. Радио, телевидение юк чакта дәүләтнең иң көчле пропаганда коралы кино булган бит инде. Киномеханик күпчелек очракта йә сугыштан гарипләнеп кайткан, яисә берәр төрле сәбәп белән сугышка ярамаган яшь ир-егет. Хатын-кыз булса — берәр усал маржа. Аларны татар авылларына жибәрмиләр диярлек, чөнки кинолар телсез, эчтәлеге дә урысча язылып бара. Шуна күрә татар авылларында киномеханикка киноны күрсәтү генә житми, ул оста тәржемәче хезмәтен дә үти, телсез киноны тере тавышлы кино итүче дублер да була. Кайда ничек булгандыр, ә безгә килгәннәре бик оста, мавыктыргыч итеп «тавышландыралар» иде телсез киноларын.

Билгеле, кино үз аягы белән йөрми. Аны ат белән, арбасына аппаратурасын төяп, күчмә кино итеп йөртәләр. Авылга кино килгән көн малай кешеләргә үзе бер бәйрәм була иде. Кино караудан бигрәк, ул көнне һәрберебез үзенең «егетлеген» күрсәтергә тырыша. Акча түләп керү — иң түбән дәрәҗәдә булдыксызлык санала. Бөтен максат һәм «спорт дәрте» кинога түләмичә керүгә юнәлтелгән. Иң ышанычлы, ихтирамга лаек юлы — эшләп керү. Анысы болай була. Кино килеп төшүгә, иң әүвәл аның нинди кино икәнен түгел, ничә «пәрдәле» икәнен белү кирәк. «Пәрдә» дигәне — кино кисәкләре салынган түгәрәк калай савытларның саны. Кино аппаратын механик үз кулы белән әйләндерсә дә, кино бит электр уты белән яктыртылып күрсәтелә. Электр утын эскәмиягә беркетеп куйган генератор бирә. Ә генераторны, «пәрдә» саен алышынып, без — малай-салайлар әйләндерәбез. Үткенрәк «егетебез» киномеханик белән килешү төзи: әйләндерүчеләр киноны бушлай карыйлар. «Кандидатлар», билгеле, «пәрдәләр» саныннан һәрвакыт күпкә артыграк була. Сайлау процедурасы, бернинди фальсификациясез, озын таяк житмәсә, дилбегә тотышып үткәрелә. Кино башланыр алдыннан киномеханик жинеп чыгучыларның бүрекләрен жыеп ала. Эш башланып китә. Генераторны әйләндерү бик жинел эш түгел ул. Артык тиз дә, бик әкрен дә әйләндерергә ярамый, өзлексез һәм бер чама, бер тизлек белән генә кирәк. Шактый жылынып чиратыңны үткәргәч, бүрегеңне алып, урыныңа утырасың. Эшләп керә алмаганнар үз хәйләләрен уйлап табарга тиеш булалар. Нинди генә талантлар уянмый шул этлекне тормышка ашыруда!

Мөгаен, һәр татар авылында ул телсез киноларны карау үзе бер тамаша булгандыр. Бигрәк тә әгәр жор телле, шаянрак киномеханик туры килсә. Киноның эчтәлеген ул үзе аңлаганча тәржемә итеп бара. «Зал»дан берәрсе аның белән бәхәскә дә кереп китә кайчак.

Кинолар барысы да диярлек сугыш турында. Анда безнекеләр немечләрне кырып кына салалар, ә үзләренә берни тими. Хатын-кызлар «сугыш» барышын минеке күренмәс микән дип, күзәтеп утыралар. Ин актив тамашачылар — беренче герман сугышын үткән абзыйлар, бабайлар. Сугышның дөрес бармаганын бик тиз күрәләр. Киноларның берсендә безнекеләрнең бер блиндажы турында бәхәс купкан иде. «Блиндажны шулай коралармыни инде. Моның өстенә берәр тычкак сыер килеп басса да ишелеп төшә бит бу. Әй, ахмаклар!» дип Шәйхулла бабай башлап

жибәрде. Китте шуннан дискуссия! Киномеханик та үзенекен өсти. Кайвакыт Шәйхулла бабайның үзенә дә төрттереп алалар иде. Безнекеләрнең пулеметыннан кырылып ауган немечләрнең берәрсен якынайтыбрак күрсәткәндә: «Шәйхулла, синең мөртәтенне чәкеделәр түгелме?» дип сүз кыстырып куйгалыйлар иде. Ә ул төрткe сүзнең «тарихи» нигезе бар иде. Безнең күршебез Шәйхулла бабай герман сугышында пленга эләгеп, Германиядә берничә ел гомерен үткәреп кенә калмаган, анда бер немец маржасына өйләнеп, бер малайларын тудырып та өлгергән. Бергәләп төшкән гаилә фотосурәте өендә рамда эленеп тора иде. Аны күргән кешегә ул, әнисенең алдында утырган малайга бармагы белән төртеп: «Менә бу мөртәт малай безнекеләргә каршы сугышып йөри торгандыр әле», дип әйтә торган иде.

Экран итеп җәеп эленгән ак чүпрәктә сугыш күренешләре үзгәргән саен, бәхәснең темалары да алышынып тора. Менә шундый актив тамашачылары, сүзгә оста киномеханиклары белән бик кызыклы булалар иде ул телсез кинолар. Бер дә үкенмим безнең чорда хәзергесе кебек «спецэффектлар» тутырылган матур кинолар булмавына.

## Бәләкәй чак мәктәбем

Әтием укытучы булгангамы, мәктәпкә йөри башлауны мин бик көтеп алдым. Өч мәктәптә укырга туры килде миңа. I-IV классларны Актүбәдә үттем, V-VII классны Мәльбагыш авылында, сигез чакрым йөреп укыдым. Унъеллыкны Бөгелмә татар мәктәбендә тәмамладым. Өчесендә дә укытучыларымнан уңдым. Барысына да олы хөрмәт белән рәхмәтлемен. Үрнәк булырлык шәхесләр иде алар. Мәктәпләрдән тыш «мәктәпләрем» — тормыш биргән дәресләрем дә файдасыз булмадылар.

Безнең заманда беренче класска 8 яшь тулгач алалар иде. Минем өчен ул 1944 ел булды. Мәктәбебез урам буйлап үткән инешебезнең аргы ягына, биек яр башындагы ачык урынга иркен итеп бурап салынган алты почмаклы, калай түбәле йорт иде. Дүрт класска ике укытучы. Берсе революциягә кадәр дә укытып өлгергән, Актүбәдә күп еллар укыткан Шәех абый, икенчесе «күчмә» укытучы — ел саен алышынып тора торган кызлардан. Бер смена укыйбыз, бер бүлмәдә ике класс утыра. Дәрес икесенә дә берьюлы алып барыла. Кышның бик салкын көннәрендә, яисә укытучыларның берәрсе килә алмаса, дүрт класс бергә утырып укыйбыз. Дәреслекләр юк диярлек. Булганы да сугышка тикле басылганнары гына. Өйдә укырга аларны начаррак укыган балаларга гына бирәләр. 1944 елның беренче класс укучыларына безнең мәктәптә бөтен уку елына ике дәфтәр, ике каләм, бер карандаш бирделәр. Язарга караны мич корымыннан ясый идек. Арифметика өчен дәфтәрләрне каян нәрсә тапсаң шуңардан, иске газеталардан, ташландык китап битләреннән үзебез ясый идек. Кайберәүләрдә үзең белән йөртешле, дәфтәрдән зуррак, берничә битле кара такта да була иде. Грифель тактасы дип атала иде бугай ул. Аңа акбур сыман әйбер белән язып та, сөртеп тә була.

Менә шундый хәерчелек шартларында да, илебезгә үлем куркынычы якынайганда да, бер мәктәп тә ябылмаган, бернинди «оптимизация» үткәрелмәгән. Бүгенге, баеп чери башлаган илебездә мәктәпләрне дисталәп, йөзәрләп «кыскарту» бара. Гитлер булдыра алмаганны бүген үзебез БУЛДЫРАБЫЗ.

Сугыш елларында дәреслекләргә генә түгел, гомумән китапларга да мохтаҗлык бик зур иде. 1939-40нчы елларда урыс графикасына күчкәч, иске китаплар бетерелгән, ә яңалары күренә генә башлаганнар. Беренче укыган китабым «Мәхәббәт турында җырлар» булды. Аны икенче класста укыганда шкаф өстендәге чүп-чар арасыннан табып алган идем. Шуны укып латин әлифбасын үзләштердем. Аннан соң келәттә тагын бер калын китап таптым. СТЗ-ХТЗ тракторының төзелеше, эшләеше турында кулланма иде бу. Җентекләп өйрәнеп чыктым мин ул «тимер атны». Мавыгып укый башлагач, китаплар да төрле яклардан табыла башлады. «Мең дә бер кичә» әкиятләре, Яков Перельманның «Кызыклы астрономия»се икенче-дүртенче классларда иң яратып укыган китапларым булдылар. Ләкин булганнарын да иркенләп укып булмый иде әле. Көндез — вакыт, караңгы төшкәч, яктылык җитми. Йорт-өй тирәсендә бик күп эшләр бала-чагалар җилкәсендә: чишмәдән су

ташу, учакка утын әзерләү, бозауны, көтүдән кайтмаган сарыкларны эзләп табып алып кайту, абзарны чистарту, бәрәңге әрчү, бакча утау — алар санап бетергесез. Кыз балаларның безнекеннән дә күбрәк. Китапны качып-посып кына укыйсың. Көннәр кыска вакытта өстәл янына сукыр лампа каршына китап-дәфтәр тотып утырсам, әбиемнең ачуы килә башлый иде. «Көне буе ни эшләп утырасыз ул мәктәбегездә, өйгә кайткач та керәчин әрәм итеп укып-язып утырырлык булгач», дип шелтәли иде. Шулай итеп, дүрт классны мин өйдә дәрес әзерләп утырмыйча гына укыдым. Бабам гарәпчәдән, фарсыдан, иске төрки телдән тәрҗемәләп укыса да, әбием укый-яза белми иде. Бер генә китапны — Коръән китабын гына китап дип таный иде. Башка китаплар турында: «Аларның берсен укыгач, башкаларын уку ни пычагыма кирәк икән?» дигән сүзләре көлдерә иде мине.

Актүбәнең башлангыч мәктәбендә бер яхшы традиция бар иде. Октябрь бәйрәме, Яңа ел алдыннан авыл халкына «театр» уйнап күрсәтә идек. Миңа да «артист» булырга туры килде. «Киләчәк безнеке» дигән «театр»да мин бер бабай ролен «уйнаган» идем. Сүстән үзем ясаган сакал-мыекны сагыз белән битемә ябыштырып чыкканымны гына хәтерлим. Пьесаның эчтәлеге исемдә калмаган. Авторы Габдрахман Әпсәләмов икәнен әле шушы көннәрдә генә, «Татар энциклопедиясе»н актарып утырганда гына күреп алдым.

Мәлбагышка йөреп укыганда Яңа ел бәйрәменә тагын бер «театр» әзерләп алып кайткан идек. Анысы турында бераз соңрак.

Актүбә башлангыч мәктәбеннән соң V-VII классны Мәлбагышка, әйткәнемчә, сигез чакрым йөреп укый идек. Кышкы салкыннар, кар-бураннар башлангач, безгә көн саен барып-кайтып йөрергә рөхсәт итмиләр иде. Мәктәп янында «торак» дип атала торган, өч өлешкә бүленгән бер буш йортны биреләр иде. Бер башында кызлар, икенчесендә без — малайлар кереп урнашабыз. Уртада уртак бүлмә. Анда ничек әзерли алсак, каян тапсак, шул утынны тутырабыз. «Торак» бөтенләй үзебезнең карамакта. Шимбә көн дәрестән соң Актүбәбезгә кайтып китәбез. Дүшәмбе көн иртән туры дәрескә киләбез. Дәресләрдән соң, мичкә ягып, өч көн буена суынып беткән «торагыбызны» җылытабыз. Чуен чүлмәкләр белән иртән, кичен бәрәңге пешерәбез. Вакыт-вакыт боламык, крахмал боткасы белән аш төрләндерәбез. Бераз сөтебез дә була иде. Аны бозландырып катырып алып килә идек. Каймагы өскә күтәрелеп каткан була. Беренче көннәрне шуны калак белән кимереп сыйланабыз. Зәңгәрсу аскы ягы боткага китә. Өч чүлмәгебезнең икесе зуррак, алардан өчәр малай туена. Кечерәк чүлмәгебездән — икебез. Иртән иртәрәк торып, мич ягу, кичтән әзерләп куйган чуеннарны мичкә кую — чиратлап эшләнә. Бишенчедә укыйсыңмы син, жиденчедәме — бернинди аерма юк, бертигез җаваплылык. Будильниксыз ничек уяныллгандыр — белмим.

Бик каты салкыннар, күз ачмаслык бураннар булганда, безне ял көненә дә Актүбәгә җибәрмичә, төн житкәнче саклыйлар иде. Ә кайтасы, кайтып, өйдәгечә сыйланасы килә. Төрле хәйләсен табып, качып та киткәли идек. Мәсәлән, дәрестән чыккач, мичне ягып җибәрәбез. Сакчы укытучы өчен бу кайтырга жыенмыйбыз дигән «сигнал» була. Шуңа ышанып, үзе дә өенә кайтып китмәсә, кичке бәрәңгене пешерергә әзерләнә башлыйбыз. Укытучы апаның үз йортында да эшләре күп, «Ярый, балалар, иртәнгә буран тынса, кайтып китәрсез» дип китеп бара. Ул күздән югалуга, берәмләп чыгып, урам башында җыелабыз да, Актүбәгә юнәләбез. Ул чорда төнге буранда сигез чакрым арада адашу бик җинел иде бит. Юллары да, авыл ягыннан күренерлек ут яктысы да, каяндыр үткән-сүткән машина уты-тавышы да юк. 10-15 адымнан бер-беренне күрмисең. Элегрәк елларда юлчы адашмасын өчен юл буйлап «маяклар», очына бәләкәй салам көлтәсе бәйләнгән таяклар, утыртып куя торган булганнар. Без укыганда аларны куеп йөрерлек кеше юк иде. Кызларыбыз да батырлар иде. Без малайлар качу «операциясен» оештырганда, беркайчан да бездән калмадылар, һәм берсе дә безне сатмады. Бишенче класстагылары арасында бик бәләкәйләре дә бар. Бигрәк тә Гадимә исемлесе, Газизә апа кызы. Барыбыз да бәрәңге балалары инде. Арыганнар-талганнар буран ыжгырган ачык төнге даланы үткәндә юлдан язмасыннар өчен бәләкәйрәкләребез, йомшагракларыбыз алдан әзерләп юлга алган дилбегәгә тотынып баралар.

Гомумән, 40нчы елларның кышлары бик салкын, күз ачмаслык буранлы, ә җәйләре бик эссе булдылар бугай. Кыш көннәрендә: «Кибеттә аракы каткан!» дигән сүзләрне ишетергә туры килә иде. Авыл кешесенең йорт тирәсен, абзарларын каплап куйган бураннарны үзебезнең күргәнебез булды. Ял көненә кайтасы бер көнне менә шундый буран купты. Безгә «дежур»га иң кырыс, иң яраткан ир укытучыбызны, сугышта бер кулын калдырып кайткан Галиев абыйны куйдылар. Холкы бик тә «командирский» иде. Аның алгебра дәресләрендә иң шук малайлар да фәрештә балалары кебек утыралар. Берәребезнең йокымсырап китәнен яисә игътибарсыз утырганын күрсә, бер сүз эндәшмичә акбур кисәген чиртеп очырган төсле генә итеп атып җибәрә тегенең маңгаена. Арттарак утырганы булса да тидермичә калмый. Соклана идек аның снайперлыгына. Шул номерын циркта күрсәтеп тә ипилектозлык эшли алган булыр иде. Холкыннан шүрләсәк тә, барыбер аның янына сыена идек. Галиев Мөхәррәм абыйның нинди кешелекле җан икәнен, бер көнне үзенең шул искиткеч оста һөнәрен күрсәтми калуда күргән идем. Көз ахыры. «Торак»ка керергә иртәрәк. Мәктәпкә, сигез чакрымга, әле көн саен килеп-китеп йөрибез. Бер көнне салкын яңгырдан чыланып, лыжыртаган чабаталар белән килеп кердек Галиев абый дәресенә. Арткы рәттә, янымда утыручы минем иң якын дустым, туганнан туган Индус, башын партага салып йоклап китте. Төртеп карадым, уянмый. Ямаулы иске телогрейкасы өстеннән пар күтәрелгәне күренә. Галиев абый моны күреп кулына бурны алгач, бер-ике мизгел карап торды да, тактага борылып яза башлады. Бөтен дәресне йоклап үткәргән Индусне, күрмәгән кебек итеп, уятырга да кушмады.

Менә шул «снайпер» укытучыбыз теге буранлы төнгә каршы безне сакларга куелган иде. Барыбер качарга булдык. Буран артык әшәке булу сәбәпле, бу юлы малайлар гына. Сыналганча башладык «операция»не: ашыкмыйча мич ягып торакны җылыттык, кичке бәрәңгене пешереп ашадык. Һәр шимбә клубта була башлаган кинога билетлар алып кереп киттек! Клуб безнең күршедә генә. Бүректән башка, өске киемнәрне киеп тормадык. Качу ниятебез турында бер шик тә калырлык түгел иде сыман. «Разведка» безнең сакчыны күренмичә генә күзәтә. «Китте!» дигән хәбәр килү белән 5-10 минут үтмәгәндер, без инде юлда идек. Мәлбагыштан чыгып бер чакрым да үтмәгәнбездер, арттан безне ат атланган бер кеше куып җитте дә, атыннан сикереп төшеп, әле беребезне, әле икенчебезне бер кулы белән якадан, икенчесе белән штан төбеннән эләктереп як-якка ыргыта башлады. Алдан баручы, Декан дигән сәер исемле, шуклыгы белән танылган малайны башы белән кар көртенә батырып куйды. Күз ачып йомганчы диярлек тиз булды безнең «операцияне» чәлпәрәмә итү. Кем икәнен беренче «матур» сүзләреннән танадык безне тар-мар итүчене. Мәктәбебезнең директоры Исхаков абый үзе иде ул! «Пленныйлар»ны куган кебек итеп алып кайтты ул безне торагыбызга. Галиев абыебыз бездән хәйләкәррәк булып чыккан. Шунысы гаҗәп: икенче көнне дә, соңрак та безне ачуланучы, шелтәләүче, тикшеренүче булмады. Актүбәгә килеп, аналар җыелышы үткәргәндә дә, Исхаков абый ул төнге вакыйганы искә алмады.

Берәребезнең дәрес хәзерләп утырганын да хәтерләмим мин ул «торакта». Ярым караңгы бер бүлмәдә, чит авылда салкын кышны үткәреп, бернинди контрольсез яшәп ятучы төрле яшьтәге сигез малай ничек инде «җиделе» сукыр лампа тирәсендә дәрес карап утырсын ди? Андый гадәт безнең кызларда гына бар иде. Яз җитеп, көн саен барып-кайтып йөри башлагач, имтиханнар алдыннан бераз өйдә дә укырга туры килә иде килүен.

«Җиделе» сукыр лампага да керосин житкереп булмый иде әле. Мәктәп директорының, укытучылар бүлмәсенең лампаларыннан сорамыйча алып чыккаларга туры килә иде. Хуҗалары юк чакта, лампаларының башын борып ачып, керосинын авызыңа тутырып аласың да, торакка чыгып йөгерәсең. Ерак юл түгел. Малайлар үз бүлмәләренә, кызлар үзләренекенә ташыйлар. Хәзерге сайлаулардагы «карусель» формасында була иде ул, үзеңнең лампага бушатасың да, кабат йөгерәсең. Шундый «операциянең берсе минем гаебем белән өзелә язды. Галимә исемле теге иң бәләкәй кызыбыз директор бүлмәсеннән чыгып килә. Яңаклары басудан янак капчыкларына бөртек тутырып кайтып килгән әрләннекесыман кабарып чыккан, куркуыннан күзе

акайган. Шуны күреп, түзә алмыйча кычкырып көлеп җибәрдем. Гадимә дә, көчкә тыелып, мәктәп ишеген ачып чыгу белән керосинын бушатты. Коридорда түгеп, эзе, исе калса, эләгүебез мөмкин иде. Шуннан соң мине кагнаштырмадылар бу җаваплы эшкә. Сакта тордым.

«Җиделе лампа» дигәне аның җиде буй җепкә тукылган тар филтәсен аңлата. Ә «сукыр лампа, пыяла куыксыз лампа дигән сүз. «Җиделе куыксыз» бер шәм яктылыгы бирә. Куыгын кидертсәң, күпкә яктырак, ләкин керосинны күп яндыра. Хәллерәк кешеләрдә, яисә кунаклар килгәндә, ашка җыйганда «унлы» куыклы лампа кулланыла иде.

Берәр кызыклы китап кулга эләксә, аны беребез укып чыга да, утны сүдереп яткач, шуны безгә сөйли. Иң оста китап сөйләүчебез Әмир исемле малай булды. Жюль Верннның «Серле утравын», «Унбиш яшьлек капитанын» яттан белгән кебек җентекләп, сурәтләп, әллә ничә төн рәттән сөйләгәне хәтердә. Бөтенләй ятим үсте ул бик тә талантлы малай. Әнисе сугыш алдыннан вафат булып, әтисе сугышта ятып калды. Солдат хезмәтенә киткәнче әбисендә булды. Армиядан Донбасска китеп, пенсияга тикле күмер казыды, аннан авылга кайтып, урман караучы булып эшләде. Бүгенге көндә Әмир Галиев, мин һәм минем туганнан туганым, классташым Индүс Мостафин — өч якын дус, безнең чор Актүбә малайларын төрле уеннарга, шуклыкларга әйдәп йөрүчеләр генә әле исәннәр.

Иң кызыклы маҗаралар, иң тәвәккәл шаяртулар «идеясе» Индүстән чыга иде. Инде үсеп җитеп, армия хезмәтеннән кайткач та, күрсәтте ул үзенең егетлеген. Армияга киткәнче үк яратып йөргән, әтисез-әнисез үскән Азнакай кызы Рәйханәне әбисе ирексезләп башка егеткә кияүгә бирергә җыенганын ишеткәч, Индүсебез ат атланып, бездән 20 чакрым Азнакайга чабып, Рәйханәсен, үзенең беренче һәм гомерлек мәхәббәтен, урлап алып кайтты. «Урлап» дисәң дә бик дөрес булмый әле. Индүс барып җиткәндә никах мәҗлесе инде башланган булган. Рәйханәсен ул шул мәҗлестән талап алып кайтты.

Сүз унаеннан, шуны да әйтер идем: ачлык, хәерчелек, әйтеп бетергесез гаделсезлек елларында әтиләрсез, әниләрен дә күрер-күрмәс үскән Актүбә малайлары-кызлары арасыннан берсе дә нинди дә булса бозыклык юлына басмады, җинаять кылмады, әниләрен, әтиләренең исемен, авылдашларын хур итмәде.

Әйе, Мәлбагыштагы «торагыбыздан» кышкы каникулга алып кайткан «театр»ны искә алырга вәгъдә иткән идем. Хәзер шуның турында сүз. Ул «театрның», ягъни, пьесаның авторы да, эчтәлеге дә инде бөтенләй онытылган. Күрәсең, күңелгә ятышлы әйбер булмагандыр. «Сәхнә» артыннан «суфлер»ыбызның «артистларыбызга» гына түгел, бөтен «залга» ишетелерлек итеп, «Ишеттеңме?» дип әйткән бердәнбер сүзен генә хәтерлим. «Театр» барышының икенче яртысындагы бер күренештә, ролен алтынчы класс кызыбыз Сания уйнаучы бер «хатын» ачуланып, икенче «хатынга» нәрсәдер сөйли. Тегесе, «Әйе шул, әйе шул» дип җавап биреп кенә тора. Сания үзенең «монологын» ятлау түгел, укып та карамаган. «Суфлер»дан ишеткәнен ишетеп, ишетеп җиткермәгәнен үзенчә итеп, ачулана бит тегесен. Тамашачылыр да тыныч кына утырмыйлар: «Әнисенә ошаса да ошар икән» дип Санияне мактыйлар, көлешәләр. Халык шаулашкан саен, «суфлер» да тавышын көчәйтә. Аның «артисткага» ишетелсен дип, кычкырып диярлек: «Ишеттеңме?» дип әйткән сүзен Саниябез: «Эт тишеге!» дип җикеренеп «кабатлап» та куйды. Шул җитә калды халыкка. Буылып көләбез барыбыз да, кая анда «театрны» дәвам итү! «Артистларыбыз» уйнарлык хәлдә түгел. Өлкән укытучыбыз Шәех абый урыныннан торып басып: «Рәхмәт, балалар! Тырышкансыз. Бик күңелле театр алып кайткансыз», дип, безне мактап, халыкны тагын бер кабат көлдереп тәмамлады ул тамашаны.

Мәлбагышта укыган елларыбыз бәләкәй чагыбыз белән хушлашуыбыз булган икән. Җиде класс укуны тәмамлагач, күпчелегебез укуларын дәвам итә алмады, төрле һөнәрләр үзләштереп, эшкә урнаштылар. Безнең якларга килеп җитә башлаган нефть чыгару күпләребезне колхоздан аерды, авыл халкының әкренләп хәлен яхшыртты дияргә була. Укуларын дәвам итүчеләр төрле якларга таралдылар. Сигезенче класска мин берүзем Бөгелмәгә, авылыбыздан 33 чакрымга 3нче татар урта мәктәбенә киттем. Бу язмаларымның темасы бәләкәй чак турында булганга

күрә, анда укыган елларым һәм аннан соңгылары турында җәелеп язып тормыйм. Бәләкәй чагымның кая таба борылганын берничә җөмлә белән әйтеп китү өчен генә искә алып, хәтер капчыгымны янадан төйнәп куям.

## Очып китә алмасам да, талпынып карадым

Бөгелмә мәктәбенә бабам мине үзе алып килде. Үз йортлары белән торучы электән таныш кешеләргә мине урнаштырганнан соң, мәктәп директорына мине җитәкләп диярлек алып кереп, ана: «Улым синдә укысын!» дип, ә мина: «Кеше булганчы укыйсың!» дип, мине калдырып, кайтырга чыгып та китте.

Тугызынчы класста укыганда мин Мәскәүнең халыкара мөнәсәбәтләр институтына керергә хыяллана башладым. Яраткан укытучым инде бик өлкән яшьтәге Неонелла апа Шашель ярдәме белән немец телен ныклап өйрәнергә тотындым. Унынчы класста җинелрәк немец телле китапларны сүзлексез укый башлаган идем инде. Институтка гариза яздым, тиздән җавап та килде. Бик тә беркатлы хыялый егет икәнсең дип турыдан-туры әйтелмәсә дә, ул җавапның мәгънәсе шулайрак иде. Әдәпле генә итеп, КПСС өлкә комитетыннан рекомендация алып килергә кушканнар. Немец телен шактый үзләштерсәм дә, обком телендә сөйләшерлек рәтем булмады шул... Зәңгәр күккә менәргә исәпләп корылган хыялый баскычым чәлпәрәмә җимерелеп төшкәч, акыл-тәҗрибә туплап өлгермәгән хәлдә җирдә калдым. Аның өстенә, мәктәпне тәмамлап чыккан көнне диярлек авырып китеп, бер айга хастаханәгә эләктем.

Аннан дәваланып чыкканда инде берәр институтка юл тотарга соң иде. Кая китеп «кеше булганчы» укуны ничек дәвам итәргә кинәш бирерлек кешем дә юк. Паспортсыз авылыңа бер кайтып эләксәң, аннан үзең теләгән якка китә алуың да шикле. Шуларны уйлап, Бөгелмә урамнарында арлы-бирле сугылып йөргәндә, хәрби училищеларга чакырган бер белдерүне күреп, военкоматка кереп киттем. Анда инбашларына күп йолдызлар тагылган бер абый утыра иде. Аның «капитан» булганын үзем курсант погоннарын таккач кына аңладым. Саратовка, танк училищесына барасыңмы?» —дип сорагач, «барам» дидем инде. Казаныбызда шундый ук училище булганын мин белми идем, ул әйтмәде. Саратовка планы үтәлмәгән булгандыр инде.

Хыялларымда гомеремне хәрби хезмәткә багышлау гел дә юк иде юкса. Кырыс холыклы бабамның: «Кеше булганчы укыйсың!», дигән сүзе чигенергә юл калдырмады.

Авылга кайтып, офицерлыкка укырга җыенганымны әйткәч, бабам куанып хуплады. Улың, Әнвәр абыйны да күз алдына китергәндер инде.

Училищены тәмамлап өйгә кайткач, лейтенант погоннары тагылган, ул елларда гамәлдә булган бик тә ялтыравыклы парад формасын киеп, бабам каршына килеп баскач, ул, күнеле тулып: «Булдымы, улым? Укып чыктыңмы?» — дип сорады. «Булды, бабай, рәхмәт сина», — дидем. Бик сөенде бабам. Әтиемнең ана: «Кайтмый калсам, Фәндәсне укыт!», дигән васыяте булган икән. Шул көнне генә бабам аны мина җиткерде. Җаным тартылмаган юлны сайлаганыма үкенгәнемне бабама да, әниемә дә беркайчан да сиздермәдем.

Армиядә хезмәт итүем, бер барып эләккәч, 34 елга якын сузылды. Холкым армиягә ярашлы булмаса да, отставкага полковник дәрәҗәсендә чыктым. Хәрби хезмәттә яшьлек елларымны, ярты гомеремне үткәргәнемә инде күптән үкенмим.

Язмыш барыбер үзенекен итте. Күңелемә ятышлы киләчәгем дә, «кеше буласым» да мине әле алдарак көткән икән...

# ҖЫРЛЫ-МОҢЛЫ ЕЛЛАР...

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ ОЕШУГА 75 ЕЛ

Һәр үткән ел күпмедер вакыттан соң тарихка әйләнә. Һәр үткән елда диярлек җәмгыятьтә булган ниндидер бер вакыйга үзенең эзен калдыра. 1937 елның 21 августында Татарстан Совнаркомының 1383 нче карары нигезендә Татар дәүләт филармониясе оештырылу да әнә шундый вакыйгаларның берсе. Дәүләт карамагындагы әлеге оешманың барлыкка килүе дә иҗат көчләрен бергә туплап бер максатка, бер идеологиягә хезмәт иттерү була. Еллары да нинди еллар бит! Дустың яки хезмәттәшеңнең елмаеп исәнләшмәвеннән дә дошман эзли торган вакытлар. Нәрсә турында җырлаячагыңны, ни сөйлисеңне бары тик өстәгеләрнең җиз иләге аша үткәреп кенә халыкка житкерә аласың. Тик ничек кенә булмасын, Татар дәүләт филармониясенең оешуы татар җыр сәнгатен, фольклорын, милли музыкасын үстерүдә мөһим роль уйный.

Филармония — грек сүзеннән гармония дигәнне аңлата, ягъни филармония эчендә барлыкка килгән симфоник оркестр, җыр һәм бию ансамбле, милли эстрада һәм башка сәнгать әһелләре берләшеп югары дәрәҗәдәге сәнгатьне тудыру.

Бу шулай ук эстрада бүлегендә эшләгән аерым җырчыларның үзләрен таныта алуларына да зур мөмкинлек бирә. Йөрәгендә милләтпәрвәрлек хисе булган һәр татар баласы ул чорда сәнгатьнең никадәр авырлык, сабырлык, тырышлык белән бирелүен аңлый булыр.

Филармония оешып, инде тулы көчкә эшләргә, милли сәнгатьне үстерүгә мөмкинлекләр ачылды дип сөенеп кенә йөргәндә Ватан сугышы башлана. Илгә килгән кайгыны ил белән күтәрергә кирәклеге композиторларыбыз, сәнгатькәрләребез иҗатларына да үзгәрешләр кертә. Репертуарда күбрәк Ватан-ананы саклау, дошманнардан азат итү, җиңү көнен якынайту темасына караган җыр-шигырьләр өстенлек итә. Әнә, Татар дәүләт опера һәм балет театрында Муса Җәлилнең халык фольклорына таянып иҗат ителгән, туган илне, милләтне саклау проблемаларын яктырткан «Алтынчәч» операсының премьерасы бара, сәхнәдән Алтынчәчнең: *Куркакларга хатын булганчы, батырдан тол калу яхшырак...* дип өзгәләнгән сүзләре яңгырый; Камал театры сәхнәсендә Фатыйма Ильская «Тормыш җыры» әсәрендәге Басыйр образы аша тылдагы күпме хатын-кызны үзләренең Басыйрлары белән очраштыра: *Мин үлмим, җиңелмим, җиңелә торган кеше түгел мин!* Филармония артистлары Фәйзи Йосыпов, Әзәл Яһүдин, Зифа Басыйрова, Җәвәһирә Сәлахова, Гөлсем Сөләйманова, Разия Тимерханова, Әлфия Галимова һәм башка бик күпләр тыл хезмәткәрләренә, фронтларга барып салкын окопларда, госпитальләрдә сугышчыларга газиз аналарының, сөйгәннәренең сәламнәрен җыр аша ирештереп яралы җаннарын дәвалыйлар.

Филармония тарихында мәшһүр җырчы Рәшит Ваһапов исеме аерым бер урын алып тора. Үзенең саф халыкчан тавышы белән халык җырларының кабатланмас үрнәген тудыручы, татар моңын үзенә генә хас булган төсмерләр аша житкерә белүче җырчы филармониядә 22 ел эшли, татар җырын халыкка таныта. Ләкин «Бармы соң бездә чын кеше кадерен белү» — филармониягә иң күп табыш китерүче җырчы хөкүмәт тарафыннан зурлаулар, игътибарга бик үк тиенә алмый. Шулай ук, халык никадәр генә яратса да әлеге хәл «музыкаль белеме юк» дип Габдулла Рәхимкуловны да читләтеп үтми.

1946 елның 26 февралендә Г.Тукайның тууына 60 ел тулу уңае белән филармониягә бөек шагыйрьнең исеме бирелү филармония тормышында зур вакыйга була.

1940-50 еллар филармониянең күтәрелеш чоры булса,1960-70 еллар чын мәгънәсендә чәчәк ату чоры дип бәяләнә ала, яңа, яшь талантлар өлгереп житә. Әлеге еллар

Илһам Шакиров һәм Әлфия Авзалованыкы дип тә атала аладыр, бәлки. Ул елларда яше-карты, олысы-кечесеннән башлап әлеге талантларны белмәгән, аларның иҗатларын яратмаган кеше булдымы икән? Патриотик җырлар тематикасы беркадәр онытыла төшеп, җырчыларның репертуарында лирик җырлар өстенлек итә башлый. Халык аларның концертларына агылып йөри, авылларда концерт куйганда үзләрендә кундырып, юк ризыкны да бар итеп, хөрмәт күрсәтүне мәртәбә, дәрәҗәгә саный. И халкымның ихлас, самими чаклары! Ул вакытта һәркем үз дәрәҗәсен, үз урынын яхшы белгән шул.

Татар җыр сәнгате турында сөйләгәндә күз алдына үзенең тыйнак елмаюы, йомшак-моңлы тавышы белән Таһир Якупов килеп баса; татар сәхнәсенә салмак бию хәрәкәтләре белән килеп кергән, композиторларыбыз әсәрләрен дә, халык көйләрен дә тыңлаган саен тыңлыйсы килерлек дәрәҗәдә башкаручы Вафирә Гыйззәтуллина, Венера Шәрипова, Зиннур Нурмөхәммәтов, Рабига Сибгатуллина, Флера Сөләйманова, Римма Ибраһимова, Хәмдүнә Тимергалиева һәм башка бик күпләр татар җыры аша үзләрен таныта, татар җыры үсешенә үзләреннән зур өлеш кертүче җырчылар саналырга хаклы.


*Филармония артистлары Урта Азиядә гастрольдә. 1957 ел.*

Симфоник оркестр, Җыр һәм бию ансамбле бераз вакыттан соң филармониядән аерылып чыгып аерым коллектив булып яши башлый. Ләкин максатлар, бурычлар уртак: татар музыкасын, җыр сәнгатен югары сәнгать дәрәҗәсенә үстерү, тарихын баету! Озак еллар филармониянең сәнгать җитәкчесе булып эшләгән, мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров үзенең бер язмасында: «Сәнгатьнең нинди генә төрен алсак та, ул тирән милли хисле һәм югары профессиональ дәрәҗәдә булырга тиеш. Ә безнең татар милли сәнгатен ул дәрәҗәгә күтәрүдә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең дә, филармониянең дә өлеше бик зур булды» — дип искә алып үтә.

Филармония тарихы, аның эшчәнлеге турында сөйләгәндә нәфис сүз сәнгатенә дә тукталмыйча үтеп булмый. Нәфис сүз, шигърият ул чакта сәхнәнең түрендә иде. Чын мәгънәсендә нәфис сүз остасы булган Х.Сәлимҗанов, Г.Шамуков, Ф.Йосыпов, Ә.Яһүдин, А.Арсланов, И.Сафин, Р.Сабировлар шигырьнең асылын, сүзнең тәмен, кичерешләрнең гамен бирә алучы осталар иде. Кызганыч, бу жанрны соңгы елларда «очсызлы» юмор алыштырды, тамашачы концертка ял итәргә, көләргә килә дигән нияттән чыгып, тамашачыны чын сәнгатьтән бераз читләштерделәр. Әлеге нәфис сүз осталарының һәркайсының чыгышын аерым-аерым гына да сәгатьләр буе тыңлап була иде, чөнки аларның максаты үзләрен күрсәтеп дан казану түгел, милләтебезнең, халкыбызның асыл ташлары булган шигъри хәзинәсен халыкка ишеттерү, халыкка җиткерү.

Үзенең затлы килеш-кыяфәте, мәгрур тавышы белән Айрат Арслановның Тукай әсәрләрен укуын ул чор тамашачылары әле дә хәтерли булыр; Әзәл ага Яһүдинның «Саратский яшел гармун»ны үзе сөйләп, үзе уйнап җибәрүләре! Концерт эчендәге тагын бер кечкенә генә концерт иде. Үзе дә соңыннан йөрәк авыруыннан вафат булган Илдус Сафинның «Кайсыгызның кулы җылы, бәйлисе бар йөрәкне?» дип залдагы тамашачыга әрнүле чакыру җибәрүе, татар шигъриятен яхшы белгән, һәр сүзе, һәр интонациясе белән йокымсырап утырган тамашачыны да уятырлык итеп яңгырата алучы Рәшит Сабиров... Шагыйрь, язучы, көйләр авторы һәм башкаручы,күп концерт программаларының сценарий авторы һәм режиссеры Алмаз Хәмзин... Бар бит бездә талантлар,бар, тик аларны югалтмаска, таркатмаска гына кирәк!

Җыр сәнгатенең беренче көннәреннән үк җырчыларыбызның уң кулы булган баянистларыбыз... Башкортта кубыз-курай, татарда мәҗлес күрке булган гармун-баянна-

рыбыз! Инде сезне дә сагынып сөйләргә генә калыр микәнни... Сәхнәдә – фонограмма, мәҗлесләрдә караоке («карап укы»). Юкса хәзерге сәнгать әһелләре дә «сәнгатькә, халыкка хезмәт итәбез» диләр, тик нинди дер ясалма, җинел юл белән. Фәйзулла Туишев, Оркыя Ибраһимова, Рәфкать Гомәров, Марс Макаров, Фәрит Хатипов, Рамил Курамшин, Кирам Сатиев, Рөстәм Вәлиев һәм башка бик күпләр — чын мәгънәсендә кин профильле музыкантлар, композиторлар, татар музыка сәнгате турында китап авторлары. Аларны тыңлап җанына рәхәтлек аласың, үзләрен күрмичә дә беренче аккордларыннан ук кем уйнаганын аерасың, чөнки алар бер-берсен кабатламый, һәркайсының үз стиле, үз уйнау осталыгы. Бу хакта 1967-73 елларда филармониянең сәнгать җитәкчесе, Тукай премиясе лауреаты, музыка белгече Мәхмүт ага Нигъмәтҗановның сүзләрен китереп үтү дә урынлы булыр.



*А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор ансамбле.*

«Ул чакта филармониядә 300 гә якын музыкант, җырчы һәм биюче эшләде. Андагы 4 коллективның иҗади эшчәнлеге турында махсус китаплар язып булыр иде, чөнки аларның һәрберсе (симфоник оркестр, милли ансамбль, лекторий, эстрада) аерым, үзенчәлекле мөстәкыйль коллектив, һәм алар барысы да татар милли сәнгатебезнең төрле якларын чагылдырдылар, аның байлыгын, милли йөзен, дөнья мәдәниятенә керткән өлешен лаеклы гәүдәләндерделәр. Коллективтагы шәхесләрнең шактые турында озак итеп сөйләп булыр иде һәм алар аңа лаек». *(«Ватаным Татарстан» 2002 ел, 18 октябрь).*

Әйе, болар барсы да үткәндә... Кайчакта күңелгә шундый уйлар да килә, филармониядә эстрада бүлеге, ягъни җыр сәнгатен үз тирәсенә туплап,тотып торучы үзәк таркалмаган булса, бәлки җыр сәнгате бүгенге көндә бу хәлгә төшмәс, көйсез җырлар, сүзсез шигырьләр, тавышсыз җырчылар өстенлек алмас иде...

...Филармония белән 75 еллык гомерендә берничә кеше җитәкчелек итә. Араларында музыкаль белемгә ия булмыйча оста оештыручы булганнары да, сәнгатьне тирәнтен аңлап эш иткәннәре дә бар. Бүгенге директор Кадим Назир улы Нуруллин филармонияне 2003 елда — беркадәр авыр вакытында кабул итеп ала. Илдәге үзгәртеп коруларның сәнгатькә дә нык кына суккан, ак-каралар бутала башлаган, эстрада бүлеге таркалып, гастрольләргә йөрүләр дә тукталган вакыт була ул. Филармонияне саклап калыйм дисәң эшне традицияләргә таянып,төрле жанрлардагы сәнгать әсәрләрен бүгенге көн таләбенә туры китереп, заман ихтыяҗына җавап бирерлек итеп оештырырга кирәклеге ачык билгеләнә. Россиянең халык артисты, Г.Тукай премиясе лауреаты А.Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестрының, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Анатолий Васельевский җитәкчелегендәге джаз оркестрының да, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге фольклор ансамбленең дә,Татарстанның халык артисткасы Лидия Әхмәтова җитәкләгән әдәби-музыкаль лекториябүлегенең дә бүгенге көндәге бурычы Тукай исемен йөрткән Татар дәүләт филармониясен чит илләрдә таныту белән берлектә зәвыклы яна буын тамашачысы тәрбияләү.Татар моны,татар милли сәнгате яна этапта. Әле аны яңгыратасы да яңгыратасы...

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА,**
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Балык Бистәсе

Балык Бистәсе авылы — Балык Бистәсе районы үзәге, Казаннан 91 чакрым ераклыкта урнашкан.

Балык Бистәсе атамасы тарихи-статистик белешмәләрдә искә алына. XVIII гасыр мәгълүматлары теркәлгән белешмәдә күрсәтелгәнчә (аны Д.А.Корсаков төзегән), Балык Бистәсендә 761 дворовый крестьяннар көн иткән. И.А.Износков җыеп чыгарган тарихи белешмәдә дә авыл искә алына. Ул бик күптәнге заманнардан бирле бу авыл кешеләренең кайберләре көмешчелек һәм балыкчылык эше белән шөгыльләнүе, сату өчен төрле савыт-саба, бизәнү әйберләре, ат җигү дирбияләре ясаулары, ә хатын-кызларның челтәр әйберләре бәйләве турында яза.

1898 елгы белешмәдә Балык Бистәсендә урыслар яшәве искәртелә. К.П.Берстель белешмәсендә бирелгән мәгълүматларга караганда, Балык Бистәсе авылында 603 рус кешесе яшәгән. Бер тарихи чыганакта язылганча, Балык Бистәсендә көмешчеләр дә булган.

Республиканың үзәк өлешендә, Каманың уңъяк ярындагы Балык Бистәсе районы 1965 елның 12 гыйнварында оештырылган. 2005 елның 1 апреленә Балык Бистәсе районы мәйданы — 2052, 1 кв. м. Халкының саны 28,9 мең кеше. Авыл җирле үзидарәләр саны — 28, шәһәр тибындагы бистә (полелок) — 1, авыл торак пунктлары — 77, шуларның икесендә кеше яшәми.

Районда сөт комбинаты, кирпеч заводы, балык эшкәртү, ипи пешерү заводлары, икмәк кабул итү предприятиесе (Балык Бистәсе), спиртзавод (Шомбыт), Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы бар.

Балык Бистәсендә ике урта мәктәп, аның берсе мәктәп-гимназия исемен алган. Авылда хастаханә, даруханә, китапханә, балалар бакчалары, мәдәният йорты, мәчет бар.

## Балыклы Чүкәй

Балыклы Чүкәй авылы Балык Бистәсе районында, район үзәге Балык Бистәсе авылыннан 22 чакрымда, Казаннан 39 чакрым ераклыкта утырган.

Балыклы Чүкәй атамасы тарихи белешмәләрдә шактый еш очрый.

1898 елда басылып чыккан белешмәдә авыл атамасы искә алына. Авылда татарлар көн иткән. К.П.Берстель белешмәсендәге мәгълүматларга караганда, Балыклы Чүкәй авылында 860 татар яшәгән.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Балыклы Чүкәй авылы халкы күршедәге Шәдке, Казиле, Олы Укмас, Кече Укмас авыллары белән июньнең беренче декадасы ахырында Казы җыены үткәргән.

Олылар авыл атамасы барлыкка килүен болай аңлата.

Элек авыл уртасында бик зур һәм тирән күл булган. Күлнең бер читендә тирәк агачы үскән, шул агач төбеннән чишмә ургып утырган. Күлнең суы да шул саф чишмә суы белән тулып торган. Шушы балыклы түгәрәк күл буенда ялгыз гына чүңкәйгән бер өй булган икән. Менә шул чүңкәю сүзеннән чүкәй сүзе килеп чыккан һәм авыл Балыклы Чүкәй булып киткән имеш.

Билгеле, бу халык этимологиясе генә.

Балыклы Чүкәй авылы тау башында утырган. Авылның як-ягында урманнар, елгалар һәм чишмәләр бар. Авылның уң кул яктагы елгасының исеме — Чаптырган. Ана чишмә кушыла һәм халык: “Чишмә суы чаптырып ага”, — ди. Бу елгага Акъяр чишмәсе кушыла. Чишмә биек ак ярдан челтерәп агып төшә. Ә сул кул яктагы елга Ындырчы дип атала — ул элекке колхозның ындыр табагы артыннан ага. Бу елгага да чишмә кушыла. Урман куенында агып ятучы чишмәне исә авылда туып-үскән, шәһәрдә көн иткән Габделхак атлы бер кеше карый. Элек ул ташландык булган.

Авылга терәлеп үк аккан зур гына елганы халык Завод елгасы дип йөртә. Сугыш елларында завод кызыл кирпеч чыгарган. Еллар үтү белән завод беткән, истәлеккә елга атамасы гына калган.

Ындырчы елгасы агып төшә торган тау башында, куаклар эчендә, биек агачлар арасында Яшьләр аланы бар. Ул аланга яшьләр җыелышып утырырга менгәннәр, бәйрәмнәр һәм туган көннәр үткәргәннәр.

Авылның зираты артында, Чаптырган елгасы буенда Карлыганлык дигән болын бар. Анда элек колхозның карлыган бакчасы булган. Бакча матур булып күп уңыш биргән. Хәзер анда карлыганнар калмаган диярлек инде.

Ындырчы суы аша салынган күперне халык Баллы күпер дип атый.

Балыклы Чүкәй авылында укытучы гаиләсендә Сәет Габделхәй улы Шәкүров туып-үскән.

## Бәби

Янгырашы бераз сәер тоелса да, Бәби атамасы аптыратмаска тиеш. Чөнки Татарстанда һәм гомумән, барлык төрки топонимиядә дә без әби, баба, бәби, ата, ана сүзләре кергән географик берәмлекләрне шактый очратабыз. Бу, күрәсең, төркиләрнең ата-ана, әби-баба, бәбине бик хөрмәтләве белән бәйләнешледер.

Бәби авылы Кама Тамагы районында, район үзәге Кама Тамагы эшчеләр бистәсеннән 25 чакрым ераклыкта, җирле үзидарә советы үзәге Олы Кариле авылыннан — 4, тимер юл станциясе Каратуннан — 50, Красновидово пристаненнән 15 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бәби атамасы тарихи белешмәләрдә искә алына.

XVIII гасыр мәгълүматлары тупланган Д.А.Корсаков белешмәсендә күрсәтелгәнчә, Бәби авылы чишмә янына утырган. Анда 90 ясаклы татар һәм 2 керәшен татары көн иткән. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Бәби авылының 69 хуҗалыгында 196 ир-ат һәм 196 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Бәби авылы халкы Коры Үләмә бассейнындагы 30 дан артык авыл белән бергә июль башында Чабыр җыены үткәрүдә катнашкан.

Олылар сөйләве буенча, иң беренче мәртәбә бу урындагы чишмә янына гаиләсе белән Биби исемле карчык килеп утырган. Габит исемле кеше урман чистарткан, йортлар салырга урын әзерләгән. Габит чокыры дигән елга да бар. Урман кисеп ышна ачкан Габит абзыйның исеме елга-чокыр атамасы буларак ныгып калган. Тирмән аралыгы дип йөртелгән су Үләмә елгасына сул яктан

килеп кушыла. Чыгыш суы яки Шәйтани кизләү суы Тирмән аралыгы елгасына уң яктан ялгана. Шул кизләү янында Сики русларының тегермән корасылары килгән, ләкин аны төзи алмаганнар. Кичкә тегермәнне сүтеп куючылар табылган. Авыл янында Каз күле бар. Бу күлнең суы вакыты белән була, вакыты белән бетә дә икән. Тирмән аралыгы елгасына Ермак яки Аракы елгасы кушыла. Бу елга янында качкыннар яшәгән дип сөйлиләр. Корбый тавы Яна Сала белән Бәби авылы арасында. Корбанбай исемле кеше бригадир булган. Ул бу тирәләргә ясмык чәчтергән, ләкин ясмыгы уныш бирмәгән, ә исеме ябышкан да калган. Халык телендә Әлмәндәр юлы дигән атама да сакланган. Әлмәндәр исемле кеше урманны чистартып җир ачкан.

## Бәки

Бәки авылы Кама тамагы районында, район үзәге Кама Тамагы бистәсеннән — 36, җирле үзидарә советы үзәге Келәнче авылыннан 3 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бәки атамасы тарихи чыганакларда һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә еш очрый. Казан ханлыгы чорына караган тарихи документларда да Бәки авылы искә алына. Бу авыл янында археологлар борынгы һәм соңгы болгар чорларына нисбәтле берничә авыл хәрабәләре тапканнар.

Д.А.Корсаков җыентыгында Бәки авылында XVIII йөздә ясаклы татарлар саны — 71, йомышлылар — 4, керәшен татарлары 6 кеше дип күрсәтелгән. Бәки авылында (XIX йөз) 48 хуҗалык булып, аларда 121 ир-ат һәм 101 хатын-кыз яшәгән.

1898 елгы китапта Бәки авылында татарлар яши дип күрсәтелә.

Бәки авылы янындагы Чабыр тавы янында Бәки һәм күрше-тирәдәге 30дан артык авыллар Чабыр исемле җыен бәйрәме үткәргәннәр. Диалектология белгече Нәҗия Борһанова чабыр сүзен Идел-Кама болгарларының савир-сувар этнонимына тиңләштереп карый.

Көчләп чукындыру сәясәтенең шаукымы буларак, авылда әле дә керәшен нәселләре дип аталган кешеләр бар. Элек аларны аерым күмгәннәр һәм авыл янында керәшен зираты урыны сакланган.

Аксакаллар сөйләвенә караганда, Бәки авылына кешеләр Шәһри Болгар таркалган чорларда килеп утырган. Элек бу урыннар калын урман белән капланган булган. Авыл урынын да халык урманнан чистартып утырган. Басуда Алып чабата каккан җир дип аталган ике таучык сузылган. Белгәнебезчә, мондый исемдәге географик берәмлек авылның шактый борынгы булуы турында сөйли.

Авыл яныннан Шаһиян инеше агып уза һәм Үләмәгә килеп кушыла. Ышна, Чилчә инешләре, Чабырлы тау астыннан чыга торган кизләүләр — тирә-юнь табигатен бизәп тора.Авыл янындагы Иске зират урынын халык исендә тота һәм монда әби-бабалар күмелгәнен яхшы белә.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МӨХӘММӘТШИН** Гарифжан Садыйк улы (12.10.1941, Чепья р-ны (хәзерге Балтач) Арбор а.), шагыйрь, ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1964) Мамадыш р-ны Үсәли (1964-68) һәм Балтач р-ны Чепья (1968-75) урта мәктәпләрендә директор урынбасары, Янгул урта мәктәбендә (1975-77) директор булып эшли, физика һәм математика фәннәре укыта. 1977-91 елларда Балтач район советы халык депутатлары башкарма к-ты рәисе урынбасары, 1991-2002 дә район хакимияте башлыгы урынбасары. «Яшьлегем кайтавазы» (1993), «Гомерлек язым» (1995), «Бәхет» (2001), «Керим әле урманнарга» (2001); балалар өчен «Уеннан уймак» (1988), «Серләвек» (1999), «Югалган йомгак» (2001) җыентыклары авторы. М. лирик һәм фәлсәфи эчтәлекле кыска шигырьләр остасы. Әсәрләрендә милли характерның иң матур үрнәкләрен, халык традицияләрен чагылдыра. Аның шигырьләренә композиторлар Р.Яхин, С.Садыйкова, Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари тарафыннан язылган җырлар популярлык казанды, 2001 елда «Җырлар тәлгәше» исемле видеокассетасы дөнья күрде. Матбугатта публицистик мәкаләләре басылып килә. Төрек язучысы Ә.Боенага һәм Й.Тауаслының дин өлкәсенә караган китабын татар теленә тәрҗемә итә. «Балтач энциклопедиясе»н (2 томда, 2006) төзүче-мөхәррирләреннән берсе.

Әд.: Гаташ Р. Туган җир гамен тоеп // Казан утлары. 2001. №10; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МӨӘМИНОВА** Энҗе Һилалетдин кызы (18.5.1924, элекке Бөгелмә кантоны Яна Кәшер ав. — 2.3.2009, Әлмәт р-ны Габдрахман а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Ташкент пед. ин-тын тәмамлагач (1948) Әлмәт р-нының Габдрахман авылында укытучы булып эшли. 1957 елдан матбугатта шигырьләре басыла башлый. «Ефәк яулыгым» исемле лирик шигырьләр җыентыгы 1961 елда басылып чыга. Балалар өчен күп иҗат итә. «Әниләргә һәм нәниләргә» (1964), «Исемдә» (1984), «Дуслар җыелгач» (1986) җыентыкларына тупланган шигырьләрендә балаларның күңел дөньясын, психологиясен, әйләнә-тирәне ничек кабул итүләрен гади генә итеп ачып бирә. «Синең өчен язам» (1968), «Бүләгем» (1970), «Чәчәкләр китердем» (1974), «Әйтер сүзем бар» (1979), «Килер язлар өчен» (1988), «Ач серенне мина» (1999), «Еллар аша» (2004) җыентыкларында исә әниләргә, туган җиргә мәхәббәт турында сүз бара, алар балачак, кеше язмышы кебек лирик уйланулар белән сугарылган. М. поэзиясе эчкерсезлеге, гадилеге белән аерылып тора. Аның кайбер шигырьләре композиторлар И.Хисамов, А.Хәйретдинов тарафыннан көйгә салынып, популяр җырлар булды. ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. премия лауреаты (2005).

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МӨХИЯРОВА** Рәзинә Хәйбрахман кызы (26.5.1956, Башк. Респ-касы Чакмагыш р-ны Аблай а.), шагыйрә, тел белгече, филол. фәннәре кандидаты (1999). Башкорт ун-тын (1979) тәмамлаганнан соң авыл сигезьеллык мәктәбендә укыта. 1982 дән Чаллы урта мәктәпләрендә, 1992 дән Чаллы пед. ин-тында укыта (2003 тән татар теле һәм аны укыту методикасы кафедра мөдире, 2006 дан профессор). «Сина булсын җырларым» (Чаллы, 1997), «Шәмдәлләрдә утлар» (2001), «Учларымда утлы күмер» (2002), «Алиһә» (2003), «Тыңла мине» (2004), «Җидегән йолдыз» (2007) шигъри җыентыклар авторы. Хезмәтләре лексикология, укыту методикасы, хәзерге татар теленең лингвистик поэтикасы мәсьәләләренә карый.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МУЛЛАГАЛИЕВ** Сафуан Галәветдин улы (12.9.1927, хәзерге Оренбург өлкәсе Абдуллин р-ны Чаганлы а. 19.9.2008,

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

Казан), шагыйрь. 1947-82 елларда Үзбәкстанның Маргилан шәһ. яши. 1982 дән—Казанда. «Сәлам бирәм» (1986), «Көзге балкыш» (1988), «Мәңгелек йөрәк»(1989), «Йөрәктәге төеннәр» (1997) җыентыкларында туган як табигате, гади кешеләрнең күңел байлыгы кебек темалар үзәктә тора. Туган ягыннан читтә яшәргә мәҗбүр булган кеше язмышын сурәтләгән «Биздерсәләр туган иленнән» (1 кит. 1993, 2 кит. 1997) исемле шигъри повесте М.нең иң уңышлы әсәре.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МУСИН** Флүн Мослах улы (23.2.1939, Мөслим р-ны Иске Карамалы а. — 22.9.2009, Казан), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. д-ры (1983), проф. (1993), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1962). 1963 тән (тукталып торып) ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли, 1987-97 елларда, 2007 дән соң әдәбият бүлеге бүлеге мөдире. 1997-2003 елларда ТРнең Укытучылар белемен күтәрү ин-тында татар теле һәм әдәбияты кафедрасын җитәкли. 1980 еллар ахырыннан 20 йөз татар әдәбияты тарихын яңа редакциядә язу буенча иҗат төркемен җитәкли. Татар әдәбияты тарихын өйрәнү һәм укыту методикасы мәсьәләләрендә тарихилык һәм милли юнәлеш принциплары б-н эш итте. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбияты тарихы һәм теориясенә; Г.Исхакый, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Һ.Такташ, М.Җәлил иҗатларына; РФ һәм БДБда татарлар компакт рәвештә яшәгән регионнарда милли уку-укыту системасы эшенең актуаль мәсьәләләренә карый.

Әс.: Тормыш сынавы аша. К., 1969; Чор белән аваздаш. К., 1983; Гаяз Исхакый тормышы һәм эшчәнлеге. К., 1998; По координатам жизни. М., 1976; Связь времён. К., 1979.

Әд.: Ханзафаров Н. Танылган галим // Казан утлары. 1999. №2; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МУШИНСКИЙ** Әхәт Хәй улы (27.5.1951, Казан), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Рус телендә яза. Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1976-82 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасының җаваплы сәркәтибе, 1982-89, 1992-94 елларда ТАССР Язучылар берлегенең әдәби консультанты, 1989-92 елларда «Идел» ж-лы баш мөхәррире урынбасары, 1993-2003 елларда «Яшел камин янында» («У зеленого камина») телепрограммасын алып барды. 1994 тән Милли китапханәдә, 1995 Татар ПЕН-үзәктә эшли, бер үк вакытта 2006 дан «Казан альманахы» («Казанский альманах») ж-лы баш мөхәррире. «Өчпочмаклар» («Треугольники», 1984) хикәя һәм повестьлар җыентыгы, балалар өчен язылган «Бер тибүдә—гол» (2000, рус.телендә «Гол в девятку», 1991), «Минем адаш малай» («Мой тёзка — Адаш малай», 1994), «Анас-ананас и другие = Әнәс-ананас һәм башкалар» (2004, РФнең «Заветная мечта» исемле балалар өчен милли әдәби премия, 2006) китаплар; «Шәех һәм астролог» («Шейх и звездочёт», 1991), «Бөкре кеше язмалары» («Записки горбатого человека», 2000, Г.Р.Державин исем. әдәби премия, 2002) романнары авторы. М. әсәрләренә психологизм, фәлсәфи тирәнлек хас; әсәрләр тукымасы Казан һәм республика турындагы мәгълүматларга бай.

Әд.: Малышев С. Обречённая на успех // Идель. 2000. № 6; Гамбәр Н. Очканында ни булса... // Казан утлары. 2001. № 5.Нац. дет. лит. премия России «Заветная мечта», 2006

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Газиз Кашапов–Үзиленең тууына 70 ел

Газиз Кашапов-Үзиле (Газизҗан Салих улы Кашапов) 1942 елның 21 августында Татарстанның Аксубай районы Яңа Үзи авылында туа. 1957 елда туган авылында җидееллык мәктәпне, ә 1960 елда Иске Ибрай авылы урта мәктәбен тәмамлагач, ул ике ел колхозда бухгалтер ярдәмчесе, тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. 1962 елның көзендә Совет Армиясенә алынып, хәрби училищеда укый, аннары гаскәри берәмлекләрнең берсендә офицер-механик булып хезмәт итә. 1969 елда егерме җиде яшьлек офицерга «дөнья жандармы» булырга омтылган совет җитәкчелегенең гаделсез шаһиты һәм корбаны булырга туры килә — совет гаскәрләре сафында Чехословакиядәге «контрреволюцион фетнә»не бастырган чакта алган каты җәрәхәтләрдән сәламәтлеген югалтып, 1971 елның февралендә отставкага чыга.

1973 елда Г.Кашапов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, бер үк вакытта, 1974-1982 еллар арасында, Татарстан китап нәшриятында кадрлар бүлеге мөдире, Әлмәт шәһәрендә чыга торган «Хезмәт байрагы» газетасы һәм КамАЗ радиотапшырулар редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының Түбән Кама, Алабуга, Мамадыш, Тукай районнарындагы үзхәбәрчесе һәм язучыларның Чаллы оешмасында пропаганда бүлеге хезмәткәре, соңрак оешманың җитәкчесе булып эшли.

Газиз Кашапов әдәби иҗат эшен шигырьләр һәм хикәяләр язудан башлый. Аның «Әти йолдызы» исемле беренче хикәясе 1974 елда «Ялкын» журналында басылып чыга. Ләкин аны өметле яшь прозаик итеп таныткан беренче әсәре —1976 елны «Казан утлары»ның җиденче санында дөнья күргән «Сәмум җиле» повесте. Хәрби темага багышланган, гаскәри кешеләрнең авыр хезмәтен, хәтәр хәлләрдәге кыюлык-тапкырлыкларын реаль тормыш вакыйгалары эчендә ышандырырлык итеп тасвирлаган бу әсәр әдәби җәмәгатьчелек һәм укучыларның уңай бәясенә лаек була. Яшь авторның шул ук хәрби тормыш белән бәйле вакыйгаларны үз эченә алган «Солдат иртә ир була» (1982), «Гомернең утлы өлеше» (1985) исемле повестьлары да укучылар тарафыннан уңай бәяләнә.

Яңа сәнәгать үзәге Чаллыда төпләнеп яшәү, Чулман төбәген танымаслык итеп үзгәрткән, сөенечле дә, көенечле дә булган зур төзелешләрнең шаһиты булу Г.Кашаповны «Җир җылысы» (1982), «Язмышыңа ышан» (1985), «Вөҗдан хәтере» (1989), «Гыйфрит» (1990) кебек күләмле повесть һәм романнар иҗат итәргә рухландыра. Гомеренең соңгы елларында ул үзенең мәшһүр якташы Хәсән Туфан турында документаль романын («Киек Каз Юлы») төгәлләргә ашкынып яши, әмма әле илле яшен дә тутырып өлгермәгән талантлы каләм иясе 1991 елның 30 августында вафат була.

Г.Кашапов-Үзиле — 1983 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

***

**Әллә таныш, әллә таныш түгел,**
**Күргән саен сүзсез елмая.**
**Күзләрендә төссез моңсу караш**
**Чагылып кала көлгән уңайга...**

**...Таныш түгел абый, дүрт яшь ара...**
**Без янәшә инде бүген дә.**
**Кояш көлми, йолдызлар да тынган.**
**Нинди төсләр күңел күгендә?!**

**Үпкәләмә... Йөрәк ярасына**
**Мин кабаттан инде кагылмам,**
**Без янәшә чакта — мин бәхетле,**
**Аерылгач — өзелеп сагынам...**

**Хисләреңне әллә яшерәсең**
**Син моңсулык иңгән күзеңә?**
**Ләкин нигә сүзсез кагыласың,**
**Күз яшьләре тамган йөземә?!**

**Таныш абый... Әллә таныш түгел?**
**Ул яулады минем йөрәкне.**
**Яшьтәшләрем көлә, аңламыйча**
**Миңа бары тик ул кирәкне...**

**Күзләр күздә күптән, куллар кулда...**
**Йөрәкләрнең чыңы сизелә...**
**Бала диеп көлмә, мин зур инде —**
**Син канатлар куйдың иңемә...**

**Хисләр чынлыгына ышанам мин,**
**Ышанычны җуймам кабаттан.**
**Таныш түгел абый, дүрт яшь ара.**
**...Ә мин инде аны яратам!**

***

*Скажи мне, Мама, сколько стоит моя жизнь*
*Моя жизнь – это драма, моя душа несется ввысь*
В. М. Вакуленко (Баста)

**Җавап бирче, әнкәй, күпме тора**
**Бу тормышта минем гомерем...**
**Язмышымның яңа ялганыннан**
**Телгәләнгән чагы күңелнең.**

**Әйтеп бирче, әнкәй, нигә кирәк,**
**Кемгә файда минем газаптан?!**
**Мин яшәүдән туеп ачтым күзем.**
**Артта калды ләззәт тулы таң...**

**Кичер, әнкәй, мондый уйлар өчен,**
**Тик күңелем күккә ашкына.**
**Газапларын кулда кыскан килеш**
**Хыялларым юкка атлыга...**

**Мәгънәсез бу яшәү... Бу кешеләр.**
**Икейөзле пычрак елмаю...**
**Кайта бара күңел — күңел ката.**
**Күзләрдә яшь, сүзсез моңаю...**

**Җавап көтмим, әнкәй, бу сүзләргә.**
**Алар өчен күптән җавап юк.**
**Авыр яшәү бу елмаю белән.**
**Ә йөрәккәй яна, йөрәк — ут!**

**Минем күңел хак-дөреслек белән**
**Очрашулар эзли көнгә бер.**
**Тик ялганнар гына... Атылыйммы**
**Мин кулыма алып револьвер?!**

**Үз чигәмә төбәп, күзем йомып**
**Соңгы тапкыр үбеп хисләрне —**
**Атылыр идем... Ләкин синең күңел**
**Мине шулай кабул итәрме?!**

**Таңнар саен кат-кат дога кылып,**
**Зур өметләр миңа баглама.**
**Мин тормышның ни икәнен белмим,**
**Күзләр тиде, әнкәй, балаңа...**

**Алсу НУРГАТИНА.**
*КФУ студенты.*

*Хикәя яза аласызмы?*

*Үткән елгы 9нчы санда әнә шундый иҗат бәйгесенең «2 нче сериясе»н игълан иткән идек. Бирелгән башламны дәвам итеп язылган хикәячекләр (аларның күләме бер журнал битеннән артмаса иде) килә тора. Җиңүчегә бүләк — «Сүнмәс утлар балкышы» дигән уникаль китап.*

# КИЧЕР МИНЕ, КИЧЕРАЛСАҢ...

Кунакханәнең мин туктаган бүлмәсе кояш карый торган якта булып, төн уртасы якынлашуга карамастан, һаман бөркү иде. Йокыга китә алмаячагымны аңлап, диңгез ярына чыктым...

Кая да булса барасым булса, яки барып кайткан булсам, алган хисләремнән тәэсирләнеп тә йоклый алмый торган гадәтем бар минем. Бер дә барасым килмәгән иде бу юлы бу сәфәргә, әмма ни хәл итәсең, өстән фәрман булгач, безгә буйсынырга гына кала...

Һәм мин монда, ерак Каф тавы артларында, дулкыннар кочагында диярлек, хисләнеп басып торам. Күктә бихисап күп йолдызлар, кул сузымында гына үзләре шундый шаян, үзләре шундый куркыныч мина таныш булмаган ярсу дулкыннар...

Чү! Бу нинди аяк тавышлары? Тыныч кына мина таба култык таякларында бер ир якынлаша. Аның ап-ак күлмәге дә, төймәләре каптырылмаган кара-кучкыл плащы да, дулкын-дулкын бөдрә чәче дә, зәңгәр күзләре дә мина елмаялар түгелме соң?

— Йа Аллам! Рәхмәтең сал! Бу синме, Рүзәл? — дидем мин, каршымда аны күрүемә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

— Менә бу очрашу ичмасам! Синме бу, Зөлфия? Баярак күземә ышанмадым... Мин монда бер ай яшәдем инде, иртәгә китәм. Әллә китмәскә микән?

Рүзәл дә, мин дә, артык дулкынланудан тынсыз калып, бер-беребезнең кочагына чумдык.

Мин күземне йомдым. Яшьлектә калган, ничә еллар хыялымда йөрткән зәңгәр күзле, якты карашлы Рүзәлне мине кочагына сеңдергән култык таяклы Рүзәл белән янәшә куйдым. Бөртек тә үзгәрмәгән ул! Шундый эчкерсез,шундый ихлас, шундый якын! Йа Алла! Өнемме бу, төшемме?

...Мин беренче курста укыйм. Иптәш кызларым белән трамвайга утырдык та, театрга барабыз. Күңелле, көлешәбез, рәхәт!

— Кызлар, безгә дә әйтегез әле, нәрсәдән көләсез шулай? Бергә көлик!

Чибәр генә ике егетнең безнең көлүгә кушыласылары килә икән. Рәхим итегез! Билгеле инде, таныштык. Егетләр — кыю халык, биш минут эчендә безнең кайларда укуыбызны да, торуыбызны да, исемнәребезне дә белеп алдылар.

Шуннан соң очрашулар башланды. Аны сагынып-сагынып көтеп алулар...

— Рүзәл, хәтерлисеңме, без синең белән кулга-кул тотынышып чәчәкләр жыя идек... Син мине чәнчә бармагымнан гына тота идең. Үләннәр, бөҗәкләрнең исемнәрен әйтеп, ярыша-ярыша аларны эзли идек. Без кайдагы парклардан, урамнардан эзләдек икән аларны?..

— Хәтерлисеңме, бервакытны мин синең янына килдем. Юк, алай түгел, без икәү кайтабыз синең Әми тавындагы квартирыңа. Карыйбыз, капка төбендә бер егет тора.

— Исемдә, мин аның белән сөйләшми идем инде. Килмә, дим, ә ул гел килә. Берсендә сез очраштыгыз... Мин аңа тагын да шул сүзләрне әйтәм, ә ул китми дә китми. Шуннан сез сугыштыгыз.

— Юк инде, без егетләрчә сөйләштек кенә. Мин аны бүтән килеп йөрмәслек иттем. Сүзне аңламады бит, йодрык «әңгәмәсен» дә үзе башлады...

— Мин сине бик юаш дип йөри идем, шул көннән соң син минем өчен бик көчле кешегә әйләндең...

— Ярар инде, мактама, әйдә атлыйк, әнә таң да ата.

Без беседка эченә кереп утырдык. Салкынча булып китте. Мин, артык дулкынлануданмы, калтырана башладым. Рүзәл плащын салды, иңнәремә каплады. Тынычландым.

— Син гел шулай игътибарлы икән. Күзең дә шундый ук зәңгәр, чәчең дә бөдрә... Ә без нигә аерылыштык соң, Рүзәл?

— Мин дә синнән шул турыда сорамакчы идем. Син минем солдат киемендәге фоторәсемемне алдыңмы соң?

— Алдым, хат та яздым әле.Шуннан соң мин сине югалттым. Ни хатың, ни открыткаң килмәде.

— Ә мин сиңа ул рәсемле хаттан соң ярты ел буе хат яздым. Аннары туктадым. Кая китте бу, нишләде бу Зөлфия дип ел буе синнән хәбәр көттем. Кияүгә чыккандыр дип уйладым да, сине онытырга тырыштым.

— Ә мин Әми тавыннан соң Киров районындагы җизнәмдә тордым, аннан общагага күчендем. Хатларыңны күрмәдем. Кичер мине, яме, кичералсаң...

Сулкылдый-сулкылдый елыйсым килде, әмма күземнән яшь чыкмады. Күз яшьләрем минем туган Казанымда, үзем аңлы рәвештә сайлап алган, бергә балалар үстергән «бәхетем» янында утыз еллык гомерем кысаларында коелып беткән иде шул инде.

Мина Рүзәл алдында оят булып китте.Тик нихәл итәсең, язмышың шулай язылгач?

— Син гаепле түгел, Зөлфия. Мин гаепле. Мин бит егет кеше. Командир булган кеше. Сине эзләмәдем. Гомеремне армиягә багышладым...

Әфганнарда сугышкан, шунда аягын калдырган, сәламәтлеген җуйган ир-егетнең күзендә чып-чын , эре-эре яшь бөртекләре җемелди иде...

**Надия ВӘЛИЕВА.**

*Казан.*

Бирелә файдаланылганыннан тыш тагын җиде башлам бар. Менә алар:

*Укытучы егет класска килеп керү белән, унберенченең кызлары бердәм хихылдаша башладылар.*

***

*Алар аерылышып, инде елыйсы еланып, бер-берсе турында яманы да, яхшысы да сөйләнеп, онытылып бетте дигәндә ул Аны яңадән очратты.*

***

*Айратның бармаклары шуып китте һәм Фәридәгә дигән СМС ялгыш Миләүшәгә «очты»...*

***

*Халык агымына ияреп җир астына төшеп барганда Аяз сискәнеп китте: аның аяк очында — эскалаторның көмеш баскычында — ике нәни песи баласы утыра иде. «Карале син, әй, болар да Тукай мәйданында булачак пикетка ашыгалар, ахрысы!» — дип уйлады егет.*

***

*«Камил Сәлимович! Мин сине яратам!» — кара тактага шулай дип язылган иде! Яшь укытучы кулына акбур алды.*

***

*Яшь адвокат Нуриев кесә телефонының онытылып калганын вокзалга килеп җиткәч кенә сизеп алды. Такси тотып, тиз генә яңадан фатирга кайтып килергә кирәк иде.*

*Кайтса... Кыңгырау сүнгән, тимер ишек эчтән бикле.*

## «Сабый ачышлар»ыгыз юкмы?

2010 елгы 6нчы санда бер төш күрүемнән соң психофизиология өлкәсенә кагылышы ачышым хакында сөйләгән идем. Ул чакта мина сигез яшь иде. Икенче сыйныфта гына укыган үсмернең ни психология, ни физиология дигән фәннәр хакында берни дә белмәве аңлашыладыр, шәт. Шулай булгач, ачыш ясавынны ничек аңлыйсың ди инде? Өстәвенә, ачышның ни-нәрсә икәнен дә белмәгән кеше бу хакта уйланамыни? Андый очракта белемгә ия олыларның ярдәме кирәк

Быел февраль башында гына АКШның Канзас-сити каласында ун яшьлек кызбаланың, химия дәресендә укытучы биргән эшне башкарганда, энергия туплый торган яңа матдә ижат итүе хакында язганнар иде. Молекулалар төзелешен өйрәнү өчен ясалган модельләр белән эшләгәндә Клэр Лэйзен анарчы билгеле булмаган структура ижат иткән. Аның укытучысы Кеннет Бер күңел салмаса, ачыш галим халкы игътибарыннан читтә калган булыр иде. Укытучының дусты, химия белгече профессор Боб Зеллнер, яңа матдәне җентекләп өйрәнгәч, тәгълиматти химия журналына мәкалә әзерләп җибәрә. Шулай итеп ун яшьлек кызчык профессор белән бергә абруйлы журналдагы мәкалә авторы буларак танылa.

Бу язмама алыну өчен кышкы һава шартларында була торган бик кызыклы нәрсә этәргеч булды. Мин аны сабый чакта ук белә идем. Ә унбишенче яшем якынлашып «олыгая» башлаганда серен дә ачыклый алдым һәм... ничектер кинәт тынычланып, аның белән бөтенләй кызыксынмас булдым. Чөнки галимнәр бу хәлнең хикмәтен беләдер, дип уйлаган идем.

Баксаң, кайбер галим затлар кайчагында ишетелә торган, гадәти булмаган, чамадан тыш калын, аз ешлыктагы шомлы тавышларны Кояш активлыгының артуы белән аңлатырга тырышалар икән. Кемгәдер алар ерткыч җанварлар тавышын, ә башка берәүләргә механизмнарның гүләвен хәтерләтә, кемдер аларны җир астыннан, ә башкалар күктән ишетелә дип аңлата икән.

Мин фәкыйрегез нәкъ шул калын тавышларны үсмер чагымда ук, кышкы салкын төннәрдә уянып һәм шөбһәләнеп, йокламый тыңлап ята идем. Бу хакта олылардан да сорашып карадым, әмма алар, күктә очкычларның әрле-бирле йөрүләренә сылтап, җиңел генә аңлатып бирәләр иде. Сугыштан соңгы авыр тормышта яшәгән халыкның мәшәкатьләре беткәнмени, тавышлар тыңлап төн уздыру түгел, көндәлек тормыш хакында баш ватасы бит! Ә мине «очкычлар версиясе» тынычландырмый иде, чөнки бу очракта бихисап очкычлар бертуктаусыз һаваны бораулый дип уйларга кирәк.

Уйлануларымның нәтиҗәсе бик кызыклы булды: атмосфераның ниндидер бер биеклегендәге катламы кайтаваз булдыра торган сыйфатларга ия. Яктылык нурын көзге кире кайтарган шикелле, ул да тавыш дулкыннарын кире кайтара, әмма «атмосфера көзгесенә» тавыш «нурлары» төрле җирдәге чыганаклардан, тәгаен алганда поездлардан да, төрле юнәлешләрдән киләләр, нәтиҗәдә кайтарылган тавышлар бик катлаулы кушылма буларак шомлы тоташ гүләү булып ишетеләләр.

Менә шулай, унбиш яшьлек «Гельмгольц»ыгыз сәер тавышларның серен ачыклый алды да, шуннан соң бу мәсьәлә белән баш катырмады. Аны тикшерү өчен галимнәр бар, алар өйрәнсеннәр, янәсе. Ни гаҗәп, бу «ачыш»тан соң нигәдер кышкы салкын төннәрдә уянмас булдым, иртәнге йокым бик каты була иде. Хәер, мәсьәләне ахыргача ачыклаганда авыл баласы түгел идем инде. Ә кала дигәнең шау белән «дыңгычлап тутырылган», күктән килә торган төнге авазларны ишетермен димә. Хәер, саласы да хәзер төнге тынычлыгы белән мактана алмый. Техника кайда да күп.

Ә шулай да бу юлларның авторына быелгы февраль аеның, шагыйрь әйтмешли, «салкын күкрәгендә»ге атмосфера атамалы «тун»да тавыш дулкыннарын кире кайтаручы катлам булганына тагын бер кабат инану да, галим халкының бу күренешне һаман да тирәнтен өйрәнмичә, ошбу сәер гүләүгә «гаҗәпләнүенә гаҗәпләнү» дә насыйп булды. Чөнки җилсез, утыз градустан түбәнрәк салкын иртәләрдә ике сәгатькә сузыла торган, кайберәүләр тарафыннан «ахырзаман авазы» дип аталып өлгергән гүләүләрне тыңлап, сабый һәм үсмер елларымны искә алып ятулар ничектер күңелне сафландыра иде.

Тупланган белемем һәм күзәтүләремнән чыгып тавышны кайтара торган әлеге «көзге»не сферик катлам дип күзаллыйм. Аның Җир өслегеннән биеклеге ун чакрымнан кимрәк булырга тиеш. Нигә дисезме? Җырдагыча, «күктә, бик биектә очып» йөрүче очкычларның тавышы гадәттә безгә, соңарып булса да килеп җитә, очкыч офык кырыена якынлаша башлагандa гына аның тавышын ишетә башлыйсың. Әмма бу салкын вакытларда, хәрби очкычлар бик биектә һәрдаим очып йөрсәләр дә, аларның тавышлары беркайчан да ишетелмәде. Димәк, теге сферик катламның өске, космоска караган кабарынкы ягы очкыч тавышларын югарыга юнәлтә, ә аскы, Җирдән караганда батынкы өслеге поездлардан килгән тавышларны кире Җиргә кайтара. Ул катламда микрокөзгеләр ролен җылы су парларының туңуы нәтиҗәсендә пәйда булган кристаллар башкара, алар бер-берсенә «терәлеп» тормасалар да, аларның үзара ераклыгы тавыш дулкыннарының озынлыгына караганда бик кечкенә. Шуңа күрә әлеге сферик катлам тавыш дулкыны өчен тоташ җисем шикелле була. Өстәвенә кристалларның тиешле тәртиптә урнашуына аларның Җирнең магнит кыры тәэсирендә полярлашуы да ярдәм итә.

Сүземне тәмамлар алдыннан «күктән килүче» шауның ни өчен шомлы икәнен дә аңлатыйм инде. Андый тавышлар тукымасында бик аз ешлыктагы, ягъни бик озын дулкынлы тибрәнешләр дә була. Андыйларын инфратавыш дип атыйлар. Без аларны ишетә алмыйбыз, әмма бөтен организмыбыз аларны кабул итә, эчке органнарыбызга, мәсәлән, йөрәгебезгә, тәэсире шактый була. Кеше аны ниндидер, сәбәбе билгеле булмаган шөбһәләнү кичереше дип кабул итә. Җир тетрәү алдыннан шундый инфратавышлар купканын кайбер җан ияләре, мәсәлән, этләр дә яхшы «ишетә»ләр.


Менә шулай галим затларның серле күренешләрнең серлелеген күрмәүләре, ә галим булмаган шәхесләрнең андый мәсьәләләргә мистика аша якын килүләре күптәннән тикшерелергә тиешле проблемаларның игътибардан читтә калуына ярдәм итә.

Булмас димә, бу юлларны укучыларым арасында киләчәктә «атмосфера акустикасы» шикеллерәк атамалы яңа фәнгә нигез салучы галим затлар да үсеп тернәкләнер, мөгаен. Ә бәлкем, кайберәүләрегезнең әле беркемгә дә чишмәгән, йә чишеп тә аңламаган «сабый» ачышларыгыз да бардыр инде?

**Ким ШАКИРОВ**

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@yandex.ru*

## Ребусны чишсәгез, татар халык мәкален укырсыз




*Җавабы киләсе санда.*

*Төзүчесе* **Зөфәр ХИСАМОВ**

# ЯҢА МУЛЛА

Ни өчендер аны Бака Нәҗми дип йөртәләр иде. Кемдер аның борынгы бабасы Бакый исемле булган ди, кайсысыдыр аның бабасы Бәкер булган икән ди, кемдер аның нәселе куе җирән чәчле булганына күрә Бакыр кушаматлы булган ди. Имеш, аның бабасының атасы Тарыш мулла ачлык елны, кешеләр күпләп кырылганда бака ашатып, гаиләсен үлемнән саклап калган диләр. Тарыш мулла амбарындагы бөтен ашлыгын ачларга таратып, үзе дә халык белән бергә ачыга башлаган. Гаиләсен ачтан үтермәс өчен, Тарыш мулла гөмбә җыеп, тозлап та, пешереп тә ашый торган булган, ләкин халык «гөмбә ул мөселман ризыгы түгел» дип, агуланудан куркып, гөмбә ашамаган, ачтан кырылган. Аннан соң Тарыш мулла күл бакаларын чиләккә тутырып алып кайтып, тозлы суда пешереп ашаган. Тарыш мулла кешеләргә: бака тотыгыз, җан сакларсыз, дип вәгазь укыган, ләкин кешеләр бака ашарга теләмәгән. Яртысы кырылып беткән. Сәвитләр килгәч, Тарыш мулла салдырган мәчетнең манарасын аударып, клуб ясадылар, аскы каты таш булганлыктан, амбар иттеләр.

Нәҗминең бабаларын авылдан куганнар, ата-анасы гүрдә, абыйлары, апалары кайсы кая чәчелгән.

Бака Нәҗми ялгызы гына яши. Ул шахтада эшләгәндә ташкүмергә басылып, сул аягы гарипләнеп, яшьли пенсиягә чыккан. Каралты-курасы уртача. Хуҗабикәсе булмаганлыктан, ул бөтен эшне үзе башкара. Вак-төяк малы да бар шунда. Тавык-чебеш, каз-үрдәк дигәндәй. Эчәренә дә, ашарына да җитәрлек, шөкер.

Аның ике гадәте бар. Ул эчә. Эчеп буза куптармый, ләкин авызына каптымы, ул өендә утыралмый, кеше арасына чыга, клубка бара, урамда сөйләнеп, җырлап та йөри. Аек чакта ул курасыннан чыкмый, кешеләр белән аралашмый. Өй эшләрен караштыра, яки китап укып утыра. Калхуз-инвестр эшләренә йөрми, үз җаена гына яши бирә.

Нәҗми «исерек, айнымас сәрхуш» дәрәҗәсен кире алмастай итеп үзенә беркеткән инде.

Ләкин Нәҗминең бер гадәте кешеләрне аптыраашта калдыра бирә. Бака Нәҗми ураза аенда эчүен ташлый. Бака Нәҗмине ураза аенда эттән алып, эткә салып сүкмиләр. Бар андый алкашлар, авыл тулы. Ләкин алар ураза аенда, корбан гаетләрендә дә егылып эчәләр.

Ураза аенда, корбан гаетләрендә Нәҗмине аштан калдырмыйлар. Ул чиста киемнәр киеп, яхшылап кырынып, хәергә бирәсе акчасын күкрәк кесәсенә салып, чакырылган вакытына мәҗлескә килә. Бу вакытларда аңа сокланмаган кеше юк.

Башка авыллардагы кебек, Таштугайда да Тарыш мулла мәчетенең таш нигезе урынына яңа мәчет салдылар. Шушы авылдан чыккан бер бай егет мәчет чыгымнарын каплады. Мулласы да табылды. Шушы авылның элеккеге парторгы Җәмшык Таптыргановны мәчеткә имам-хатыйп итеп беркеттеләр. Бака Нәҗми яхшы хәтерли әле, әтисе сөйләгән иде: Җәмшык

өйгә кереп, киштәдәге гарәп хәрефле китапларны, дивардагы шамаилләрне кубарып алып, ишегалдына алып чыгып яндырган.

Бака Нәҗми анын мулла булып китүенә дә шаккатмый, булсын, бәлки ул тәүбә иткәндер, тәүбә иткәннәрне Аллаһ ярлыкый лабаса. Нәҗминең ачуын китергәне шулдыр ки, Җәмшык Таптырганов каядыр китеп, берике атна дин сабаклары алып кайтты да, мулла булды да куйды. Парторг чагында йорт саен кереп аракы таптырып, тиресеннән чыгып, Алла сүккән атеист Җәмшык мулла булып кайткач, үтә диндар булып китте. Чалма урап, алтын ука белән чигелгән яшел хөббә киеп, кулына артыштан ясалган карышкы таяк тотып алгач, гел харап, шамакайга охшап калды. Коръән уку мәҗлесләрендә Җәмшык мулла вәгазь сөйләгән була, сөйләргә сүзе юк, гыйлем сандыгы буш. Алланы сүккән чакта ул сүзләр таба иде, ләкин динне, Коръән сүрәләрен аңлатырга аның белем җегәре җитми иде. Парторг булган чакларында ул түрә иде, ул житәкче, хәзер дә ул авылның җитәкчесе булырга тырыша. Дилбегәне кулдан ычкындырасы килми. Ул мөнбәрдән дә, табын янында да кычкырып, куркытып сөйли, ул бердәнбер хөкемдар, бердәнбер дөреслекне сөйләүче кебек кылана.

Бака Нәҗми аның вәгазьләрен тыңлап, җир тишегенә кереп китәрдәй булса да, мәҗлесне бозмады, Җәмшыкның хаталарын төзәтмәде, кеше алдында аның йөзен ертмады. Табын әзерләгән хуҗаларның кәефен җибәрергә теләмәде.

Әмма мәчеттә, соңгы җомга вәгазендә ул түзмәде, мулла абзыйга сорау бирде.

— Хәзрәт, менә сез вәгазегездә әйттегез: уң кул белән ашарга кирәк, мөселман кешесе фәкать уң кулы белән генә ашарга тиеш, дидегез. Әгәр дә кешенең уң кулы булмаса, ул нишләргә тиеш?

Җомгага байтак кеше килгән иде, шәһәрдән бәйрәмгә кайтканнар белән мәчет тулы иде. Шаулашып утыра торган кешеләр кинәт тынып калды. Сорау барысының да игътибарын тартты. Мулла кеше көтелмәгән сораудан каушап калды, сорау бирүче шундук аның дошманына әверелде. Ни әйтергә сүз табалмагач, Җәмшык мулла:

— Мин исерекләрнең мәгънәсез сорауларына җавап бирмим! — дип кычкырды. — Әүвәл башыңа түбәтәеңне киеп кил, аннан соң сораулар бирерсең.

Мөселманнар шаулаша башлады. Куштаннар мулланы яклап:

— Дөрес! — дип кычкырды.

Кайсыларыдыр:

— Нәҗми исерек түгел! — дип шаулый.

Гыйбадәт залы икегә аерылды. Шаулашу озакка сузылгач, шәһәрдән кайткан, мәчет салдыруда үҗәт катнашкан Варис Игъламов исемле кәттә егет:

— Мулла абзый, — диде. — Син сорауга җавап бир инде... Мине дә бу мәсьәлә бик кызыксындыра, сулагай кеше кайсы кулы белән ашарга тиеш? Менә мин дә сулагай.

Мәчет калхуз җыелышына әверелеп китте. Кемдер:

— Ике кулы да булмаганнар ничек ашарга тиеш? — дип кычкырды.

Дәррәү көлештеләр. Җомга намазы сәхнә тамашасына әйләнеп бара иде. Шулчак Нәҗми аягүрә калыкты:

— Түбәтәй мәсьәләсендә, — диде ул. — Түбәтәй киеп мәчеткә йөрү мәҗбүри түгел, түбәтәй кигәнгә савап юк, түбәтәй кимичә йөрүнең дә гөнаһасы булмас.

Габбас исемле егет сикереп торды:

— Дөрес! — диде ул. — Җәмшык абый мине, түбәтәй киеп кил, дип

мәҗлестән куып чыгарды, шуның аркасында мин Коръән укыганны тыңлый алмый калдым.

Җәмшык мулла шау-шуны туктатыр дәрәҗәдә түгел иде. Ул һаман кан дошманы Нәҗипкә акыра:

— Бака ашаучы нәҗес син, Нәҗми, намазны боздырдың!

Мөселманнар тагын да катырак шаулый башлады. Кемнең ни кычкырганы аңлашылырлык түгел иде.

Нәҗми ике кулын да күтәреп, халыкны тынычландырды.

— Тавыш! — дип кычкырды Варис. — Нәҗми абыйны тыңлыйбыз!

— Җәмәгать! — диде Нәҗми сабыр гына. — Бака ите мөселманга харам түгел.

Ирләр тагын шауларга тотынды.

— Коръәндә бака ите ашарга ярый диелмәгән! — дип кычкырды Җәмшык.

— Ләкин бака ите харам диеп тә язылмаган! — диде Нәҗми.

— Ә син каян беләсең язылганмы, язылмаганмы! — диде элеккеге парторг.

— Җәмгый хәзрәт! — диде Нәҗми «хәзрәт» сүзенә аеруча басым ясап.

Габбас:

— Хәзрәт түгел ул — хәсрәт! — диде.

Нәҗметдин дәвам итте:

— Коръәннең Нәхел сүрәсенең 14 нче аятендә болай дигән Аллаһы Тәгалә: саф ит ашасыннар дип, зиннәтләр чыгарсыннар дип, Ул сезнең өчен диңгезне, елгаларны яралтты. Бишенче сүрәнең 96 аятендә дә әйтә: суда ау оештыру, тотылган ризыкны ашау хәләл кылынды. Коръәндә, мулла абзый, бака турында сүз юк. Коръән тыймый икән, димәк, ул хәләл.

Габбас исемле егет тиз генә китап киштәсеннән Коръәннең татарчасын алып килеп, кирәкле сүрәне эзли башлады, ниһаять, тапты да кычкырды:

— Нәкъ Нәҗми абый әйткәнчә, шулай язылган! — диде.

Кемдер кул чапты, кемдер Нәҗмине аягүрә торып алкышлады. Тагын кәттә Варис калыкты.

— Авылдашлар, монда кем соң мулла? Җәмшыкмы хәзрәт, әллә Нәҗметдин абзыймы?

Халык шаулашып алды да тынды. Кәттә егетнең сүзе бетмәгән иде әле?

— Менә без Җәмгый абзый Таптыргановны Казанга муллалыкка укырга җибәреп кайтардык. Ул аннан әллә ниләргә өйрәнеп кайтты. Мәрхүмнең өчесендә, җидесендә, кырыгында Коръән укырга ярамый дип, безнең бабайлар йоласын тыйды. Ни өчен ярамый, кайдан чыккан ул закон, Җәмшык абзый?

Мулла ачулы карашын Нәҗмидән алып, Вариска текәде, карышкы таягын әвәләп алды да тамак кырып сүз башлады:

— Коръән мәетнең рухына багышланырга тиеш түгел, ул Аллага гына багышланырга тиеш.

— Дөресме шул? — диде Варис Нәҗмигә борылып.

Нәҗми әйтте:

— Өйдәме, мәет янындамы, кабер өстендәме, урмандамы, дачадамы, Коръән уку тыелмаган. Киресенчә, Коръәнне чиста, саф урында уку, нинди урын, нинди вакыт булуга карамастан, хуплана.

Халык шаулаша башлады. Мулла намаз вакыты җиткәнне белгертеп, идәнгә таяк орды. Ләкин намазлары намаз булмады. Мулла да, башка мөселманнар да әлеге сөйләшүдән нык борчылган иде. Намазны тәмам кылгач, тагын калхуз җыелышы башланды. Кычкырышып арыгач,

таралдылар.

Шәһәрнекеләр китеп барды. Ураза ае бетте. Җәмшык ачулы иде. Анын нәжесе тышка чыккан, ул төксе, җиңелүне авыр кичерә. Урамга чыкса, эте дә, бете дә:

— Надан парторг, надан мулла! — дип кычкырып кала.

Шулай итеп, ул җомга намазларына да чыкмас булып китте, аны өендә эчеп ята диделәр. Чыннан да аның исереклеге расланды. Айныган чакларында ул намаз укыта, бер-ике атна шулай йөри дә тагын юкка чыга, капланып эчә.

Ни гаҗәп, бу ураза гаетеннән соң Бака Нәҗми авызына тамчы да капмый, аек йөри башлады.

Көннәрдән бер көнне авылга Кәттә Варис кайтып төште дә капыл гына җыелыш җыйдырды.

— Җәмәгать, мин үз кесәмнән чыгарып мәчет салдырдым, аның мулласы өчен дә мин айлык хезмәт хакы бүлеп барам, күп булмаса да авыл җирендә ярап тора. Ләкин бу яңа мәчеткә укымышлы яңа мулла кирәк. Бу исерек парторгка өмет юк.

— Синең бер мең-нә яшь мулла килерме соң, аңа торыр урын кирәк. — дип кычкырдылар.

— Шуңа күрә, авыл кешесен сайлыйбыз! — диде Варис.

— Кемне? — диделәр.

— Нәҗметдин абзыйны! —диде Варис. — Мин аңа өч мең бирәм. Эшләсен!

— Шул сәрхушнымы? — диючеләр дә булды.

— Нәҗми абый сәрхуш түгел! — диде Варис. — Ризамы син Нәҗми абый.

Бака Нәҗми дәшмәде.

— Дәшмәү — ризалык галәмәте ! — диде Варис.

— Җәмшык мулла сәрхуш булды, сәрхуш Нәҗми мулла булды! — диде Габбас.

— Озакка барырмы Бака Нәҗминең аеклыгы? — диделәр.

Шулай итеп, Бака Нәҗми Таштугай авылында бабасы салдырган бина нигезендәге мәчетнең имам-хатыйбы булып китте һәм вафатына чаклы мулла булып торды.

**БАТУЛЛА**



*Татар һәм башкорт язучыларыннан бер төркем. Уңнан сулга: Гилемдар Рамазанов, Мостай Кәрим, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази һ.б. 1960 ел.*



*Шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов. (1935 - 2008)*



*Ике Нәҗибә: шагыйрә Нәҗибә Сафина, актриса Нәҗибә Ихсанова. 90нчы еллар.*



*Чыңгыз Айтматов, Назиф Мириханов (Татарстанның Россия Федерациясендәге Тулы хокуклы вәкиле), Олжас Сөләйманов. 2000 ел.*



*Башкортстанның халык шагыйре Марат Кәримов һәм язучы Ләбиб Лерон. 2010 ел.*

## САБАНТУЙ ИЛ ГИЗӘ

***

Июньнең соңгы көнендә Владивостокта федераль Сабан туе үткәрелде. Бәйрәмдә Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты.

Тантаналар «Динамо» стадионында һәм Спорт гаванендә үтте. Кунакларны бу төбәктә яшәүче халыкларның милли ризыклары, кул эшләре күргәзмәсе каршы алды, шунда ук татар милли киемнәре, сувенирлар сатылды. Сабан туенда катнашучыларны Президент Рөстәм Миннеханов, Приморье крае губернаторы Владимир Миклушевский котлады, Россия мәдәният министры Владимир Мединскийның котлау телеграммасы укылды.

Тамашачылар алдында Казан һәм Түбән Каманың иҗат төркемнәре чыгыш ясады. Халык уеннары, спорт ярышлары стадионның берничә мәйданында барды. Владивостокка Россиянең төрле төбәкләреннән иң көчле көрәшчеләр җыелган иде. Шулай да бәйрәмнең баш батыры булып Түбән Камадан Ленар Иванов калды.

Сабан туе көнне Владивостокта «Казан» мәчетенә нигез салынды.

— Әлеге мәчет кешеләргә хезмәт итәр һәм шатлык китерер, — диде Президент Р.Миннеханов. Ул мәчеткә мөселманнарның изге китабы — Коръән бүләк итте.

Шул ук көнне Р.Миннеханов һәм В.Миклушевский үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру чаралары планын имзалады. Приморье крае һәм Татарстан арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында килешү Р.Миннехановның Владивостокка эшлекле сәфәре вакытында 2011 елның 26 ноябрендә төзелгән иде.

Бирегә су асты көймәләрендә һәм корабльләрдә Татарстаннан 16 егет хезмәт итә икән. Президент Р.Миңнеханов алар белән дә очрашты, якташларыбызның теләкләрен тыңлады, Тын океан флоты белән хезмәттәшлекне көчәйтү зарурлыгын әйтте.

***

Россия башкаласы Мәскәүдә уза торган Сабан туе соңгы берничә елда милли бәйрәмнән бигрәк халыкара форумны хәтерләтә. Дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребез аны үзенә күрә бер аралашу мәйданы итеп күрә.

Сабан туе башкаланың иң матур урыннарыннан берсе — «Коломна» дәүләт музей-тыюлыгында үтте. Татарстан делегациясе башлыгы, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин бәйрәмне оештыруда зур ярдәме өчен Мәскәү җитәкчелегенә рәхмәт белдерде.

Сабан туен татар халык уеннарыннан башка күз алдына китереп булмый. Мәскәүнең төбәк татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рәсим Акчурин Сабан туен ачык дип игълан итүгә капчык киеп йөгерү, аркан тартышу, күзне бәйләп чүлмәк вату кебек уеннар оештырылган мәйданнарга халык агылды. Тамаша кылучыларны Мәскәү хөкүмәте исеменнән төбәкара хезмәттәшлек, милли сәясәт һәм дини оешмалар белән элемтә департаменты җитәкчесе Юрий Артюх тәбрикләде, аннары Мәскәү мэры Сергей Собянинның котлавын укып ирештерде.

Тамашачылар алдында Татарстан, Башкортстан, Мәскәү җыр-бию коллективлары чыгыш ясады. Әлбәттә, халыкның күпчелеге татар көрәшен карады. Быел да баш батыр исеменә Мәскәү егете Максим Афонин лаек булды.

## ДЕРЖАВИН КӨННӘРЕ

13-15 июльдә Казанда һәм Лаеш районында бөек шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның тууына 26 ел тулуга багышланган фестиваль чаралары булып узды.

Фестиваль шагыйрьнең Казандагы Лядской бакчасында куелган һәйкәле янында тантаналы төстә ачылды. Анда Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, күренекле язучылар, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты. Алар шагыйрьнең һәйкәленә чәчәкләр куйдылар. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан үзенең чыгышында бөтенроссия статусы алган фестивальнең үзара әдәби элемтәләр урнаштыруда роле зур булганлыгын әйтте.

Татарстан Милли музеенда шагыйрьгә багышлап әдәби кичә, Лаешның үзәк мәйданында шигырь бәйрәме уздырылды. Анда Г.Державин исемендәге Бөтенроссия әдәби

бүләге дә тапшырылды. Быел бу мәртәбәле бүләк «Наш современник» журналының баш мөхәррире, шагыйрь, публицист, әдәби тәнкыйтьче Станислав Куняев һәм Казанда туып-үсеп, хәзер Мәскәүдә яшәп иҗат итүче прозаик Айдар Сахибзадиновка бирелде. Казан федераль университетының филология һәм сәнгать институтында «Державин һәм мәдәниятләр диалектикасы» дигән темага фәнни конференция үткәрелде.

### «СӘЛӘТ» ДӨНЬЯГА ТАНЫЛА

Биләр тыюлыгы биләмәләрендә «Сәләт» фестивале 16нчы тапкыр уздырылды. Быел исә ул яна статус алды — Халыкара яшьләр мәгариф форумы буларак, Болгарда да эшчәнлеген дәвам итте. Анда 45 ил вәкиле катнашты. Республика олимпиадаларында, иҗат бәйгеләре һәм спорт ярышларында җиңгән 3 меңгә якын малай һәм кызны Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов, Ислам Хезмәттәшлеге оешмасы вәкилләре, танылган фән, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре сәламләде. Президент үз чыгышында киләчәкнең яшьләр кулында булуын, Татарстанда көчле яшьләр оешмалары күп булуын билгеләп узды.

«Безнең максат — дус-тату яшәүдә, дөньяның киләчәге яшьләребезгә бәйле! Гореф-гадәтләребез, мәдәниятебез һәм динне саклау аеруча мөһим. Без «Сәләт» форумында катнашучыларның уңышлары белән горурланабыз һәм ярдәм итәчәкбез. «Сәләт» елдан-ел үсәргә тиеш», — диде ул. Илбашы, форум кысаларында эшләгән «Фән һәм мәгариф», «Эшмәкәрлек», «Мәдәният» юнәлешләре остаханәләренең эше белән дә танышты.

### ЯШЬЛӘР МИРАСНЫ КАЙГЫРТА

Казанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитеты Яшьләр моделенең беренче пленар утырышы үткәрелде. Аны ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев уздырды. Утырышта шулай ук Премьер-министр Илдар Халиков катнашты.

Әлеге чара бу комитетның Санкт-Петербургта үткән 36нчы сессиясе кысаларында башкалабызда тәүге тапкыр уздырылды. Ана комитетка кергән 21 илдән Бөтендөнья мирасын саклау мәсьәләләрен өйрәнүче 20-25 яшьләрдәге 2шәр вәкил (кыз һәм егет) чакырылды.

М.Шәймиев Яшьләр моделе эшен ачып, чарада катнашучыларны Татарстан Президенты исеменнән сәламләде. Дәүләт Киңәшчесе әйтүенчә, башка илләрнең мәдәни һәм тарихи мирасын саклау тәҗрибәсен белү республикабыз өчен бик тә мөһим.

### МУЗЕЙЛАРЫБЫЗНЫ БӘҺАЛИЛӘР

Республикабызның өч музее Мәскәүдәге «Интермузей-2012» фестиваленең бүләкләренә лаек булды. «Музей һәм туризм: туристлык индустриясенә интеграция» темасына үткәрелгән фестивальдә 200дән артык Россия һәм чит ил музее катнашты. Быел анда музей мәдәни туризмы, туристлык ярдәмендә мәдәни мирасны саклап калу һәм территорияләрне үстерү тармагындагы тәҗрибә белән уртаклаштылар. Фестивальнең Гран-прие Алабуга дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгына бирелде. Татарстан Милли музееның музей кыйммәтләрен саклау буенча проекты РФ Мәдәният министрлыгы дипломы белән билгеләп үтелде. Россия Музейлар берлегенең «К... шәһәрендәге музей» бәйгесендә Г.Державин исемендәге Лаеш музее җиңеп чыкты.

### ТАТАР КӨЕ АМЕРИКАДА

Рәшит Ваһапов исемендәге халыкара татар җыры фестиваленең чираттагы этабы АКШта зур уныш белән үтте. Фестивальнең иҗат делегациясен Сан-Францискога Америка төрки-татар ассоциациясе чакырган иде. Кунакларның беренче чыгышы Төрек мәдәни үзәгендә булды, анда җырчы Филүс Каһиров С.Сәйдәшев, Р.Яхин, М.Мозаффаров, С.Садыйкова әсәрләрен башкарды. Икенче көнне Р.Ваһапов фестивале концерты Сан-Францискодагы Татар йортында тәкъдим ителде. Татарстаннан килгән кунаклар махсус программа белән Вашингтондагы Сабан туенда да чыгыш ясады, Лос-Анджелес һәм Нью-Йоркта татар диаспорасы вәкилләре белән очрашты. Моңа кадәр Р.Ваһапов фестивале илчеләре Финляндия, Швеция, Алмания, Польша, Латвия, Эстониядә һәм башка илләрдә булган иде.

### АЛЬБИНА — ЕЛ ҖЫРЧЫСЫ

Татарстанның халык артисты Альбина Шаһиморатовага «Casta Diva» Россия опера премиясе тапшырылды. Җырчыга М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында куелган «Лючия ди Ламмермур»да Лючия, Россиянең Зур театры куйган «Руслан һәм Людмила»да Людмила ролен башкарган өчен бирелде.

«Casta Diva» — Россиядәге опера сәнгате өлкәсендә югары бәяләнә торган бердәнбер махсус премия. Төрле елларда аңа Ирина Архипова, Галина Вишневская, Елена Образцова, Валерий Гергиев һ.б.лар лаек булган.

### НӘҖИП НӘККАШ КҮРГӘЗМӘСЕ

«Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура музей тыюлыгы, Ислам мәдәнияте һәм сәнгате клубы тарафыннан әзерләнеп, Кол Шәриф мәчетендә эшләп килгән Татар шәмаиле галереясендә танылган хәттат-каллиграф, галим Нәҗип Нәккаш әсәрләреннән оештырылган күргәзмәсе ачылды.

Төрки халыкларның данлы үткәнен мәңгеләштергән гарәп язуын шәмаил, тугра кебек сәнгать төрләре аша зур биеклеккә күтәргән, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кульязмалар һәм текстология бүлегендә 32 ел эшләп, гарәп, фарсы, төрек, борынгы төрки телләрдәге чыганакларны өйрәнеп, урта гасыр татар прозасын тикшереп, аны хәзерге хәрефкә күчереп, басма китап рәвешендә халыкка кайтарган, Казан педагогика көллияте, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында, Россия Ислам университетында матур, камил язу дәресләре алып барып, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам Н.Нәккаш тарихи-мәдәни мирасны саклауга үзеннән зур өлеш кертә. Нәҗип Нәккашның күргәзмәсе «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Ислам мәдәнияте музее, Татар мәдәнияте һәм сәнгате клубы оештырган «Мәңгелек хакыйкатьне аңлау юлы буларак каллиграфия» дип исемләнгән арт-проект кысаларында оештырылды. Бу проект рәссамнар Н.Нәккаш, Р.Сәлахетдинов, Ч.Шәрифуллина, Ә.Исхакова кебек гарәпчә язуга гашыйк рәссамнарның әсәрләреннән күргәзмәләр оештыру аша хәзерге заман татар каллиграфия сәнгатенең байлыгын, төрлелеген күрсәтүне максат итеп куя.

## ӘДИПЛӘРЕБЕЗ БАШКОРТСТАНДА

Татарстан Язучылар берлегенең яңа рәисе Р.Корбан, Д.Салихов, Р.Гаташ Уфада булдылар. Алар анда Г.Тукайның Уфага килүенә 100 ел тулу көннәренә карата уздырган чараларда катнаштылар. Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Р.Тойгынов аларны башкорт язучылары тормышы, яңа гына узган съезд хәлләре белән таныштырды, ике оешма арасында киләчәктә оештырылырга тиешле мөһим чаралар билгеләнде. Аннары кунаклар Уфада татар телендә чыгып килүче, зур тарихлы «Кызыл таң» газетасы коллективы белән очраштылар. Кичен исә М.Кәрим исемендәге Яшьләр театры бинасында Г.Тукай иҗатына багышланган зур әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Ике халыкның уртак дуслык бәйрәме булып узган бу кичәдә Татарстан Язучылары берлеге рәисе Р.Корбан, Татарстанның халык шагыйре Р.Гаташ, драматург Д.Салихов, чыгыш ясадылар.

Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Р.Тойгынов, халык шагыйрьләре А.Игебаев, К.Аралбаев, күренекле каләм осталары И.Кинҗәбулатов, Х.Назар, М.Нәзиров, Х.Мөдәррисова, С.Рәхмәтулла һ.б. бөек Тукай иҗатын халыклар, әдәбиятлар дуслыгын даими үстереп торучы мәңгелек көч итеп тасвирладылар. Уфа мэриясе исеменнән чыгыш ясаучы шагыйрә З.Ханнанова сүзләренә караганда, тиздән Башкортстан башкаласында Г.Тукайның һәйкәле дә куелуы көтелә.

## ЧАТЫР-ТАУДА ЯҢА ФЕСТИВАЛЬ

Азнакай районында урнашкан Чатыр-Тауда төрки халыкларның фольклор фестивале үткәрелә башлаячак. Бу карарны Азнакай районы башкарма комитеты һәм мәдәният идарәсе кабул иткән. Алар фестиваль ярдәмендә төрки халыкларның мәдәниятен торгызырга һәм үстерергә ниятли. Чараның төбәк күләмендә әһәмияте булган Дәүләт табигый заказнигы территориясендә урнашкан Чатыр-Тауда узуы юкка гына түгел. Азнакайлылар республиканың әлеге гүзәл почмагын тиешенчә бәяләнергә тиеш дип саный.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанда — Республика көне.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* драматург **Шамил Фәрхетдинов**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Республикабыз җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. 15 июль көнне Татарстан Республикасы халык рәссамы, Татарстан Республикасы атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты **Әхсән Сәрим улы Фәтхетдинов**ның 74нче яшендә йөрәге тибүдән туктады.

Ә.Фәтхетдинов 1939 елда Татарстан Республикасының Чирмешән районы Вагаповка бистәсендә дөньяга килә. Түбән Кама шәһәрендә яшәп иҗат итә.

1966 елда Түбән Тагил педагогия институтының сәнгать-графика факультетын тәмамлаганнан соң институтның сынлы сәнгать кафедрасында ассистент булып эшли. 1969 елда РСФСР Сәнгать фонды Татарстан бүлегенен Түбән Кама участогына рәссам-бизәүче буларак эшкә урнашып, бирегә 30 ел хезмәт куя. 1983 елдан — Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы. Әхсән Сәрим улы соңгы елларда иҗтимагый эш белән актив шөгыльләнде.

Ә.Фәтхетдинов — сынлы сәнгать остасы, скульптор, монументалист. Аның иҗаты үзенчәлекле генә түгел, тиңдәшсез дә. Әсәрләренең төп темасы — Габдулла Тукай тормышы һәм иҗаты. Аның бик күп рәсемнәре һәм скульптура композицияләрендә шагыйрь, аның әсәрләре геройлары урын алган. Әхсән Сәрим улы үзенең үзенчәлекле дөньясын булдырып, шуны татар мәдәниятенең табигый бер өлешенә әйләндерде. Агач пластика һәм рәсем сәнгатенең башка өлкәләрендә иҗат ителгән хезмәтләрендә татар халкының бай мифологик мирасы һәм сынлы сәнгатьнең бүгенге чаралары уңышлы үрелгән.

Ә.С.Фәтхетдинов әсәрләре белән Татарстан, Россия шәһәрләренең, чит илләрнең музейлары һәм күргәзмә залларында танышырга була. 1992 елда Венгриядә рәссамның шәхси күргәзмәсе зур уңыш казанды. 1997 елда Түбән Камада Ә.Фәтхетдиновның даими эшләүче күргәзмәсе ачылды.

«Иҗләр» милли эпосы буенча эшләр сериясе өчен Ә.Фәтхетдинов 1993 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булды.

2001 елда Әхсән Сәрим улына Татарстан Республикасының атказанган халык рәссамы дигән мактаулы исем бирелде. 2006 елда «Фидакарь хезмәт өчен» Татарстан Республикасы медале белән бүләкләнде.

Ә.Фәтхетдинов иҗтимагый бурычка зур җаваплылык хисе, хезмәт сөючәнлек, кешеләргә ихтирамлы мөнәсәбәте, яраткан эшенә иксез-чиксез тугрылыгы белән аерылып торды. Әхсән Сәрим улы Фәтхетдиновның күпкырлы иҗаты, гомуммилли байлыгыбызга әйләнеп, киләчәк буынларыбызга үрнәк булып калды.

Аның якты истәлеге күңелләребездә озак сакланыр.

**Р.Н.Миңнеханов, М.Ш.Шәймиев, Ф.Х.Мөхәммәтшин,**
**И.Ш.Халиков, Ю.З.Камалтынов, А.М.Сибагатуллин,**
**А.Р.Метшин, Н.Н.Хәмидуллин, З.Ф.Гыймаев**



Шамил Фәрхетдинов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)